
# казан утлары

5

МАЙ -1975


СССР
ПОБЕДА
1945
1975

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

5
МАЙ
1975

## Бу санда

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

М. ҖӘЛИЛ. Сугыштан соң. Шигырь . . . . . 3
С. ХӘКИМ. Сугышның бер көне . . . . . . 4
Заман дәшә сезгә, җырлар дәшә . . . . . . 13
З. НУРИ. 22 июнь. Шигырьләр . . . . . . . 16
М. ХӘБИБУЛЛИН. Чоңгылпар. Роман . . . . . 19

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . . 80

Ә. ИСХАККА 70 ЯШЬ

Р. МОСТАФИН. Кызыл кошлар җырчысы . . . 83
Ә. ИСХАК. Ышану. Шигырьләр . . . . . . . . 85

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

М. КӘРИМ. Минем Җиңү көнем . . . . . . . 92
Н. АРСЛАНОВ. Узганнарны хәтерләгәндә . . . . 98
Ә. МАЛИКОВ. Солдат шигырьләре . . . . . . 99
Х. ВАХИТ. Мин — солдат . . . . . . . . . . 101
М. САДРИ. Мәскәү — Берлин. Шигырьләр . . . 102
Г. ПАУШКИН. Кургаш ява. Шигырьләр . . . . 104
С. ШӘКУРОВ. Истәлек . . . . . . . . . . 105
М. ХӨСӘЕН. Туган ил өчен! Шигырьләр . . . . 106
И. ГАЗИ. Куен дәфтәреннән . . . . . . . . . 108
М. ӘМИР. Сугышчан сәлам белән. Хатлар . . . 123

М. А. ШОЛОХОВКА 70 ЯШЬ

М. ШОЛОХОВ. Алар Ватан өчен сугышты. Романнан өзек . . . . . . . . . . . . . . . 128

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

И. АХУНҖАНОВ. Мәхәббәт һәм нәфрәт җырчысы. 137
А. АЙНЕТДИНОВ. Юллар батырлыкка чакырды . 145
Т. НАСЫЙРОВ. Ватан сугышы һәм китап . . . . 155

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. УРМАНЧЕЕВ. Уйланулар, борчылулар . . . . 159

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Р. КУКУШКИН. Шагыйрь һәм образ . . . . . 163

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

С. ШАКИР. Нур Баянның тууына 70 ел . . . . . 173
И. РӘМИ. Шакир Мөхәммәтов . . . . . . . . 177

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Сугыш еллары юморыннан . . . . . . . . . . 178
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Производствога бирелде 7/II-1975 ел. Басарга кул куелды 31/III-1975 ел. ПФ 09010. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91744 экз. Заказ Я-52. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1975 ел.

## Муса Җәлил

### Сугыштан соң

Май аенда тагын җыйналырбыз,
Кызыл шәраб килер табынга.
Бокалларның көмеш чыңы белән,
Табын җыры яңрар тагын да.

Өстәл тулар җанлы чәчәк белән,
Чәчәк төсле кызлар, усаллар!
Каш кыреен гына үпкән булып,
Котлап безнең кулны кысарлар.

Кайберәүләр булмас бу табында,
Алар урыны шулай буш калыр.
Һәм беренче бокал күтәрелер
Исеме белән батыр дусларның.

Бик күңелле булыр бу очрашу,
Шундый авыр көннәр кичереп,
Без шәрабтан түгел, ә шатлыктан
Җырлашырбыз, бәлки, исереп.

Тик күп түгел, каплап бокалларны,
Без, табыннан бергә кузгалып,
Юнәлербез дуслар каны тамган
Киң кырларга, җиңне сызганып.

Ватык юллар, янган зур калалар
Без килгәнне көтеп яталар.
Уянсыннар батыр тракторлар,
Уйнасыннар кулда балталар.

Кырны тутырып алтын бодай үссен,
Ауган йортлар торып бассыннар.
Җиңгән илнең хезмәт тире белән
Кырлар көлеп чәчәк атсыннар.

Октябрь, 1943.

## Сибгат Хәким

# СУГЫШНЫҢ БЕР КӨНЕ



Мин ничәмә-ничә әсәремне, мәкалә, биографиямне 1943 ел, июль. Дуга дип башладым икән... Партия стажымны сораган кешеләргә Дугадан дип җавап бирү хәзер минем гадәткә керде. Дугадан. Аңлатып торасы юк, барысы берьюлы аңлашыла кебек. Дугадан. Бу сүзне мин горурланып әйтәм. Бу сүз минем бөтен тормыш юлымны кинәт яктыртып җибәрә шикелле. Эпизод та истә кала. Әмма эпизод, аерым вакыйгалардан өскә калкып янган көннәр була тормышта. Андый көннәр эпизодлар кебек вакытлы түгел, синең рухыңда озак еллар дәвамында яши...

Бер көн... Еш кына языла торган поэмаларга, сюжетка килеп керә, ятмый, алып ташлыйм, ә үзе яздырта, җылыта, якты, бөек, романтик. Бер уйласаң, ул көн үзенең драмасы, трагедиясе белән истә калырга тиеш иде, сугыш бит, үлем... Юк, ул аларны онытгырып, июль рәшәсе, ут-төтен рәшәсе эченнән өскә күтәрелә...

Бер көн. Ул көнне алгы сызыкка дивизиянең политбүлегеннән фотограф килде. Партбилетка фоторәсем кирәк. Урын эзләдек. Уңайлырак, җайлырак урын эзләдек: ут астында кайда ул җайлы урын... Алгы сызыкта бердәнбер тыныч төш — снаряд казыган тирән чокыр. Фотограф өчаягын шунда җайлап азапланды. Якты аз, ә якты җитми. Фото, билгеле, тонык чыкты. Шул тонык рәсем минем өчен иң истәлекле, иң кадерле нәрсәгә әйләнде соңыннан... Сугыштан соң беренче тапкыр партия билетларын алыштырганда да аерыласы килмәде ул рәсемнән...

Бер көн... Алгы сызык, таныш түгел фотограф, снаряд чокыры... Шушы гынамы? Ул көннән миндә менә утыз ел инде күңелне үзенең бер мизгеле белән горур иткән олы хис яшәп калды. Нинди мизгел? Нинди хис? Калинин фронтындагы кичерешләр, әрнүләр һәм шулардан соң Курск дугасында туган күтәренке рух мине шундый итеп әзерләгән, шушы фронтларның дулкыны, тыл, халыкның патриотик дулкыны белән алгы сызыкка китерелгән кеше итеп сиздем үземне. Партия сафына ничек кергәнемне хәтта тоймый калдым сыман. Шушы мизгел, шушы хис кадерле миңа!

# СУГЫШНЫҢ ДҮРТ ЕЛЫ...

Шәһәр партия комитетының чакыруы буенча 1973 елның мартында Ржевта булдым. Шәһәр читендә почмакланып торган урман бар иде. Үз башыннан күпне кичергән урман. Кайчан карама: ут, төтен. Янгын исе, көек исе... Әйтерсең чыршы, наратларның очларын сугышның махсус пычкысы белән кисеп алганнар. Тиеннәр әйтерсең ут йомгаклары, ут кисәкләре, агачтан агачка күчеп, тынычрак урын эзлиләр. Шулай калды бу урман минем хәтердә. Утыз ел-

дан соң башта ук шунда барасы килде. Тирән карга бата-бата, шул карт наратларны эзләп киттем. Күңел бу урманны һаман элекке хәлендә күз алдына китерергә тели иде. Ләкин, юк, мөмкин түгел. Төсләрне аеру читен. Сугыштан соң утырткан яшь агачлар искеләрен каплап киләләр, иске төсләрне күмеп баралар. Сугыш төсе һәм аңа утыз ел эчендә тормыш өстәгән бөтенләй башка төсләр килеп кушыла да, тормышның туктаусыз хәрәкәте алдында гаҗәпләнеп каласың. Бөтен җирдә шулай.

Кайвакыт сугышның дүрт елы синең иҗат плацдармың булып тоела. Шунда сугышкансың, шунда кичергәнсең. Язар өчен шул материал азмыни, җитмимени? Шул кайчандыр күргәннәр белән чикләнергәме, әллә Ватан сугышының утыз ел буена кешеләр рухында үткәргән яңа чикләрен эзләргәме? Мин Калинин өлкәсеннән Белгород өлкәсенә ашыктым, аннан Тольяттига, КамАЗга... Үземнең дүрт ел белән тынычланып калмавыма куанып бетә алмадым. Язучыга бер генә көнгә дә элекке урында туктап калырга ярамый икән дигән фикергә килдем. Дөресрәге, бу фикергә мине бүгенге тормышның искиткеч үзгәрешләре китерде. Ватан сугышы темасының ниндидер аерым чор белән чикләнгән локаль бер тема түгел икәнлеген аңладым. Ул теманың яңа шартларда яңача икенче вакыйгаларда, икенче халәттә чагылышын күрдем. Конкрет эпизод формасында түгел, Ватан сугышы тудырган патриотик хиснең яңа буын кешеләренең бүгенге омтылышларында яшәвен күрдем. Ул теманың хәзерге укучыларны һаман дулкынландыруының хикмәтен, сәбәбен дә, үземчә, бүгенгедән торып, бүгенгедән килеп ачарга тырыштым. Илнең КамАЗ кебек бер генә участогында да ничаклы кешенең уй-хисләре кристаллаша, һәр сәгате батырлык-фидакарьлектән торган нинди көчле энтузиазм барлыкка килә. Зур масштабтагы эшләр кешеләр җанын да зур итеп ача. Кеше уйларының тирән катлауларына үтеп керү дә читенләшә. Ә ил язмышы, халыкның үз язмышы хәл ителгән вакыйгаларга керү җиңелме? Бөек Ватан сугышы Октябрьда азатлык алган, дөньяны яңача таныган милләтләр өчен беренче зур сынау да иде. Ватан сугышында фашизмга каршы СССРда яшәгән һәр халыкның мең еллык потенциаль рухы хәрәкәткә килде, һәр халыкның тарихы, традицияләре кузгалды, патриотизм хисе дип аталган бер изге хиснең ничаклы тирәндә ятканлыгына мин шунда, сугышта төшендем. Ватан сугышы темасының дәвамлылыгы — шул олы хиснең дәвамлылыгында, тирәнлегендә, буыннар язмышына күчеп баруында. Тормыш иске төсләргә яңа төсләрне аралаштырып сала.

## Туган як — сандык...

Туган як — сандык, зәңгәр күк —
Өстендәге сырмасы...
Сандыкта яткан сөлгеләр —
Һәркайсы бер җыр башы.
Әбкәйләр һәркайсын каклап
Салып калдырган кебек,
Кагылам серле нәрсәгә
Килеп кагылган кебек.
Туган як — сандык, хәзинә,
Җырга мин нәкъ ач кеше,
Ачам теләгән вакытта,
Үз кулымда ачкычы.
Туган як — сандык, зур сандык —
Җыры белән дан тоткан,
Чыгарам сөлгеләр төсле
Җырларымны сандыктан.
Чыгарам берәмләп тартып,
Казанга сузылганчы,
Сузам, уйнатам кулымда,
Әйтерсең кызыл малчы.
Алам бер елга җитәрен,
Эчке бер тетрәү белән,
Ябамын иплəп, ачкычын
Билгеле төшкә эләм.

Карыйм ерактан, туган як —
Билләһи, сөрле сандык,
Җырларым өстә, әнкәйнең
Догасын төпкә салдык.

●

Кырга кайчандыр полоса
Сузган авылдашларны
Йөрдем сагынып, чыкты болыт,
Килде, давыл башланды.
Яуды яңгыр, юлда шунда
Кердем күпер астына,
Үтteләр өстән дөбердәп,
Өскә күпме бастылар,
Түздем, күкри күк, әйтерсең
Бу күпер ике катлы,
Узды йөзләгән машина,
Һәм узды ике атлы...
Дөберди ике кат күпер,
Суксаң, яшен, сук әйдә...
Талый сагыш, торам өнсез,
Сөялдем дә субайга...
Күкри күк, давыл күпернең
Такталарын куптарыр,
Узды күк авылдашларым
Сөйрәп авыр тупларын.
Качып калган кеше сыман
Чыктым, куптым өнемнән,
Солдатлар менеп бара күк
Салават күпереннән.

●

Тәмле төшләр күреп йоклаганда,
Белгород я Харьков
Уята таң белән, әнкәй кебек
Юрганымнан тартып:
— Тор, солдат, тор, син коткарган көн бу...
Алам биштәремне,
Яңартырга чыгам тынып калган
Иске хисләремне.
Шагыйрьләрне иҗат үрләренә
Илһам алып менгән,
Итәм бәйрәм мин шәһәрләр белән,
Ил-халыклар белән.

●

Исәпләсәң истәлекләр шактый
Тере, иминнәргә;
Без сугышкан җирдән чыга каска,
Чыга ременьнәр дә...
Сугыш шунда кабат алыр төсле
Җир биленнән элеп,
Чыга иске траншеялар язын
Шул ременьнәр кебек.

•

Яшен уты минем шигырьләрнең
карап эчтәлеген,
Тикшерде күк аннан астын, өстен
язу өстәлемнең.
Фронтларда йөреп яшьлек үтте,
инде яшем үтте,
Килгәнме шул ялгыш сукмый калган
иске яшен уты?
Сынар өчен генә әллә күктән
аткан бер шармы ул:
Ара-тирә кисәткәләп торсам,
шүрләр, йомшармы ул?
Яза бирдем, курку түгел, хәтта
җаным кымшанмады,
Үз гомеремдә күп уйнады өстә
төрле ут шарлары.

•

Ватан сугышы маршаллары...
Күңел шундый күнеккән,
Өлкәләр, фронтлар булып
Калды Жуков, Коневлар...

Тормыштан китә маршаллар,
Ә син тыныч торып кал,
Яңадан кулдан киткән күк
Булды миңа фронтлар...

•

Бу бик күптән. Язаргамы, юкмы?
Башлыйм шикләнергә,
Привалларда фронт юлларында,
таш юл читләрендә
Мөмкин иде изрәп китеп шунда
йоклап калырга да,
Ләкин бер таш торды һаман төртеп
минем кабыргага...
Яуды карлар җирнең яраларын
каплап ташлар төсле.
Мин гел уяу, калды борчуларым
кантар-ташлар төсле.

•

Чаллы шәһәр партия комитетының
элекке икенче секретаре Сөләйманов
Архимед Александровичка.

Бөтен фәнен җирнең җыйды КамАЗ,
Яна, балкый утлар,
КамАЗ — гигант, уртасына кереп
Басты Архимедлар.

Аркылысын, буен — масштабын
Рөхим ит тә үлчә,
КамАЗ авыр, аның авырлыгы
Архимедка төшә...

●

Яңа Чаллы. Урам. Яңа туфрак...
Тизрәк ал да ута:
Чәчәкләрне узып чыгып килә
Җирдән алабута.
Бала чакта мин тормышны белдем:
Ипи, он, ботка дип.
Алабуга дәшә: үткәнеңне,
Малай, онытма, дип.

●

Нигезләрдә безнең гасыр буе
Җыелып килгән хисне
Бульдозерлар туфрак өемнәрен
Ишкән кебек иште.
Экскаваторлар ул хисләрне
Машинага состы,
Язылачак шигырьләрем шунда
Тузан булып очты.

●

Есенин ул — авыл, үстек әле
Без сиреньсез, дидек,
Көн итәрбез моннан соң да әле
Есенинсыз, дидек.
Есенин ул — авыл, шуннан башка
Урын калмас аңа...
Ә ул безнең барыбыздан алда
Керде КамАЗларга.
Кичәләргә керде торакларның
Атлап ишегеннән,
Һәр өстәлдә автограф калды —
Китап Есениннан.
Маляр кызлар рәсемен ясап элде
Интерклубларда,
Карадылар көнләшерлек итеп,
Интим көлеп аңа.
Тольятти һәм КамАЗларны салган
Батыр яшь дусларым
Үлчиләр күк кеше хисләренең
Шунда масштабын.

●

«Булмады игенгә шартлар
Хәзерге шартлар кебек...»
Игеннәр карарга чыккан
Борынгы картлар кебек,

Кузгалып, кубып таң белән,
Мактанып Ватан белән,
Кыргалап тамак ниндидер
Бер горур мәкам белән,
Болытлар йөри сөйләшеп,
Безнең иске межада,
Туктап полоса буенда,
Киңәшәләр үзара.
Болытлар йөри сөйләшеп,
Һаман ялгыз бу башым,
Торам кызыгып, килә кайчак
Шуларга сүз кушасым.

●

«Безнең эш, үзең беләсең,
Җиренә җитсен кушкан эш...»
Тора кырыйда үз данын
Ятсынган күк Кушлавыч.
Үткәнен искә алса да,
Белмәдем тук айны, дип,
Кычкырмас ләкин дөньяга,
Мин бирдем Тукайны, дип.
Күп соң татар авыллары,
Ташкичү, Ябынчылар,
Кайсысы шуның дәгъвалап
Мәрҗани данын сорар?

Күп соң татар авыллары
Урманнар ышыгында,
Яши мәшәкать эчендә,
Хезмәттә кеше шунда.

Тудыра бөек улларын,
Кала гел булып гади,
Озата, әйтми башка сүз,
Бары тик «онытма» ди.

●

Менә ул ел буе
Тир түккән, син көткән,
Ур гына, ал гына,
Арышлар сөрлеккән.

Ур гына, ал гына
Хезмәтең җавабын...
Үч иткән шикелле
Ява да ява гел.

Дулкыннар шикелле
Арышлар ишелгән,
Шатланыр урында
Елыймын эчемнән.

Әйләнде кайгыга
Туктаусыз аккан су,
Кыйналган кеше күк
Бөкрәйтеп аркасын,

Ятканнар арышлар,
Җир, гүя, күперә,
Кыр охшап калган күк
Тоташ бер күпергә.

Үкенер өченме
Кыр тулы ашлыгым,
Ничә көн, ничә төн
Ашавым аш түгел.

Ачылган арада
Урдылар, суктылар,
Кешеләр нинди зур
Соклангыч рухлылар.

Шушындый вакытта
Күрсәтеп сәләтең,
Чыгарсаң иде син
Кояшын сәнгатьнең.

●

Баш куеп искән җилләргә,
Йөрим кырда куанып,
Йөрим арышларым белән
Мин бергә дулкынланып.

Баш куеп искән җилләргә,
Онтыл да онтыл икән,
Яшьлек ул кырда уйнаган
Дулкын да дулкын икән.

Яшьлек шул дулкын шикелле
Узар, үтәчәк икән,
Яшьлек дип алдандым, алда
Бары күк чәчәк икән.

Арыштан аерым кем күргән
Арышның күк чәчәген?
Нәрсә язса да — шушында,
Шушында — күрәчәгем.

Юктыр июнь җилләредәй
Ягымлы һәм шәфкатьле,
Иң татлы яшьләрем белән
Юам шунда шәфәкъне.

•

Язмышым, рәхмәттән башка
Бер сүзем юк бу җиргә,
Мин риза-бәхил, колак сал
Минем соңгы гозергә,
Мин башка гозерләр белән
Сине бүтән йөдәтмәм,
Язмышым, үзең аердың,
Юк әткәм һәм юк әнкәм.
Юк җирдә башка шатлыгым,
Әйтче, мин кемнән, я, ким?
Әнкәмнән мәхрүм итсәң дә,
Телемнән итмә ятим.

•

Казан өсте, читтә аэродром,
Алына, яна утлар,
Кайта арып ерак кырлар буйлап
Кичке самолетлар.
Уем минем аэродром өстен
Урап чыга элек,
Кайта алар кичке ашка кайткан
Уракчылар кебек...
Алтмыш түгел, илле түгел миңа,
Бары ун яшь төсле,
Борыннарга керә сагындырып
Сөтле умач исе.
Кичке Казан, кайта самолетлар.
Минем бөтен хисне
Кузгатты шул сөтле ашка салган
Тәмле бөтнек исе.

•

Мин кайттыммы — яучы килә,
Мин кайттыммы — туй була.
Үз җырым белән сыйлыйлар,
Шунысы бераз туйдыра.

Соңыннан шатланам ләкин
Яңасы язылганда,
Илһамым минем — яшьлеккә,
Мәңгелек Фазылларга.

•

— Күп эләкте сиңа бу тормышта,
Сиңа күп эләкте,
Гомер буе күпсенделәр төсле
Җаның — күбәләкне.
Ничек һаман исән котыласың,
Юк кулыңда калкан?
— Кыйналганда бары йөрәгемне
Мин кочаклап ятам.

Ике куллап чытырдатып кысам,
Еласын, кан саусын,
Бары тик шул йөрәгемне саклыйм,
Йөрәгем сау калсын...

●

Фатыйма,
Өй артында үскән шомыртының
Төбендәге яшел чирәмне
Син чикмәсәң килеп, дәфтәремә
Таң җилләре килеп чигәрме?

Фатыйма,
Эзләгәндә иртән күңелләрне
Бер ашларлык җылы шигырьне,
Өстәлемә алып ябар идем
Бер ашъяулык кадәр җиреңне.


●

Хатын-кызның мәхәббәте
Иргә, диләр, сирпелә,
Еллар авышкач сирпелә,
Тышта салкын җил өрә.

Ирнең, диләр, мәхәббәте
Хатын-кызга сирпелә,
Картая төшкәч сирпелә,
Йөрәк юкка җилкенә.

Яшьлектә, диләр, мәхәббәт
Йөзгә тигез сирпелә,
Вакытлы түгел, гомергә
Сирпелүен син телә.

1974.



Ватан сугышында һәлак булган язучы һәм журналистларга багышланган стендның гомуми күренеше. (Казан. Матбугат йорты.)

## Заман дәшә сезгә, җырлар дәшә

Утыз көн дә түгел сыман —
Утыз ел узып киткән.
Сугышта калган дусларым
Мәңге онытылмый икән.
Көн дә укыйм исемнәрен
Клубка узган чакта,
Әйтерсең алар тереләр,
Һаман торалар сакта,
Һаман да безнең сафта!

ШӘЙХИ МАННУР.

●

Күрде заман Алып малайларын,
Бусында да якыннан күрде:
Идел лирикасы, кылыч булып,
Аждаһаның өненә керде.

ХӘСӘН ТУФАН.




Стендтан бер фрагмент.

●

Сугышларда байрак — изге нәрсә,
Аннан кыйммәт һични саналмый,
Актык сугышчысын югалтса да,
Байрак калса, полк таркалмый.
Һичбер пуля сезне егалмады,
Байрак йөртүчеләр — үлемсез,
Сезнең җырны, полк байрагыдай,
Кабул итеп алдык бүген без.

ФӘНИС ЯРУЛЛИН.

●

Җәлил, Алиш, Кәрим исемнәре
Утлы хәреф белән язылган.
Без эзлибез сезне һәм табабыз
Дәртле, җырлы Җиңү языннан.

ИЛГИЗ КӘЛИМУЛЛИН.

●

Исемнәре уелып калды ак мәрмәргә,
Васыятьләре күчеп янды
йөрәкләргә.

НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ.

●

Окопларда туган кайнар җырлар!
Алар яши! Бар да халыкта.
Сезнең гомер җырга әверелгән,
Җырларыгыз — каһарманлыкка!

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН.

●

Яуга барды Шигырь, дауга барды
Солдат белән бергә, гел янәшә.
— Коткаручым! — диеп
еллар дәшә,
Заман дәшә сезгә,
чорлар дәшә!
Сезнең сүзләр җылы язлар сыман,
Безнең янда алар,
гел янәшә.
— Онытмам, — дип, — һаман
еллар дәшә,
Заман дәшә сезгә,
җырлар дәшә!

Күтәрелсен бөек
азат аваз,
Көчле аваз һаман
гел яктыга,
Мең ярадан исән калган җырлар,
Исән кайткан җырлар хакына!

ЗӨЛФӘТ.

●

Ерак Пруссия кырларында,
Буйларында карлы Альпның
Җырчылары йоклый, җирне кочып,
Җәлилләрне биргән халыкның.

Кутуйлары йоклый... Кәримнәре...
Сагынганда бирсен түземлек.
Европаның чит-ят туфрагында
Гомерләре калган өзелеп.

Каберләре калган... Ил җилләре
Ул якларга моңсу исәләр.
Каберләре калган... Ә үзләре
Йөрәкләрдә һаман исәннәр.

РӘШИТ ГӘРӘЙ.

## Зәки Нури



Зәки Нури. Хәрби хезмәткә 1941 елның маенда китә. Сугыш башланганда илебезнең Көнбатыш чигендә тупчы була. Дошман тылында калып, партизаннар хәрәкәтен оештыруда катнаша. 1942—1944 елларда Константин Заслоновның партизаннар берләшмәсендә башта разведчик, соңыннан разведка начальнигы була.
1944 елгы рәсем.

### 22 июнь

Бу — хәтәр көн. Хәтта көн түгел — таң...
Безнең өскә бомба ташланды.
Чиктә идек. Тел күтәреп булмый,
Әйтеп булмый: «Сугыш башланды...»

Палаткадан очып чыкты бераү,
Ә бераүләр... чыга алмады.
Нинди афәт килүләрен илгә
Шунда гына йөрәк аңлады.

Җирне күңел бүтән төстә күрде,
Күзләренә сугыш керде дә:
Томан — төтен. Таң яктысы — ялкын.
Тирәдә юк бүтән бер ни дә.

Юк! Чәчәкләр бар бит! Таҗлар — бармак,
Йомарланды бар да йодрыкка!
...Йөгер тупка! Әмма кайбераүләр
Җитәлмәде шунда йөгереп тә.

Ят козгыннар чөнки кургаш сипте.
Бөтенесе — кара тәреле.
Без шуыштык. Тупка тотарга дип
Фашистларны — женне, пәрине.

Кем шуышып, кемнәр үрә торып —
Бөтенебез утка ташланды...
Каршыланды бу көн таңы шулай,
Бөек Җиңү шулай башланды.

### Яралы яфрак

Кайлардандыр очып килде иртән
Бәп-бәләкәй имән яфрагы.
Хәтсез иде аның куркулары...
Кулларыма кунып калтырады.

Әйтте төсле: «Җилнең каты кулы,
Ник тырнадың яшел тәнкәмне?

Ник аердың безне? Нишләрмен мин
Табалмасам инде әнкәмне?»

Май башлары иде — җәелгән чак
Җиргә яшел хәтфә юрганнар,
Тырышкан чак иде яфрак ярып
Барча бакча, барча урманнар.

Кулда яфрак. Шушы иксез-чиксез
Нәниләрнең ул да берсе бит...
Әйтә күңел: «Бергә нәфрәтләнеп,
Бергә ярсыйк, бергә көрсеник!»

Сизәм чөнки: газиз әнкәсеннән
Сугыш җиле аны аерган.
Әнкә үлгән... Фашист аны җирдән

Төбе-тамыры белән каерган.

Ә яфракны, сизәм, корыч тузан
Бер бөртеге белән тырнаган.
Һәм төште ул минә минем янга,—
Бу окоп бит диеп тормаган...

Искә төште кинәт: шул ук корыч
Бер анага ничек тигәне,
Ә яралы нарасые аның
«Мин ник, әни, кызыл?..» дигәне.

Яфракка мин җылы сулыш өрдем —
Яшеллеге аның яшәрде! —
Флягама, салкын суга салдым
Бер уй уйлап: озак яшәрме?

Әйдә йөрсен, керсен һөҗүмнәргә
Башкисәрнең башын кискәндә...
Рәхәт булыр язын яшел яфрак
Коймый торган җилләр искәндә!

## Бер көз белән бер яз җыры

Көз яңгыр сибә. Көз җылый...
Ә мин шул көзне язам.
«Язны яз,— ди көз.— Һәр елны
Мин бит,— ди,— соңгы азан».

«Юк,— дим,— юк! Тәүге җырым — син!
Булсаң бул мең кат азан...
Яңгырың булып җыладым
Дүрт ел мин... шуны язам.

Үземнән куркып җыладым
Маңгайга ярчык тигәч,
Җыладым, син, миңа сыенып:
«Яраңны юам!» дигәч.

Кыскасы, бергә яшь түктек —
Икебез дә күз идек:
Без күбәүләр, ә син бер күз —
Бер сүз: «Чыда! Түз!» идек.

Аннары авыр юлларда
Тагын бергә җыладык —
Түккән яшь кургашы белән
Фашистларны сыйладык.

Шул яңгыр белән юылды
Бранденбург дигән мәйдан!
Юк, сине, күз, аерып булмый
Кояшлы, җырлы майдан.

Җиңүне аңлавы кыен
Шул хисне тоймый торып,—
Кырык берне кырык биш белән
Янәшә куймый торып.

## Гөлләр килә

Таңнар әле хәтта атмаган.
Гөлләр инде ашыгып киләләр,—
Соңгарсалар әгәр, әйтерсең
Бер минутта сула-шиңәләр.

Ашыгалар гөлләр, әйтерсең
Чык булсын дип безнең күз яше.
Без, солдатлар, ләкин еламыйк —
Түз, карты син, һәм син түз, яше.

Эндәшергә гүргә «син» диеп
Безнең телләр яуда күнде бит.
Дөмектергәч дусның дошманын,
Безнең куллар дусны күмде бит!

Авыр безгә... Ләкин сыгылмыйк.
Яшел җиле майның дуласын.
Обелиск, сине кочаклап
Алсу гөлләр бары еласын.

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ЧОҢГЫЛЛАР

РОМАН

## 1

Кошлар туңып төшәрдәй салкыннар айга якын сузылды. Кояш колакланып уяна, баеганда, шәмәхәзәңгәр төскә керә. Өй түбәләрендә, агач ботакларында — бөтен җирдә сыкы. Коры суык сулышны буа, төнлә агачлар чатный, шытырдап-зыңгылдап елга бозы ярылып китә.

Март аена керергә атнадан азрак вакыт калып килә, ә салкыннар һаман кайтмый әле. Печән-салам эскертләре күзгә күренеп кими, силос базлары саега — терлеккә азык бермә-бер артык китә.

Моңа кадәр малкайларга азык-фураж җитәсенә Талипның күңеленә шик килмәгән иде, айлар буена сузылган салкыннар исә аны да борчуга салды. Хәтта ул бер тапкыр шикләнеп тә куйды: «Әллә соң ике кыш бергә киләме быел?»

Председатель булып эшләү дәверендә ул шактый суык, дәвамлы кышларны күрде. Ләкин быелгыдай усалын хәтерләми әле. Бусы нык тиде, нык үтте үзәккә. Комплекс салу тукталып тора, лабораториянең түбәсен яба алмый җәфаланалар. Шифер кагу түгел, кирпеч тә тезеп булмый. Өстәвенә, мастерскойга җылы җитми — торбалар ката, техниканы ремонтлау тукталды, корыч коралларга кул тидерерлек түгел.

Талип өеннән чыкты да, бит-борынын тун якасына яшерә төшеп, идарәгә таба китте. Авыл уяна, морҗалардан ишелеп-ишелеп төтен күтәрелә, ләкин гадәттәгечә өскә, һавага менеп китми, телевизор антенналары тирәсендә тулгана. «Аз гына булса да йомшартачак болай булгач,— дип сөйләнде Талип һәм агач ботагында чыркылдашкан чыпчыкларга карап: — Болар да сизенә әнә», — дип куйды.

Юл такыр, тимераякта шуарлык. Талип юлдагы катып үлгән бер чәүкәне читкәрәк тибеп җибәрде дә идарәгә таба борылды. Болдырга менде, туктады, тирә-юньгә күз ташлады, суык чеметтерә башлаган борын очын ышкыштырып алды. Нәкъ шул чак болдыр янындагы тупылның бер ботагы шартлап сынды да һава сызгыртып җиргә төште. Талип салкынга чыдамыйча сынып төшкән ботакка күз ташлады, агачны кызганып куйды.

Гажәп тә соң бу дөнья! Кайдадыр экваторда кояш кыздыра, ябалдашларын киң җәеп мәһабәт пальмалар үсеп утыра, җанга рәхәт йомшак җил исә, чылтырап чишмәләр ага...

Талип бүгенге көндә һавасы утыз-кырык градустан да артык кыза торган Африка илләрен күз алдына китерә һәм үзе яшәгән, менә үзе басып торган төбәктәге суыкны тоя. Әйе, табигать бездә рәхимсез, усал, һәммә тереклекне, хәтта агачларны да һәр вакыт сынауда тота. Ә кешеләргә тагын да кыен.

Авыл өстен морҗалардан бөркелгән аксыл төтен катыш фирәзә түсендәге томан сарган. Ай кебек ук салкын кояш Рә тавы артыннан чыгып килә. Иртәнге нурлар өй түбәләренә кунуга, авыл ачыграк күренә башлады. Бүген, ниһаять, кояш колакланмаган иде. Талипның эченә җылы йөгерде. Сындырачак болай булгач, чынлап торып йомшартачак.

Талип идарәгә керергә дип ишеккә юнәлде, әмма үзенә таба килгән агрономны күреп туктап калды. Талип белән Харисов Казанга киткәч, агроном егет башбаштакланып, ярамаган эш эшләп ташлаган иде, кичә кайта-кайтышлый, эче сизепме, ул складка керде һәм тәртәгә ярарлык каеннарны күреп аптырый калды. Кем кисте бу каеннарны? Каян?

Каеннарны урман полосаларыннан агрономның кистерүен белүгә, Талип йөзгә алышынды, кайта-кайтышлый ук өенә кереп сүгәргә иткән иде, ни кодрәт килептер, иртәнгә кадәр сабыр итәргә булды. Алай да өлкән диспетчерга кичтән ук: «Иртәгә иртән агроном минем кабинетта булсын!» — дип кисәтеп куйды.

Мидхәт Бәдретдиновны ул Садыйков киткәч эшкә алды. Егет яңа гына Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган, дипломлы агроном һәм күрер күзгә өметле белгечкә охшаган иде, ә ул әнә, килеп ярты ел эшләмәде, инде үз тәртипләрен дә урнаштыра башлаган. Ун-ун-бер ел эчендә шактый буй алып, тирә-юньгә ямь биреп, җәй килдеме күңелләрне җилкендереп торган, сылу кызлардай утырган каеннарны беркем белән киңәшмичә кис тә ташла, имеш. Урман полосаларын сирәкләтә. Ни өчен, нигә сирәклләтә? Әйе, әйе, ни өчен сирәклләтә?

Талип абыең да төшеп калганнардан түгел, авыл хуҗалыгын синең кебек белгечләрдән ким аңламый, ун ел буена председатель йөген тарта, ел аралаш белем күтәрү курсларына барып укый. Авылда читән үреп үсмәсә дә, буй урманнарның кыр-басуларга нигә кирәк икәнен бик яхшы белә. Ашыкма әле, егет, син ул тиклем абзаң белән күчәр башы орырга. Берәү әнә орып-орып карады да чыдамады, утырган арбасының күчәре күкрәк төбеннән шартлап сынып чыкты. Ахыр килеп, бөтенләй китәргә мәҗбүр булды. Инде, егеткәем, син дә шуны куасың икән...

Талип идарәгә таба килгән агроном Мидхәтне күрә, Рә тавы артыннан калкып чыккан кояшка карый. Һәм янә егеткә күз сала. Мидхәтнең өстендә ясалма күннән дубленкага охшатып теккән тун, аягында монда эшкә килгәч кенә бастырып алган киез итек, башында куян бүрек. Барлы-юклы якасын күтәргән, муенын җыера-куыра яшергән. «Юка киенә, салкын тияр дип тә курыкмый, яшьлеге белән масая», — дип уйлады Талип, килеп җитеп үзе белән кул биреп күрешкән егеттән күз алмастан.

— Исәнмесез, Талип Кәрамович! Исән-сау кайттыгызмы?

— Ару гына болай. Юл унды дияргә була. — Талип Мидхәтнең өсбашына күз ташлап алды. — Юка киенәсең, егет. Салкын тиюе бар.

— Зыян юк, салкынга күнеккән мин.

— Алай. Әйдә әле, әүвәл керик. Салкынга күнеккән, димәк, чыныккан да булгач, батыр егет икәнсең. Тик менә җавапны ничегрәк тотарсың.

Кабинетка сүзсез генә үттеләр. Мидхәт председательнең ни өчен чакыруын беркадәр чамалый иде, шуңамы, бераз турсайганрак кыяфәттә керә-керешкә, ишек янәшәсендәге калай белән тышланган мичкә аркасын терәде, түргә узмады. Талип туп-туры түргә юнәлде, бияләйләрен салып өстәлгә ташлады да кулын-кулга ышкыштырып:

— Бу атнада да китмәсә бу суыклар, хәтәр булачак, — дип сөйләнде. — Ужымнар ни хәлдә? Көзге бодай? Тикшергәлисеңме? Укытулар ничек бара? Механизаторларны бик теләп йөрмиләр дип әйтә Әдһәм абый, расмы шул?

— Йөрмәүчеләр бар-барын. Чакырып сөйләштем мин алар белән, укырга сүз бирделәр.

— Менә нәрсә, Мидхәт. Без аларга шушы курсны тәмамлаганга таныклык бирик. Кем дә кем укуга йөрмәгән, имтихан кебек нәрсәләрне тапшырмаган — язгы чәчүгә катнаша алмый, менә шул.

Талип өстәл артына керде, сводка кәгазьләрен караштырды.

— Ә менә тирес чыгару өчен махсус звено оештырмыйча булмастыр. Кышкы чорга гына. Ләкин башка тармакларга звеноларның һич кирәге юк. Мин моны ни өчен әйтәм? Менә ни өчен: без синең белән авыл хуҗалыгындагы бөтен процессны промышленностька нигезләп корырга тиешбез. Аңлашыламы шул сиңа?

Агроном башыннан бүреген салды, әмма мич яныннан кузгалмады.

— Минем бу өлкәгә кагылган кайбер фикерләрем бар иде, Талип Кәрамович.

Талип агрономга өнәми генә карап алды, каршы әйтүе ошамадымы, куе кашлары сынып китте, күзләре кысылды.

— Әйт әле, Мидхәт, урман полосаларындагы каеннарны кем кушуы буенча кистердең? Үзеңнең башың җиттеме, әллә булмаса башка берәүнең киңәше белән эшләдеңме?

— Үз инициативам. Чөнки шулай кирәк.

— Алай. Димәк, синең инициативаң...— Талип тун төймәләрен ычкындырып җибәрде. — Син беләсеңме әле, егет, элекке агроном белән ни өчен тыныша алмадым мин? Беләсеңме?..

Агроном дәшмәде, ияк каккалап кына алды.

— Беләсеңме, әллә юкмы? — дип тавышын көчәйтә төште Талип, егетнең дәшмәвенә ачуы кабара башлап.

— Хәтерлим. Садыйков белән мин институттан ук таныш. Үткән киңәшмәдә очраттым мин аны. Нигәдер мактамады ул сезне, Талип Кәрамович.

— Җитеп торыр!

Талип кулларын җәеп өстәлгә таянды, бер тын пыяладай шома өстәл өстендә чагылган сурәтенә карап торды. Аннары эһ дип җәһәт кенә кузгалды да ярсынып ишекле-түрле йөренергә кереште.

— Син миңа каеннарны кистерүеңнең сәбәбен аңлат. Садыйковның мине мактавы, мактамавы турында соңыннан сөйләшербез. Әйт әле, синең белән минем арада сөйләшү булдымы ул каеннарны кистерү хакында, юкмы?!

— Юк, булмады, — диде агроном һәм кинәт урыныннан кубып өстәл янына килде. — Талип Кәрамович, минем сезгә бер сорау бирәсем килә. Ярармы? — Талип, биреп кара дип, баш какты. — Үзегез әйтмешли, әйтегез әле, бу колхозда башкарылган эшләр өчен сез генә җавап бирәсезме әллә? Мин монда үземә йөкләнгән эшкә җавап бирергә дип килдем. Үзем кистердем һәм үзем җавап та тотармын. Каеннарны мин белеп кистердем, иптәш Бикмуллин.

Талипның болай да кызыл муены тагы да кызарып китте. Ул, йөргән мәлгә тунын салып, чөйгә элеп килде дә урындыгына утырды, тәсраеп агрономга карады.

— Әһә, хикмәт әнә нәрсәдә икән. Тәк-тәк, болай булгач, киләсе елгы уңыш өчен бер син генә җавап бирәсең булып чыга инде.
— Каеннарны кистерүебезнең сәбәбе менә нәрсәдә...
— Кистерүебезнең түгел, кистерүемнең диген. Шулай ачыграк булыр.
Мидхәт, председательнең соңгы сүзләренә игътибар итмәстән, өстәлдә яткан бер бит кәгазьне үзенәрәк тартып алды, карандашка үрелде.
— Каеннарны кистерүемнең хикмәте менә нәрсәдә...
— Әлегә хикмәтеңне калдырып торчы, дускай. Башта син шуны әйт: кем ул каеннарны утыртты, кем үстерде? Синме, безме?..
Бүлмәгә Харисов килеп керде. «Берек» колхозының партком секретарена алтмыш яшьләр тирәсе булыр. Керү белән ул туп-туры түргә узды, икесе белән дә кул биреп күреште.
— Иртәләгәнсез бүген. Ни кырып ятыш? — Харисов өс киемен салып чөйгә элде, өстәл янына килде.
— Менә, Әдһәм абый, — дип башлады Талип, партком секретаре утыруга. — Каш ясыйм дип, күз чыгарган. Сорамый-нитми урман полосаларын сирәкләтә башлаган.
Харисов агроном егеткә сораулы караш ташлады.
— Сирәкләтмичә булмый ул полосаларны, — диде Мидхәт.
— Минемчә, полосаларны без ул кадәр куе утыртмаган идек.
— Менә-менә, мин шуны әйтәм бит, — дип урынына килеп утырды Талип.
— Хикмәт менә нәрсәдә,— дип башлады агроном сүзен, алдындагы сызымнар, саннар төшерелгән бер бит кәгазьне өстәл уртасынарак этәреп куйды. — Бүй урманнарга агачлар кирәгеннән артык куе утыртылган. Шул сәбәпле полоса буйларына калын итеп кар сала. Кагыйдә буларак, ул кар май азакларына кадәр эреми. Нәтиҗәдә менә диген уңдырышлы туфрак, ягъни йөзләгән гектар җир әрәм була. Без ул полоса буйларына соңгы культураларны чәчәргә тырышабыз. Ләкин бу юл безгә кулай түгел. Басуларыбыз болай да тар, куәтле техникага борылыр урын юк диярргә була.
Харисов агрономның сүзләренә колак сала-сала уйланып утырды. Теге вакытта ул, Садыйков белән Талип тынышмый башлагач, алай гынамы, бу ике кеше арасындагы дәгъва-бәхәс район партия комитетына кадәр барып җиткәч, яшь белгечнең кыйбла-юнәлешендә дөреслек күреп, Садыйковны яклап чыккан иде. Ләкин райком секретаре Хөснетдинов бу бәхәсне үзенчә хәл кылды. Тотты да Садыйковны үз туган авылы Наратбашка председатель итеп тәкъдим итте. Һәм ялгышмады кебек.
Инде бу егет белән дә Талип тарткалашуга күчсә, эшләре гел ызгышка китсә, Харисов, ниһаять, хакыйкатьне яклар. Тегесен ничектер сизмичәрәк калды бугай. Ләкин бусы Садыйковны да уздырды кебек: колхозчылар күз карасыдай саклап үстергән урман полосасы каеннарын кистергән. Полосалардагы һәр агач, һәр куак исәптә чакта...
— Әдһәм абый, я, нишлибез инде бу егет белән? Килүенә ярты ел юк. Аңламыйм мин бу яшьләрне!
Талипның эчке тавышында: «Теге вакытта миңа каршы чыккан идегез, инаныгыз инде, монысы да үз белдеге белән эшләргә керешә», — дигән мәгънә ята иде.
— Бик кирәкме бу чара, Мидхәт?
Агроном егет партком секретаренең күзләренә текәлде. Шуны аңламыйсызмы дип гаҗәпләнүе идеме? «Кыю хәзерге яшьләр, кыю кыланалар, тәвәккәл», — дип уйлады Харисов, егеткә үзе дә туры карап.
— Мин бу эшне җитди чараларның берсе итеп күрәм, Әдһәм абый...

Талип беравык башын чайкап торды һәм сабыры төкәнеп:

— Кызлар кебек сылу каеннар иде. Ничек кулыгыз барды, ничек балта күтәрдегез! — дип, янә ишекле-түрле йөренергә кереште.

— Бу мәсьәләдә хаклы булуымны эшем белән күрсәтермен, Талип Кәрамович, борчылмагыз.

— Юк инде, мин сине ул мәшәкатьтән арындырырмын болай булгач. Син уйлаганча ук надан түгел Талип абыең.

Талип кабат өстәл янына килеп утырды, диспетчерга шалтыратты.

— Каюм, — кабул итү аппаратында диспетчер Зиннуровның «әү!» дигән нечкә тавышы ишетелде, — буй урман агачларын сирәкләтергә кичә ничә кешегә наряд биргәннәр иде сиңа?

— Унике кешегә, Талип абый. Тик бүген берәү дә бармый.

— Нигә алай, ни булды?

— Ни бит, Талип абый, туктаттык без аны. Менә монда егетләр белән килештек-килештек тә... Бу ниндәен ахмаклык, бастырыкка ярардай каеннарны кем кисәргә кушты дип Галләм абзый да тузынып китте.

Бүлмәгә кояш нуры керде һәм өстәл башына куныл калды. Талип, аппараттан бармагын алмый гына, Харисовка:

— Ишеттегезме инде, Әдһәм абый? Каеннарны кистерүгә Галләм абзый да каршы икән бит,— дип агрономга таба борылды.— Ә ул бит ярты гомерен Карамалыда агроном булып эшләгән. Полосаларны үзе утыртып, үзе үстергән кеше.

— Буй урманнарны үз вакытында рәткә китерү, кирәкле күләмдә сирәкләтү агрочараларның бер шарты, — диде Мидхәт тә торган саен үҗәтләнә барып.

— Корыган-сарыганнарыннан арындыру — ул бит бөтенләй башка мәсьәлә, иптәш Бәдретдинов. Аны да, мөгаен, язга табарак эшләргә кирәктер. Шулаймы, әллә мин ялгышаммы?

— Агачлар куерак үскән саен полоса буена кар калынрак сала...

— Начармыни ул?! Кыш буена кыр-басуларда кар тотабыз, ә бу, акыллы баш, кар калын салмасын дип, буй урман агачларын кистерә. Инде инандыңмы, Әдһәм абзый, нинди уңган агроном туры килгән безгә! — Талип кайнарланып урыныннан купты, кояш чыгышы ягындагы тәрәзә каршына барып басты, кулларын артка куеп чалыштырды, гасабиланып, бармакларын угаларга кереште. — Колхоз белгече булган бар кеше дә үз белдеге белән генә эш итә башласа, кая тәгәрәр икән идек без, Әдһәм абый. Әйтик, син үзеңчә генә эшләсәң, башкалар фикеренә колак салмасаң, мин үземчә генә, — диде Талип, көрсенеп алды һәм, кузгалып, Мидхәт каршына килеп басты. — Беләсеңме, туганкаем, Болгариядә бер агач кискән өчен нәрсә эшлиләр? Бер төп агач өчен ун төп агач утыртып үстерүне таләп итәләр. Унны, ун төп! Ә син йөзләгән төп каенны эһ тә димичә кискәнсең дә аткансың.

— Полоса буйларына калын итеп кар сала, уҗымнар чери, Талип Кәрамович. Май аена кадәр ул җирләргә бернинди ашлык чәчеп булмый...

— Шуның өчен син каеннарны кисәргә булдың инде? Юк, туганкаем, болай булса безгә бергә эшләүләре кыен булыр. Карны аны самолеттан күмер оны сиптереп тә эретеп була. Ниһаять, бездә техника да җитәрлек хәзер аңа...

Харисовны ишектән дәшеп алдылар. Партком секретаре чыккач, Талип текәлеп Мидхәтнең күзләренә карады. Сынап карады. Мәгәр аның карашын егет җиңде, күзләрен читкә алмады.

— Әгәр судка бирсәм мин сине, шома егет?

Агроном: «Һы!» — дип кенә куйды. Аннары: «Бирегез. Мин үземне гаепле санамыйм. Полоса агачларын барыбер сирәкләтергә кирәк!» — диде.

— Ялгыз агачны җил кага.

— Ялгыз агачның тамыры тирән китә, иптәш Бикмуллин.

— Ялгыз агач таралып үсә, тәбәнәк була, ә минем шәм кебек каеннар үстерүдә хыялым, — диде Талип һәм, үрелеп, агроном алдындагы кәгазь битен алды. — Инде хәзер нишләргә синең белән?

Талип егетнең йөзендә үкенү дә, каушау да күрмәде. Үкенсен, үртәлсен иде, ичмасам.

— Үзең теләп китәсеңме, приказ белән куыйммы?

— Мин бирегә китәргә дип килмәдем...

Башлыгының чәнечкеле елмаюын күреп, егет тә көлемсерәп куйды. Моны ни дип юрарга да белмәде Талип. Үзе исә аның «мең төп агач утыртырмын» дигән сүзенә елмая иде. Ник дисәң, хикмәт бит егетнең бу эшне булдыру-булдырмавында түгел, ә егетнең үз гаебен аңлавында иде. Ә агроном егет председатель ни теләгәнне аңлады булса кирәк.

2

Пеләш башлы, кызыл йөзле, су кебек төссез күзле баш агроном бүтәнен сайларга урын калдырмыйча, Мидхәткә болай диде:

— Районда ике колхозга агроном кирәк. Берсе — «Берек» колхозы, дүрт мең гектарга якын сөрү җире бар, икенчесе — «Урал», сөрү җире биш мең гектар. «Берек»нең председателе белеме белән юрист, «Урал»да югары белемле агроном, яшь кеше, институт тәмамлавына да ике-өч ел гына бугай әле.

Мидхәт Карамалыга, ягъни «Берек»кә барырга дигән фикергә килде. Ни өчен дисәң, «Урал»да югары белемле агроном үзе председатель, ике тәкә башының бер казанга сыймавы бар. Ә менә «Берек»тә эшләп булыр.

Институт тәмамлаган һәр белгечнең үз хыялы, үз максаты була. Мидхәт тә күңел түрендә нинди дә булса ачыш ясау хыялы белән яши иде.

Председатель аны район үзәгенә үзе килеп алды. Киң яңаклы, юантык гәүдәле, монгол кешесен хәтерләтә торган кысыграк күзле председатель аз сөйләште, кәефе юк кебек иде. Карамалыга кайтып житкәч, ул Мидхәтне фатирга китерде һәм: «Юлдан соң ял ит, аннары колхоз белән танышырсың», — дип китеп барды.

Фатир хуҗасы кечкенә генә гәүдәле, озын чал мыеклы Галләм карт утыз елга якын Карамалыда агроном булып эшләгән, хәзер пенсиядә икән. Галләмнең карчыгы картына бөтенләй капма-каршы кыяфәтле иде: юан гына гәүдәле, җәйпәк йөзле, җете кара күзле, үзе гаять тере, хәрәкәтчән, житез кылана, бертуктаусыз кыстап кына тора. табындагы теге яки бу ризыкны Мидхәт алдына күчергәләп, кунак итә.

Ашап эчкәннән соң аңа түр яктагы такта белән генә бүленеп алган бүлмәгә урын җәеп бирделәр. Карчык: «Кызыбыз кайтканчы шунда йоклап торырсың», — дип, егет күңеленә әллә ниткән өмет-хыяллар салып куйды.

*
* *

Уянды Мидхәт һәм бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Түр яктагы стена буена китап шкафы куелган. Шкафта авыл хуҗалыгына багышланган журналлар да күренә. Шкаф янәшәсендә стенада кнопкалар белән генә беркетелгән зур фоторәсем. Җәй көненең бер күренеше һәм шул

табигатьне тагы да матурлаган җәйге җиңел күлмәкле чибәр генә бер кыз. Кулында чәчәкләр. Кара чәчләре иңбашларына сибелеп төшкән. Үзе назлы гына елмаеп, уң кулы белән чәчен төзәтә.

Күрше якта берәү кыштыр-кыштыр йөренә башлады, тамак кырды. Мидхәт сикереп торды да, трикосын киеп, алгы якка чыкты.

— Хәерле иртә, Галләм абый!

— Иртә ярыйсы болай. Йокы ничек булды соң? Саташтың да бугай бераз. Уятырга иткән идем, Тәгъзимә апаң кушмаган булды.

Галләм карт шадра йөзен сыйпаштырып, мыегын бөтереп алды.

— Әйдә, юын да чәйләп алырбыз.

Мидхәт ишегалдына чыкты. Тышта салкынча октябрь иртәсе иде. Егет ап-ак кырау төшкән үләнгәрәк үтте дә физзарядка ясарга кереште. Галләм карт та чыкты. Ул тәрәзә астындагы эскәмиягә утырды, тәмәке көйрәтеп җибәрде. Ә үзе мыек астыннан гына Мидхәтне күзәтте.

— Үзең кайсы яктан? Кичә бик соң алып кайтты үзеңне, сорашып та булмады.

— Минзәлә якларыннан.

— Алай икән. Атаң-инәң исәнме соң?

— Ашыга төшүләр алар, Галләм агай. Дөньяны катырак кудылар бугай.

— Нишлисең инде, һәммәбезгә дә анда бер барасы,— диде Галләм карт һәм янә сорап куйды.— Туган авылыңа кайтырга булмадыңмыни?

— Исәп юк түгел иде дә, җибәрмәделәр. Дәүләт кешеләре бит без. Үзе укыткач, үзе теләгән җиргә җибәрә.

— Анысын бик дөрес эшли,— дип мөһер сукты Галләм карт.— Югыйсәң, сезнең ише кыска койрыкларны ничек тыеп бетермәк кирәк. Тик менә Карамалыга килүеңә үкенеп куймагаең.

— Ник алай дисез, Галләм агай?

— Түрәбез каты куллырак. Үз дигәнен итәргә яратучан,— диде карт һәм, бу сүзләренә нииндидер эчке мәгънә салуын аңлатып, уч төбенә генә елмаеп куйды.

— Мин биргә тик бер максат белән генә килдем, Галләм агай, иген үстерергә.

Мидхәт ишегалдында чатыр чабып йөгерергә кереште.

— Әйдә, чабып кал. Талип абыең чаптыра башласа, физзарядка кайгыларың качар. Агроном Садыйков та килгән мәлне шулай сикергәләнә торган иде, эшкә керешкәч, баш тераргә вакыты калмый башлады, бахырның. Ул да миндә торды бит. Талип эшләтә белә ул, аңа тарма, тарсаң — арыма.

Мидхәт тирән сулый-сулый Галләм карт янына килеп басты.

— Мин аны председатель белән тыныша алмады дип ишеттем, хакмы шул, Галләм агай, әллә мине үртәп кенә сөйлиләрме?

— Хагын-нахагын кем белгән инде аның. Кайтып керсә зарлана торган иде. Игенчелектә звенолар оештырырга исәп иде, председатель каршы төште, дип. Кукуруз чәчүдә уртак тел тапмадылар. Садыйков квадратлап чәчик дип барды, тегесе рәт ара чәчтерде, имеш, яшел масса күбрәк чыга. Һәм анысы шулай да. Пар калдыруда да бугазгабугаз килеп беттеләр...

— Ни белән бетте соң?

— Эшләре райкомга кадәр җитте. Егеткә китәргә туры килде. Туган авылына председатель итеп күчерделәр. Авылдашлары канәгать ди әнә үзеннән.

Галләм карт һавага карады, тәмәке төпчеген аяк астына ташлады да итек башы белән бөтергәләп алды.

— Томалады бу тәмам, әй! Берәр фурман салам китерермен дигән идем, булмады инде болай булгач, чәнчелгере. Югыйсәң, Талип рөхсәт кәгазен дә биргән иде.

— Саламга кадәр председатель рөхсәт бирәмени?

Мидхәт шулай дигәч, Галләм карт аңа гаҗәпсенеп карап алды. Аның мыегы кебек үк чаларган киң кашлары бергә кушылды, авыз тирәсенә җыерчыклар өелде, маңгаендагы болай да тирән буразналар тагы да тирәнәеп китте.

— Күренеп тора: бер дә тәҗрибәң юк әле синең, энем. Салам... Салам ул крестьянның малы да, түбәсе дә. Хәзер генә ул әнә шифер уйлап таптылар. Сугыш елларында малкайларны шул бер салам белән асрадык...

— Син дим, ашарга керегез! — дип дәште Тәгъзимә карчык, тәрәзә капкачын ачып.

Беренче тойгылар сүрелә төшкәннән соң, Мидхәт «Берек» колхозының председателен күз алдына китерергә тырышып карады. Шул ук вакытта ул боларның үзе өчен кирәкмәгән бер кысыр кайгы икәнен дә бик яхшы белә иде. Вакыт — менә нәрсә хәл итәчәк аларның үзара мөнәсәбәтен. Институтта бер профессор аларга: «Һәр кешенең дә бер талантына ике кимчелеге булыр»,— дип әйтергә ярата торган иде.

Мидхәтне алырга бригадир килде. Ак чырайлы, җилкәле генә, утыз яшьләр тирәсендәге кеше.

Тәкәллефсез генә таныштылар.

— Бердәнбер комплекслы бригаданың башы Зариф Бакиров,— диде ул, стройдагы солдат сыман ачык итеп.

Мидхәт тарантаска менеп утырды.

— Тиздән бу Галләм абзый турына вертолет белән генә төшәргә калачак, — диде бригадир, дилбегәне кулына алып. — Күрә торып саз уртасына өй китереп салган. Яз житсә, өенә су керә. Ике елга бер моржа чыгарып тора. Китми генә шушы урыннан. Урман якын, күл-су аяк очында, имеш.

Бригадир сукрана, дилбегәсен тарткалый. Өй каршындагы саздан ат тарантасны көч-хәл белән тартып чыгарды.

— Талип абый куштымы?

— Әйе. Эшне кабул итә торыгыз. Агроном вазифасын үтәгән кызыбыз сессиядә. Ә эш муеннан. Шуңа аптырый калдым әле. Нигә бу Талип абый килгән бер агрономны Галләм абзыйга урнаштыра. Үзе агроном булгангамы әллә? Агрономнар семьясы дияргә була. Кызын да шуңа укыта. Чибәр, сылу кызы. Тамчы исемле.

— Атың җилле күренә, — диде Мидхәт, ә үзе бүлмәдә күргән рәсем турында уйлады. «Менә кем икәнсең син, кызыкай».

Кара биянең янбашлары ялтырап тора. Сазлыктан чыгуга, ул, дилбегә какмас борын, җилле генә юыртып та китте.

— Минем көйгә өйрәнгән. Элдертә. Сезгә кадәр булган агрономга биргән идем, йөртә алмады малкайны. Кирәксә-кирәкмәсә дә чыбыркы белән суга иде. Бер тапкыр дулады бу. Алып китте, мин сиңа әйтим, тегеләй иттереп. Тигән җиргә тия тәгәрмәчләр, тимәгән җиргә тими дә кала. Көчкә сикереп төшеп калды. Аягын каймыктырды, бер атна больницада ятып чыкты агрономыбыз.

— Яхшы ат — юлдаш, яман ат — гүрдәш, диләр бит.

Бригадир дилбегәне тарта төште, атны тыйды. Тыкрыкка борылуга, ике кеше очрады.

— Тпру-у, һәй, юкка йөрисез, Сираҗетдин абзый, кибет ябык, Гөлсинә сельпога китте.

— Типте бия тәртәгә болай булгач, — диде Сираҗи дигәне, барган җиреннән кырт туктады.— Әйдә, Инсаф, түбән оч Әһлиулла абзыйга, әче балы бар аның.

— Хәзер үк борылыгыз, Сиражетдин абзый. Машиналар саламга кузгала. Мин сезне салам төяргә куйдым.

Сиражи янәшәсендә басып торган Инсафка терсәге белән орынып алды: янәсе, нишлибез?

— Хәзер әйләнәбез, Зариф энем, эһ дигәнче идарә янында булачакбыз. Безнең өчен борчылма.

— Я хәзер үк борыласыз, Сиражетдин абзый, я бу эшегезне җыелышка куям. Кичә булды кичә каядыр китеп югалдыгыз. Җитте!..

Сиражи дигәне уңайсызланып бер урында таптанып алды.

— Анысын булдырырсың син... Әйдә, Инсаф, борылдык. Кеше хәленә керүче бармы хәзер. Үләм дисәң, авызыңа су салучы табалмассың бу Карамалыда.

— Менә шундыйлар да бар шул әле бездә. Болай начар кешеләр дә түгел кебек үзләре. Ә менә, бер ычкынып алсалар, шул агуны эзләп Наратбашка кадәр чабалар. Талип абый кыса төште үзләрен, аңардан шүрлиләр. Шулай салып йөргән берәүне тәмам авылдан куды.

— Дөрес эшләгән.

Зариф өнәми генә агроном ягына сирпелеп алды. Атына чөңгереп, дилбегәсен тәрткәләп куйды.

— Игенне кем игәр соң аннары, иптәш Бәдретдинов? Беләсегез килсә, механизаторлар җитешми бездә хәзер. Былтырларны егерме җиде балабыз унны тәмамлады, шулардан унике егетебез армиягә китте, бишәүсе институтка керде, тик өч егетебез генә авылда калды. Кызлар турында әйтеп торасы да юк — аттестат алу белән шәһәргә шылалар. Ел саен биш-алты механизатор пенсиягә чыга. Һәр эчкән кешене колхоздан куарга килеребез сайрак шул, дускай. Талип абый бераз кысты кысуын. Шелтә бирде, премиядән мәхрүм итте үзләрен. Ләкин бит әле бездә бу чараларның киресен аңлаучылар да бар. Миңа шелтә бирделәр дип, Инсаф атлы берәү ике атна буена баш күтәрми эчте. Шуннан соң әле булса мантыганы юк. Ычкынды исә ун көн буена салып йөри.

— Эчәр өчен акча кирәктер бит, каян ала соң ул аны?

— Башын шуңа салган кеше акча тапмыймы соң, дус кеше. Һич югы, көмешкә куа башлый. Я арыш бүрттерә, я чөгендердән кайната. Болай үзләре тәртипсез кешеләр дә түгел кебек.

Бригадир янә агрономга сәерсенеп карап куйды. Әмма бу юлы сүз сөрмәде — артык яшьсендеме егетне, санга сукмадымы, кыюлыгы ошамадымы.

Идарә каршында ике-өч машина тора иде. Машиналар тирәсендә уралучылар, тарантас килеп туктауга, бригадирга ябырылды.

— Саламга барабызмы, юкмы бүген?

— Каюм ни ди соң?

— Яңгыр явачак ди, җибәрми торган була.

— Көн бушка үтмәсен. Бер булса да юлларга кирәк.

Әлегә кадәр Мидхәткә игътибар итүче булмаган ир-егетләр арасыннан берсе:

— Малайлар, яңа агроном килгән икән бит! — дип әйтсә дә, аңа карамадылар, дәррәү кузгалып машиналарга төялделәр. Идарә болдырына председатель чыгып басты.

— Исәнмесез, Талип Кәрамович!

— Әйдүк, егет. Өйдә ятасыгыз килмәдеме? — диде Талип һәм җавап та көтмәстән өстәде: — Фатир ошадымы соң? Ошатмасаң, яңага күчерәбез. Хәер, кирәкмәс, тиздән кунак йортыбыз өлгерә, шунда күчәрсең.

— Ә сиңа, Зариф, — диде председатель, карашын бригадирга күчереп. — Салам төяүчеләр янына китәргә туры килер. Үзең күзәт, авып-түнеп, коеп-чәчеп йөрмәсеннәр. Җәен — салам, кышын — печән, яхшы салам — ярты азык, әрәм-шәрәм итмәгез.

Председатель Мидхәтне идарәгә нәртеп керде. Талип түргә узганда, аның авыр гәүдәсеннән идән сайгаклары сыгылып куйды кебек. Төптән юан, таза, сәламәт гәүдәле иде председатель.

— Утыр әйдә, менә моннан уз. Чөнки сөйләшү җитди булачак.

Мидхәт плащын салды, беретын бөгәрләп кесәсенә тыкты, өс киемен ишек янындагы чөйгә элде. Председатель исә плащын үзе утырган урындык терәгенә ташлаган, күк эшләпәсе өстәл читендә ята.

Урынына утыруга, ул аппарат төймәсенә басты. Ишектә йомышчы кыз күренгәч, аңа карамыйча гына:

— Люция, Әдһәм абыең мәктәп янында йөри бугай, бире дәш әле үзен,— диде.

Мидхәт кызның сары муенсаларын, дугаланып торган сөрмәле кашларын, күпертеп таралган коңгырт чәчләрен генә күреп калды.

— Каян, кем баласы булуыңны сорамыйм. Чөнки беләм. Биографияң белән кыскача гына танышмын, — диде председатель маңгаен угалап.— Синең киңәшең кирәк, райидарә лаборатория салырга тәкъдим итә. Зонадагы сөрү җирләрен, ягъни туфрак структурасын тикшерергә исәпләре. Ләкин расход-авырлыклары безгә төшә. Шуңа карамастан, мин риза булдым. Әйтәсеме, бу безнең шактый чыгымны алачак, ул гынамы, төзелеп яткан объектлардан эшчеләрне алырга туры килә, чөнки лабораторияне ашыктыралар. Имеш, яңа елга өлгертергә. Хәер, бусысы мәсьәләнең практик ягы. Ә мине аның теоретик ягы борчый. Беләсем килә, иптәш Бәдретдинов, кирәкме ул лаборатория безгә, хаҗәте бармы? Вакытлыча файдалану өчен генә төземәбезме?

Беренче сәгатьтән үк председатель шактый кыен хәлгә калдырды Мидхәтне.

— Мин бу мәсьәләдә сезгә киңәш бирә аламмы соң әле, Талип Кәрамович? Әгәр дә мәгәр...

— Бирә аласың. Үзең әйтмешли, әгәр дә мәгәр председатель сине үзенә чакырып киңәш сорый икән, димәк, ул моны шулай кирәк дип тапкан.

— Минемчә, лаборатория бинасы колхоз өчен ул хәтле зарур түгел. Инде райидарә моны нәкъ менә Карамалыда салырга кирәк дип тапкан икән, риза булырга кирәктер. Сорт-сынау һәм туфрак структурасын тикшерү максаты белән лабораторияләр салуны мин иген игүдәге иң җитди эшләрнең берсе дип карыйм. Басуларны фән чыганакларына нигезләнеп эшкәртү — игенчелекне культуралаштыруның бер чарасы. Һәр агрономның изге хыялы дияр идем мин моны. Басуларда туфрак структурасы биш-ун ел саен үзгәреп тора, шушы үзгәрешне белеп, аны фәнни юлга салсаң, әлеге кебек сукыр көйгә эшләү гомумән булмас иде.

— Ышандырдың. Килештек. Тик миңа тагын шуны әйт: ул лабораторияне салмасак та басуларыбыздагы туфрак составын белеп тора алыр идекме?

— Белеп була, ләкин бу дәрәҗәдә түгел. Район белән район, колхоз белән колхоз җирләре генә түгел, басу белән басу туфрагы арасында да үзгәлек бар. Ә инде туфрак структурасын тикшерү лабораториясе бу өзеклекне дә калдырмас иде. Икенче төрле итеп әйткәндә, сукыр игенчене күзле итәр иде. Җир-туфрак дигән нәрсә җанлы бит ул...

— Мин дә шулай уйлыйм, — диде председатель кулларын угалап. Әмма дөресен әйтмәде, лаборатория бинасын салу мәсьәләсендә кичә генә бөтенләй башка фикердә иде ул. — Димәк, салабыз.

Талип бер тын, оялчан кызлар кебек, башын түбән иеп утырды. Ул уйлады: инанган фикереңнән үз-үзеңне ваз кичәргә мәҗбүр итү кыен икән. Ләкин тормыш үзе шуны таләп иткәндә, үзеңнең кире фикереңне үткәрергә тырышу ахмаклык булыр иде.

— Киңәшең өчен рәхмәт, фикереңне идарә членнарына житкерергә тырышырмын...

Мидхәт шуңа игътибар итте, председатель аның белән «син» дип сөйләшә башлады.

— Иң мөһиме безнең эштә, Мидхәт, бер-береңнең киңәшенә колак салу. Мин, гомумән, яңа килгән белгечләргә зур өмет баглыйм. Чөнки аларда яңаны тою була. Шул ук вакытта ул практик кеше булырга, ниндидер тузга язмаган хыяллар белән эш кешеләренең башын катырмаска тиештер, минемчә. Шулаймы, юкмы? — Мидхәт аның белән килешеп ияк какты. — Шулай. Сиңа кадәр эшләгән агроном белән эшли алмадык. Китүенең сәбәбен сөйләп тормыйм. Килешмәдек и баста. Максатлар бер, ә карашлар башка иде. Колхоз белгечләре арасында агроном бездә почетта. Үзеңә бер ат, кирәк дип табасың икән, мотоцикл бирербез. Ярдәмче ышандырмыйм. Читтән торып авыл хуҗалыгы техникумында бер кызыбыз укый укуын, әмма ул яшь әле. Галләм абзый әйтмешли, авызында ана сөте кипмәгән. Озын сүзнең кыскасы, кабул итеп ал эшне. Хезмәт хакы бездә акчалата, завод инженерларыннан ким алмассың, артыграк та булыр... Үзең соң өйләнгәнме әле, семья бармы?

— Өлгермәдем әле, Талип Кәрамович.

— Өлгерерсең. Кача торган хәл түгел ул. Кызлар бездә ерып йөргесез, балсыз кабып йотардайлары бар.

Мидхәт көлемсерәп түбән карагач, Талип, ирен чите белән генә елмаеп, куе төк баскан кул аркасын ышкыштырып торды.

— Ә ул агроном кызыгыз кайчан кайтачак?

— Бүген-иртәгә кайтып төшәр. Галләм абзый кичә үк көтә иде инде үзен. Күрерсең, үзләрендә торасың...

...Тамчы кич соң гына кайтты. Мидхәт яткан иде инде. Ул барысын да ишетеп торды. Галләм абзый белән Тәгъзимә апа аталы-аналы, урамда машина тавышы ишетүгә, каударланып кызларын каршы алырга куптылар. Тышта суык дип, Галләм карт карчыгына чыкмаска кушты, ә үзе дөбер-шатыр килеп ишегалдына ашыкты.

Мидхәт аңлый иде: кызларының кайтуына ата-ана гаять шат, куаныпмы-куаналар. Әни кешенең күзләре дә яшьләнеп алды бугай — егет моны аның пошык-пошык борын тартуыннан ук сизде.

Табын янына утырыштылар. Тамчы Мидхәтнең чөйдәге плащын күреп, әти-әнисенә сораулы караш ташлады, күрәсең, — картларның икесе беравыздан акланырга керештеләр.

— Талип абыең үзе китергәч яхшысынмадык инде, кызым, — дип башлаган иде Тәгъзимә карчык, калганын Мидхәт ишетмәде, кайсыдыр килеп ишекне япты.

## 3

— Иптәшләр, көттерәсез, сезгә кадерле булган вакыт миңа да кадерле,— дип каршы алды райком секретаре Хөснетдинов «Берек» колхозы председателе Талип Бикмуллин белән партком секретаре Әдһәм Харисовны.

Кул бирешеп күрештеләр. Утырыштылар. Хөснетдинов елан тиресенә охшаган кара-чуар галстугын бушатып, күлмәк сәдәфен ычкындырды. Секретарь нигәдер эсселәгән: җыерчыклы маңгаена бөрчек-бөрчек тир чыккан иде.

— Сөйли башла, Талип. Лаборатория бинасы ни хәлдә, кайчан төгәллисез?

— Төгәлләнеп килә инде ул...

— Төгәлләнеп кенә киләме, төгәлләнәме?

— Әллә соң район оештырган комиссия кабул итәргә тиешме ул бинаны?

Хөснетдинов шакмаклы кулъяулыгы белән битен-муенын сөртеп алды һәм Харисовка таба борыла төшеп:

— Мин аңламыйм, Әдһәм, нигә Талип бу бинаны теләп төземәде? Сәбәбе нәрсә? Чынлап та финанс ягы хөртме әллә? — дип, конкретрак төпченергә кереште.

Беренче секретарь Әдһәм Харисов белән «син» дип сөйләшә. Үзе китереп куйгангамы, Талипны да якын күрә иде. Кирәк тапса, ул аны кыздырып алырга да күп сорамый. Харисов моңа күнеккән, Талип Бикмуллинны Хөснетдинов бастырып орышса да, соңгы чиктә ул аңа начарлык эшләмәвен белә, шуңамы Талипны яклау һәм якламау мәсьәләсендә үзе дә аңлап бетермәгән уңайсыз бер хәлдә кала торган иде. Менә ничәмә-ничә ел инде бергә эшләп, Талипны да һаман аңлап бетерә алмый ул. Холкы-фигыле белән артык кайнар да түгел кебек, ә менә бер киреләнеп китсә, үзенекен итә дә тора. Ә кайчак тәмам әтисе урынына күреп, киңәшә, исәпләшә иде.

— Лаборатория төгәлләнер, Ирек Нәҗмиевич, Бикмуллин аны эшләр. Җитәр кебек инде бабайлар тәҗрибәсенә генә таянып эшләү. Ниһаять, безгә дә җирләребезнең эчке серләрен өйрәнергә вакыттыр. Фәнни нигездә җир-туфракны культуралаштыру — чор, заман таләбе, без генә бу яңалыктан йөз чөерә алмабыз, әлбәттә...

Харисов, үз тавышын үзе тыңлап, ашыкмыйча гына сөйләде. Эшләү дәверендә ул бик күп райком секретарьларын күрде. Аларның беришесе бугаз белән алдырырга тырыша иде — ул чорны да кичерде Харисов. Икенче берәүләре йомшак җаеп катыга утыртырга һәвәс иде. Акыл сатып, фәлсәфә белән йөдәтүчеләрне дә, бөтен урам-тыкрыкларны өндәү һәм чакырулар, лозунглар белән тутырып, райком эшен шунда күреп мавыгуларны да күрергә туры килде аңа. Ә менә күп еллар өлкә комитетында эшләп тә, әллә үзе теләп, әллә кем тарафыннандыр тәкъдим ителеп, бирегә килгән, чыгышы белән Наратбаштан булган Хөснетдиновны һич аңлый алмый «Берек» колхозы коммунистларының башлыгы. Хөснетдинов һич кенә тузынмас, итагатьле кыланыр. Мөнәсәбәт — гап-гади, дусларча. Әмма бер канын кыздырсалар, нык итеп, каты итеп сугар. Бәхәскә җиңел керә, каршы әйткәнне яратып бетерми, мәгәр чик-чаманы белә: «Бу бәхәсне әлегә калдырып торыйк»,— дип, әңгәмәдәшен тизрәк озатып куюны карый.

— Я, Талип, син ни белән дәлилли аласың бу пошмаучанлыгыңны?

— Безгә ул лабораториянең һич тә хаҗәте юк иде, Ирек Нәҗмиевич. Сез кушкач, каршы килмәгән булдык инде. Колхоз әнә бер шуңа гына ничәмә мең сум чыгым тотты. Плансыз кергән шул бина аркасында исәпкә куелган комплекс токтарланды, дүрт торак йорт төзелмәде. Кыскасы, күчәр башын сындырды ул лаборатория безнең, — Талип башын аска иеп, беравык сүзсез утырды. — Бездә, Ирек Нәҗмиевич, югары белемле агроном да бар бит. Туфрак серләрен, минемчә, ул да начар белми. Биш ел буе дәүләт әпәен ашап, шуңа укыган кеше.

— Агроном дигәннән, ни булды тагын аның белән синең арада? Тагын тынышмыйсызмы?.. Бер агроном ярамады, инде бусы белән дә килешмисеңме?

— Һәр җитәкченең үз эш стиле бар, Ирек Нәҗмиевич. Ошатмыйсез икән минем эшне, алыгыз. Мәгәр пока мин председатель...

Талипның кыска бармаклары йодрыкка йомарланды. Хөснетдинов торды да аның янынарак килде.

— Синең ул егетең бер дә күчәр башы сындырырга җыенмый кебек. Килде ул бирегә, сөйләштек без аның белән.

Секретарь сөйли, Талипны үгетли, үзе Харисовка караштыргалап

ала. Менә Хөснетдиновның маңгаена җыерчыклар чыкты, кашы дугаланып китте һәм ул, чит бер кешегә әйткән кебек, почмакка карап:

— Садыйковтагы яңалыкларны кабул итмисең икән, бигайбә, Талип, — диде. — Ләкин мин сиңа консерватор булырга юл куймам. Яңалык юл ярганда башың чөеп читкә тайпылма! Чоры, заманы ул түгел! Институт кадәр институт галим кадәр галимне дүрт мең гектар сөрү җире булган колхозга җибәрә икән, моңа шатланырга кирәк. Ә син, ишетүемчә, договорга кул куймый маташкансың. Хакмы шул, Әдһәм? — дип, партком секретарена күз төшереп алды Хөснетдинов.

Харисов килешеп баш какты.

— Мәшәкать өстенә мәшәкать. Мин ул мәсьәләдә Садыйковтан да туйган идем инде, — диде Талип тора башлап, ләкин тормады, кире утырды, киерелгәндәй итеп аркасын урындыкка терәде.— Нигә соң ул лабораторияне Садыйков үзендә салмады? Белә шул ул...

— Вакланма, Талип, вакланма, зинһар. Дан өчен эшләмәсәң, һич югы, сан өчен эшлә.

Талипның җәйпәк йөзенә кызыллык йөгерде, киң маңгаен ярып, буй җыерчык сузылды.

— Туфрак банитетлары бер булса да, Садыйковның танавына чирттек бит әле. Бөртеклеләрдән гектарына егерме биш центнер һәм кайбер кырлардан утызарны суктырып алдык, ә мактаулы Садыйков егермегә дә җиткерә алмады.

— Онытма, Талип, азмы-күпме ул «Берек»тә эшләп китте.

— Агроном халкын эзләп торасы юк хәзер. Садыйков китте, икенчесе килде, ул да әнә шул ук хыяллар белән саташа. Моның да басуларны яңача бүләргә исәбе. Шуңа проект әмәлләп ята. Каршы килмәдем, әйдә эшләсен, идарә утырышында тыңлап карарбыз. Күрәсез, Ирек Нәҗмиевич, мин яңалыкка каршы түгел. Әмма да бер «ләкин» бар. Үзкыйммәт! Садыйковта бер центнер икмәк җитмеш тиенгә төшә, бездә ул илле биш тиен генә булды. Әйтер сүзем шул: галим кадәр галим килмәсә дә өйрәтүчеләрдән, белдеклеләрдән тук мин, Ирек Нәҗмиевич. Уңышның нигезе туфракны эшкәртүдә һәм вакытында тиешле ашлама салуда.

— Галим дигәнең сезнең якташыгыз түгелме соң әле?

— Булмагае!

Талип бу сүзне әйтүгә, Харисов куырылып алды. Атасы кебек райком секретаре белән Талипның дорфа сөйләшүе бер хәл, алар еш кына шулай әйтешеп алалар. Ә менә Талипның бирегә килгән галим турында эре сөйләшүен ничек аңларга?

— Әдһәм, син беләсеңме Карамалыга кем килгәнен?

— Әюп абзый малаемы? Аны шул өлкәдә эшли дип әйткәннәр иде.

— Үзе, — диде Хөснетдинов.

Талип әле Хөснетдиновка, әле Харисовка карап-карап алды. Харисовның балаларча куанып китүе аңа сәер тоелды. Хөснетдиновның да елмаюын аңламады ул. Күп вакытта Хөснетдинов сүзеннән чыгарга базмый йөргән Талипның бүген бу ике секретарь белән ачуланышасы килә һәм ул усалрак сүзләр эзли кебек иде.

Талипкамы соң Харисовны аңлау! Авылга киләсе галимнең исемен белмәмешкә салышуы, Харисов өчен шундый кадерле булган кешенең улы турында сөйләгәндә председательнең авыз бүлтәйтеп утыруы тәмам ачуын чыгарды аның.

— Талип, син төзелеш базасы оештыруга да каршы идең түгелме әле? Аннары башта диспетчерлык оештыруны да биш куллап кабул итмәдең. Бөтен нәрсәне акчага бәйләү, шуңа гына кайтарып калдыру бер дә бизәми сине, Талип. — Харисов куш йодрыгын өстәлгә куйды. Талипка таба борыла төште. — Бу мәсьәләдә мин үлгәнче үз фикеремдә калачакмын...

— Бик әйбәт, кала бирегез. Минем сезгә үз фикеремне көчләп тагарга җыенганым да юк.

— Ун ел тартасың колхоз йөген, Талип, — диде Хөснетдинов тыныч кына. — Артта сөйрәлгән колхозны алдынгылар рәтенә чыгардың. Районда беренче булып комплекс төзергә керештең. Рәхмәт. Мәгәр, туганкаем, узынма. Соңгы вакытта халыкка игътибарсызлык күрсәтәсең, дорфа сөйләшәсең. Үз-үзеңне тыя белергә кирәк. Өстәл сугуны, эштән кууны нәрсә дип беләсең син! Шулмы эш стиле?! Синең кебек җитәкчедән күп нәрсә таләп ителә хәзер!..

Харисовның уң яңагы тартыша башлавын күреп, Талип аны кызганып куйды. Ул Хөснетдиновны тыңлады, үзе Харисовка карап утырды. Бәхәс кызган саен партком секретареның бит-муены кызара бара, сул як яңагы тартышып-тартышып китә иде.

— Ярый, Талип, бар кайт инде,— диде Хөснетдинов, бу хәлне күреп.— Ләкин ишет аны, тәртипле бул. Агроном егет белән дә булышма. Аннары Гайзулла җизнәңне тый әле бераз. Бер төркем картлар мәчет салырга рөхсәт сорап гариза китергәннәр. Кем оештырган эш дип беләсең син аны? Гайзулла үзе яисә хатыны бит?..

Хөснетдинов өстәл аша гына Талипка кул сузды. Талип теләр-теләмәс кенә күтәрелде, ниндидер бер уңайсызлану тоеп, ишеккә таба атлады. Шунда житкәч, ул кулын тоткага салды, туктады, башын игән килеш идәнгә карап торды, аннары алар арасында киеренкелек булмаган да кебек:

— Әдһәм абый, минем монда бераз эшем бар, кайтуга Фәритне кире җибәр, сәгать алтыдан да калмасын, — диде.

## 4

Түбә чүпрәге уңып-агарып беткән газик калкулыкка күтәрелүгә, Чәчәганак тавы күренде. Ул арада машина тау сыртына да җитте һәм шунда туктап калды. Кабинадан өстенә тун, башына бәрән тиресеннән теккән бүрек кигән бер кеше төште дә кырга тирес-черемә ташыган трактор эзеннән тау сыртына таба атлады.

Тау буйлап бер ара килгәч, ул туктап калды, күзенә төшереп кигән бүреген күтәреп куйды, тирә-юньгә күз ташлады. Аста, иңкүлектә, Карамалы авылы. Авыл ай урагы сыман дугаланып аккан елга буена утырган. Базарлы авыл, исеме еракка таралган зур авыл. Мең йортка якын хуҗалыгы булган. Карт-корысы, бала-чагасы белән өч-дүрт меңнән артык кеше яши иде Карамалыда. Хәзер бераз кимеде кимүен. Төзелешләргә китә халык, нефтькә генә дә иллеләп семья китте.

Кайчандыр менә моннан, әлеге юлчы басып торган төштән, олы сырт юл үткән. Колхоз оешкач, юлны сөреп ташлап түбәннәнрәк салдылар. Сырт юл, борынгы юл, авыл тарихына исеме белән генә кереп калды. Кемнәрнең генә эзләре калмаган ул юлда. Бервакыт үз укчылары, тупчылары, атлы казаклары белән Емельян Пугачев Казан ягына юнәлгән. Әби патша — Екатерина — Казаннан Оренбургка шул юлдан барган. Николай патша заманында революционерларны шушы юлдан Себергә сөргәннәр. Гражданнар сугышы елларында бервакыт аклар белән кызыллар арасында ике атнага якын канлы сугыш булган. Кызыллар акларны башкорт ягына таба куып киткәч, Карамалы халкы атна буена мәет күмде. Таз тау итәгендә туганнар кабере калкып чыкты. Әдһәм боларны үз күзе белән күрде, мәетләрне үзе дә күмеште. Тиз генә онытарлык хәлләрме! Малай-салай әле булса тау итәгеннән шартламый калган гранаталар, сабы череп беткән мылтыклар, тутыккан штыкклычлар, буш гильзалар, патроннар таба.

Шушы үк сырт юлда, ирен югалткач, шул кайгысы өстенә йорт-ка-

ралтысыз да калгач, беренче яше яңа тулып килгән баласын күтәреп, Гөлзифа Латыйпова Казанга абыйсы янына киткән.

Гомер, гомер. Хәзер әнә шул бала галим дәрәҗәсенә җитеп Карамалыга кайта, ди. Ничек моңа куанмаска кирәк! Ә Талип Бикмуллин аны бөтенләй белмәмешкә сабыша. Әюп Латыйповка күптән музей ачарга кирәк иде инде Карамалыда, яисә һәйкәл куярга. Шул уй белән дәртләнеп йөргәндә һаман да шул Талип Бикмуллин туктатты түгелме соң әле? Имеш, колхоз акчасын әрәм-шәрәм итәргә җай эзләп кенә йөрмәгез әле, Әдһәм абый. Сиңа ул шулайдыр да бит, ә мин менә алай уйламыйм. Кадерле кеше миңа Әюп Латыйпов. Бик кадерле кеше. Ул миңа киләчәккә юл күрсәтте, күземне ачты. Сиңамы соң моны аңларга, Талип!

Уй йомгагы өзелеп китте. Көнбатыш якта батып барган кояшка таба кара-кучкыл болытлар агыла. Харисов аяк астындагы туң черемәгә итеге белән тибеп алды. Көн кояшлы булса да, черемә яңа эри башлаган, кояшка караган якта көмеш төсенә кереп көпшәкләнгән боз ялтырый иде. Кисәк кенә җил чыкты, Таз таудагы агач вышка ыңгырашып куйды. Харисов бу вышканың кем тарафыннан һәм ни өчен куелганын белми, ул исәя башлаганда ук бу вышка Таз тау түбәсендә утыра иде инде. Минһаҗ бабай сөйләвенә ышансак, бу вышка яу килгәнне күзәтү өчен бабаларыбыз тарафыннан куелган, имеш. Чөнки бередән ерак түгел башкорт ягындагы Кушкаран тавында да шундый ук вышка утыра. Малай чакта Әдһәмнең шул вышкага менеп караганы бар. Анда менсәң, Чатыр тавын күрәсең. Ә Чатыр тавы итәгендә Емельян Пугачев туктап ял иткән. Тау астыннан тибеп чыккан чишмә янына мунча салдырган. Йөзләрчә ел үтүгә карамастан, мунчаның нигезе әле дә булса исән, диләр.

Хәзер инде вышкалар черегән, җилле көннәрне бу тарих шаһитләре шыгыр-шогыр килеп ыңгырашалар, гүя бабайлар тарихын сөйлиләр. Таз тау түбәсендәге вышканың колач җитмәстәй баганаларын алырга, гомумән, вышканы сүтәргә батырчылык итүче юк.

Җил тагы да көчәя төште, Харисовның тун чабуын йолыккаларга кереште, салкын теле белән бит-йөзне ялмап алды.

Харисов машина янына килгәндә кояш баешы ягын кара куе болыт каплаган, һавада кар бөртекләре оча башлаган иде. Ул машинага утырды. Шофер Фәрит башын рульгә салган да черем итә. «Ял тими егеткә, Талипка тарсаң шул инде, үзе дә рәтләп йокламый, бу бахырга да тынгы бирми. Әле тагын бер юлны ике итеп райүзәктә калган булды», — дип уйлады Харисов, шофер егетне чынлап торып кызганып.

Кузгалып киттеләр.

— Акрынрак кайт, буран чыгып тора, юлдан язып куюың бар.

— Бу юлны күз йомып та беләм мин, Әдһәм абыкаем. Ике арага килəп сара-сара өченче машина туздырам инде.

Харисов дәшмәде. Бу чынлап та шулай. «Москвич» алганнар иде, бер ел да йөрмәде — шырпы кабы кебек таралды да бетте, икенчесе дә шул ук марка булды, ул да тузды. Аннары менә газик алдылар. Монысы йөри әле, чыдый.

— Сулгарак тот. Юл сулдарак түгелме соң? Бу тирәдә силос базлары бар.

Бик тиз эңгер инде, котырынып буранлый башлады. Фәрит утларын кабызды. Шундук тәрәзә алдына кар пәрдәсе эленде.

— Ай-һай, тиз тотты бу! Берни күрерлек түгел. Ничек Талип абыеңны барып алырсың инде. Әллә бармыйсыңмы?

— Таш яуса да барам, — диде Фәрит.

— Сак йөре. Акрын, алда кеше бар сыман!

Харисовның шулай дип әйтүе булды, машина алдында ике карачкы пәйда булды. Фәрит рульне кисәк кенә уңга алды, тормозга басты.

Юл өстендәгеләрнең калын шәл бәйләгәне машина алдында калды, бүрек колагын төшергәне шофер ягыннан кабина ишеген ачты.

— Инәйне өйгә илтеп куй әле, братишка. Тәмам күз ачарлык түгел. Изгелегеңне онытмам.

Фәрит, рөхсәт итәсезме, дигәндәй, Харисов ягына карады.

— Курыкма, түрәң атлый торыр, өе юл аша гына, — диде Кәнзел. Хәзер инде Харисов та таныды аны. Абыстай аштан кайтып килә иде, күрәсең.

— Илтеп куй, — диде Харисов, кузгала башлап. — Аннары Талип абыеңны алырга барырсың.

Машинага утырганда абыстай аңа бәрелеп китте, һәм Харисов аның йөзендә мыскыллы бер елмаю күреп калды.

«Усаллык бу абыстайда! Нишлисең, мин — аның фикер дошманы. Мин — коммунист, халыкка коммунизм идеяләре җиткерәм, ә ул дин белән халык аңын томаларга тырыша. Икебез бер юлда булсак та, юнәлешләребез капма-каршы. Бер генә уртак фикеребез дә юк. Һәм булмас та. Миңа калса, Әюп абзыйның башына җитүчеләр дә шулар токымы гына», — дип уйлады Харисов, буран эченә кереп югалган машинаның кызыл утына карап атлый-атлый.

## 5

Талип райүзәктән шактый соңгарып кайтты. Тәрәзәләрдә утлар сүнгән, багана башындагы лампочкалар гына бөтерелеп торган кар эчендә елтырап-елтырап китә иде. Фәрит аны капка төпләренә кадәр китереп куйды.

— Талип абый, иртәгә мин чыга алмыйм, двигательне карыйм, — диде Фәрит инде машинадан төшә башлаган Талипка.

— Карый бир. Мин иртәгә идарәдән ары чыкмыйм.

Өйгә ул гаепле бер тойгы белән кайтып керде. Борынына тәмле аш исе бәрелсә дә, ут алмады, акрын гына чишенде дә ялан аяк кына түр өйгә юнәлде, мыштым гына ятты һәм, башы мендәргә тиюгә, йоклап та китте.

Иртән ул гадәттәгечә иртә уянды, сыңар күзен генә ачып, стена сәгатенә карап алды. Сәгать алтынчыга киткән иде. Ләкин йокы туймаган, авыр баш оеп, тагын мендәргә түнәргә тора. Күзләрен йомды. Шундук кичәге хәле күз алдына килде. Кичә райкомнан чыккач туры Миннисаларга баруын, сәгать төнге икегә кадәр аның янында юануын хәтерләде. Ләкин аның бу турыда уйлыйсы килмәде. Күкрәк түрендә гүя авыр кургаш утыра. Их, нигә, нигә бәйләнде соң әле ул аның белән?.. Беравык, күзләрен ачмыйча, күз алдында биешкән көмеш тәңкәләрне тоеп, туасы көндәге эшләре турында уйланып ятты. Тамчыны лабораториягә урнаштырасы булыр. Өйрәнә торсын. Казан белгечләре киткәч, бәлкем үзен шунда ук калдырырмын... Бүген киләсе инженерны Мәрхәбә апага урнаштырырга кирәк. Өе зур, бер ялгызы тора, аш-суга һәвәс... Кар тотуны дәвам итәргә... Ашлама кайтаруны язга калдырырга. Складлар юк...

Талип торып утырды, салкын идәнгә ялан аяк кына басып, өй эченә күз йөртеп чыкты. Аңа өйдә берәү дә юк сыман тоелды. Шуңамы, гаҗизләнеп хатынына дәште:

— Кәфия!..

Шылт иткән тавыш та ишетелмәгәч, алгы якка чыкты, ишек төбендәге чүәкләр арасыннан аягына туры килгәнен элде дә киерелә-сузыла мич каршына үтте.

— Әнисе, син дим!..

Шунда аның кылт итеп исенә төште: Кәфия «син» дигәнне яратмый, авыл картлары кебек кыланмасана, дип тиктомалга орышып ташлый иде. «Кәфиясе больницададыр, Миңлекамалттәй кая икән соң?»

Миңлекамал карчык — аның чыбык очы кардәше. Кайчандыр Себергә куылган булганнар. Сугыштан соң картын шул якларда җирләп, үзе туган якларына кайтты. Талип аны кызы Җәүһәрияне карарга дип үзләренә алып килде. Җәүһәрияне Миңлекамал әбисе үстерде дияргә була.

— Миңлекамалттәй! Соң бу өйдә бер җан иясе дә юкмыни, ходайның хикмәте?!

Алгы өйдә дә, ишегалдында да тавыш-фәлән ишетелмәгәч, Талип мич алдындагы кече тәрәзәдән күршеләр ишегалдына күз салды. Ишегалдында күз камашырлык ап-ак кар. Кояш чыгып килә. Абзар ягында сузып-сузып сыер мөгри. Кая соң болар? Абзарга маллар карарга чыкканнар дияр идең, сыер асрамыйлар, сыерларны колхозларга җыю шаукымы вакытында, колхозчыларга үрнәк күрсәтәм дип, Талип башта үзе илтеп бирде. Тик аны анламадылар. Өч-дүрт кеше сыерларын китергән булды, ләкин алар да соңыннан шундук тана сатып алдылар. Талип хәтта аны да эшләмәде. Харисов партком секретаре булуга карамастан: «Минем карчык жылы сөтсез яши алмый, үзем дә яңа сауган сөт яратам»,— дип, сыерын тапшырудан баш тартты. Партком секретареның бу үрнәге кайбер икеләнеп торучы колхозчыларга житә калды. Әйбәт «инициативасы» өчен Харисовка райком бюросына чакырып шелтә чәпәделәр. Харисов исә шелтә кәгазен чүлмәк астына кыстырып, буы чыгып торган сөтне эчә бирә, ә Талип һәр көн диярлек фермадан сөт сатып ала.

Талип, бил тиңентен чишенгән килеш, ах-ух итеп салкын су белән юынды да өстәлдәге бидонда сөт күреп, күмәч кисеп алды һәм сөт белән ипи ашарга кереште.

Мараты Марат инде, аның китүенә биш ел тулып килә, кызлары Җәүһәрия киткәч, тәмам узынды бу Кәфия. Өйдә бөтенләй тәртип бетте. Миңлекамалттәйнең дә биләмнән башы кайтмый. Тфу, председатель башың белән, кармак салырга ашыккан малай-салай кебек, ипи белән сөт ашап утыр инде. Бүген үзенә әйтәсе булыр, больницасына китә икән, һич югы, Миңлекамалттәйне биләмгә җибәрмәсен.

Шулай дип уйлады, ләкин теләгән нығытырдай һичнинди дәлил таба алмады. Кичә соңга калып кайтуы, райүзәктә Миннисага янына баруы исенә төштеме, моңа кадәр булмаган бер оялу тойды.

Буран инде басылган, койма-ихата буйларына сыртлап-сыртлап көрт салган. Кояш чыгышы ягында аксыл-зәңгәр һавада, нур өстенә нур өстәп, алтын-көмеш җепләр сузылган.

Талип зират тыкрыгына борылды һәм үзенә таба килүчене күреп, чак кына кире чигенмәде. Тыкрыкны бер итеп, тун кесәләренә кулын тыккан килеш, көлә-елмая Кәнзел энесе килә иде. Нигәдер нәкъ менә шул минутта Талипның исенә Хөснетдинов әйткән сүзләр төште.

Кәнзел шактый буйчан гәүдәле, ябык чырайлы, бүлтәеп торган зур авызлы бер кеше иде. Талип абыйсы белән ул үзен үтә әрсез тота. Талип «тырышлыгы» белән төрмәгә эләгеп, аннан исән-имин әйләнеп кайткач, Кәнзел аның белән тагы да дорфарак сөйләшә башлады. Әлбәттә, туганы Кәнзел аның бу изгелеген онытмый иде, жай килгән саен исенә төшерә, ә инде салып алса, бөтенләй күзе-башы тона, Талипка бәйләнә.

— Син генә утырттың мине, туганый, ишет, мин синнән үч алачакмын әле,— дип шапырына.

Әнә шуңа күрә күзенә Кәнзел чалынса, Талипның колак төбендә шул сүзләр яңгырый башлый. Талип, әлбәттә, Кәнзелне йолып алып

калган да булыр иде, әмма алай итмәде, вөҗданы кушмады. Кәнзел, төрмәдән кайту белән, Талип янына килде, эш сорады. Талип аны тегермәнгә җибәрде. Кәнзел ирекtәге эшкә хирысланып кайткан иде, күрәсең, бик теләп эшкә керешә. Тегермәнче үлгәннән соң җүнләп эшләмәгән су тегермәнен менә дигән итеп ремонтлап җибәрде, фураж тартырга көйләде. Савым сыерларга бу бик ярап куйды.

— Сәлам түрәгә!..

— Сәлам, сәлам, Кәнзел. Ни эш бетереп йөрү?

— Эш беткән, өйләнергә исәп әле тагын бер. Бәлкем монысыннан уңармын. Туйга килерсең бит, абзый кеше? — Кәнзел күз төпләрен җыерчыкландырып, авызын кыйшайтып елмаеп куйды.— Кичә җиңгәчәйнең туган көне түгел идеме? Ә син, ишеттем, райүзәктәге кәнтәең янында төн үткәргәнсең икән. Җиңгәчәй төнге сәгать уникегә хәтле көтеп утырган үзеңне. Ояла бел бераз, туганый...

Талипның башына кайнар кан йөгерде. «Карале син аны, чынлап та шулай бит! Кичә Кәфиянең туган көне иде!»

Кәнзел кулын кесәсеннән алып, куян бүреген күтәребрәк җибәрде.

— Синең кая югалганны җиңгәчәй белми дип уйлыйсыңдыр инде?

«Моннан да явыз, әшәке адәмне көндез чыра яндырып та таба алмассың»,— дип уйлады Талип һәм кузгала башлады.

— Кемнең кем янына йөргәнне тикшергәнче, әүвәл үзең турында уйлар идең. Өченчегә өйләнергә йөрисең түгелме?

— Мин синең кебек катлаулы кеше түгел, туганый, синдәй итәк астыннан ут йөртә алмадым. Кем әйтмешли, түрәләр туй итә, без су эчәбез. Ярый, эчеңнән куан: җиңгәчәй әйбәт катын, юкса, сине әллә кайчан ташлап киткән булыр иде.

— Усаллык синдә, Кәнзел. Кемнән килә бу, һич төшенә алмыйм.

— Синең мәктәбең, син укытып кайтардың, туганый. Бер дә бүтән түгел, син генә...

Кәнзел кесәсеннән сигарет чыгарды, чырт итеп зажигалкасын кабызды, көйрәтеп җибәрде. Талип туктап калган җиреннән тагын кузгала башлады, мәгәр нигәдер янә тукталды.

— Сиңа барадыр иде әле. Киңәшкә, бер очтан туйга чакырырга. Туганнар бит без, ә йөрешмибез, эреләнде берәү, — диде Кәнзел, авыз тутырып тәмәкесен суырды да Талип ягына таба өреп җибәрде.

— Җиңгәчәңнең туган көнен каян белдең?

— Миңлекамалттәй бездә кунды, шул әйтте.

— Тегермәндә тартасы ашлык күпме? — дип сорады Талип, ни әйтергә белмәүдән җаны көеп. Ачуыннан ул иреннәрен тешләштерде. Кәнзелгә әйтергә көйдерерлек усал сүз эзләде. Ләкин башына һични килмәде. Күңеленнән ул Кәнзелне бер яклады, бер эт итеп сүкте. Кәнзел аңа ачы хакыйкатьне ярып әйтә, шул сүзләргә Талипның бәгыре телгәләнә. Кәнзелдән бигрәк үз-үзенә ачуы килә иде аның. Ә бит дөресен әйтә эт ялаган нәмәстә!

— Тегермәндә ашлык тормый. Ут ясадым мин ул ташларны. Тарткан онны ташып бетерә алмыйлар. Тегермәндә минем, туганый, эшләр ал да гөл. Рәтле кыз гына табып булмый менә...

— Я, әйтәсе сүзеңне әйт, ату мин ашыгам.

Урам чатында Кәфия күренде. Хатынын күргә, Талип баскан җирендә таптанып алды, колакларына кадәр януын тоеп, көрсенеп куйды. Аның кинәт кенә каушап китүен Кәнзел дә сизми калмады.

— Юкка бимазалама үзеңне. Әйтер дип куркасыңмы әллә?! Мин әлегә чалбарлы ир-ат. Кайберәүләр кебек...

— Җитмәсме, Кәнзел! — диде аңа Талип коры гына.

Ул Кәфиянең килүен түземсезлек белән көтеп алды. Талип белә иде: Кәнзелдән теләсә нинди әшәкелек көтәргә була. Шуңа ул сорап куйды:

— Кемгә өйләнәсең, тагын кемне төшерергә исәбең?

— Көйри бәгырьләр берәүнең, көйри, әй!..
— Аның өчен син бик уфтанма, көйрәр-көйрәр дә бер сүрелер әле, туганый. Әбезне тикшермә, җингәчәңә кем янында булуым турында житкерсәң җаныңны алырмын!
— Әттә-тә-тә-тә, туганый. Бу ни инде! Бу бит янау! Карале, җингәчәй, — диде Кәнзел, Кәфиягә таба атлап. — Талип абыйны туйга чакырам, ә ул вакыт юк дип маташа.
— Исәнмесез, Кәнзел, исәнме, Талип! Инде тагын өйләнергә булдыңмыни? — диде Кәфия һәм шундук Талипка таба борылды да таләпчәнрәк рәвештә: — Син кая болай югалдың, әтисе? — дип сорады. Үз итеп, якын итеп, һичнинди шик-шөбһә тотмыйча сорады кебек. Ләкин Талип үзендә эчке бер куырылу тойды.
— Эш чыкты, — диде ул, ләкин Кәфия аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде, Кәнзелгә дәште: — Бусысы кайсы авылдан, Кәнзел?
— Наратбаштан, — диде Кәнзел өчен Талип, — иң алдынгы савымчы. Былтырларны районда беренчелекне алган иде. Менә дигән кыз.
— Кыз түгел инде ул, хатын! Ярамаган тагын безгә — каты тезгә. Зато ул менә дигән оста. Яренгә Карамалы чыгачак беренче урынга, туганый. Кәнзел энеңә рәхмәт әйтер көннәрең алда әле.
— Тагын язылышмыйча өйләнәсеңме? — дип сорады Талип, Кәнзелнең тел төбендә мәкерле мыскыл сизеп.
— Һәй, туганый, җүләрмени мин! Әйеме, җиңгәчәй? Нигә, әйтик, башта язылышмыйча берәр ел торып карамаска. Бәлкем холкыбыз килешмәс. Аннары ул үзе дә беренче ире белән аерылышмаган икән әле. Тәк што, бәйрәм ашы — кара каршы. Я, туганый, туема киләсезме инде?
— Киләбез, киләбез, Кәнзел. Тыңлама Талип абзыеңны. Ә нигә, Талип, — дип иренә күзләрен түгәрәкләндереп карады Кәфия, — бәлкем ул өенчесе белән бәхетен табар? Шулай бит, Кәнзел? — диде, янә Кәнзелгә таба борылып. — Барабыз, барабыз, Кәнзел, күңелең тыныч булсын.
— Бигайбә алай булгач, мин киттем.
— Түткәйгә сәлам әйт. Барып та чыгып булмый үзләренә. Җизнәй ни хәлдә ята?
— Пычагым булсынмы аларга?! Аштан башлары кайтмый...
Кәнзел киткәч, Кәфия Талипны култыклап алды. Ире үзалдына уфтанып куйгач, Кәфия аның күзләренә үрелебрәк карады.
— Ни булды сиңа, нигә уфтанасың?
— Кичә Хөснетдинов белән әйтештек. Әдһәм абый да аның яклы булып маташа. Икәүләп акыл саталар. Әйтерсең мин агач бүкәне, бернәрсә аңламыйм, алар гына аңлыйлар да, алар гына акыллылар.
Кәфия андый-мондый сүз башламасын өчен, Талип үзе сөйләргә тотынды. «Иренең эчендә ни көйрәгәнен белә микән, ичмасам, бу Кәфия? Сорамасаң иде, Кәфия, син шул турыда миннән. Их, сорамасаң, нинди изге һәм саф хатын булып калыр идең син минем өчен! — дип уйлады Талип, колак очларына кадәр ут кебек януын тоеп. — Ярып, күзгә бәреп әйтсә, ни әйтер ул аңа?!»
— Кара аны, Талип, бүген вакытында кайтырга тырыш. Кичә бит минем...
— Беләм, — диде Талип, йөрәгенең кысылып китүен тоеп. — Бүген вакытында кайтам. Ә хәзер кил, соң булса да колагыңнан тартыйм.
Кәфия аның күзләренә карады. Нык итеп, туры итеп карады. Талипның чыраеннан кан качты.
— Кичәге өчен гафу ит. Ышан, ул хәл яңадан кабатланмас.
— Вакытында кайт. Пилмән пешерәм бүген. Кичә үзеңне көтә-көтә ит үткәреп куйдым...

Хатыны больницага таба киткәч тә Талип уңайсызлану хисеннән арына алмады. Үзалдына оялып, ул өметсез бер кыяфәт белән ап-ак кар һәм зәңгәр һава диңгезе эчендә тулганган Кәфиянең гәүдә-сынына карап торды, аннары идарәгә таба атлый-атлый яшьлеген исенә төшерде.

Язмыш аларны тагын кавыштырыр дип кем уйлаган.

Миңниса белән алар мәктәптән үк танышлар. Тугыз-унны бер класста укыдылар, бергә Казанга бардылар. Икесе ике институтка керсәләр дә, гел бергә булдылар диярлек. Икесе дә конкурстан узгач, шатлыктан кулга-кул тотынып, атна буе кино-театрларга чаба иделәр. Университет белән финанс-экономика институты бер тын арасы юл гына, лекцияләр бетүгә, Талип Миңниса янына йөгерә, институт бинасының биек баскычлары төбендә сәгатьләр буе аның лекциядән чыгуын көтә иде.

Талип аны кайчан яратып китүен дә тәгаен белми. Алар арасында мәхәббәт булмады да кебек, ә менә бер-берсенә ияләшү, озак аерылышып торсалар, бер-берсен юксыну булды. Бәлкем бу аның беренче мәхәббәте булгандыр, яшьлеге белән генә аңламагандыр ул аны!

Дүртенче курста укыганда Талип Кәфия белән танышты һәм әйтсәң кеше ышанмастай хәлдә аңа гашыйк булды. Юк, ул гына аз, Талип Кәфиядән башка берәүне дә күрми, бәхет-шатлыгыннан җиргә басканын да тоймый кебек иде. Кая инде ул Миңниса кайгысы! Кәфия үзенең ярсу мәхәббәте белән тәмам томалады Талипнең күңелен. «Ярата белү ул — сәнгать», диләр. Әллә соң чынлап та шулаймы?» дип уйлый торган иде Талип, Кәфиянең гүзәл йөзен, үз итеп, үтә яратып елмаюын күз алдына китерде исә.

Шулай да Миңниса белән булган бер хәл истә калган. Казанның Ленин урамындагы Үзәк ЗАГС бүлегендә язылышып чыккач, инде машинага утырырга торганда аның янына чәчәк бәйләме тоткан бер кыз килде. Килде дә Талип кулына букет тоттырды. Талип башта искәрмәстән аңа:

— Рәхмәт сезгә! — диде. Ләкин кызның бөтенләй ят кеше булуын абайлап: — Кемнән? — дип сорады.

Кыз аңа туры карарга оялып башын иде, Талип ишетерлек итеп кенә:

— Иң-иң якын кешеңнән, — диде дә кырт борылып китеп барды.

Талипның йөрәге кысылып куйды. Чәчәкләрне кем җибәрүен ул йөрәге белән тойды. ЗАГС бинасы тирәсендә уралган кешеләр арасыннан күзләре белән Миңнисаны эзләде. Юк, янында Миңниса күренмәде.

Бабаларына кайтып табынга утырганнан соң да тиз генә күз алдыннан китмәде бу хәл. Күзләре өстәл уртасындагы чәчәкләргә төшкән саен Миңниса турында уйланды. Нindидер гаеп тойды ул үзендә. Әйтмәде бит, ичмасам, өйләнәм дип тә әйтмәде үзенә. Акыл җавабы йөрәк җавабы түгел шул, мизгел эчендә кайтарып булмый, Миңниса исенә төшәр хәлдә идеме ул көннәрдә...

Талип Кәфиягә өйләнүенә бер тапкыр да үкенмәде, кайта-кайта өзгәләнмәде, үртәлмәде. Кәфия белән тату яшәделәр, алма кебек ике бала үстерделәр.

Күпме еллар үткәч, күпме сулар аккач, әнә тагын яңадан табыштылар һәм әллә ничек бәйләнде шунда...

Комплекс салу белән җенләнеп йөргән чагы иде, йомышы төшеп, ниндидер документка кул куйдырырга идарәнең төзелеш бүлегенә килеп керде Талип. Бүлек начальнигы ир-зат, аның якын ук танышы иде. Талип рөхсәт-фәлән сорап тормады, ишекне киң ачып, бусагадан атлады һәм килеп керүгә баскан урынында катты да калды. Өстәл янында аның яшьлек дусты Миңниса утыра иде.

— Әйдә, түрдән үт, Талип. Нигә алай керә-керешкә үк аптырап калдың? Мине биредә күрермен дип көтмәгән идеңме әллә?

Әйе, гаҗәпләнерлек иде шул. Миңниса гәүдәгә юанаеп киткән, тавышы көрәйгән, күкрәк түреннән чыга, тулы йөзендә, күзләрендә сәер елмаю — бераз масаюмы шунда, эрелекме, белəм мин сине дигән сыман мыскыллы бер кинаяме — нинди дер эчке тәкәбберлек, горурлык күрде Талип шунда Миңнисаның елмаеп утыруында.

Миңниса урыныннан күтәрелде, беренче булып аңа кул бирде.

— Әйдә башта кул биреп күрешик!

Талип аның кулын тотты да җибәрми торды, яшьлек дустының күзләренә карады. Юк, күзләре һич ни яшерә алмый. Күз — күңел көзгесе. Шул мәлдә Талип Миңниса кулының җиңелчә калтыранып китүен, уч төбенә эләккән кош баласыдай сабырсызланып алуын тойды. Күңелдә үзе дә көтмәгән гаҗәп бер хис кымырҗып куйды. Талип аның кулын ныграк кысты, шуңа Миңнисаның бит очлары алсуланып китте. Килеш-килбәте белән күпне күргәннәргә охшаса да, Миңнисаның болай кызарынып китүен ул ни дип юрарга да белмәде.

Утырыштылар. Сөйләшеп киттеләр.

Шушы еллар эчендә Миңниса кияүгә чыккан, әмма тора алмаганнар. Аерылышканнар һәм менә Миңниса Галимуллина, Ниса Хәйдәровна Куклина булып, туган якларына кайткан.

...Зур урамны бер итеп, юл ярып бульдозер килә. Аның көчле гөрелтесе кышкы һаваны тетрәтә, тавыш колак түрендә эленеп тора. Төнге буран сырлап-сырынтылап салган көрт өстендә купшы саесканнар йөренә. Ихатага кунган ала карга тәкәббер башын әле бер якка, әле икенче якка боргалап күзәтә.

... Таз тау итәгендәге кырда ике трактор кар тота. «Иртәләгәннәр егетләр, молодцыйлар. Агроном эшне коры тота», — дип уйлады Талип, шул минутта Мидхәтне исенә төшереп.

Талип болай агрономның эшеннән канәгать иде. Менә өч-дүрт ел инде җәйләр я бик эссе килә, я тоташ яңгырлар белән җәфалый. Җәй үтә коры килгәндә басуларда тиешле дым саклап калу — киләсе елның уңышы дияргә була. Ләкин ул агроном турында бөтенләй икенче яктан уйлый түгелме? Нигә әле «Берек» колхозына гына кире беткән бу агрономнар туры килә соң?!

Иң әүвәл Талип әнә шуңа төшенә алмый иде.

## 6

Баш очында гына тургай талпына. Аның җыры зәңгәр һавада яңгырап тора-тора да, чылтыр-чылтыр аккан чишмә шикелле, кояш нурларына изрәп яткан кыр өстенә коела, гөрләвекләр тавышына кушылып, сине хиссияткә күмә, моңа кадәр йоклап яткан күңел кылларыңны тибрәтә.

Таз тау түбәсе шәрәләнеп калган. Инде ничәмә-ничә еллар каршы ала ул шундый тыныч язларны. Ала-тилә булып торган басулар өстеннән күзгә күренер-күренмәс бу күтәрелә. Урман буена нинди дер дәһшәтле җанварга охшап кар сырынтысы сузылып яткан. Борынга язгы дымлы туфрак исе килеп бәрелә. Буй урман агачларында каргалар кайнаша — кызып-тузып оя ясыйлар. Мәрхәмәтле, игелекле яз барысын да уяткан, һәммәсенә эш тапкан.

Гариф, Чәчәганак чокырына батып калган райком газигына әйләнеп карый-карый, Карамалыга таба атлый. Кичә район үзәгенә килеп төшкәч, соң дип кунып калган иде. Ялгышкан булып чыга. Яз ашыга.

Юл әнә өзелеп тә куйган. Трактор алырга киткән шофер озаклагач, Гариф авыл ягына таба җәяү атлый торырга булды.

Әллә ниткән күңел җилкенүе тоя Гариф. Күңел түреннән яшьлек хатирәләре калкып чыга, моңа кадәр тыныч кына типкән йөрәк каядыр, ни өмет итептер ашкына башлый. Ләкин ул үз гомеренә туры килгән бар язны да авылда үткәрә алмады. Аларның күбесе, сизелмикүренми генә, Казан шәһәренең асфальт җәйгән такыр урамнарында үтте. Шәһәр язы белән авыл язын, басу язын ничек чагыштырмак кирәк! Шәһәрдәге асфальт исеннән генә дә борыныңны тотар дәрәҗәгә житәсең, чак кына әчкелтем, чак кына төчерәк тә сыман туфрак исен сулаган саен сулыйсы килә — кошлар тавышы, шарлавыклар шавы, гөрләвекләр челтерәве! Ул гынамы, Гариф бүген туган авылына кайта, шул авылның басу юлыннан атлый. Моңа кадәр аңа бер тапкыр да Карамалыга кайтырга туры килмәде. Нишләмәк кирәк, җае чыкмады. Әнисе кайткалады, ә ул юк. Кызы Әдилә дә кайтмады кебек. Хәер, Әдиләгә ни, монда туганмы да монда үскәнме дигәндәй. Карамалы шактый зур авыл икән. Кояш баешы ягында яңа өйләр күренә. Шул тирәдә үк дәү-дәү биналар — мәктәп-клублар булса кирәк. Арырак, ындыр артында — производство биналары, тегермән, үзәк урамның түбән очы су буендагы урманга барып төртелгән. Урман Наратбаш авылы чигенә җиткән дә, кырт уелып, әрәмәгә әверелгән.

Нәкъ менә шунда, Наратбаш авылы белән Карамалы чигендә — Чәчәганак чокыры һәм батып калган газик. Тау өстеннән чана җиккән бер атлы төшеп килә иде. Гариф туктады. Арбага иртә, чанага инде соң булган бу көндә нинди адәм тәвәккәлләп юлга чыккан икән? Чәчәганак чокырын ничек үтәр? Гариф кызыксынып атның чокырга төшүен көтеп торды. Чанада ике кеше икән. Ләкин ат шәп булдымы — чокырны тиз чыкты. Гариф кузгалмады, аттагыларны көтеп алырга булды. Гариф янына житәрәк чанадан берәү төшеп калды да җәяүләп китте. Гариф борын тишекләре киңәйгән атны һәм бүрек колакларын бәйләмичә күтәреп куйган ат тотучыны ияк кагып кына исәнләшеп үткәреп җибәрде. Чана артыннан килүче кеше хатын-кыз булып чыкты. Аның башында ак калфак, өстендә ак якалы, чия төсендәге пальто, аякларында — резин итек.

Хатын, килеп житәр-житмәс, күзләрен күтәреп Гарифка карады. Гарифның йөрәге мерт итеп китте. Бик якын кешесенә охшатты ул бу хатынны.

— Исәнмесез! Көттереп киләсез. Әдһәм абый сезне кичтән үк көтә иде инде.

— Исәнмесез, саумысыз!

Бу хатынның үзе белән артык ачылып китеп сөйләшә башлавы бераз сәеррәк тоелса да, Гариф аның адымына тигезләшеп атлап китте.

— Гафу итегез...

— Сезне белүемә аптырый калдыгыз? Шулаймы, Гариф Әюпович?.. — Гарифка: «Шулайрак шул», дип ияк кагудан башка әмәл калмады. — Карамалыга беренче тапкыр килеп төшкәч, мине дә шулай шаккатырганнар иде, гайбәтләремә кадәр белеп торганнар, — диде хатын.

Сәер, күңел түрендә матур хисләр, язмы шулай тәэсир итә.

Саниясе белән танышулары күз алдына килә Гарифның. Күз алдында тулганган рәшә сыман язгы дымлы һавада Саниясе пәйда була: көләч йөзле, бераз хәйләкәррәк кыланышлы, зифа буйлы... Ягымлы тавыш... Гүя ул җиргә иңгән дә аңа таба йөгерә. Бөтен хәрәкәтендә нәфислек, гүзәллек, тик нигәдер Гариф янына гына килеп житә алмый. Буй-сынына сыланып торган аксыл-зәңгәр күлмәгенең озын, киң итәкләре аякларына урала. Сания урман буендагы кар көртенә житүгә егыла... һәм кинәт юкка чыга. Ниндидер мизгелдә Гарифка

моңсу, бик моңсу булып китә. Саниясе сурәтенә кергән алиһә юкка чыккач, Гариф сискәнеп куйды. Нәрсә бу, галлюцинацияме әллә?

Гариф янәшәсендә атлаган хатынга карады һәм, аңарда Саниясендәге таныш чалымнар күреп, аптырый калды. Текәлебрәк карады. Ләкин инде ул кадәр охшашлык күрмәде. Юк, әлбәттә, кеше кешегә түгел, йолдыз йолдызга да охшамый, бу охшату язгы ямансу хисләрдән туган алдавыч сурәт кенә. Әлеге хатынга кырык яшьләр булыр. Күз тепләрендә инде вак-вак җыерчыклар, һавадан аермастай зәңгәр күзләрендә сине үзенә җәлеп иткән серле тылсым бар. Атлаган саен пальто чабулары ачылып китә һәм ак халат итәкләре күренеп ала, йомры тез башлары күзгә чалына.

Хатын, керфекләрен еш-еш каккалап, Гарифка караштыргалап барды. Калфагы астыннан чыккан чәч бөдрәләрен төзәштергәләп куйды.

— Семьягыз да килә дигәннәр иде, Гариф Әюпович, үзегез генә килергә булдыгыз, күрәсең.

Сүз кушарга базмый гына барган хатынның кисәк кенә батыраеп китүенә гаҗәпләнмәслек түгел иде. Шулай да Гариф сер бирергә теләмәде.

— Рас әйтәсез, — диде.

Ә үзе эченнән: «Карамалыда бар хатын-кыз да моның кебек чая-кыю булса, «өйләнәчәк» сиңа берәүсе, Гарифҗан, сак бул!» — дип уйлап куйды.

— Мин монда ун ел гомер иттем инде. Ә үзем Казанда туып үскән кеше. Авылда торуы рәхәт, күңелле болай. Тик юк-юк та барыбер Казан сагындыра. Кайтып Черек күл буйларында исәрләнеп бер йөгерәсем килә кайчакларны...

— Нигә кайткаламыйсыз соң?

— Эш, авыруларымны ташлап китә алмыйм. Ничә ел инде менә ординатурага барырга җыенам, әле булса тәвәккәлләп чыгып китә алганым юк.

— Димәк, биредә больница да бар?

— Утыз койкалык кына. Киңәергә исәп юк түгел, тагын егерме койкалык бина салырга ният, — дип, хатын үзалдына елмаеп куйды. — Ә Казанны сагынам дип болай гына әйттем, Гариф Әюпович. Менә торып карагыз әле Карамалыда, һич ташлап китәсегез килмәс.

— Гафу итегез, мине каян беләсез?

— Бөтен республикага билгеле кеше бит сез, Гариф Әюпович.

— Рәхмәт, сөендердегез. Моңа кадәр мин үземне алай ук билгеле кеше дип уйламаган идем. Үзегез, күрәм, биредә доктор булып эшлисез. Изге эш ул врач булу, моның шулай икәненә минем иманым камил.

— Иремне авылга эшкә җибәргәч, мин дә башта бармыйм дип тыпырчынып караган идем. Ир — баш, хатын — муен, диләр бит. Баш алып киткәч, муен кая барсын инде. Күнектем инде хәзер. Җитмәсә, Наратбаш авылын өстәделәр. Әле менә шуннан кайтып киләм. Бер әбекәй әҗәл көтеп ята, үләсе килми. Туксан яшен тутырып узган.

Гариф пальтосын салып, беләгенә элде.

— Картлыктан дәва — көчеңә күрә хезмәт һәм тыныч тормыш. Ә сездән аларга — йомшак тел, игътибар...

Авылга якынайган саен юл өстенә җыелган сулар ешрак очрый башлады. Врач хатын башта ул суларны урап-урап чыкты да, бераз баргач, бөтенләй игътибар итмичә атлап китте. Гариф пычрак буласын белеп, аягына өр-яңа солдат итеге алып кигән иде, юл уртасыннан атлады.

Авылга җитәрәк ындыр артындагы яңа бина янында кешеләр күреп, юлдаш хатын:

— Сезне көтәләр, Гариф Әюпович. Ә миңа бу якка... — диде.

— Хушыгыз. Рәхмәт сезгә, бергә атлый-атлый озын юлны шактый кыскарттыгыз. Тик исемегезне генә белә алмадым.

— Сау булыгыз. Танышырбыз әле, Гариф Әюпович. Мине биредә белмәгән кеше юк...

Гариф аның кызларча җиңел-җиңел атлап китеп баруын күзләре белән озатып калды.

## 7

Язның беренче яңгыры кинәт килде. Таң беленер-беленмәстә көньяк-көнбатыштан кабарып-күпереп чыккан болыт ерактан торып бер-ике тапкыр гөрләрәп тавыш бирде дә, экияттәге Каф тавыдай калкып, ярты күк йөзенә таралды. Рә тавы артыннан кояш күтәрелә башлауга, ул, киң кара-кучкыл канаты белән көнне тагы да караңгылатып, бөтен күк йөзен томалап алды. Күп тә үтми, салкынча яңгыр җиле Карамалы урамнарында давыл-өермә кузгатты. Кар сулары киткәннән бирле битен-күзен бер тапкыр да юмаган барча агачлар, яңгыр сизепме, шаулашып куйдылар.

Бераздан урам-тыкрыклардагы чүп-чарны бөтереп-себереп, өермә җиле үтеп китте. Һава, афәт көткәндәй, берара тынып торды. Менә шунда һәммә нәрсә, барча тереклек инде тагын ни булыр дип көтеп торганда, күк йөзен икегә ярып яшен яшьнәде, аның артыннан ук чатырдап күк күкрәде, һәммә җан иясе дерт итеп сискәнеп куйды. Беренче курку үтәргә дә өлгермәде, таш юлдан мичкә тәгәрәгәндәй, күк йөзе тагын дөбердәде, ул да түгел, эре-эре яңгыр тамгалый башлады, ә берничә минуттан чиләкләп коеп китте.

Яңгыр әллә ни озак та яумады кебек. Әмма юл-сукмакларга су җыелды, шаулап гөрләвекләр агып китте.

Яңгыр туктар-туктамас борын идарә бинасыннан, мастерскойдан, диспетчерлыктан шау-гөр килеп халык чыкты. Яшьрәкләре этешә-төртешә уйный-көлешә башладылар, өлкәнрәкләре яңгырның бик тиз китүеннән зарланырга керештеләр. Гариф, аларның сүзләрен рәтләп ишетмәсә дә, әңгәмәнең шул турыда баруына мыскал да шикләнмәде.

Лаборатория болдырына басып, якын-тирәдәге тамашаны күзәтеп торганда, аның янәшәсенә ассистенты Вафа атлы егет чыгып басты. Гариф сүзсез генә болдырдан төште дә ишегалдындагы яшел чирәмгә таба атлады.

Язның бер көне ел туйдыра, ди халык. Менә шушы көнгә охшаш җылы яңгырлы көн булырга тиештер инде ул. Ә бу яңгыр яумаган хәлдә крестьян нишләргә тиеш соң?. Җәйләр коры килгән елларда элек крестьян читкә күчеп киткән. Алабута ашап кыш чыккан, әмма туган җирләрен ташлап чит-ят җирләргә китмичә, язның бердәнбер яңгырлы көненә өмет тотып калганнары да булган. Хәзер, әлбәттә, бөтенләй уңыш алмаган еллар булмый диярлек. Туфракны яхшы итеп эшкәртү, кыска срокта язгы чәчүне башкарып чыгу, басуларны ашлау нәтиҗәсе бу. Республикада гектарына уртача унбиш-егерме центнер уңыш җыела. Бу бик аз. Якын елларда һәр колхоз һәм совхоз ким дигәндә гектарына утыз-кырык центнер икмәк үстерергә тиеш. Моңа нинди юллар белән ирешергә? Гариф бирегә әнә шул проблеманы хәл итәргә килде. Аның максаты яңгырсыз коры елларда да югары уңыш алуга ирешү. Моның өчен туфракның серләрен ачу кирәк. Үз басуындагы туфрак генезисын, аның морфологиясен, структурасын, уңыш бирә алу сәләтен белмәгәндә, әлбәттә, бу максатка ирешү кыен булачак.

Болдырдан төшеп, Гариф янына Вафа килеп басты. Бу — чәче җилкәсенә төшеп торган озын, чандыррак буйлы егет иде. Әүвәл Вафа аспирантураны тәмамлыйм да өйләнәм дип йөрде, хәзер нигәдер ул

хакта сүз кузгатмый башлады, әллә бу тантананы кандидат булганга кадәр калдырып торырга исәбе, әллә үзенә ошаган кыз таба алмый, бирегә килгәч исә кызлар кайгысы китте егеттән — башыннан эшкә чумды.

— Көн бүген, Гариф Әюпович, хәйран калырлык. Заказ белән килгән диярсең.— Вафа кулын-кулга ышкыштырып алды, күктән бөрәм-сәрәм төшкән энҗе бөртекләрен җыярга теләгәндәй, уч төбенә яңгыр тамганны көтеп, кулларын җәеп җибәрде. Шунда ул лабораториягә таба килгән Тамчыны күреп, аңа таба китте.

— Календарьга язып куй, Вафа. Май аена сигез көн кала, ягъни егерме икенче апрельдә яңгыр яуды. Явымның туфракка сеңү тирәнлеге биш сантиметр,— диде Гариф, әмма Вафадан җавап булмагач, аңа әйләнеп карады. Егетнең авызы колагына житеп елмая-елмая Тамчыга каршы китеп баруын күргәч, үзалдына көлемсерәп куйды. Аннары карашын ишек каршындагы яңгыр суында чырык-чырык килеп коенган чыпчыкларга күчерде.

8

Иртәгә чәчүгә төшәбез дигән көнне Талип барлык механизаторларны җыеп тагын бер сөйләшергә булды. Кемнең кайда эшлисе кыштан ук билгеле булса да, председатель, имтихан алгандай, һәр механизатордан башкарасы эше турында сорашып чыкты. Ниһаять, чират бригадирга житте.

— Я, Зариф, йомгак сүзен сиңа бирәбез. Нинди житенкерәмәгән яклар бар? Зарланып калыгыз, эшкә тотынгач, теге юк, бу юк дип, сынықка сылтап йөрерлек булмасын.

Бригадир барысын да тәфсилләп сөйләгәч, Талип борынын сыпырып куйды. Бу — аныңча, әйбәт! дигән сүз иде.

Өстәл янына кереп утырган юантык гәүдәле, җәйпәк симез битле, нәрсәсе беләндер спорт комментаторы Озеровка охшаган Талип тирләп чыккан, битен-муенын кулъяулыгы белән сөрткәләп утыра, шул арада нигәдер агроном Мидхәт ягына да карап-карап ала иде.

Агрономга да сүз нәүбәте житте.

— Я, син ни әйтерсең, Мидхәт? Әйдә, сөйләп күрсәт.

Язгы чәчүгә хәзерлек көздән үк башланса да, өлешләренә тигән ашлама март аенда гына кайтарылган иде. Складлар булмау сәбәпле, Мидхәт кайтарылган ашламаны кая бушатырга дип каңгырып йөргәндә, председатель аңардан: «Ашламаны кая бушатасыз соң?» дип тә кызыксынмады. Председатель агрономны бөтен кыенлыкларга куеп карарга тели иде, күрәсең. Әллә соң башка берәр нияте бармы? Садыйковтан котылган кебек, Мидхәттән дә котыласы киләме?..

Агрономның дәшми утыруына беренче булып Талип түзмәде.

— Әйдә, иптәш Бәдретдинов, вакытны үткәрмик. Гаять житди эшкә керешү алдында торабыз. Әллә барысы да ал да гөлме? Әйдәгез, сөйләшәсен бүген сөйләшеп калыйк. Орлыклар мәсьәләсе хәл ителде бугай инде.

Мидхәт торып басты, җыелыштагыларга күз йөртеп чыкты. Әйе, бу кешеләрнең берсе белән дә әле аның эшләп караганы юк. Кем ничек эшләр? Шулай да кышкы укыту чорында кемнең кем икәнен беркадәр күргән иде инде. Ул вакытта звенолар оештыру мәсьәләсендә дә күп сөйләшенде. Механизаторларның бер ишеләре язгы чәчүдә звеноларга оешып эшләргә риза иде, икенчеләре, нигәдер, каршы төшкән булдылар. Имеш, болай итү кырларны бүлгәләүгә генә китерәчәк. Председательнең исә звенолар турында ишетәсе дә килмәде.

— Иптәшләр, мәгълүм ки, без язгы чәчүгә һәммәсен дә хәзерлә-

дек,— дип дәвам итте Мидхәт.— Чәчү агрегатлары комплекслаштырылды. Һәр агрегатка тәҗрибәле чәчүчеләр, механизаторлар беркетелде. Сменалап эшләү, ашату-эчертү мәсьәләсе дә хәл ителгән. Тик, иптәшләр, бу турыда мин сезгә кышкы укуларда да әйтә килгән идем инде, язгы чәчүне звеноларга оешып башкарганда әйбәтрәк булмас микән? Чәчеләсе һәр басуны бер звенога бүлеп бирсәк һәм карап үстерүне дә, уру-сугуны да шул кешеләргә тапшырсак, ышанып әйтәм, «Берек»ләр моңардан отар гына иде.

Председатель янә уч төбенә генә тамак кырып алды да:

— Иптәш Бәдретдинов, мәсьәләгә якынрак килегезче,— диде.— Минемчә, звеноларга оешырга без инде соңга калдык. Гомумән, кирәкме ул безгә? Юк. Группалап чәчүне менә бүген сөйләшә алабыз. Аннары, һәр агрегат үзе группа инде ул. Ике агрегаттан торамы ул, өчтәнме, эш анда түгел, минемчә. Хикмәт, иптәшләр, язгы чәчүне аз вакыт эчендә югары сыйфатлы итеп башкарып чыгуда. Шулаймы, юкмы, дөрес сөйлимме мин? Беренчедән, хезмәт житештерүчәнлеге югары, икенчедән, бөтен техника бер тирәдә булачак. Шулаймы, Мансур?

— Шулай, шулай,— диештеләр механизаторлар. Инженер Мансур да председатель белән килешеп: «Шулай»,— дип баш какты.

— Производстводагыча була инде алай булгач,— дип сүз кыстырды механизаторлардан Гарәфи исемлесе.— Түләү гектар санынnанмы? Бергәләп чәчкәндә тәртип булмый төшә бит, Талип Кәрамович.

— Производстводагы тәртипләр булсын иде әле ул бездә, анда нишләрен белер идек. Шул тәртипләрне урнаштыра алмыйча җык чигәбез түгелме соң, Гарәфи абзый? Эшнең сыйфаты иң әүвәл тәртиптән башлана, һәркемгә билгеле хакыйкать бу, минемчә,— диде председатель һәм, кайнарланып китеп, агрономга утыр дип кулы белән генә ишарә ясады да үзе торып басты.

— Мин дә звенолар оештыру ягында, группалап чәчү җавапсызлыкка китерә,— дип күтәрелде алдынгы механизаторлардан Кәрам Садыйков.

— Кешенең фикере алдыннан борыны йөрмәсен иде. Җыелышларда әйтелгән фикер нигезле, ышандырырлык булырга тиеш. Күккә дә күтәрелеп китә алмаган, җиргә дә төшә алмаган идеяләр күп булыр ул. Ә менә шуны тормышка ашыру — гаять кыен хәл. Менә синең дә, Кәрам, борының алданрак бара кебек күренә миңа.— Һәммәсе дә көлешеп алдылар.— Әйт әле, Кәрам, былтыр язгы чәчүдә күпме хезмәт хакы төшердең?

— Анысы ярыйсы. Ун көнгә өч айлык хезмәт хакы алды — дүрт йөз дә уналты сум алтмыш җиде тиен! — диде бухгалтер Кәримулла.

— Причем әле монда хезмәт хакы?! — дип кызып китте Кәрам.— Сүз язгы чәчү турында түгелме?! Бергә өелеп чәчкәндә җавап бирүчене табып булмый. Былтыр әнә Мәгъсүм агрегаты чи калдырды. Игеннәр шытып чыккач, шуның өчен чәчүчеләрне премиядән мәхрүм иттегез. Группалап эшләү җавапсызлыкка китерә, шул турыда сөйлим мин.

— Син, Кәрам энем, былтыр кысканга быел кычкырып утырма инде,— дип телгә килде өлкән механизаторлардан Гарәфетдин.— Ул «чи»нең кемнеке икәнен кайсыбыз төгәл генә әйтә ала? Бәлкем аны син үзең калдыргансыңдыр?..

— Юк, Гарәфи абзый. Ул көнне Мәгъсүм салган баш белән килгән иде. Үз-үзенә урын таба алмыйча йөрде. Шул көнне калды ул чиләр.

Талип утырды, кулъяулыгы белән җилләнеп алды.

— Утыр әле, Кәрам, утырып кына сөйлә. Нигә ул тикле кызасың? Әйтик, сыйфат комиссиясе ни караган? Люция! — диде ул ишек төбендәге йомышчы кызга.— Лотфулла абзый кайда, нигә килмәде, чакырдыңмы син аны?

— Ул, ни, Талип абый, мунчадан кайткан иде, томауладым дип тора. Соңгарып булса да килэм, диде.

— Гарәф ага, ул көнне агроном сезнең янда булмадымыни?

— Кем тыңласын ди ул терсәк буе кызны. Йөргән булды шунда. Узыныбрак китте егетләр. Мәгъсүм турында әйтәм. Салгалый бит, туганнар, карагыз сез аны, кулдан ычкынуы бар егетнең. Инсафетдин нишләде әнә. Әдикалуннарга чаклы эчә бит, ходайның хикмәте. Кәрам дөрес әйтә, тыярга кирәк ул егетне. Шул ук Лотфулланың да авызыннан хәмер исе киткәне юк. Менә бирегә иптәш Харисов күренми, аңа да шул турыда әйтергә теләгән идем...

— Ә нигә безгә әйтмәдегез? Тимерне кызуында сугу әйбәт,— диган булды председатель.

— Сез өйдә юк идегез. Икенче көнне килеп әйттем бит, Талип абый.

Талип андый хәлләрне онытамы соң! Бүгенгедәй хәтерендә. Мәгъсүмне, агрономны чакырып сөйләште.

— Быел, мин уйлыйм, андый чатаклыклар булмас,— диде председатель һәм инженер Мансурга таба борылып:— Механизаторларны кисәтеп куй. Әгәр дә мәгәр чәчүчеме ул, тракторчымы, эшкә салмыш баштан килә икән, һич нигә карамыйча, кайтарып җибәрегез,— диде.

Председатель алдындагы кәгазьләрне актаргаларга тотынды. Аннары агрономга карап алды. Әйдә, хәзер син дәвам ит дип, баш какты.

— Димәк, шулай да группалап чәчүгә кайтып калабыз. Әйтәсеме, звеноларга оешсак, һәр звенога участоклар бүленеп бирелсә, әйбәтрәк буласы иде. Кәрам дөрес әйтә, группалап чәчкәндә механизаторлар да, чәчүчеләр дә тиешле җаваплылык тоймыйлар кебек миңа...

— Моңа безнең механизаторлар үзләре хәзер түгел,— диде Талип, бу турыдагы сүзгә нокта куйгандай, һәм механизаторларга күз йөртеп чыкты да:— Әдһәм абый кая соң әле? — дип сорады.

— Чирли ул,— диде Кәримулла.

— Бу ниткән көн булды соң әле, барысы да чирләгән! — диде Талип башын чөя төшеп, диванда иркенләп утырган бухгалтер Кәримуллага карады.— Минемчә, иптәшләр, звенолар оештырырга быел соңга калдык. Экономик, мораль яктан да хәзер түгел кебек әле без моңа. Шулаймы, юкмы?

— Шулай,— диештеләр механизаторлар.

Механизаторлардан шундый аваз ишетүгә, Талип тураебрак утырды.

— Минемчә дә, соңга калдык,— диде комсомол секретаре Равил Кадыйров.

— Менә комсомол да хупламый сезнең тәкъдимне, иптәш Бәдретдинов. Чынын, тик чынын гына әйткәндә, безнең максатыбыз звенолар булмаска тиеш. Колачлырак уйларга, колачлырак эшләргә вакыттыр, ниһаять, безгә дә, иптәшләр. Промышленность үрнәгендә икмәк игүне дә тамырдан үзгәртергә вакыт түгелме икән? дип уйлыйм мин. Ә син, Мидхәт, теге мең каенны кайчан утыртырга исәбең? — дип кинәт башка мәсьәләгә күчте председатель.— Бездә егетләр ике сөйләми торганнар иде. Үсентеләрне үзем табам. Ә менә утырту ягын үзең кара. Биргән вәгъдәне үтәргә кирәктер, минемчә. Егетләрчә. Ә? Казаннан килгән якташыбыз Гариф Әюпович белән сөйләшеп тордым мин. Безнең кырларга шактый үзгәрешләр кертмәкче ул. Дәлилләре нигезле, ышандыра. Кайбер урман полосаларын күчерергә куша, яңаларны утыртырга дип басуларны яңача бүлеп ята. Кыскасы, шактый мәшәкать ясый ул безгә. Ләкин аның тәкъдиме авыл хуҗалыгын индустрияләштерүгә, промышленностька нигезләп коруга кайтып кала. Шулай булгач, звено кебек нәрсәләр оештыру ул икмәк игүнең киләчәген ваклау булыр иде.

— Миңа урман полосаларын үзгәртү турында идарәдән күрсәтмә булмады.

Талип мыек астыннан гына көлемсерәп куйды. Агрономның чарасыз калып аклануы аны бераз гаҗәпләндерде. Шул ук вакытта ул эченнән җиңү хисе кебек бер нәрсә дә тойды. Кечкенә, бик кечкенә булса да, Талип өчен барыбер җиңү иде ул.

— Мәсьәлә аңлашылды кебек. Иртәгә сәгать алтыга барыгыз да машиналарыгыз янында булыгыз. Ягулыкларыгыз салган, путевкаларыгыз кулыгызда булсын. Үзем килеп карап чыгачакмын. Орлык илтү мәсьәләсен, чәчкечләрне тикшерү, тирәнлек — агроном җаваплылыгында. Аңлашылдымы?

— Аңламаган кая! — дип дәррәү кузгалды механизаторлар.

## 9

Кичке уй иртәнгә ярамый диләр, хак икән. Төнлә чалт аяз торган күк йөзен таң алдыннан болытлар каплады һәм күп тә үтмәде, шаулап яңгыр явып узды. Озак яумады, әмма җилләп җитмәгән дымлы җиргә җитә калды — юлларны пычратып, машина түгел, тракторлар да йөрмәслек итте. Чәчүгә төшәргә команда гына көтеп торган механизаторлар, кабызган машина-тракторларын сүндереп, түбәсе ябыла башлаган мастерской ышыгына җыелдылар.

— Шулай итәр әле ул аллаһы тәгаләсе, адәмнең изге эшенә аяк чалмый калса, йокысы йокымыни аның! — диештеләр механизаторлар.

Иртә таңнан биредә буласы председатель дә юк иде әле, Мидхәт ни кыларга белмичә механизаторлар арасындагы Мансур янына килеп басты.

— Эшләр шәп түгел, Мансур,— диде ул борчылып.

— Нишлибез инде хәзер, Мидхәт энем? Муллага алла баш булса, безгә — агроном. Әйдә, бир команда! — диде мыек очлары саргайган Гарәфи. Аның иске эшләпәсе күзенә төшкән, өстендә сырган бишмәт, авыз читендә сигарет төти иде.

— Ничәмә еллар чәчеп мондый хәлләр булмадымыни, күрмәдегезмени, Гарәфи абзый?..

— Булгандыр инде ул, энекәш. Тик онытылгандыр. Элек бит яңгыр яуса председательгә чәчү, безгә эчү иде. Аннары язы да яз төсле килә, җәе дә ул хәтле кыздырмый, яңгырлар яугалый торган иде. Былтыр әнә җәй буе таммады да бит. Иртә чәчмәгән булсак, Наратбашлар кебек, орлык теләнергә каласы идек. Иртә чәчтерде Талип. Башы эшләде үзенең, уңдырды. Без былтырларны гектардан егерме биш центнер суктырып алдык, Наратбашлар егермене җыйса җыйды, алай да юк бугай әле.

— Былтыр иртә чәчтергән дә, быел әнә үзе дә юк әле,— диде Мидхәт, Гарәфинең председательне мактавын ошатмыйча.

Шул вакыт диспетчерлык бинасыннан Зиннуров чыкты һәм ашыкмыйча гына мастерскойга таба юнәлде. Ул шундый юан, аркылысыбуе бер дигәндәй, карсак гәүдәле, аягы белән атлап түгел, тәгәрәп йөри сыман иде.

— Егетләр, агай-эне, ак мыек, Зиннуров килә. Талип галиҗәнабларыннан боерык китерәдер,— диде арадан берсе.

— Кыяр тавындагы басуда яңгыр таммаган да. Талип абый бөтен техниканы, орлык төягән машиналарны шунда җибәрергә кушты,— диде Зиннуров килеп җитмәс борын ук һәм, әллә бөтенесе үзенә карап торудан уңайсызланып, пинҗәгенең бердәнбер сәдәбен каптырырга кереште.

— Маташма инде, Каюм, барыбер җиткерә алмассың. Дәүләт сиңа үлчәп тексә, биш кешегә җиткән кәчтүмлек китәр иде, билләһи дип әйтәм.

— Ни ашыйсың син, малай, Каюм? Өйрәт әле шул серенне? Минем мөнә эч-эчкәябышкан. Бер атна буе утыруда чиле-пешле ун йомырка сыдырып карадым. Корсак үсми генә бит. Хатынны эшеннән каршы алырга чаба башладым,— дип, берсе артыннан берсе диспетчер Зиннуровны үрти башладылар.

Механизаторлар шулай тел чарлашкан арада Мидхәт үзалдына уйланды: «Кыяр тавы басуы авылдан ким дигәндә ун-унике километр. Әле чыккан хәлдә дә тракторлар ике сәгатьләп барачаклар. Аннары Кыяр тавындагы басуларга ашлама салынмаган бит әле. Райүзәктән берсекөнгә генә самолет бирергә ышандырдылар. Ашламасыз чәчәргә исәбеме әллә бу Бикмуллинның? Юк инде. Үлсәм үрә торырмын, әмма ашлама сиптермичә ул басуга бодай чәчтермәм!»

— Кыяр тавындагы басуга ашлама чыгарылмаган ич. Ул турыда Талип Кәрамович үзе дә белә,— диде үзсүзләнәнә барган Мидхәт.

— Самолет безнең аэродромда инде. Ашлама төйи,— диде Зиннуров.— Сез баргалаганчы сиптереп тә чыгар ул.

«Кем бирде самолет? Ничек болай иртә?..» Яшь агроном бу сүзгә аптырап, тагы уйлана калды.

— Кузгалыйк,— диде ул аннары Мансурга.

Шуны гына көткән кебек, механизаторлар шау-гөр килеп машиналарына таралыштылар. Мидхәт инженерның «вездеход»ына утырып аэродромга китте. Бу машинаны чәчү чорына аңа беркеткәннәр иде. Шофер, яшь күренсә дә, житез кылана. Салулый-салулый булса да, аэродромга килеп життеләр. Анда инде самолет тора, ашлама белән машина килеп туктаган, төяүчеләр янында бригадир Зариф булышып йөри иде.

— Сәлам, Зариф,— диде Мидхәт.

— Сәлам! Тракторлар киттеме әле?

— Алар юлда инде.

— Югыйсә, Талип абый борчыла,— диде Зариф, жилкәсенә ашлама капчыгын салды.— Мөнә, күрәсең, үземә төяшергә туры килде. Нибарысы ике егет таптым. Авылга төшеп булмады. Баткак. Боларны да фермадан гына алдым. Давай, давай, егетләр. Кызурак булыгыз. Унбиш минуттан самолет һавада булырга тиеш.

Зариф илле килограммлы капчыкларны жилтерәтеп кенә ташлый, самолетка бушатучы егет авыз-борынын кулъяулыгы белән бәйләгән, шуңа карамастан, пырх-пырх төчкерә иде.

— Икенчесен ассагыз да төямим, Зариф абзый. Ашлама төйим дип чехотка алыр хәлем юк,— диде егетләрнең берсе.

— Икенчесенә билгеләгән кешеләр килер. Мөнә монысын төяве мәхшәр әле анын.

Мидхәт капчыкларга тотыныргамы, юкмы дип икеләнеп тора иде, машина әрҗәсеннән ашламалы капчыкларны биреп торучы шофер:

— Әйдәгез әле, иптәш Бәдретдинов, сез дә бераз билегезне язып алыгыз,— дип, аны да эшкә кушты. «Вездеход»тагы шоферны да төяшергә дәшеп алды бригадир.

Самолет тулгач, моңа кадәр бер читтә басып торган очучы, Зариф янына килеп:

— Егет икәнсең,— дип, бригадирның кулын кысты.— Унбиш минут диден, унбиш минутта төядегез дә. Сезнең председателегез дә ут шул. Өемә үк килеп алды.

— Габсабир, син хәзер хет йөзеп, хет сөреп гаражга кайтасың,— диде бригадир. Ә мин мөнә бу чикерткәгә утырып авылга төшәм һәм сиңа төяүчеләр китерәм. Иптәш Бәдретдинов, сездә безнең беләндер бит?

...Машинага утыргач, бригадир кепкасын арткарак чөеп куйды да үзалдына сөйләнә башлады:

— Очучыбыз гына туктамасын. Үз эшен ул бер сәгатьтән тәмамларга сүз бирде. Шул арада без ашламаны китереп җиткерергә тиешбез. Анда инде ике-өч сәгатькә соңгарыбрак булса да чәчү башланачак. Ә башланган эш — беткән эш. Җиде агрегат. Җиде агрегатка җитмеш гектар. Бүген төнгә Кыяр тавында эшне төгәлләргә дә була. Ә иртәгә түбән кырлар да җилләр. Җәйге яңгыр тиз кибә ул. Картлар, җәйге яңгыр җиде сәгатьтә җилләсә, көзге яңгыр җиде көндә дә җилләмәс, диләр...

«Каян белгән Талип Кыяр тавында яңгыр яумаганын? Аннары, кай арада Бөгелмәгә барып кайткан да, кай арада яңадан Кыяр тавына чапкан. Бөгелмә шәһәре Карамалыдан кимендә йөз-йөз ун километр. Дөрес, барасы юлның яртысы асфальт. Алай да, алай да...» дип гаҗәпләнде Мидхәт.

Шулай икән шул, үткән ел гына институт тәмамлаган яшь агроном Мидхәт Бәдретдинов аңларлык кына кеше түгел икән бу председатель.

Машина юлдагы күлләвеккә кергән саен алгы тәрәзәгә су чәчри, пыяла сөрткеч арлы-бирле йөреп, башта тәрәзәне берни күренмәслек итеп пычратып ташлый, аннары, шофер су йөгерткәч,— юып ала, көн яктырып, аязып киткәндәй була. Кемдер инде бу юлдан эз салып үткән. Бикмуллинның Бөгелмәгә киткән машина эзе булса кирәк. Әллә кырга чыккан эземе?

Көн аяз. Болытлар төсе уңган ситсыдай агарып калган. Әнә Кыяр тавына таба тракторлар, машиналар менгәне күренә. Ерак булгангамы, алар ташбакалар шикелле әкрен генә хәрәкәтләнә иде. Мидхәтнең уен аңлаган кебек, бригадир:

— Ике сәгатьтән һәммәсе Кыяр тавында булыр, иптәш Бәдретдинов, борчылмагыз,— диде.

Мидхәт бригадирга карап көлемсерәп куйды.

— Икебез дә бер нәрсә турында уйлыйбыз икән.

— Талип абый әйтмешли, уйлар гына түгел, теләк-хыяллар да бер булырга тиеш хәзер безнең, Мидхәт дус. Сезнең белән минем өчен иң җаваплы көннәр башланды. Шунда сынала инде безнең брат.— Хәзерге житәкче камчы шартлатучы түгел, ә көрәшче, әнә шул эш өчен көрәшүче. Талип абый үзе дә эшли, кешеләрне дә эшләтә белә. Син әле уйлап кына йөрисең, ул инде хәл итеп тә куйган. Интуиция көчле ул шайтанда.

— Кызык теория,— диде Мидхәт баш селкеп,— җитәкче чыбыркы шартлатучы түгел, көрәшче, имеш.

— Ә сез ничек уйлыйсыз?

— Минемчә, хәзерге заман җитәкчесе иң әүвәл кешеләрнең ихтирамын казанырга, аларның уй-хыялларын аңлый белергә тиеш.

— Озын һәм аңлаешсыз. Кеше бит ул һәммә нәрсәне гадиләштереп аңлый. Яхшы белән начарны ул шундук аера. Халык әйбәт җитәкчене шундук күреп ала.

— Бу бәхәсне дәвам иттерербез әле, иптәш Бакиров. Әйтик, чәчүләрне тәмамлагач.

*
* *

Мидхәтне райүзәккә киңәшмәгә чакыргач, ул Талип янына килде.

— Бүген-иртәгә эшләсәләр, тәҗрибә участогына чәчеләсе ике йөз гектар борчак кына кала. Ләкин безнең ул участокка салырга гранулланган ашлама юк,— диде агроном.

— Карале, егет, ашламаны бер председатель генә кайгыртырга тиеш түгелдер бит? Юк икән, табарга кирәк. Ә син миңа менә шуны әйт: «Берек» колхозының рентабельлеге белән кызыксынганың бармы

синең? Кыш буена колхозчыларга лекцияләр укып йөрдең — рентабельлекне ничек аңлыйсың син?

Талип Мидхәткә артык гади сораулар биргәли иде. Бу хәл бер генә кабатланмады инде. Мидхәт ышандырырлык итеп, нигезле җавап бирә. Менә хәзер дә Бикмуллин аңа, үзебезнең колхоз экономикасын әйбәтләбрәк аңлатыгызчы, диячәк иде. Бу мәсьәләгә килгәндә исә, Мидхәтнең «Берек»тәге һәммә тармак белән дә кызыксынганы юк, вакыты житенкерәми иде. Кичә әнә километр чамасы кыр ышыклау полосасы утырттылар. Ярый әле, мәктәп балалары, комсомоллар булышты. Мәктәп директоры Мотыйгулла абыйга һәм комсомол секретаре Равил Кадыйровка рәхмәт, бер көндә ике мең төп агач утыртылды. Үсентеләрне кем китерде? Бикмуллин. Каян? Күпмегә? Димәк, һәр нәрсәгә акча кирәк.

— Рентабельлек ул, Талип Кәрамович, — керем, авыл хуҗалыгының табышын күтәрү, колхозчыларның көнкүреш һәм культура шартларын үстерү. Аннары... нигә әле сез миңа тиктомалга бәйләнәсез, Талип Кәрамович?

Талип Бикмуллин иртән иртүк идарәгә килеп утырган һәм ул инде кыр станы белән дә, урынбасары диспетчер Каюм белән дә элемтәгә кереп өлгергән иде. Агрономның райүзәккә киңәшмәгә китәсен белгәч, ул аны үз янына чакырып алды. Ни өчен? Нигә? Мидхәт аңламады. Әллә соң акыл өйрәтү, вәгазь уку һәм төрле куркытулар белән Мидхәткә нинди дә булса йогынты ясарга исәбеме бу председательнең? Райүзәккә баргач, Талип Бикмуллинны яманлап бик узынып йөрмәсен әле дип, бераз дагалап җибәрергә уйлавымы әллә?

— Урман полосаларын рәтләүдә эшне тиз тотуың ошады миңа. Ә менә рентабельлекне аңлатуың институттагыча килеп чыкты. Безгә, күрәсең, әле синең белән шактый чиләнергә туры килер. Сиңа мәгълүм, безнең кырларның кара туфрагы дөньяның бер илендә дә юк. Моннан нәтиҗә: җир ашлауны фәнгә нигезләп эшләмәсәк, туфракны бозып куюыбыз бар. Тегеләй дә болай дип тәкъдим итүчеләргә сукыр килеш иярмик. Без, минемчә, иң элек туфрак структурасының төзелешен, агрофонын, аңардагы еллык дым күләмен белергә тиешбез. Бу өлкәдә безгә ярдәм итүчеләр бар. Лаборатория салынды. Анда күренекле галим, белгечләр эшли. Галим абыебыз безгә ниндидер дым-су каналлары казырга куша, туңга сөрү мәсьәләсендә дә аның фикерләре гаять кызыклы. Кыскасы, сезнең басуларда гектарына алтмыш-житмеш центнер икмәк үстерергә мөмкин дип бара. Без бит әле чынлап та басуларны кай юнәлешкә уңайлы, шул якка сөреп каплатабыз. Ә ул алай кушмый. Авыш җирләрне, кырын төшләрне белеп, язгы сулар китмәслек итеп сөрергә өнди...

Мидхәт председатель яныннан тәмам иләсләнеп чыкты. Ни тели бу председатель аңардан? Карусыз буйсынунымы?..

Шулай да Мидхәт туп-туры лабораториягә юнәлде. Председатель әйткән өчен түгел, иң әүвәл анда аның Тамчыны күрәсе бар иде. Әлбәттә, ул башта Тамчының үзе белән сөйләшер, аннары галим янына кереп, Тамчының үз урынына калып торуын сорар. Ул бит аңлады председательнең үзеннән ни теләвен. Аңлады! Ашлама булмаса да, таш яуса да чәчүне иртәгә тәгәлләргә! Таш яуса да. Ә менә моның өчен ашлама кайтып җитмәгән. Мидхәт райүзәккә барыр һәм ике көн йөрерме анда, өч көнме — барыбер ашлама табар һәм сортлы борчакны ашламалап чәчәрләр.

Бәдретдинов лабораториягә кергәләсә дә, галим абыйсы белән иркенләп сөйләшә алганы юк әле. Әллә ничек һаман туры килмәде инде...

Кунак йорты салынып беткәч, Бикмуллин аңа шунда күчәргә кушты. Мидхәткә пенсионер Галләм карттан китәргә туры килде. Югыйсә, фатир хуҗалары Мидхәтне җибәрмәскә дә иткәннәр иде, әмма Талип сүзне кыска тотты.

— Галләм абзый тирәсенә машина керерлек түгел. Ә бу егет миңа минут саен кирәк булып тора, агроном өчен генә йомышчы тота алмыйм,— диде.

Кунак йортына күчеп киткәннән соң Мидхәт Тамчыны сирәк күрде. Үзләрендә торганда бергәләп киногa бара торганнар иде. Янәшәләрендә һәр вакыт Вафа йөрсә дә, Мидхәт эче белән сизә иде: иртәмесоңмы Тамчы барыбер аныкы булыр. Ник дисәң, Мидхәт Бәдретдинов Карамалыда каласы, ә Вафа күп дигәндә бер-ике елдан бередән китәсе кеше. Шулай дип үз-үзен тынычландырып торгангамы, Мидхәт кызга мәхәббәте турында чишелергә ашыкмады, өлгерермен дип уйладымы, я булмаса мәхәббәте бөреләнеп житмәгән идеме? Һәрхәлдә, бу ике сәбәпнең икесе дә бар иде бугай.

Уйлана башласа, кайчак аңа бик моңсу булып китә. Шундый минутларда ул Тамчыны аерата юксына. Тик ул гына аңлар кебек аны. Ләкин кыз белән очрашырга, култыклашып күл буйларында йөрергә егетнең вакыты калмый, шайтан алгыры. Кая ул кичләрен чыгып, түбәноч Галләм картның кызын озатып йөрү. Вафа әнә вакыт таба. Шул ук вакытта Мидхәт үзе генә белгән изге бер өмет белән яши. Килер бер көн, ул аңа үзенең иң саф, иң изге мәхәббәтен ачар. Кызны кочагына кысып, моңа кадәр һичкемнән ишетмәгән назлы сүзләр әйтер. Тик әлегә әнә шул хыял белән генә яши Мидхәт. Анысы дөрес, Мидхәтнең үтә бирелеп эшләвенә, аның ябыгып китүенә кунак йортын караучы Хәтимә апа да гаҗәпләнә.

— Тамагыңа үтмиме әллә синең, балакаем, бигрәк аз ашыйсың инде, болай көн-төн чапсаң, бөтенләй урынга калмагаең,— ди ул, аның хәленә кереп.

Чынлап та ябыкты Мидхәт, каешына да ике өстәмә тишек тиште инде. Төсе дә үзгәрде: маңгаендагы җыерчыклары куерды, борыны зураеп калды, житмәсә, җил-яңгырга бөтен бите киселеп кубаклана башлады. Холык-фигыленә моңарчы күренмәгән сыйфат өстәлде: төнлә уянып китә дә алдагы көндә эшлисе эшләре турында уйланып ята. Кыскасы, моннан да ары болай яши алмастыр, өйләнергә кирәктер. Кызык итсен әле Вафаны, кәкре каенга терәтеп калдырсын әле Казан сорнаен...

Мидхәт Тамчы янына керергә ниятләсә дә, башта галимнән рөхсәт сорарга булды. Латыйпов аны елмаеп каршылады. Сәламен алып, түрдән урын күрсәтте. Галимнең өстәлендә исәп-хисаплау таблицалары, каралама карталар.

— Я, ничек хәлләр? Бик кыен түгелме? Чәчүләрне төгәлләп киләсезме инде? — дип сорады Гариф.

— Иртәгә бөртекле культураларны төгәллибез. Ике-өч йөз гектар гына калып бара. Шуның янына сортлы борчак җире.

— Ә-ә, ул борчак җирегезне без тикшердек. Киңәш йөзеннән әйтәсем килә, ул басуыгызның туфрагы шактый ярлы. Туфракның уңыш бирү сәләте без тикшергән башка басуларныкына караганда күп түбән. Моннан нәтиҗә: аны мулрак итеп ашларга кирәк. Элек бередә чәчү әйләнеше тәртипсез булгандыр, күрәсең.

«Сорарга иде бу галимнән: колхоз председателе турында ни уйлый икән? Аннары Тамчыны иртәгә минем урыныма җибәрер микән? Җибәрмәгән хәлдә Мидхәт киңәшмәгә бара алмаячак. Ә ул анда сөйләргә тели, картограммалар хәзерләде. Председатель аны аңламады, бәлкем үзенең тәкъдимнәренә ул район киңәшмәсендә юл табар. Ләкин галим агасы Мидхәтнең ашыгуын белми. Ул аңа лекция сөйли. Аны

бүлдереп, Тамчы турында сүз кузгату гафу ителмәслек ахмаклык булыр иде».

— Ашламаларга кытлык зур шул әле бездә, Гариф Әюпович. Һәр килограммы исәптә. Ике йөз гектар сортлы борчак җиренә дә ул ашламаны табу кыен булачак. Ә ул җирне ашламасыз чәчтерәсем килми минем. Сезгә, Гариф Әюпович, бер үтенечем бар иде...

Гариф, алдындагы картограммаларны бер читкәрәк күчереп куеп, тыңларга җыенды.

— Мине район үзәгенә җитди киңәшмәгә чакыралар. Иртәгәгә сезнең лаборанткагыз Тамчы минем урынга кырга чыкмас микән?

— Тамчы гына түгел, минем үземнең дә анда барып чыгарга исәп әле. Ихсанованы җибәрергә каршы түгел мин. Тик үзенә дә әйтеп, ризалыгын алып китегез. Ә инде басуларга ашлама чыгаруда иң әүвәл син җаваплы, Мидхәт. Уңышны иң әүвәл синнән сораячаклар...

## 10

Гариф башын да күтәрмичә эшләде. Кайбер көннәрдә ул хәтта лабораториядә куныл калгалады.

Иртәнге салкында су буйларында йөреп кайткалады. Яр читенә басып, башкорт ягыннан чыгып килгән кояшны күзәтә торгач, ул бер нәрсәне искәрде: җиргә тереклек бирә, гаҗәеп манзаралар тудыра торган бу ут шары көн саен диярлек төсен алыштыра. Бер көнне ул аксыл-сары төскә манчылып килеп чыга, икенче көнне күксел-ал төскә керә, ә бер дә бер көнне чәчрәп килеп чыга да бөтен тирә-юньне җете алсуга манып, кызылдан киендерә. Болытлы көннәрне Гариф йөрергә чыкмый, иртүк эшенә утыра иде.

Шактый эш башкарылды. Басулар тарихы өйрәнелде, туфрак генезисы белән танышылды. Хәзер туфрак анализлары төгәлләнеп килә инде. Әмма институт җибәрәсе техник-картографның әле булса килеп житкәне юк. Вафа универсаль егет булып чыкты. Инженер-җир белгече дә ул, лаборант-аналитик та, техник-картограф та, ниһаять, туфрак белгече дә. Дөрес, туфрак катламын, аның генетик төзелешен тикшерүгә Гариф үзе дә катнаша.

Муеннан эшкә чумса да, Гариф еш кына әнисен, Әдиләне һәм аның нәни кызы Чәчәкне исенә төшерә, аларны сагына. Язган сүзләре дә исәнлек-саулык. Хәер, Гариф алардан артыгын өмет тә итми иде.

Гариф өстәл янынан торды да түр яктагы урындыкка күчеп утырды. Тәрәзәгә якын бу урындыктан Карамалының олы урамы, Рә тавы, клуб алды, идарә болдыры күренә. Уйга чумды. Кем җибәрде аны бирегә? Үзе килде. Үзе риза булды. Һәм ничек риза булды әле!

...Гариф эш бүлмәсеннән чыкты да институтның киң коридоры буйлап салмак кына атлап ишеккә юнәлде. Бу коридордан ул бик күп еллар үтеп-сүтеп йөрде. Әйе, күп эшләр башкарылды бу институтта. Диссертациясен яклагач, коридор чатында аны Тимирязев академиясеннән килгән күренекле бер галим туктаткан иде.

— Хезмәтегез гаҗәп кызыклы һәм яңа. Мин сезнең өчен бик тә шат, коллега. Ләкин мин моны сезнең үзегезгә генә әйтергә телим, авыл хуҗалыгы өчен менә бүген мөһим булган мәсьәләләргә кыюрак тотыныгызчы. Хезмәтеңнең нәтиҗәсен үзең исән чакта күрүгә ни җитә. Сез бит әле яшь кеше. Хезмәтегезне практика белән ныгытыгыз. Сез күтәргән теоретик мәсьәлә җанланырга тиеш,— дигән иде.

Гариф коридордан үткәндә әнә шул сөйләшүне исенә төшерде.

Хакмы ул? Егерменче гасыр галиме бер практикага гына бәйләнеп ятарга тиешме?

Әйе дә, түгел дә.

Әйе — авыл хуҗалыгындагы иң мөһим мәсьәләләрнең берсе туфракның серен белеп, бөртекле ашлыкларның уңышын күтәрү.

Түгел — теориясез практика ул — стихия... Ә стихия ул — кешелек фаҗигасе.

Бездә туфрак эшкәртү өлкәсендә хаталар күп булды. Моңа кадәр бездә чәчү җирләрен арттыру исәбенә уңыш алынды. Мәгәр хәзер бу чараның да чикләре билгеләнде. Бу юл буш җирләргә, игелмәгән чирәм җирләргә бәйле иде. Чирәм җирләр бетте. Ә уңыш алу елдан-ел артырга тиеш.

Нинди юллар белән?

Гектар башыннан уңышны арттыру исәбенә.

Докладны ул республиканың бишенче фәнни конференциясендә сөйләде. Һәм зур кызыксыну уятты. Профессор Горизонтов, Үтәй һәм башка галимнәр аңа зур бәя бирделәр. Шулай итеп, Гарифның «Бөртекле культураларның агротехникасын яхшырту һәм аны тотрыклы фәнни юлга салу» дигән хезмәте белгечләр тарафыннан хупланды. Икенче көнне аңа: «Сезнең докладыгыз белән өлкә комитеты секретаре да кызыксынган»,— дип ишеттерделәр. Һәм озак та үтмәде, секретарь аны үз янына чакырды.

...Баскычларны тутырып җәйгән паластан атлаганда, Гариф: «Картаела, ә үзем һаман зур өметләр белән яшим», дип уйлады. Һәм йөрәге ашкынуын басарга теләп, ике катны менгәч, бер як читтәге диванга утырып хәл алды.

Гариф зур, якты бүлмәгә килеп керде. Өстәл яныннан торып, секретарь аңа каршы үзе кузгалды. Бу җете кара чәчле, чигә тирәсенә кырау төшә башлаган, тулы түгәрәк йөзле, буйчан, таза гәүдәле кеше иде. Килде дә кул биреп күреште һәм Гарифны терсәгеннән җиңелчә генә алып, түргә әйдәде.

Утырыштылар, хәл-әхвәл сорашылды. Институтта укыган елларын, аспирант булып йөргән чакларын кызыксынып сораштырды секретарь. Ул да, Гариф кебек үк, Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган икән.

Гариф секретарьның болай сөйләшүен лирик чигенеш дип кенә кабул итте, тыштан сиздермәсә дә, ни өчен бирегә чакырылуын бераз белә иде ул.

Ниһаять, секретарь Гариф Латыйповны ни өчен чакыруын әйтте. Нияте изге икән: республиканың кара туфраклы көнчыгыш районнарының берсендә фәнгә нигезләп сорт сынау һәм туфракның эчке төзелешен тикшерү өчен агрохимик-зональ лаборатория ачу икән. Гариф күтәргән мәсьәлә секретарьда җитди фикер уяткан. Үткәрелергә тиешле чара гаять мөһим һәм вакытлы дип, Министрлар Советы да секретарьның фикерен хуплаган. Димәк, материаль ягы хәл ителәчәк. Инде барып, эшне башлап җибәрүчесе, җайга салучысы кирәк икән.

Гариф һәр сүзен үлчәп, ашыкмый сөйләгән секретарьны игътибар белән тыңлады. Докладны язганда мондый резонанс булыр дип һич тә уйламаган иде ул. Аңарда һәр кешедә була торган горурлык хисе уянды.

— Сез, Гариф Әюпович, бу мәсьәләне куеп авыл хуҗалыгы белгечләрен тәмам кузгаттыгыз бит әле. Әмма ул кәгазьдә генә калмасын иде.

— Максат изге дә бит,— дип башлады Гариф, секретарь туктаугач.— Әмма галим тикшеренүләре ул еллар буена башкарыла торган эш.

— Ә без сезгә ышанабыз, Гариф Әюпович. Сез бит республиканың көньяк-көнчыгыш районнарының берсендә кайчандыр баш агроном булып эшләгән кеше. Аннары,— секретарь, монысын әйтим микән, юкмы дигән кебек, уйланып торды,— аннары, үзегез дә шул яктан икән. Бәлкем туган авылыгызга да кайтырсыз әле. Бу турыда без райком секретаре иптәш Хөснетдинов белән сөйләштек инде. Яхшы шартлар булдырыр идек дип ышандырды.

Гариф дәшми торды. Ул Ык елгасы буендагы Карамалы авылын күз алдына китерергә тырышты. Әнисе еш кына Карамалыны исенә төшереп сөйли торган иде. Сагынам дип әйтеп әйтә иде, ике-өч ел элек кайтып та килде. Секретарь Карамалы турында сүз кузгаткач, Гариф, күңеле тынычсызлана башлап, йөреп килде. Туган авылы турында әнисенең аңа беркайчан да киңәеп сөйләгәне булмады. Заманында бик каты яра салган иде аның йөрәгенә Карамалы авылы. Шунда аның ире Әюп һәлак булган. Үле гәүдәсен дә таба алмаганнар. Шунда кайтып эшләргә туры килә инде болай булгач.

— Минем монда әнием, кызым бар.

— Беләбез, Гариф Әюпович.

— Ярый соң, принципта мин риза.

Секретарь елмаеп куйды:

— Нишлисең, без коммунистларга һәр вакыт заман таләпләрен тоеп яшәргә туры килә бит. Рәхмәт, мин сезгә баштан ук ышанган идем...

## 11

Борчак чәчеләсе тәҗрибә участогына Тамчы иртән иртүк килде. Гариф Әюпович агрономның үтенечен әйткәннән соң ул бераз дулкынланып та алды. Үзләрендә айга якын яшәп киткән агроном егет турында күп кенә имеш-мимешләр йөри. Аңа чаклы эшләп киткән Садыйков кебек, ул да председатель белән тынышмый икән. Алай буласына ышана иде Тамчы. Талип абыйлары корырак, холыксызрак кеше, аның сүзеннән чыксаң, үч алуга кадәр житә. Әллә чын-чынлап, әллә юри түбәнсетү нияте белән, үч алу ягын гына чамалап йөри башлый сыман. Үткәндә дә, сүткәндә дә төртелеп-сугылып алырга гына тора. Моны ул күзгә-күз килгәндә генә эшләми, ә җыелышларда, халык алдында кузгата. Әтисе әйтмешли, Талипка тарма, тарсаң — арма. Агроном булып эшләгәндә Тамчыны да шактый тинтерәтте председатель. Башы басудан кайтып кермәде кызның. Төннәрен йокыдан язды. Ябыкты, сулды. Әмма шунысы аяныч, үзе дигәнчә эшли алмады, председательгә каршы әйтергә кыймады. Ләкин Тамчы да инде кайбер нәрсәләргә төшенеп килә. Яхшымы-начармы, Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумының икенче курс студенткасы, лекцияләр тыңлый, имтиханнар бирә — акыл җыя, аннары бергә эшләгән Вафа да аның күзен ача тора. Кыскасы, белгеч буларак, фәнгә якыная төште Тамчы. Гариф Әюпович та фән дөньясындагы кызык-кызык хәлләр белән таныштыра. Ныгый, батырая бара агроном булачак кыз.

Ай, бу Вафаны! Көн саен өенә озата, иртән яктырып-елмаеп каршы ала. Тамчы аның култык астыннан гына булса да, Вафа янында иркен, горур тота үзен. Аңа көннән-көн Вафа белән янәшә атлавы, караган кинолар, укылган китаплар, күргән-белгән хәлләр турында сөйләшүе кызыграк була бара. Шул ук вакытта агроном егетне дә күзеннән җуймый Тамчы. Хагы хак, әллә нигә аның күзенә күренергә ояла төшә. Беренче көннән үк, үзләрендә күргәч тә, шулай булды һәм хәзер дә шулай. Ояла, әмма күңеле белән аны күрәсе килә.

Ни генә булмасын, икесе дә якын аның күңеленә. Алай булмый, диләр. Була икән шул менә. Кичә Мидхәт аның янына керде. Булмә-

сендә — анализга алып кайткан туфрак үрнәкләре, морфологик язмалар, басу көндәлеге. Мидхәт анализлар язган кәгазьне укып торган булды. Анда кагылды, монда сугылды. Бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Тәрәзә төбендә — ящиклар, үсентеләр. Идән тулы туфрак салып этикетка ябыштырылган капчыклар: басу саны, үрнәкнең номеры, колхоз исеме язылган. Почмакта кыр ящигы, туфрак ала торган бораү. Институтта укыганда колхозга практикага баргач, шундый бораү белән Мидхәт тә туфрак үрнәкләре алып йөри торган иде.

Тамчы егеткә каш астыннан гына карап-карап торды да:

— Исәнмесездән башка сүз әйтергә дә хәлегез калмадымыни инде, Мидхәт? — дип мөлаем генә елмаеп куйды.— Талип абыйга тарма...

— Беләм,— диде Мидхәт,— тарсаң — арма. Исемдә, әтиең сүзе.

— Чаптыра белә ул Талип абый, кайсыбер көннәрне җеп өзәрлек тә хәлең калмый.

Тамчы башын кырын сала төште. Дугаланып киткән кашлары очынгалап алды. Мидхәт чарасыз калды, бер мәлгә зиһене чуалды. Нәкъ шул үзе бит. Бу юлы инде, аның алдында рәсеме түгел, җан иңгән сурәте утырып тора. Чәчәкләр дә җыймый, җәйге күлмәк тә кимәгән, ак халаттан. Ә барыбер эш халаты да килешә үзенә. Чибәр, сылу иде шул Тамчы.

— Мине, Тамчы, ике көнгә киңәшмәгә чакыралар. Тәҗрибә участогын гына чәчәсе калды. Ике йөз гектар. Үземнең күзәтәсе килгән иде, югыйсә...

— Мин бит хәзер кеше кешесе, иптәш Бәдретдинов,— диде Тамчы, Мидхәтнең шулай артык рәсми тонда сөйләшүен ошатмыйча.

— Мин Гариф Әюпович белән ул турыда сөйләштем инде. Ул каршы түгел.

Тамчы, ышанмыйча булса кирәк, Мидхәткә күзләрен елтыратып карады, әмма йөзендә үзгәреш күрмәде.

— Мин анда нишләргә тиеш булам инде, иптәш Бәдретдинов?..

Шул чакны ишек ачылды һәм бусагада озын буйлы Вафа күренде.

— Тамчы! — диде ул.— Кичәге үрнәкләр әзерме инде, күрсәтче.

Вафа өстәл янына килде, банкада утырган шомырт чәчәкләрен иснәп карады. Шунда гына, Мидхәтне яңа күргән сыман:

— Ә, агроном, иптәш Бәдретдинов. Нинди җилләр ташлады? — дип сораган булды.— Сезне дә күрер көннәр булыр икән. Председателегез: «Агроном сезнең белән тыгыз элемтәдә булыр», дигән иде, үзен түгел, эзен дә лаборатория тирәсендә күргән юк дип дәгъва тотарга исәп иде. Ниһаять, килгәнсез икән, дәгъваны калдырырга булыр. Безгә кунаккамы?..

Вафа Мидхәткә ике авыз сүз әйтергә ирек бирми, әйтерсең лекция сөйли, теле-телгә йокмый иде.

— Чәчүләр беткәч, лабораториягездән чыкмам да әле. Аерата менә бу бүлмәдән. Ә пока... Эшләр үкчәгә баса бераз.

— Ышандык ди, шулаймы, Тамчы?

Вафа, кызның чәчләренә бите белән кагылып диярлек, Тамчының күзләренә карады.

Тамчы башын юри күтәрмәде.

— Шулай, Вафа Сафиевич, шулай.

— Менә күрәсез, иптәш Бәдретдинов, авылдашыгыз да минем сүзне куәтли.

— Безнең авылдан түгел ул,— диде Тамчы, нидер яза-яза.

— Бәй, шулай бит әле. Без икебез дә килмешәк ич, онытып җибәрә язганмын. Кызлары чибәр, табигате, җире-суы матур булгач, мин үзем дә Карамалы кешесе булырга каршы түгел болай. Тик менә кабул итәрләрме, анысы мәсьәлә.

— Зур күл суында коенган һәр кешенең бу авылда яшәргә хакы бар,— диде Тамчы көлемсерәп.
Мидхәт, йөрәге кысылып куюын тоеп, китәргә ашыкты.
— Ярый, хушыгыз,— дип, ишеккә житүгә туктады, Тамчының күзләрен эзләде, ниһаять, Тамчы аңа таба борылды.— Сөйләшү шул инде, Тамчы, барырсыз бит?..
Вафа башын күтәреп жибәрде.
— Кызларга ышанма — Иделгә таянма, агай-эне...
— Ирләргә ышанма — Иделгә таянма,— диде Тамчы.
— Тик минем бер үтенечем бар иде, Тамчы,— дип дәвам итте Мидхәт, Вафаның шаяруын ошатмыйча, аны ишетмәмешкә сабышып.— Борчак гранулланган ашлама белән катнаш чәчелергә тиеш. Үтенеп сорыйм, шунсыз чәчтермәгез. Ашлама кайтуын Зиннуров хәбәр итәр.
Вафа һаман шаярта бирде.
— Сез дигәндә — аяк идәндә, диегез, Тамчы.
— Равил да, сыйфат комиссиясе председателе Лотфулла абзый да анда булачак,— диде Мидхәт.
— Минемчә, Лотфулла абзыйга Идел тубыктан,— диде Тамчы.
— Алай булгач, кем сайлады соң аны комиссия председателе итеп?
— Председатель Талип Бикмуллин. Үзенә кулай, вәт и сайлаттырды.
— Туктагыз әле, тукта. Ничек була инде бу? — дип, сүзгә кушылып китте Вафа.— Ул кеше ферма мөдире түгелме соң?
— Жәмәгать эше тәртибендә сыйфат комиссиясе председателе вазифасын да үти.
— Гыйбрәтле хәл бу,— диде Вафа һәм кинәт житдиләнеп Мидхәткә:— Син борчылма, Мидхәт дус, мин анда үзем дә барам. Безгә дә жилләнеп алырга ярыйдыр. Шулаймы, Тамчы? — дип, авыз ерып, кызга таба борылды...
Тамчы басуга килгәндә әнә шуларны исенә төшерде. Сәер икән бу ике кешенең дә күңелен үзеңдә тою. Башына әллә нинди уйлар килә. Икесе дә гашыйк булып, икесе дә тәкъдим ясаса... Тамчы кемне сайлар икән? Вафа китәсе егет, бер-ике ел уралыр да Казанга китеп барыр. Ә Тамчының биредә әтисе, әнисе бар. Тукта, ничек оялмыйча шулай уйлый әле ул! Күңеле Вафаны сайласа, ул аның белән жәһәннәмгә китәргә дә риза булачак ич. Тик ул мәхәббәт, бәхет ничек, кайсы яктан киләсен белми шул әле. Күңеле икеләнгән чагы. Йөрәге Мидхәтне сайлый калса, алар Карамалыда калырлар иде. Тамчы — лабораториядә, ә Мидхәт — агроном.
Хыял, хыял! Шул булмаса, Тамчы нишләр иде икән. Шуңа да юана тагын күңел дигәнең, бермәлгә дөньялар тәмам яктырып китә, эшләгән саен эшлисе килеп тора. Тамчы хискә бирелеп күккә карый, ә анда чыр-чу килеп сабан тургае сайрый, төпсез зәңгәр күктә, тай муенына таккан кечкенә кыңгыраудай, күңелле бер моң чыңлый. Кош үзе күренми, ә моңы басулар өстенә коела да коела.
Менә ул борчак чәчеләсе тәжрибә участогы. Туфрак мамыктай итеп эшкәртелгән. Вафа белән Гариф абыйсы да килербез дигәннәр иде. Килерләр микән? Ашлама ташучы машина да һаман күренми. Бәлкем ул агрегатлар янындадыр? Бүген чәчү тәгәлләнәсе көн. Иртәгә Май бәйрәме. Диспетчер Каюм абый кинооператорлар, корреспондентлар киләчәк дигән булды. Киножурналга төшерсәләр, Тамчы да эләгәчәк бит!
Тамчы, беркадәр борчылып, өс-башына күз төшереп алды. Әйе, бигүк шәптән түгел икән шул. Сөргән жир өстендә йөрергә туры килер дип, резин итек кигән булды, өстендә — иске куртка, башында — күк яулык. Әй, бу Каюм абыйсын да. Иртәрәк әйтсә ни була инде. Ичмасам, бераз ясаныбрак килгән булыр иде.

Күк йөзе чалт аяз. Таз тавындагы вышка зәңгәр һавада тулгана. Җирдән фирүзәдәй бу күтәрелә, борынны ярып черегән үлән, камыл, яфрак исе килә. Бик биектән реактив самолет үтеп китте. Якында гына йомран сызгыруы ишетелә... Яз килде, барча тереклеккә яңа мәшәкатьләр башланды. Балалар үстерәсе, азык җыясы бар. Аерата кешегә кыен: җәй буе икмәк үстерә, кыш чыгып, яз килүгә, янә шул ук хәл кабатлана. Юк икән шул инде, кеше турында фәлсәфә сатарга вакыты калмаган Тамчының. Аның күзе шәмәхә төскә кереп калган урман полосаларына төште. Полоса буйлап тракторына вымпел таккан агрегат килеп чыкты. Шуннан соң гына двигатель гөрелтесен ишетте Тамчы. Шул тирәдә тагын ике агрегат күренде.

«Алдагысы Кәрам абый булырга тиеш,— дип юрады Тамчы.— Кичә чәчүдә беренче урынны алды дип радиодан әйткәннәр иде»...

Агрегатлар да килеп җитте. Басуларны гөрелте күмде. Алар артыннан орлык төяүче машиналар... Чәчүчеләр агрегатларын тикшерә, майлый башладылар. Тракторчы егетләр, яңа шытып килгән чирәмгә кырын төшеп, тәмәке көйрәтергә керештеләр.

Тамчы алар янына килде.

— Исәнмесез! Килеп җиттекме?

— Менә фәрман котәбез,— диде Кәрам атлысы.— Киногa төшерүчеләр тоткарлый. Тегеләй ит, болай ит дигән булалар, чәчү чәчеп бетерерлек вакытны әрәм иттеләр.

Кәрам янәшәсендә авыз ерып ятучы Мәгъсүм:

— Шуңа миннән артта калдыңмы бүген? — диде һәм, ике кулын баш астына куеп, йөзен кояшка борды, күзләрен йомды.— Иң элек вымпелны минем тракторга күчереп эл, аннары сөйләшерсең абзаң белән, Кәраметдин дус!..

Кәрамның йөзенә ачу чыкты. Ул авызындагы сигаретын бер якка төкерде дә, чәчкеч янында маташкан егеткә:

— Рафаил, вымпелны Мәгъсүм абзыең тракторына күчереп куй әле! — дип кычкырды.

— Менә шулай,— диде Мәгъсүм, күзләрен ачар-ачмас көлемсерәп.— Быел, ниһаять, инандыңмы инде минем алда булуыма. Юкса, былтыр кыстырганны быел кычкыргансың дип ишеттем әле мин...

— Ә нигә, рас түгелме? Былтыр чи урыннар калдырмадыңмы, салмыш баштан эшкә килмәдеңме?

Мәгъсүм терсәгенә таянды, сул күзен кыса төште:

— Төртер җирдә кизәнмиләр, Кәрам дус. Кем эчми хәзер, әллә синме?

— Минем чамам бар.

— Чаманы аны бизмәнгә салып үлчиләр, ә кеше карынында үлчәү юк. Берәүгә йөз грамм да бугазыннан ашып киткән, күзенә ак-кара күренми башлый. Минем эчүемдә синең ни эшең бар соң әле, кем әйтмешли, синекен эчәмме?

— Шауламагыз әле, егетләр. Сезгә ни җитмәде тагын? — дип, сүзгә кысылды өлкәнрәк тракторчы Шәйморза абзый.— Кем кайда, кайчан чи калдырганны тикшергәнче, кузгала башлыйк әйдә. Атна буе рәтләп йокламаган, якты күздә тәмамласак, кайтып мунча кереп, хатыннарыгыз янында йоклар идегез, ичмасам. Иртәгә бәйрәм.

— Кая соң бригадир? Орлык, ашлама машиналары нигә озаклый?

— Ярый, Кәрамның бичәсе бар да, мин нишләргә тиеш соң, Шәйморза абзый? Талип абзый кибеттә аракы саттырмый башлаган.

— Чәчү беткәнче генә ул,— диде Шәйморза.— Акчаң бик кычкырып торса, Наратбашка барып кил. Анда өелеп ята ди.

Механизаторлар шулай дип әрепләшкән арада, «летучка» белән ике агрегат ияртеп, бригадир Зариф та килеп җитте һәм тракторчыларның арка кыздырып ятуларын күрүгә:

— Ни җаннарыгыз белән болай ятасыз әле сез, егетләр? Ни машиналарыгызга май салмыйсыз, ни чәкечләргә орлык тәямисез. Ниндәен сүлпәнлек бу! Мәгъсүм, хәзер үк кабыз тракторыңны! Кабыз да эзгә төш! — дип кыздырып алып китте.

— Борчакны ашлама белән катыштырып чәчәргә кушты агроном, кая ул ашлама? — дип сикереп торды Мәгъсүм.

— Ашлама килгәләгәнче әйләнә торсак та берни булмас. Талип абый сезгә ни әйтеп җибәрде?!

Ул арада «летучка»дан фотокорреспондентлар, кинооператорлар коелды. Бригадирдан нәрсәдер сорадылар да чәчеләсе җир башына таба киттеләр.

Зариф басып торган чәчүчеләр янына Тамчы килеп туктады.

— Зариф абый, мин Мидхәт урынына килдем,— диде кыз.

Бригадир, бу сүзне ишетүгә, кузгалырга җыенган Мәгъсүм агрегатына күз ташлады.

— Тирәнлекне тикшерергә, димәк. Әйбәт. Рәхим итегез, тикшерә күрегез. Безгә генә ышанмыйсыз инде алай булгач? Әйт әле, Тамчы, кем сине моңа өйрәтеп җибәрде? Шул Минзәлә килмешәгеме, яисә үз башың беләнме?

— Зариф абый, оят түгелме сезгә?! Мин үзем дә бик яхшы беләм аны. Сортлы борчак тик ашлама белән генә чәчелергә тиеш.

— Тиеш,— диде Зариф һәм Тамчының үзенә генә ишетелерлек итеп өстәде:— Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый. Акыллы киңәш бирәем әле үзеңә, сеңелкәш: бар, кайтып үз эшеңне эшлә.

Тамчының күзләрендә усал чаткылар чагылып китте.

— Мин биредән беркая да китмәячәкмен, Зариф абый. Һәм ашламасыз бер генә гектар җирне дә чәчтермим!

Зариф бу юлы өнәми гена аңа карап алды, әмма сүз катмады, җир башына килеп туктаган беренче агрегатка:

— Мәгъсүм, кузгал! — дип ишарә ясады.

— Ничек инде кузгал? — диде Тамчы, чем-кара күзләрен түгәрәкләндереп.— Ничек инде башла, Зариф абый?

Кыз, җавап көтеп тормастан, урыныннан купты да агрегатка таба йөгерде, трактор алдына барып басты.

— Кузгалма, кузгалмый тор, Мәгъсүм абый!..

— Кит трактор алдыннан, кычыткан чыпчыгы, — дип, ярты гәүдәсен трактор кабинасыннан чыгарды Мәгъсүм.

— Өстемнән үтсәң үт, әмма баскан җиремнән кузгалмаячакмын!..

Бу тамашаны күреп, кинооператор аппаратын чажлатып төшерә дә башлады.

— Карамалыда җыен килде-китте, этрәк-әләм, чүп-сәлән. Нишли тагын Тамчы анда? — дип сорады Зариф янәшәсендә басып торган Равилдән.

— Агрегатны җибәрмәскә маташа. Ашламасыз чәчмәскә кушуыдыр.

— Бар әйт, ашлама булмый ул бүген. Талип абый ышандырмады. Агроном районүзәктән җибәрергә тиеш, имеш тә... Әллә була, әллә юк, көнозын ашлама көтеп ятыйкмы?

Һәм Зариф Мәгъсүмгә янә:

— Кузгал! — дип кул болгады.— Кузгал инде, кузгал! Котың алынмасын, трактор астына каласы килмәсә китәр! — дип кычкырды бригадир, сабыры төкәнеп.

Мәгъсүм моторын яман үкертеп кузгала башлады. Тамчы башта читкә тайпылгандай итте, ләкин икенче мәлдә батыраеп трактор алдына ук чыгып басты.

— Башың ике булса таптат, явыз! Барыбер китмим, ашламасыз бер гектар да чәчтермим! — дип кычкырды гайрәт белән Тамчы.

Мунча хәтле машина өстенә ажгырып килгәндә терсәк буе кыз түгел, типсә тимер өзәрдәй егетең дә шүрләп калыр. Мәгъсүм, күрәсең, Тамчыны куркыр, читкә тайпылыр дип уйлады, тракторын кызның күкрәгенә терәгәнче китерде. Бу хәлне күреп, журналга төшерүче оператор да, төшерүдән туктап, кулын күтәрде: янәсе, тукта!

— Кит юлдан, диләр сиңа, кычыткан чыпчыгы! — дип җикерде сабыры тәмам төкәнгән тракторчы.

Тамчыны авылда шулай дип үртиләр иде, бу аның икенче исеме кебегрәк, кушаматы сыманрак нәрсә иде. Тамчы, буе тәбәнәк булгангамы, бу сүз белән үртәүләрен яратмый, ишетсә — ачуы чыга торган иде. Менә хәзер дә ул читкә тайпылмады, киресенчә, тагын да үҗәтләнебрәк, тураебрак, башын чөебрәк басты.

— Китмим! Үт өстемнән!..

Тракторчы түзмәде, рулен ташлап, җиргә сикерде, лач итеп төкереп куйды.

— Башымны чапмага бирәм, кеше түгел бу. Тфү!..

— Төкермә җиргә, Мәгъсүм абый, авызың кутырлар,— диде ана Тамчы.

Шул чакны трактор каршында озын буйлы Равил күренде. Ул акрын гына килде һәм Тамчыны иплэп кенә култык астына кыстырып алды да, кызның чәбәләнүенә игътибар итмәстән, бер читкә алып китте. Моны күреп, Мәгъсүм тракторына сикереп менде, кузгалды. Журналга төшерүче, Равил белән Тамчыга карап, авыз ачып калды, иң мөһим вакытны — тракторның чәчә башлавын төшерә алмады.

Кыз, башка чара калмагач, ике куллап Равилнең күкрәгеннән төяргә керешкә, ахыр килеп, егетнең моңа авыз ерып торганын күргәч:

— Комсорг, оят түгелме сезгә! — дип елап җибәрде.

Равил Тамчыны кызганыпмы, үзенең ярамастай эш эшләп ташлавын аңлапмы, бригадир янына килде дә:

— Зариф абый, ашлама килгәнче көтик, булмаса! Киночылар алар төшерерләр дә китәрләр. Моның өчен җавап бирергә туры килмәгәе,— диде.

— Председатель ашламасыз чәчәргә дип яңа гына рациядән әйтте. Ашлама я була, я юк, диде. Бүген бу кишәрлекне, таш яуса да, бетереп кайтырга кушты. Ашламаны аны соңыннан да сибеп була.

— Шулаен шулай да...

— Шулай булгач, авызында сөте кипмәгән кыз белән курчак уйнап йөрмә! Әйдә, кузгалыгыз. Кичкә кадәр участок чәчелеп бетәргә тиеш,— диде Зариф, аннары сорап куйды:— Төнгә калырга исәбең юктыр бит? Көндез бетермәсәк, Талип абый төнге сменага калдырып булса да чәчтереп бетертәчәк. Халык бәйрәмгә кайтырга тиеш, шуны уйла бераз.

Көн кичкә авышкач, участок тәмамланып килгәндә генә кишәрлек янына Гариф белән Вафа килеп җиттеләр. Күзләре кызарып беткән Тамчы аларга бередәге ызгышуны сөйләп биргәч, галим абыйсы:

— Тотыгыз да газетага языгыз. Балалар кебек елап йөрмәгез. Сезгә хәзер үз принцибыгыз өчен үзегезгә көрәшергә вакыт,— диде дә чәчелгән җир өстенә кереп китте.

Гариф Әюпович басудан җәяү кайтып киткәч, Вафа Тамчыга киңәш иткәндәй:

— Әйдә, чынлап та, өлкә газетасына язып җибәрәбез, ә? Фактлар синнән, язуны үз өстемә алам,— диде.

Тамчы җиңелчә генә итеп егетнең җиңенә кагылды.

— Чынлап язасыңмы, Вафа?

— Егет сүзе бер булыр!..

Туган авылында Гариф еш кына Карамалының үткәне белән кызыксына, аны күз алдына китерә башлады. Әтисе Әюп Латыйпов гәүдәсе кая күмелүен авылда беркемнең дә белмәве аны тәмам борчуга салды. Аның уенча, колхозның партком секретаре Харисов Карамалы вакыйгаларыннан хәбәрдар булырга тиеш иде.

Беркөнне ул Гарифның кабинетына килеп керде.

— Әюп абзый күрсә ни әйтер иде икән, Гариф туган? Гади тимерче малае — танылган галим бит. Горурланырлык бу! Һәр авылдан да чыкмый синең кебекләр...— дип, Гарифны мактап сөйләнде.

Гариф аны шул көнне озата барды. Шактый гыйбрәтле нәрсәләр ишетте ул Харисовтан. Әтисен аклар үтергәннәр. Гариф моны белсә дә, ул фаҗиганең ничек булганын белми иде. Үтергәч, аклар аның әтисенең гәүдәсен атка салып каядыр алып китәләр. Авылны чыккач та ташлап калдырганнармы, Ыкка салганнармы — һичкем белми. Карамалыда әле оешып кына килгән ярлылар комитеты председателе Әюпне кемгәдер юк итәргә кирәк булган, кемгәдер ул комачаулаган. Кемгә?

Харисов: авыл бае Рәхим, ди, ул чакырткан акларны, ул гына житкән аның әтисенең башына, ди. Ни өчен? Билгеле инде — кан дошманы. Рәхим байның бөтен байлыгын диярлек тартып алучы һәм аны ярлыларга өләшүче Әюп була.

Кич белән ул үзе Харисовларга китте. Карчыгы белән икәүдән-икәү генә торалар икән. Бердәнбер уллары Берлинга житкәч һәлак булган. Түр якта рамга орден-медальләр таккан өлкән лейтенант рәсеме куелган. Улының рәсемен әнисе умырзая чәчәкләре белән бизәгән. Чәчәкләр, киң таҗларын түбән иеп, батыр егетне кызганып сагышланалар кебек иде.

Харисовның бөтерчек кебек кечкенә буйлы хатыны чәй куеп җибәрде. Һәм ул арада самавар кайнап чыгып, өстәлгә килеп тә утырды.

— Күмер саласы юк хәзер, электр кайната самаварны, утырыгыз, әйдә! — диде ул, авыл карчыклары кебек, яулык очы белән авызын каплый төште.

Ризык-нигъмәт тулы өстәл янына утырыштылар. Хуҗа хатыны бик төбәлеп Гарифка карап-карап алды.

— Анасы, нигә алай өнсез калгандай утырасың? Теге чия төнәтмәң кая соң? — диде Харисов.

— Һәй, атасы, дөнҗада һич кенә дә кеше үлде дигән сүзгә ышанма икән. Бәй, шулай дими ни. Мин бит Гарифулланың бишеген тирбәткән кеше. Эше бик тыгыз чакта Гөлзифа түткәй: «Галимә, үскәнем, баламны гына карап торчы», дип, гел миңа керәдер ие. Әюп абзыйны әткәй мәрхүм бик ярата ие. Гел инде менә шуның турында сөйләр ие. Типсә, тупса сындырырдай таза адәм ие дә бит, алтатардан атып башына життеләр бичаракайның. Җидеме, сигезме алтатар шартлатканны ишеткән энкәй. Өйләренә ут салгач, безне дә уяттылар.

— Кһм, анасы, карале дим теге чия төнәтмәңне. Кеше синең хикәятеңне тыңларга килгәнме әллә. Яраларга тоз салып утырмасана!

— Бетте, бетте, карткаем.

— Сөйләгез, сөйлә, Галимә апа. Ярдәм итүчеләр булса, әтинең каберен табарга иде,— диде Гариф.

— Ай-һай,— дип куйды Харисов,— вакытында аны мин дә эзләшкән идем, тапмадык. Табылса, без ул кабергә чардуганлап һәйкәл куйдырган булыр идек.

— Кеше түгел, агач та эзсез югалмый, Әдһәм абый.

— Анысы шулаен шулай, Гариф энем. Ул елларда андый үлемнәр бик күп булды шул.

— Әйдә, Гарифулла, тагын берне ясыйм,— дип, Галимә карчык кунакның чынаягына үрелде. — Эчегез әле, эч. Әнә вареньелардан, балмайдан да житешегез. Менә бу төнәтмәне дә авыз итегез инде. Үзебезнең бакча чиясеннән...

— Рәхмәт. Галимә түти, чәегез дә, төнәтмәгез дә бик тәмле.

Чәйләп алгач, жылырак киенеп, хужа Гарифны озата чыкты.

Урам якка чыгулары булды, алар янына врач Кәфия килеп туктады.

— Карагызчы, Әдһәм абый, сез бигрәк батыраеп киткәнсез түгелме? — диде ул, аннары Гарифка таба борылды:— Исәнмесез, Гариф Әюпович. Я, ничек, Карамалы ошыймы, Ык буйлары ямьлеме? Безнең әрәмәдә илле төргә якын сайрар кош бар. Иртәнге якта Ык ярына чыгып бассаң, оркестрларың бер якта торсын,— дип тезеп китте ул.

— Сандугачлар матур сайрый икән шул биредә. Ык буйлары да бик ямьле. Тик вакыт кына кысанрак, Кәфия...— Гариф Харисовка күз төшереп алды. Харисов аны аңлап:

— Гыйльмановна,— диде.

— Кәфия Гыйльмановна,— дип өстәде Гариф.

Көлешеп алдылар.

— Әдһәм абый, әйдә тизрәк керегезче, саулыгыгыз шәптән түгел бит әле сезнең.

— Хәзер, Кәфия, сез керә торыгыз. Гариф туганга бер-ике сүз генә әйтәсем бар иде.

Кичке эңгер караңгысы иңеп килә, Кәфиянең өстендә кызгылт пальто, башында ап-ак калфак. Калфагын бер яккарак кырынайтып салган.

— Талип нишләп ята? Нигә бер дә килеп чыкмый?

— Райүзәккә китте, ашлама эзләргә,— диде Кәфия, кузгала башлап.

— Бәйрәм көнне дә райүзәктәме?

— Талипка бәйрәм ни ул. Митингны үткәрде дә китеп барды.

Гариф беренче күрүендә дә игътибар иткән иде: врач хатынның буесыны сылу, заманча затлы киенгән. Кыяфәте әле дә аның игътибарыннан читтә калмады. Аннары ул тагын шуны сизде: Саниясе якты дөньядан киткәннән бирле берәүгә дә болай сокланып караганы юк иде.

— Гүзәл хатын...— дип куйды Гариф.

— Талип эше талымсыз жанга әрәм дә бит, нишләмәк кирәк, бәхетне олы юлга салып тезмиләр, кирәк төштән кирәк кадәр барып алып та булмый. Өлешенә тигән көмеше инде,— диде Харисов.

— Нигә алай дисез, Әдһәм абый?

— Юк, болай гына. Савыт-сабалары шалтыраштыргалый, мәгәр тату яшиләр кебек.— Харисов Гарифның жиңенә кагылды.— Минем бер үтенеч бар иде, Гариф энем. Сезнең лабораториядә сөтнең составын тикшереп булмый микән? Аннары терлек азыкларындагы компонентларны билгели торган аппарат кирәк иде безгә. Азыкларны кайда, ничек саклаганда сыйфат югалмый икән. Киләсе елга комплекс әзер булачак, анда приборлары, аппаратлары да, лабораториясе дә булыр. Алданрак хәзерләнәсе иде.

— Сез шактый кыен сорау бирдегез әле, Әдһәм абый. Бу мәсьәләдә мин сезгә ярдәм итә алмам шул. Безнең лаборатория бөтенләй аңа көйләнмәгән. Штатта бу өлкәдә эшләүче бер генә белгеч тә юк.

— Сездә анда буш бүлмәләр дә бар-барын.

— Мин сезне аңлыйм, Әдһәм абый. Әмма ничек кенә сезгә ярдәм итәргә? Аппарат-приборлар тапсагыз, бер-ике елга мин үземнең кызымны бирегә чакырып китерә алам. Килүе тәгаен булыр дип тә әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, бу эшне оештырып булса да китәр ул.

— Гариф энем, сез безгә бу эшне башкарырга ярдәм итсәгез иде. Югыйсә бит, бөтенләй сукыр көйгә эшләп ятабыз.

...Харисов белән саубуллашкач, Гариф, кояш баешындагы шәфәкъ кызыллыгына карый-карый, ындыр табагына таба китте. Атлый торгач, кисәк кенә тимерче тыкрыгына борылды. Түбәсе балчык белән ябылган ярым җимерек алачык янында туктап уйланып торды. 1914 елга кадәр биредә, әнә теге җирдә сеңеп беткән сандал бүкәне янында, әтисе басып торгандыр, күрек тарткан яшүсмергә һәм ярдәмчесенә дәшә-дәшә, чүкече белән сабан төрәннәре суккандыр. Гариф өчен бик якын булып китте бу алачык. Әтисе басып торган урын, сандал түмәре...

Этләр һау-һаулап өреп куя, тимерче алачыгы очындагы күлдә үрдәк кычкыра, ул да түгел, якында гына мәче башлы ябалак ухылдап ала иде.

Алачыктан Гариф караңгы төшкәч кенә чыкты һәм, өенә кайтмыйча, куе таллар арасына кереп югалган сукмактан су буена таба төшеп китте.

Караңгы. Тирә-юньдәге һәммә нәрсә әкияттәгедәй үсеп, зураеп киткән сыман. Гариф килде-килде дә аяк астында комлы таш тоеп туктап калды. Колагына су тавышы ишетелде.

Ык елгасы.

Бераздан ул басма өстенә килеп чыкты. Елга өсте тыныч түгел. Чупылдап балыклар сикерешә, басма астында су күселәре ызгышып ала. Бертуктаусыз черки безелди... Рәхәт иде су тавышын тыңлавы. Онытылып китеп, Гариф үзенең эше турында уйлады. Аның башына матур-матур фикерләр нәкъ менә шундый минутларда килә торган иде.

Бабаларыбыз ашлыкны тубалдан кул белән сибеп чәчкәннәр, аннары тырмалаганнар. Күмелгәне күмелгән орлыкның, күмелмәгәне юк — кошларга ризык булып калган. Колхозлашу чорында авылларга чәчкечләр килә башлады. Ләкин ул чәчкечне күпме генә яхшыртмасыннар — рәт аралары буш кала. Кулдан сибеп чәчелгән бодай туфракка куе төште исә куе, сирәк төште исә сирәк булып шыта. Шулай да үсеп чыккан игеннәр калын көпшәле, эре башаклы булып өлгерәләр. Әмма бу ысул белән меңләгән гектар җирне атна-ун көн эчендә чәчү һич мөмкин түгел. Рәт араларын калдырмас өчен, машина белән аркылыга-буйга да чәчә башладык. Бөртек төшмәгән буш урыннар азрак кала калуын. Ләкин туфрак таптала, ягулык бермә-бер артык тотыла.

Әгәр дә мәгәр кирәк тирәнлектә күмдереп, сибеп чәчә торган чәчкеч ясалса?.. Анда инде басуларны аркылыга-буйга таптамас идек. Һәр бөртек, үзенә тиешле мәйданга төшеп, эре башаклы булып үсәр иде. Чүп үләннәргә дә урын калмас иде. Ул чәчкечне кем ясарга тиеш соң?

Промышленность. Әйе, әйе, промышленность. Ләкин ул ясамый. Ә колхозларга андый чәчкеч кирәк, менә бүген кирәк, бик кирәк. Немец фермерлары шушындый пневматик чәчкеч уйлап тапканнар, диләр. Әмма безнең шартларда эшли алмаганнар ул чәчкечләр. Димәк, үзебезгә уйлап табарга туры килә...

## 13

Борчак басуында булган хәлне ишеткәч, райүзәктә өч көн торып кайткан Мидхәт тәмам чыгырыннан чыга язды. Кичке якта ул идарә коридорында бригадирны очратты, һәм алар шактый гына тавышланып алдылар. Аннары Мидхәт ярсынып партком секретаре янына килеп керде.

Хәле чак кына аруланука, кичә эшкә чыккан Харисов өстәл янында утыра иде. Салкын тидереп атна-ун көн чирләп яткан арада аның йөзенә сарылык иңгән, күз төпләрен шәмәхә сызыклар баскан иде.

— Әйдә, Мидхәт, уз, утыр. Кем белән шаулаштың анда? — дип сорады Харисов, агроном егет түрдәге урындыкларның берсенә килеп утыргач.

— Әдһәм абый, бу ни инде тагын? Чирләп ятканда борчырга теләмәгән идем, инде хәзер әйтмичә булдыра алмыйм. Мин Талип абыйны бөтенләй аңламый башладым. Болай да кире беткән бригадирга ике йөз гектар тәҗрибә участогына ашламыйча борчак чәчәргә рөхсәт иткән. Үз урыныма Тамчыны калдырган идем, аны бөтенләй санга да сукмаганнар. Сыйфат комиссиясе председателе Лотфулла абзый чәчү чорында бөтенләй кырда күренмәде. Һич югы, мин киткәч чыксын иде, житмәсә, үзенә әйтеп киттем бит әле. Искитәрлек хәл бу, Әдһәм абый, ЧП.

Харисов дәфтәренә нидер язып куйды.

— Талип Кәрамович ни ди соң?

— Аның җавабы әзер. Чәчеп яхшы иткәннәр, ятып калганчы атып калу әйбәтрәк, ди. Җуләр баш, вакытында чәчү беткәнгә куан, ди. Хәзер әнә яңгырга китте, ди.

— Шулай да түгелме соң?

— Өстән болай явып торганда... Туктар иде әле бер. Синоптиклар туктаячак дип әйтәләр.

— Туктый, туктый, диләр, ә яңгыр атна буена сузылды әнә,— диде Харисов, Мидхәтнең сүреләп төшүен күреп, уйлап куйды: «Дәреслек өчен көрәшкәндә дәлилләрең нык булырга тиеш шул. Ә син, күрәм, инде үз фикереңнән кайтырга да әзерсең».

— Шушы көннәрдә бригадирны партиягә аласыз дип ишеттем. Хакмы шул, Әдһәм абый?

«Әнә каян суктырмакчы буласың, Мидхәт!» — дип уйлады Харисов һәм урыныннан кузгалып, ишекле-түрле йөренергә кереште.

— Мин аңа моны болай гына калдырмаячакмын, Әдһәм абый. Бригадир буларак иң әүвәл моңа Бакиров гаепле. Председатель кушкан, имеш. Кем кемгә нәрсә кушмас! Бәлкем башы белән коега ташланырга кушар. Ташланыр идеме?! Партия сафына алу түгел, колхоздан куарга кирәк андыйларны!..

— Бригадир өстеннән дәгъваң бар икән, язып бирә аласың. Җыелышта коммунистларга укып карарбыз.

— Бер бригадир гына гаепле түгел монда. Балык башыннан чери, дисциплина юк колхозда.

— Шулайрак шул. Кыш көне син, һичкем белән киңәшмичә, каеннарны кистердең, хәзер менә бригадирыбыз председатель кушты дип тәҗрибә участогына ашламасыз борчак чәчтергән. Дисциплина юграк шул колхозда.

Агроном партком секретареннан моны көтмәгән иде, аның йөзендә ризасызлык шәүләсе чагылды, Харисовка ул күз кырые белән генә сирпелеп алды да, сүзендә калырга теләп:

— Әдһәм абый, дәгъвамны телдән генә әйтергә мөмкин булырмы миңа? — дип сорады.

— Нигә мөмкин булмасын. Бик мөмкин. Алай да ярый,— диде Харисов, Мидхәт каршына килеп туктады.— Тик башта уйла, дәлилләрең нигезле булсын. Без аны партиягә алабыз. Кеше гомерендә бер тапкыр гына була торган хәл ул. Язмыш белән шаяруга кайтып калдырлык итмә. Бригадир тиз кабынучан, әмма начар егет димәс идем мин аны. Урта белемле яшь кешегә кайбер нәрсәләрне аңлавы кыенрактыр да бәлкем; тупасрак чаклары да булгалый. Менә шуңа без аны үз сафыбызга алырга уйлаган идек. Укытырга исәп үзен, кеше итәргә. Ә бу очракта ул, бригадир буларак, председатель әмерен генә үтәгән түгелме соң? Нигә үз башы белән уйлап, ашламасыз чәчәргә ярамаганлыкны аңламаган — бусы инде башка мәсьәлә, аның аңына бәйле мәсьәлә. Ләкин ул ашлама әле дә булса кайтып җитмәде түгелме? Чәчүне бетергәнгә атна вакыт үтеп бара бит инде!

— Ашлама иртәгә кайтып җитә,— диде агроном.

— Ниндидер хурлану тоясың кебек син, Мидхәт. Үзеңнең дөреслегеңә ышанасың икән, йөрәгең кушканча эшлә. Мин биредә менә нәрсәне сизенәм: миңа калса, Талип белән сез икегез дә хаклы. Берәвегез иген игүне производство агымына салырга кирәк дип бара, икенчегез, ягъни син, безгә звенолар булсын, колхозчының кендеген жиргә бәйләргә кирәк дип барасың. Шулаймы, дөрес әйтәмме? Килер ул көн, Мидхәт, «Берек» колхозының экономикасын күтәрү эше сезгә — яшьләргә күчәр. Син дә шулар арасында булсаң иде. Бу минем теләгем. Ләкин син вакланма, кеше күңелен рәнжетергә ашыкма. Әле мин коридорда бригадир белән әйтешүегезне тыңлап тордым. Чәчкән борчакны туфрактан жыеп ала алмаган кебек, бер-берегезгә әйткән сүзләрне дә жыеп ала алмассыз. Син институтта укыган кеше. Иң әүвәл сиңа кирәк иде туктарга...

...Харисов кабинетыннан чыккач, Мидхәт болдырда тәмәке тартып торучы бригадирны күрде, янынннан сүзсез генә үтеп китәргә уйлаган иде дә, Зариф аның жиңенә кагылды һәм, яңак тамырларын уйнаткалап:

— Балалар кебек әләкләргә дә өлгердеңме? — диде.

— Үз сүземне мин жыелышта әйтермен, иптәш Бакиров,— диде Мидхәт һәм сикерә-атлый баскычтан төшеп китте.

Әле төш вакыты гына, әмма көн караңгы. Бөтен күк йөзен авыр кара болыт томалаган. Вак кына иләктән коелгандай, яңгыр сибәли. Кайдадыр, олы юл буенда бугай, машина баткан, яман тавышлар чыгарып, пычрак изә. Авыл тынып калган. Сабан ашлыклары чәчелеп беткәч, халык ял итә, мунча ягалар, хатын-кызлар кибеткә жәйге кием-салым алырга килеп тулганнар, тәмәкегә дип килгән ир-атка сатучы янына ерып керерлек түгел.

Йөрәге ярсуыннан Мидхәт, яртыны алып, кунак өенә кайтып салу нияте белән, магазинга кергән иде, биредәге чиратны күргәч, кире чыкты. Житмәсә, анда Тамчының әнисе күзенә чалынып китте. Мидхәтнең битенә ут капты диярсең. Әллә соң Фәритне алып районга китәргәме? Әмма юлда каршы очраган Зиннуров аңа:

— Фәрит белән Талип абый басуга чыгып киттеләр,— диде.

«Тынгы белми бу председатель»,— дип уйлады Мидхәт, ә үзе Талиптан бераз көнләшеп куйды.

## 14

Бюродан председатель кара коелып чыкты. Сәбәбе дә бар иде шул. Бюро членнары карамалыларны башларыннан сыйпамадылар. Сыйпамадылар гына түгел, агрономны кисәттеләр, бригадирны исә эшеннән алырга тәкъдим итәлде. Талипка шәхси делосына теркәләчәк шелтә эләкте. Комсомол оешмасы секретаре белән авыл Советы председателе дә бюродан «буш» чыкмадылар — битләреннән тәмәке кабызырлык иде.

Бер уйлаганда, барысын да тигезләгәннәр иде, югыйсә. Әмма Талип белә: таякның юан башы барыбер бригадир белән аңа төште. Ә шулай ук жавап бирергә тиешле агроном Бәдретдинов әйтерсең күләгәдә калды.

Вакыты белән гаделлек өчен газиз башын үнике ач бүре алдына салырга әзер булган Талип өчен хәттин ашкан хәл иде бу. Иң әүвәл аның районадагыларга ачуы чыкты. Аңа калса, алар мәсьәләнең асылына төшенеп житмәделәр шикелле. Звено турында да сүз куертып алынды. Имеш, Бикмуллин агроном сүзенә колак салмый, ни сәбәпледер егетне санга сукмый.

Звенолар оештыруга ул жаны-тәне белән каршы. Авыл хужалыгын күтәрүне ул индустриаль жирлектә генә күрә иде. Машина-трактор

станцияләренең бөтен техникасын колхозларга сатканда да, Талип беренче булып иске тракторлардан баш тартты. Ике урынына берне алды, әмма яңаны алды. Группалап сөрә, чәчә, ура, суктыра башлагач та районда Талип җитәкләгән колхоз беренче булып шуңа кереште. Хезмәт көненә акчалата түләүгә дә беренчеләрдән булып күчте. Элек МТСларның төшенә дә кермәгән мастерскойларны да районда иң элек Талип салды. Комплекс төзүгә дә ул алдан керешге.

Әйтәсе дә юк, илле-алтмыш меңгә төшкән лабораторияне салуга Талип башта каршы иде. Ләкин бу аңламаудан түгел, ә артык акча әрәм итәргә теләмәүдән иде. Лаборатория хезмәткәрләренең Карамалыга борчу алып киләселәрен баштан ук дөрес сиземләгән икән ул. Нәкъ шулай булып чыкты да. Районда уңыш алу буенча беренче барган «Берек» җитәкчеләренә, чәчү технологиясен бозганнары өчен, шелтә «өләштеләр». Сүз дә юк, моның хәбәре өлкә газетасына барып җитмәгән булса, Талипка каршы сүз әйтүчеләрнең авызын да ачтырмас иде бәлки район.

Кемнәр язган диген әле: Галләм картның бармак буе кызы да, Талипны күреп белүдән дә ары китмәгән Вафа атлы бер Казан сорнае. Тапкан шөгыль, урталай бөкләп итек кунычына тыгасы нәмәстә!..

... Талип чираттагы партия җыелышына аерата нык хәзерләнде. Көн тәртибендә язгы чәчүне йомгаклау һәм Зариф Бакировны партия сафына алу мәсьәләсе иде. Өеннән киткәндә Талип хатынына зарланып алды:

— Сугышырга барам, берсеннән котылган идем, инде тагын икенчесе минем канымны бозарга килде. Нигә миңа гына шундый агрономнар белән эшләргә язган икән? Мин менә шуңа аптырыйм, «Марат» колхозы председателе Исмәгыйловны беләсең бит. Агрономы белән кулга-кул тотышып эшлиләр. Нигә безгә генә үзсүзле яшьләр эләгә?

— Үзең артык үзсүзле булганга шундый алар, Талип. Син үзең тоткан җирдән сындырырга яратасың. Хәзерге яшьләрнең дөньяга карашлары башкачарак, саллырак уйлыйлар...

Талип Кәфиянең ни әйтәсен белергә тели иде, чөнки хатынының күп тапкырлар дөрес киңәш биргәне бар иде.

Җыелышта Талип үзен эре тотты һәм чыгышын шундый итеп тәмамлады — аның белән һәммәсе килеште.

Икенче сорауга күчкәч, партком секретаре коммунистларны Зариф Бакировның биографиясе белән таныштырды да сүзне аның үзенә бирде.

Хәер, сөйләп, аңлатып тору кирәк идеме, белмиләр идеме аны Карамалыда, һәммәсенең күз алдында үсте. Сигез классны тәмамлагач, комбайнчылыкка укыды, аннары эшләде, кичке мәктәпкә кереп унны тәмамлады. Яхшы эшләвен искә алып, армиядән кайткач, бригадирлар курсына җибәрделәр. Күз тимәсен үзенә, тырышты. Халык белән дә уртак тел тапты. Кирәк икән, үзе дә эшләп күрсәтте, һичбер эштән баш тартмады.

Бүген исә Зариф каушый, рәтләп сөйли дә алмый. Соңгы ЧП егетнең кәефен аерата кырган, күрәсең. Аны да бит бюрога чакырдылар. Гомумән, хәтәр икән анда. Талип Бикмуллин дип баш иеп торучылар юк. Уңлы-суллы чыбыркыладылар бахырны. Дөрес, бюродан чыккач, Талип аны тынычландырды, җилкәсенә кулын куеп:

— Шелтә ул кешене чыныктыра гына, эшли бирик, Зариф туган, — диде.

Үзе турында сөйләгәндә өзек-өзек булса да әнә шул үткән-булганнарны да исенә төшерде Зариф.

— Ягез, иптәшләр, кемнең сүзе бар? Бакиров безгә бар ягы белән таныш, автобиографиясен сөйләде, Зарифны һәммәбез белә, күз алдыбызда үсте.

— Нәрсә сорап торырга, алырга кирәк, үзебезнең егет, лаек,— дип, урыныннан купты Лотфулла.

— Дөрес, Зариф ялгышкан бераз, ул турыда әйтелде инде. Минемчә дә, безнең сафта булырдай егет ул Бакиров,— диде пенсионер Галләм карт.

Чапай Мөлек исә аңа каршы чыкты:

— Ни сөйлисең, Галләметдин! Бакиров командир ул. Ә командир ялгышса, бөтен рота кырыла. Ялгышмаска тиеш командир. Ялгышты икән, ул инде командир түгел.

— Мөлек абзый, Василий Иванович бер дә ялгышмаганмыни?

Чапай Мөлек шулай диючегә җилкә аша гына карап алды да күкрәген киерә төшебрәк утырды.

— Ул герой булган, геройлар бер генә ялгышалар, Мөлек абый. Ә бу кем? Чапай мондый ялгыш ясаган командирын үз кулы белән атар иде. Игенчелектә агроном сүзе закон булырга тиеш. Һәммәбез аңа буйсынырга, карусыз аның күрсәтмәсен үтәргә тиешләр. Шуның өчен ул укыган, шуның өчен колхозда аңа дәрәҗәле урын бирелгән.

— Сез нишләргә кушасыз соң, Мөлек абзый? — диде моңарчы тын торган Талип. Ул, эсселәгәнгә, симез битенә кулъяулыгы белән җилләнеп утыра иде.

— Атарга да, асарга да кушмыйм, Талип энем. Үз ялгышын аңласын дип берәр ел сабыр итәргә кушам. Шул гына әйтәсе сүзем.

— Нәрсә инде күп сөйләп торырга, тотарга да тавышка куярга кирәк.

— Ай-һай, кеше язмышын җиңел хәл итәсез дә соң! — дип, канәгатьсезлек белдерде арттарак утыручы Кәрам.

— Миңа да бер-ике генә сүз әйтергә мөмкин булырмы?

Моны ишетүгә, һәммәсе дә тынып калдылар. Аның чыгыш ясасын җаны-тәне белән тоеп торган Зариф, агроном торып басуга, башын түбән иде.

— Иптәшләр, мин алдан ук сизәм: минем бу чыгышымны яратып бетермәүчеләр дә булыр, ләкин мин әйтмичә дә булдыра алмыйм...

Халык гөжләшеп куйды.

— Тиешлесен алды бит инде ул, яңадан кузгатып тору кирәк булыр микән? — диделәр.

— Туктагыз әле, иптәшләр,— диде Харисов, аягүрә басып.— Сүз әйтергә ирек бирик кешегә.

Мидхәт ерактан башлады. Харисов аңа карап-карап ала — кыскарак тот, ди сыман иде. Ул башта лаборатория белгечләре ярдәме белән колхозда үткәреләсе чараларның гаять мөһим булуын сөйләде. Аннары, бригадир Бакировның башбаштаклануы аркасында, шул чараларның берсе нәкъ менә бер елга кичектерелүен аңлатты. Ахыр килеп болай диде:

— Колхоз өчен туфракны культуралаштыру иң җитди чараларның берсе булып исәпләнгәндә, бригадир Бакиров бу эшкә аяк чалды. Комсомол секретаре Равил Кадыйров та бригадирга ярдәм иткән. Гафу итегез, коммунист иптәшләр, миңа калса Бакировны партия сафына алырга ашыкмаска кирәктер. Иптәш Бакиров мине дөрес аңласын иде...

Тыныч кына янган учакка гүя бензин бөркеделәр. Харисов алдында торган графинга карандашы белән суккалады, алай да гөжләү туктамагач, өстәл эченнән җиз кыңгырау чыгарып, шалтыратып алды. Бу кыңгырауны аңа мәктәпкә электр звоногы куйгач директор биргән иде.

— Иптәшләр, әйдәгез, берәмләп кенә. Тагын кем сүз ала?

— Миңа бирегез.

— Әйдә, Талип.

Председатель бөтен кыяфәте белән ерак юл йөреп кайткан кешене хәтерләтә иде. Әүвәл ул, шактый көттереп, торып басты, алдындагы кәгазьләрне рәтләштерде. Гүя ул иң кирәкле сүзләрен шул кәгазьләр арасыннан эзли иде. Ниһаять, Бикмуллин башын күтәреп сөйләргә керешге.

— Гыйбрәтле хәл бу, иптәшләр. Бик гыйбрәтле. Юк, мин моңа тыныч кына карый алмыйм. Иң әүвәл мин шуны әйтергә телим: кемнәр безгә бу лаборатория хезмәткәрләре? Нәрсә мәҗбүр итте аларны, төгәлрәк итеп әйткәндә, кем мәҗбүр итте «Берек» колхозының менә дигән алдынгы кешеләре турында гайбәт сатарга? Бу мәсьәләдә аз гына үзем дә гаепле булсам да, күңелемә килгәнне әйтми кала алмыйм. Минемчә, Бакиров та, башкалар да ул кадәр күпертеп, матбугатта күтәреп чыгардай җинаять эшләмәделәр. Борчак җирен Бакировка ашламасыз чәчәргә мин куштым. Чөнки ашлама юк иде. Кая ул ашлама, иптәш Бәдретдинов? — диде кинәт кенә агрономга мөрәҗәгать итеп председатель.— Кая ул гранулланган суперфосфат?! Минемчә, Бакиров борчакны чәчтереп ифрат дөрес эшләде. Ә ашламаны аны соңыннан да салып була. Без монда чебеннән дөя ясарга маташабыз кебек. Әйтерсең башка эшебез юк. Комиссия, тикшерү өстенә тикшерү... Чәчү вакытында берсе дә күренмәде. Без беребез дә чәчү вакытында шар сугып йөрмәдек, футбол мәйданыбыз төзелеп кенә килә әле. Без көнтөн эштә. Без икмәк үстерәбез, комплекс салабыз... Сез миңа шуны әйтегез, иптәш Бәдретдинов. Бирегә сез иген игәргә килдегезме, әллә үз карашларыгызны тормышка ашырып, карьера казаныргамы исәбегез?.. Бакиров кебек бригадирның язмышын бер кизәнүдә хәл итмик әле, иптәшләр. Кеше күңелен эштән биздермик. Мин Бакировны үзебезнең сафка алырга дигән тәкъдим ясыйм. Бакиров моңа лаек.

Председатель, кесәсеннән кульяулыгын чыгарып, бөрчек-бөрчек тир баскан бит-муеннарын сөртә башлады. Җыелыш яңадан гөҗләп алды. Мидхәт тыныч кына утыра кебек иде, ләкин Талип күз кырые белән генә күрде: Бәдретдиновның да эчендә ниндидер ут көйри иде.

Харисов председательдән күзен алмыйча карап торды. Кече җанлы булырга теләү бик әйбәт сыйфат. Кем яратмый аны. Кем яхшы атлы булырга теләмәс иде. Ләкин иң мөһиме шул: аңлармы ул кеше синең яхшылыгыңны?

...Харисов әйтәсе фикерен җыелышка җиткерде кебек, аны аңладылар. Ул Зарифка начарлык теләми, ләкин аны бүген партиягә алу ягында түгел, сабыр итәргә куша.

Талип исә соңгы минутка кадәр коммунистларның Зариф Бакировны яклауларына ышаныч тотты. Ул чагында агроном да үз кысасына әйбәтләп урнашыр. Ләкин нәтиҗә Талип уйлаганча барып чыкмады. Тавышка куйгач, Зарифның кандидатурасы үтмәде.

## 15

Ул канәгать иде, ул җиңде. Бригадирны «Берек» колхозы коммунистлары үз сафларына алмадылар, Мидхәтнең чыгышы нәкъ үз вакытында булды. Председатель бригадирны яклап чыкты, әмма барыбер ул дигәнчә булмады. Шулай, Талип Кәрамович, мин сезгә Садыйков булмам. Мин Карамалыдан качып китмәм, мин дөреслек өчен көрәшә белермен.

Кояш баеп бара. Көн буе явып торган яңгыр болытлары кичке якта чыктылар, шәфәкъ ягы аязып, кызарып, янып тора. Шагыйрьләр әйтмешли, шәфәкъ шәфәкъ белән үбешкән чак. Их, менә хәзер Мидхәт янында аны аңлаган кеше булсын иде. Мидхәт күз алдына Тамчыны китерә. Күңелендә ул кызны күрәсе килү теләге уяна. Күрәсе иде дә

бөтен серне сөйләп бирәсе иде үзенә. Тамчы, Тамчы гына, башка һичкем түгел, ул гына кирәк иде аңа бу минутта.

Әмма егетнең күз алдына озын буйлы, чандыр гәүдәле Вафа килүгә, Мидхәтнең йөрәге кысылып куйды. «Вафа-җәфа, югал күз алдымнан»,— дигәндәй, ул күзен йомып, башын чайкап алды.

Эңгер иңә башлады. Мидхәт Таз тауга таба атлый. Тау түбәсендәге вышкада соңгы кояш нурлары. Аяк асты пычрак, итекләр таш аскан кебек авырайды.

Мидхәт борылды да су буена төшеп китте. Авыл ягында адашкан сарык бәрәне бәэлди, этләр һау-һаулап өрә. Кич. Җылы. Бераз бөркүрәк. Мидхәт плащын салып җилкәсенә ташлады. Аңа тынычланырга кирәк, аулак җирдә үзалдына уйланырга, фикерләрен бер эзгә салырга кирәк иде.

Сукмак кисәк кенә авыл очына борылды һәм Зур күл яры өстенә килеп чыкты. Авыл урамнарында утлар кабынды, клуб түбәсендәге дәү радио торбасыннан музыка ишетелә. Вальс тапшыралар. Тыңлавы рәхәт. Күл өстеннән выжлап үрдәкләр очып үтте. Күлнең аръягындагы учаклыкта каргалар кыштырдап-шыбырдашып куялар.

Мидхәт яр кырына килеп басты. Күл өсте тын. Кайдадыр адашкан бер үрдәк бакылдаганы гына ишетелгәли иде. Аннары Мидхәт кемнеңдер тыенкы гына көлүен ишетте. Бу көлүдә иркәләнү дә, назлану да бар кебек иде. Ул әйләнә-тирәсенә күз йөртеп чыкты. Кеше-фәлән күренми. Ләкин тавыш килде бит, ишетте бит ул аны.

Менә алар. Кыз белән егет, кулга-кул тотынышып, яр буйлап киләләр иде. Вафа белән Тамчы түгелме соң?

Үзләре!..

Вафа Тамчының ике кулыннан тотып әйләндереп җибәрә дә, җай китереп, җиңел генә күкрәгенә кыса, үбә. Озак итеп үбә. Мидхәт хәтта Тамчының ирен тәмен тойган сыман булды.

Менә алар сабырланып, кузгалып киттеләр. Көнләшерлек иде. Кулга-кул тотынышып, гамьсез һәм кайгысыз бер кыяфәттә, шул ук вакытта, бер-берсенең кул-йөрәк кайнарлыгын тоеп атлыйлар иде гашыйклар. Мидхәтнең беркайчан да бу кадәр кимсенү тойганы юк иде әле. Эш дип, хезмәт-вазифа дип, моңа кадәр һичкемгә сиздермичә күңел түренә яшереп йөрткән иң изге хисен буып торган икән бит ул. Әлегә кадәр, менә бу очрашуга кадәр, аны бу тойгы ул кадәр борчымый торды. Өлгерер кебек иде әле. Ә менә соңга калган булып чыкты. Йөрәк әрнешә, күңел түреннән үпкә хисе калкып чыкты.

Кемгә?

Әлбәттә, үзенә, үзенә генә.

Тамчының сөйгәне бар, ул Вафаны ярата. Икәүдән-икәү генә күл буенда йөриләр — мәхәббәт дулкынында чайкалалар. Мидхәт эчтән газапланды. Дөнья куып, мавыгып эшләп йөрүе, председатель белән дәгъвалашып-тиргәшеп бәхәскә керүе, җыелышларга барып, бригадирны хурлавы, ниһаять, дөреслекне исбат итәм дип үзенә дошманнар табуы, шуңа карамастан, ахыр килеп җиңү шатлыгы кичерүе — һәммәсе дә гүя юкка чыкты, гүя җил алды.

Мидхәтнең бу минутта йөзләрчә тылсым белгән күз буучы буласы килде. Хәзер менә күтәрелеп чыгасы иде дә, икесен дә сихерләп, май аендагы салкын суда коендырасы иде. Кайнарланып гыйшык диванасы булып йөрүдән сүрелсеннәр, тирә-юньнәренә әйләнеп карасыннар иде. Аерата Тамчының күзен ачсын иде. Күрче, күрче, Тамчы, синең алдыңда сине тагы да көчлерәк яратучы егет басып тора. Айны, гыйшык диванасы булып йөрмә, диясе иде үзенә.

Вафа белән Тамчы күздән язгач, Мидхәт аягүрә басты һәм күл буйлап китте. Йөзне сыйпап салкынча дымсу һава агыла. Аяк астында йомшак мүк, күл читендә камышлар пышылдашып ала. Балыклар

сикерешә. Рә тавы өстендә бер ягы китек ай күренде. Аның барлыюклы тоныкнуры төшкәч, су өсте көзге кебек ялтырап калды.

Күл читендәге түмгәкләргә аяк төртелеп-төртелеп китә. Алда басма күренде. Басма өстендә кеше бар сыман. Ләкин икенче карауда басмада берәү дә юк иде инде. Мидхәт, аяк тавышы ишетеп, туктап калды. Юк, берәү дә юк. Курыкканга куш күренә, шул гына. Бу ниткән шигәю соң әле? Кем аны сагаласын?..

Тымызык май төне һавасында сәер тынлык. Еракта, бик еракта самолет гүләгәне ишетелә. Басмада кемдер бар иде бит. Күрде ич ул аны, күрде.

Үзалдына елмаеп куйды. Су кызы булдымы әллә?

Мидхәт басмага керде, күл өстенә карап уйга чумды. Шунда ул үз артында тагын аяк тавышы ишетте. Ләкин әйләнеп карамады. Вафа белән Тамчы булса, әйдә, артларыннан сагалап йөри дип уйламасыннар әле.

— Шатлыктан күл буена төшеп хозурланырга булдыңмы, дус кеше?

Кукрәк түреннән чыккан зәһәр авазны ишетү белән Мидхәтнең тәне буйлап кымыржу үтте. Аның артында басып торучы — бригадир Бакиров иде.

— Әйдә,— диде Мидхәт, каушап калуын сиздермәскә тырышып.— Матур биредә, бер дә китәсе килми. Сөйгән ярларым булса, төннәрем шушында уздырыр идем, таң атуларны бергәләп каршылауга ни җитә дә бит...

— Күрәм, дускай, шатсың, хискә дә урының калган. Теләгемә ирештем дисең инде?..

— Ялгышасыз, Зариф. Мин сезгә...

Бакиров аңа таба бер-ике адым атлады. Эчке бер саклану белән Мидхәт аякларын киңәйтебрәк басты.

— Һа-һа-һа! Күрәм, дускай, сеңерең ул хәтле каты түгел икән синең. Җыелышта бик батыр идең түгелме соң! — Зариф аңа якыная төште.— Карале, Мидхәт, әйт әле чынын гына. Кешене эт итеп ташлавыңа вөҗданың газапланмыймы? Үртәлмисеңме, үкенмисеңме дим?!

Бригадир киң җилкәле, беләк-буыннары нык иде. Тазалыгы кыяфәтеннән үк күренеп тора. Мидхәт исә аның янында йолкыш кына, имән янындагы кәҗә талы кебек кенә. Кыйнарга ниятеме әллә? Соңыннан ни белән бетәсен күз алдына китерә микән бу Бакиров! Вафа белән Тамчы ерак китмәгән булырга тиешләр әле. Кычкырсам? Юк, сукмый калып, мин кычкыруга тегеләре килсәләр? Көләрләр, гарьлегеңнән җир тишекләренә кереп китәрсең. Курыкма, Мидхәт, бәйләнә калса, каршы тор!

— Аңлагыз шуны, Зариф, мин сезгә булдыра алган кадәр ярдәм итәргә тырыштым.

— Һә-һә-һә! Нинди изге кеше, әйтәсе дә юк!

— Һәр кеше ялгышы өчен ниндидер җәза алырга тиеш.

— Җәза алырга?! — диде Зариф, Мидхәткә таба тагын бер адым атлап.— Син минем телемнән тартып алдың бу сүзне. Мин сиңа нәкъ менә шул турыда әйтергә теләгән идем. Әйе, әйе, явызлык җәзасыз калмаска тиеш. Бик дөрес әйтәсең,— диде бригадир, һәм Мидхәт саклanырга да өлгермәде...

Су салкын иде. Өскә калкып чыгуга, аяк очы төпкә тиде. Басманы чамалады, шунда таба тибенде.

— Кул биримме, үзең дә чыга алырсыңмы? — диде Зариф, кинаяле генә көлемсерәп. — Түзәрсең, Карамалыга килгән һәр кешене без Зур күлдә коендырып чыгарабыз. Бабайлардан калган йола ул. Бик узына башладың, изге суларның шифасы тиеп куймасмы үзеңә.

Мидхәт дәшмәде. Басма баганаларына тотына-тотына, күл читенә

кадәр килде дә, судан чыгуга, калтырана-калтырана, басма ягына әйләнеп тә карамыйча, авылга таба китте.

Кунак йортын караучы Хәтимә апа Мидхәтнең лычма суга батып кайтып керүен күрде дә аһ итте.

— Әллә яңгыр явамы, аязып тора иде түгелме соң?

— Суга төштем, — диде Мидхәт, алдаша алуына сөенеп. — Ауга барган идем, үрдәк артыннан суга кердем...

Мидхәт, лач-лоч басып, бүлмәсенә кереп китте.

— Хәзер үк чишенеп ташла, чайкап куярмын,— диде Хәтимә апа.

Мидхәт бүлмәсенә керде дә, утны кабызмый гына, өстен чишенеп ташлады. Коры киемнәрен алып киде. Алай да калтыравы басылмады. Ут алды. Күзе юеш киемнәргә төшүгә, әллә нинди сәер бер хискә бирелеп, шаркылдап көлеп куйды.

Тавышка Хәтимә апа килеп керде.

— Ни булды сиңа, Мидхәт?

— Аракыгыз юкмы сезнең, Хәтимә апа?

— Аракы. Алла диген, акыллым. Ул шайтан суын өемдә тотаммы соң! Каты гына итеп кайнар чәй эч.

Ашханәгә кергәч, ул, картлар сыман бөкрәеп, урындыкка утырды. Күшеккән бармаклары белән йомрыны ике куллап тотты да, эссе будан сулышы каба-каба, кайнар чәй эчте. Берне эчте, икене, өчне.

— Чирканчык алдың инде алай булгач,— диде чәй ясап торган Хәтимә апа.

— Алдым,— диде Мидхәт.

— Мине дә Карамалыга килен булып төшкәч күлгә атканнар иде. Киемем-нием белән күтәрделәр дә бәрделәр менәтерәк.

Мидхәт, ачкан авызын яба алмыйча, таң-хәйран калып, Хәтимәгә карап катты. Һәр чак яулыгын чөеп бәйләгән, тутсыл йөзле, зур зәңгәр күзле һәм кай ягы беләндер күмер ягында яшәгән дәү апасына охшаган бу хатын да Карамалыныкы түгел икән ләбаса.

— Җәгъфәр белән кич йөрергә чыккан идек. Ул да әйтмәгән булды. Соңыннан үзенә үпкәләп бетерә алмадым. Өр-яңа күлмәгемне боздылар, гел төсе китте.

— Чынмы, юриме сөйлисез, Хәтимә апа?

— Кемгә чын, кемгә юри. Башта мин үзем дә Карамалыда җыен җүләр яши дип барган идем. Соңыннан өйрәндем тагын үзләренә. Усал булсалар да, ярдәмчелләр. Өем җимерелгән ие, председатель менә монда күчерде, җитмәсә, хезмәт хакы түли, пенсия алам.

— Әйе, әйтәсе юк, шәп йола,— диде Мидхәт.

Хәтимә апа тыенкы гына кеткелдәп көлеп куйды.

— Яшергән була тагын, сине дә күлгә аттылармыни?!

## 16

Гариф бик иртә уянды. Бу сәбәпсез түгел иде. Кичә кич ул кызы Әдиләдән телеграмма алды. «Әти, каршы ал, иртәгә әби белән Карамалыга очабыз»,— дигән, рейс номерын, сәгатен әйткән. Тик кызының нинди уй-ният белән килүен генә белми иде ул. Хәер, ни өчен генә килмәсеннәр, Гариф моңа шат. Сагынуы да җиткән бугай, йокысы йокы булмады, аларны уйлады.

Торып киенгәч, Гариф идарәгә юнәлде. Анда һичкем юк иде. Ә ишек ачык. Ул түр бүлмәгә атлады, тәрәзә каршына килеп басты.

Биредән бөтен Карамалы уч төбендә кебек күренә икән. Куе зәңгәрсу төскә кереп Рә тавы сузылып яткан. Тау түбәсеннән бераү ат чаптырып бара иде — ул, әкият батырыдай, дөрләп янган ут эченә ташланды — кояш нуры очларында ялтыраган каеннар арасына кереп

югалды. Тау артыннан дәү ут шары күтәрелеп килә. Кояш күтәрелгән саен агара һәм кечерәя бара кебек.

Гариф тыкрык башындагы өйгә күз төшерде. Шифер түбәле, алты почмаклы өйнең морҗасыннан куе аксыл төтен күтәрелә, әмма һава артык дымлы булгангамы, төтен манарасы шундук сүтелә-сүтелә җиргә сыена, сыегая бара, йөри торгач, бакча башындагы ак томанга барып кушыла.

Йортның бакча ягында таш өй бар. Аның белән янәшә диярлек агач келәт. Бу аның әтисе белән әнисе яшәгән йорт. Каралты-курасының барысы сакланмаса да, таш өйләре һаман хәрабә хәлендә тора бирә. Гариф шушы таш өйдә туган. Хәтфәдәй бәбкә үләне белән капланган ишегалдында төпсез ыштаннан беренче тапкыр тәпи йөреп киткән...

Карамалыда булган хәлләрне исенә төшерә башладымы, Гарифнең күңеленә әнисе әйткән сүзләр килә. Әнисе еш кына:

— Әллә нигә шунда кайтасым килә, улым,— дияр иде, күз яшен сөртә-сөртә.— Әллә атагыз тарта, әллә йорт нигезем, әллә туганнарым,— дип, капыл гына боегып калыр иде.

Гарифнең күңел түрендә әнисе сүзләре яңгырый: «Рәхим бай кияве генә атаң башына җитүче. Ул җибәргән казакларны безнең өйгә. Волостька хәбәр итәргә атаң атчабар да җибәрергә өлгерми калды».

Рәхим бай кияве? Кем ул, кая ул кеше хәзер? Әллә ул да давыллы еллар корбаны булдымы?

Шул турыда партком секретареннан сорагач, Харисов аңа: «Рәхим бай белән улы Хәсәннең гүр иясе булуларына илле еллап гомер үтте инде. Ә менә кияве белән кызы әле булса яши бирәләр»,— дигән иде.

Тик шунысы сәеррәк: Колчакның «алтын эшелон»ын сакларга билгеләнгән подполковник Солодовников казаклары арасына каян һәм нинди юллар белән барып эләккән икән бу Карамалы авылының Гайзулла атлы кешесе?

Уйланырлык иде хәлләр.

Нигә, ни өчен подполковник Солодовников Карамалыга отряд кадәр отряд җибәрә?

Гариф күз карашын янә Рә тавына төшерде. Нәкъ тау сыртыннан комбайн үтеп бара. Яз һәм комбайн. Ремонттан чыккандыр.

Нигә соң әле озаклады бу председатель? Автобус белән генә китәсе калган икән.

Рәхим байның кызы һәм кияве исән? Тукта, тукта! Алар биредә торалар диде түгелме соң мәрхәмәтле Харисов? Бәлкем шул кешеләр беләдер әтисенең гәүдәсе кая ятканын? Алай дисәң, аны эзләүдә Харисов үзе эзләшкән, тапмаганнар. Артельнең иң актив өч кешесен табалар, ә менә әтинең...

Кемдер керде. Керде дә, түргә үтмичә, ишек төбендә таптанып калды. Гариф моны күреп түгел, тоеп белде: председатель түгел иде бу, башка берәү иде. Гариф аңа таба әйләнеп карады. Ишек катында, түргә үтим микән, юк микән дип, шактый олы яшьләрдәге бер карт басып тора иде. Карт киң җилкәле, эре сөякле. Башында чите чучка колагыдай сәлперәйгән киез эшләпә. Тупас йөзле, сул як бите буйлап колагыннан авыз читенә кадәр яра эзе сузылган. Бу яра аның өске иренен куян иренен охшатып калдырган, картның хәтта маңгай тирәсенә дә эз салган: сул күзе ярым йомык. Ул ничектер үзе дә уң ягына борылыбрак баскан икән, ямьсез ярасын яшерергә тырыша кебек иде.

Гариф дәшәргә дип авызын ачарга өлгермәде, карт икегә сынып бил бөкте — исәнләште. Һәм Гариф шуны искәрде: картның күзләре капыл гына киңәеп китте, сул күз төбе тартышып тора башлады.

Гариф бу сәер картны Карамалыда беренче тапкыр күрә. Гаҗәп сәер кыланды карт аны күрүгә. Хәтта кулындагы таягы да калтырый башлады кебек.

Җилләнеп председатель килеп керде. Керү белән үк ишек төбендәге картка дәште.

— Исәнме-саумы, җизни, хәл-әхвәлләр ничегрәк, түткәй ниләр бетереп ята?

Карт аңа ирененнәрен кыймылдатып кына нидер әйтте.

Председатель Гариф янына үтте, кул биреп күреште.

— Әйдәгез, Гариф Әюпович, кабинетка керик!

Ул шулай диюгә, ишек төбендәге карт тамак кырды.

— Талибулла,— диде ул карлыккан тавыш белән,— Таҗылбанат түткәң сырхаулап китте бит әле.

— Больница чәк кенә арырак бит, җизни. Духтырга күренсен, Кәфия киленеңә.

— Һм, үземнең дә йомышым барые шул.

— Йомыш? — диде Талип бирмәлгә тукталып.— Нинди йомыш, җизни? Тагын түткәй кыерсытамы? Әллә тагын шул Кәнзел белән тынышмыйсыңмы?

— Йомыш дип, ни, Талибулла...— Карт күтәрелеп Гарифка карады. Аның бердәнбер исән күзен сары май ярысы каплаган, шуңамы, күзе яшьләнә төшкән, ә кысылыбрак торган сул күзе йөзен тагы да ямьсезли иде.— Һмм,— дип йөткереп алды карт,— бал бирәсез дип ишеткән нем. Пенсионерларның исемлеген төзеп яталар икән дип әйттеләр.

— Бал...

— Түткәң сырхаулап китте бит әле. Яңа бал дип җанга тия. Тәкатемне корытты инде. Шифасы тимәсме дигән була.

Председатель стена аша бухгалтер Кәримуллага дәште.

— Нәстә, Талип Кәрамович? — дип килеп керде Кәримулла.

— Картларның бал ведомосте әзерме?

— Хәдичә төзи, бетереп җитмәгән әле.

— Төгәлләгез дә кертегез. Абыстаегыз урынга калган ди әнә, авыру балаларыгызны кем өшкерер...

Гариф аптырап председательгә карады. Талип әлеге карттан рыялап көлә иде. Нигә ул кадәр яман итеп олы кешене мыскылларга? Карт чын-чынлап карчыгы турында кайгыртып, өлешенә тигән балын алырга дип килгән. Бөкресе дә әллә кайда чыкмагандыр, мөгаен, колхозда эшләп чыгаргандыр. Ярасын да шунда алгандыр. Бәлкем сугыш инвалиды дадыр әле.

Кәримулла чыгышлый картка таба өнәми генә карап алды. Боларның барысын да күреп торган Гариф түзмәде, төрттерә төшеп, кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла, дигәндәй:

— Бухгалтерыгыз олылар белән исәнләшергә дә теләми...— дип куйды.

Талип кесәсеннән ачкыч чыгарып, кабинетын ачарга тотынды.

— Аның әтисе ул, Гариф Әюпович. Заманында өч яшьлек улы белән хатынын ташлап, Рәхимбай кызы Таҗылбанатка өйләнгән адәм. Гайзулла мулла дигәннәре шул кеше инде. Сез аңа шаккатып тормагыз. Ул үзе болай карар күзгә генә мескен кебек. Ялгышмасам, сезнең әтиегез турында да хәбәрдар кеше ул.

Көтмәгән бу картны күрүе, председательнең шундый сүзләр әйтүе Гарифны сәер бер хәлгә салды. Ләкин аның бирегә килүенең максаты башка лабаса. Вакыт үтә. Әдилә белән әнисен каршы алырга соңга калуы бар. Моны әйткәч, председательнең хәтта йөзе ачылып китте. Ул шундук үзәк диспетчерлыкка шалтыратты.

— Каюм, «Москвич»ны идарәгә җибәр әле. Шоферы юк? Фәрит утырып килсен.— Председатель аппараттан кулын алды да Гарифка карады.— Сезнең белән сөйләшәселәр бар әле, Гариф Әюпович. Һаман вакыт җитми. Дөнья куабыз да дөнья куабыз. Басуларны күзәтә-күзәтә йөрисез. Нинди дә булса киңәш-тәкъдимнәрегез бардыр дигәндәй.

— Картограммалар төзелеп, төгәлләнеп беткәч, рекомендация язарбыз. Экономист кирәк сезгә, Талип Кәрамович. Колхозыгыз зур, сөрү мәйданнарыгыз шактый. Кырларыгызда уңышлы кара туфрак, ашламалардан яхшы файдаланганда теләсә нинди елны да югары уңыш алырга була сезнең кырларда.

Кабинетка райком инструкторы Алиев килеп керде. Ул бүлмәдәгеләр белән күрешеп чыкты да кепкасын салып өстәлгә куйды.

— Председательләргә рәхәт тә соң, билләһи. Уттай эш өсте, кырда бәрәңге утырталар, механизаторлар юл сала, транспорт җитми, ә хөрмәтле иптәш Бикмуллин кабинетында утыра. Юлга машиналар бик аз чыга бит, Талип абый,— дип кинәт сөйләү тонын үзгәртте Алиев.— Экскаватор тик тора. Инженерыгызның транспорт турында тынлыйсы да килми. Дүрт үзбушаткычыгызның икесен генә бирсәгез дә эшләр җайлана төшәр иде.

— Үзбушаткычлар басуга торф чыгара,— диде председатель, нигәдер түбән карап.

— Тракторлар бирегез, арбалылары да ярый.

— Ярармы соң?

— Ә нигә ярамаган!

— Юллар өчен борчылып, минем үземнең дә йөрәк әрни, Алиев иптәш. Сез чыбыркыламасагыз да, әйбәт, билгеле. Бөтен техниканы шуңа җигәр идем. Тик, булган-булган, асфальт юл булсын иде. Зрә машиналарны өзәбез бит. Яңа машина алуыбыз була, ике-өч елда гамәлдән сызабыз.

Ул арада ишек төбендә «Москвич» сигналы ишетелде.

— Әйдәгез, Гариф Әюпович,— диде Талип, урыныннан кузгалып.

Гариф машинага утырганда Кәфиянең идарәгә таба килүен күрде һәм баш иеп аңа сәлам бирде.

Бу хатынны күргән саен бер тойгы биләп ала аны. Дөрес, ул озакка бармый. Иртәнге томан кебек тиз генә таралып та бетә. Әмма шунысы да йөрәккә сагыш сала: хәтеренә Саниясен төшерә. Саниясенә охшаган икән бит бу врач хатын.

Гариф үз-үзенә ачыш ясагандай алга карады. Грейдер үткән юлдан чапкан «Москвич» Чәчәганак тавын менеп бара иде инде.

17

Бал язуын алды алуын Гайзулла, әмма өенә таба аягы тартмады. Идарәдә күргән ят кеше аның бөтен уй-зиһенен чуалтып ташлаган иде: эч пошу гына түгел бу, күңеле нидер сизенеп шомлана иде. «Ни калган бу Казан кешеләренә Карамалыда?.. Их, дөнья!..» дип көрсенеп куйды Гайзулла һәм сәер шәүлә күреп туктап калды. Каршында, калтыранган кулларын сузып, эчкече шадра Инсаф басып тора иде.

— Мулла абзый, бер генә сум... Зинһар өчен... Үләм бит инде...

Гайзулла Инсафның күп-күмгәк булып беткән кулларына, аннары шешенеп агарынган йөзенә, чөгендергә охшап калган борынына күз төшереп торды.

— Шул шайтан суын эчми түзеп булмыймыни соң, Инсафетдин?

— Мулла абзыкаем, нибарысы бер генә сум...

Гайзулла кесәсен капшап карады, анда кичә җыйган өч-дүрт көмеш сәдака бар иде,— чылтырап куйдылар. Инсафның йөзе сытылды. Ул калтыранган куллары белән Гайзулланың бәрхеттән теккән пиджак чабуына ябышты.

— Зинһар өчен... Мулла абзыкаем!..

Инсаф җиргә үк тезләнде.

— Тор! — диде Гайзулла ачу белән.— Шайтан суы эчеп иманыңны сатма, иблис коткысына бирелмә. Адәмгә кол булсаң да, хәмергә кол булма!.. «Бу Инсафетдин казанлыларның ни өчен авылга килүләрен

белә булса кирәк, әллә берәр сумны төртеп сорыйсымы үзеннән?» диган уй килде картның башына.

— Син, Инсафетдин, гел шул тирәдә ураласың, Казан кешеләре нишләп йөриләр безнең Карамалыда? Ни дә булса тикшерергә килүләреме, әллә лекция-мазар сөйләүчеләр генәме?

— Тимерче Әюп малае Гариф ул, мулла абзый. Карамалы җирләреннән икеләтә уңыш алырга килгән. Безне өйрәтергә исәбе, ди. Безне, җир ашап үскән агайларны! Мин бит, мулла абзыкаем, үзем менә диган чәчүче идем. Сөрдем дә мин бу колхозга, ашлыгын да чәчтем, көтү дә көттем. Зинһар өчен, мулла абзый...

Гайзулла кесә төбендә чылтыраган көмешләрне Инсафның учына төртте дә китеп барды.

— Карале, мулла абзый, җаным, урының оҗмахта булсын, юлына алтын яусын!

«Алтын яусын,— дип пышылдады Гайзулла, янә үзенә текәлеп карап торган Әюп малаен исенә төшерде. Әйе, Әюпнекеләр үз тәкъдирем белән гүргә кертмәсләр, ахры, мине. Кан саркып торган ярага тоз сибәргә генә торалар».

Сизде бит күңеле, күрү белән атасына охшатты. Борылып чыгып китәсе генә булган да бит.

Гайзулланың аркасы кымырҗып китте, зиһене томаланды. Былтырларны Гөлзифасын күргәннән соң җан тынычлыгын югалткан иде, быел әнә малаена тап булды.

«Нигә эзәрлекли мине болар? Билгеле инде, Әюпне кем үтерүен беләселәре килә. Алар гына белерлек хәлме ул! Егерме генә түгел, илле ел үтеп китте бит инде, илле!»

Тәмам пошаманга бирелгән Гайзулла, үзе дә сизмәстән, тимерче алачыгы тыкрыгына юнәлде. Нигәдер бүген кеше-кара күзенә чалынып йөрүдән курка иде ул. Тимерче алачыгын узгач, Гайзулла, кырт борылып, куе таллар арасына кереп китте. Биткә сыдырылган тал ябалдашларын читкә этә-этә атлаганда да, үз бакчасы башына җиткәч тә, аның зиһенен һаман шул сорау борчыды. «Әллә тагын мине эзләвеме бу Әюп малаеның? Булмастыр. Курыкканга куш кына күренәдер».

Таллыкка керүгә Гайзулла дымлы һава агымын тоеп туктап торды. Әллә нинди яман бер хатирә чабуыннан тарткан кебек булды аны. Кайчандыр Гайзулланың салмак кына агып яткан тормышын кинәт айкап-актарып ташлаган урын иде бу, язмышында кискен борылыш ясарга мәҗбүр иткән «тылсымлы» урын иде. Шул җир аны гомере буена бирегә тартты. Әүвәл Таҗылбанат, аннары... Юк инде, юк, аның турында Гайзулла һичкемгә әйтмәде дә һәм әйтмәс тә. Биредәге хәзинә аныкы, аныкы гына!

Менә Гайзулла тезләнде, черегән тал яфракларын актарып, дымсу җиргә учын куйды. Куе агач ботаклары арасыннан кояш нурлары үтмәгәнгәме, авыр ис килә, баз дымы аңкый иде.

Гайзулла башын күтәреп өскә карады. Тал ябалдашлары кушылган төштә кояш нурлары уйный, якында гына каты тавыш белән ала карга кычкыра иде.

Гомер, гомер... Ул чакта бу тирәкләр дә болай колач җитмәслек түгел иде әле, кер чайкарга төшкән яшь киленнәрдәй бөгелеп-сыгылып торалар иде. Шулар арасында ул Таҗылбанатны да күрде. Тал чыбыгыдай зифа буйлы бай кызы аның каршында пәйда булгач, Гайзулла бөтен тәнендә кайнар кан уйный башлаганын тоеп тәмам каушап калды. Әйе, андый хәл дә булды. Бай кызы, имеш. Гайзуллага тиң кешеме! Өйләнгән һәм инде баласы булган Гайзуллага? Бактың исә ул да шул камырдан әвәләнгән икән. Гайзулла кочагына эләккәч, аваз да салмады, чәбәләнмәде дә. Инде Гайзулла, кулына күтәреп, куе таллыкка алып кергәч, Таҗылбанатның кайнар сулышы аны тәмам акылдан

шаштыра язды. Җанын бирергә әзер иде ул бу минутта Таҗылбанаткә. Һәм шулай булды да. Гомерен аның белән үткәрде...

Гайзулла күтәрелде дә якындагы тал төбенә утырды. Былтыр гына кисте әле бу тирәкне. Хәер, күп кисте инде ул аларны, әмма бер тирәкне саклады, балта-пычкы тидермәде. «Нигә бусын да кисмисең?» — дип йөдәткән Таҗылбанатка: «Торсын, бабай төсе ул».— дигән булды.

Бер уйлаганда, әллә кайчан онытылган хәлләр дә бит, юк шул, картайган, көч-гайрәте сыегайган саен Гайзулланың вөҗданын һаман нидер эзәрлекли, нидер кимерә. Элек ул бу турыда уйламый да иде. Сабира да үз гүрендә ята бирә, бабасы да борчымый иде. Хәзер әнә көн аралаш төшенә кереп җәфалыйлар, кайсыбер төнне шабыр тиргә батып уянып китә Гайзулла. Уяна һәм шуннан бөтенләй йоклый алмас була.

Гайзулла күзен җиргә текәде. Биредә җиләс, рәхәт булгангамы, күзләр черемгә йомыла. Әмма Гайзулланың күңеле еракта-еракта — үткәндәге уй-хатирәләргә чумган иде. Әллә шулардан арынырга теләп, әллә черем итеп китүдән куркып, Гайзулла тәмәке тартмасын чыгарды һәм ике бармагы белән чеметеп тел астына он кебек вак тәмәке салды. Моңа ул үзбәкләрдән өйрәнеп кайткан иде, басмачылар белән йөргәндә.

Их, заманнар диген син аны! Әле кайчан гына Карамалыда Совет оешып киләдер иде. Бүген әнә көч-гайрәт оруларыннан котың алыныр, билләһи. Кем белгән бит аның шулай буласын. Сабирасын ташлап, Таҗылбанатка өйләнмәгән булыр иде. Ә бит хатыны Сабира актив булып йөрде, зур кеше буласы иде. Малае, Кәримулласы, кем булды диген — бухгалтер, түрәләр рәтендәге кеше. Ничек уралып китте диген ул бу Таҗылбанат белән?

Сабый чакта Гайзулла Таҗылбанатларның ишегалларына да керергә курка иде. Бер тапкыр кызгаияреп кергәч, яшь абыстай кычыткан белән пешекләп чыгарган иде аны. Таҗылбанатны Гайзулла оҗмахтагы хур кызы итеп күрде. Матурлыгы күз камашырлык иде. Бай кызы урамга чыкканда бөтен авыл халкы капка-читән аша соклапып, көнләшеп калыр иде. Киенә дә белә иде үзе: өстендә — атлас күлмәк, зифа сынына сыланып торган камзул, муенында — гәрәбә, кулларында — зөбәрҗәт кашлы беләзек, бармакларында берсеннән-берсе матур кашлы энҗе-алтын йөзек...

Ә Гайзулла?

Атасы бик үк ярлы рәтенә кермәсә дә, артык җитешле дә яшәмәде: яз җитүгә әҗәткә керә иде, хуҗалыгы бер аттан узмады. Хәер, яшьләр арасында Гайзулланың абруе бар иде барын. Сабан туйлары житсә, авыл саен көрәшкә йөри, бүләкләр алып кайта иде. Әюпкә бирешсә дә, якын-тирә авылларда икенче урынны Гайзулла тота килде. Гәүдәгә ул юкарак, тимерче Әюп кебек юан-таза түгел, һәр кигән кием килешеп торыр иде. Авыл кызлары арасыннан аңа кияүгә чыгарга теләүчеләрне санасаң, бер олау булыр иде.

Гайзулланың күз алдыннан бөтен гомере уза. Ул ярым йомык күзләре белән җиргә текәлгән дә уйга чумган. Иртәме-соңмы, бу уйлар килергә тиеш иде аңа. Үз вөҗданыңнан кача алмыйсың шул. Аңа барыбер бу хәлне кемгә булса да сөйләп бирергә туры киләчәк бит. Кемгә? Нигә? Илле ел белмәгәннәр икән, нигә хәзер белергә тиешләр? Әюпкә дә, Сабирасына да бер ул гына кул салмады ич! Ләкин аның кулыннан бик күп кеше үтте. Бик күп. Әйтерсең язмыш аңа үзе корбан китереп торды: теләсә-теләмәсә дә, кеше җанына кул салырга мәҗбүр итте. Ләкин бит заманы шул иде: я алар безне, я без аларны. Әмма алар өстен чыктылар. Ә бит Гайзулла дөрес башлаган кебек иде. Авылның иң бай кешесе булган Рәхим кызына өйләнде. Әлбәттә, революция давылы авыл өстеннән жилләнеп узмаса, күрәсе түгел иде Гайзулла Рәхим бай кызын. Заманында нинди генә егетләр Таҗылбанатка баш-

кода җибәрмәде. Бай якын да килмәде. Зурдан иде өмете байның. Ә нигә? Кулында малы бар, үз авылы гына түгел, күрше-тирә авыллар да аңа баш иеп, бил бөгеп киләләр. Нужа китерә иде. Әйе, нужа. Шул нужа Гайзулланың да якасыннан умырып тотты. Әнә шуңа ул, бер балалы хатынын ташлап, бай кызы Таҗылбанатка өйләнде. Бай һавалы кеше иде, чынлап та бай иде. Май заводы салдырды, Ык суын будырып, немец осталарыннан ике катлы тегермән куйдыртты, җиде авылда җиде кибет тотты. Ул гына да аз тоелды байга. Мәкәрҗәнең үзендә магазин ачты.

Авылда Совет власте урнашкач, Рәхим байның төлкенекедәй йомшак койрыгына каты бастылар. Мәкәрҗәдәге магазин да, Ык суындагы тегермән дә, авыллардагы кибетләре дә, мал-туары да очты, тик йорткаралты тирәсенә җыйган малына гына әлегә тимәделәр. Әнә шул калган өлешне саклау өчен байга Гайзулла кирәк булды.

Яшисен яшәгән Рәхим бай, соңгы ун елда өч хатынның башына житеп, дүртенчесенә өйләнде. Әмма тегесе бер кибетче белән Урта Азиягә качып киткәннән соң, бай яңадан өйләнмәде, малае һәм кызы белән торып калды. Балаларын тәрбияләгән, укыткан иде, әмма революциядән соң Хәсән улының генерал Колчакта хезмәт итүен ишеткәч, Рәхим бай, айнып киткәндәй, әйләнә-тирәсенә карады. Карады да таң калды: дәүләтен тартып алдылар, сусыз кабып йотардай сылу кызы саза калды — бай егетләрендә кызлар кайгысы калмаган, кайсы Себер, кайсы Урта Азиягә качты, кайсы Колчакка ияреп тайды. Ә ул, бай, ни эшләп ята? Рәхим картның эчендә өермәдәй нәфрәт уты дөрләде. Малмөлкәтен мир халкына таратучы Әюп кебекләрнең көпә-көндез бугазларына ябышасы килде. Элек аның алдында җидегә бөгелеп, сакаллары белән җир себереп йөргән адәмнәр баш иеп сәлам да бирми башладылар. Тамаша, бөтен ярлы-ябага Совет яклы иде. Совет яклымы? Бәлкем Рәхим бай яклы булганы да бардыр әле? Нигә ул кул кушырып, алма — пеш, авызыма төш, дип ята? Хәрәкәт итәргә кирәк, хәрәкәттә — бәрәкәт, дигәннәр бабайлар.

Иң әүвәл ул кызын чакырып сөйләште. Исәбе авылда абруе булган, егет чакта кыяр-кыймас кына Таҗылбанат артыннан йөргән Гайзулланы кулга төшерү иде. Кызы ризалык белдергәч, Рәхим бай чынлап торып ниятен хәл итү турында хыяллана башлады. Ул ишеткән-белгән җирләргә улы Хәсәнне эзләргә атчабарлар җибәрде. Малны кызганмады, чөнки искене кайтару теләгеннән аң-зиһене тәмам чуалган иде.

Атнага якын йөреп кайткач, атчабарлар байны куандырдылар: Хәсән улы Уфада подполковник Солодовников кул астында хезмәт итә, җилкәсендә — ак погон. Авылдашларына әйткән, тиздән кызылларны җиңеп кайтачакбыз дигән.

Бу хәбәрне ишеткәч, Рәхим бай йокыдан калды, төннәрен ишеклетүрле йөреп үткәрде. Менә кайтсын гына әле ул, Советлары кая керергә урын таба алмас. Килер, килер ул көн, аллаһы боерса. Кайтсын гына яңадан иске дәүләт, картайдым, беләгемдә җегәрем бетте дип тормас, авызы тулы алтын тешләре белән бугазларын чәйнәр, таралган малын җиеләтә, өчләтә кайтарыр.

Көннәрдән бер көнне, авыл өстенә эңгер караңгысы иңгәч, Хәсән кайтып төште. Гайзулла кияүләре аларда тора, әмма бай бу турыда малаена әйтмәде. Таҗылбанат та дәшми-тынмый гына йөрде. Хәсән абзар-кура янында атлар карап уралган Гайзулланы хезмәтче дип белде, күрәсең, тиз генә аңа атын бирде дә өйгә кереп китте...

Гайзулла кече өйдә төнозын күз йоммый Таҗылбанатын көтеп ятса да, хатыны аның янына килмәде. Тик сызылып таң ата башлагач кына бай үзе килеп керде дә иң яхшы туры айгырны эчереп иярләргә кушты. Гайзулла төпченмәде, аннан-моннан гына киенде дә, таланганнан калган дүрт ат арасыннан туры айгырны табып, әүвәл эчерде, аннары

әйбәтләп иярләп куйды. Күп тә үтмәде, өйдән Хәсән чыкты. Ул этисе, сеңелесе белән саубуллашты да ишек төбендә торган туры айгырга сикереп менде. Ат башыннан тотып торган Гайзулла, Хәсән тезгенгә үрелүгә, капка ачарга йөгерде.

Хәсән киткәч, Тажылбанат аңа абыйсы турында сөйләде: Уфада аклар штабының танылган контрразведчигы подполковник Солодовников янында хезмәт итә икән. Күптән түгел генә подпоручик дәрәҗәсе биргәннәр. Колчак солдатлары арасында, кызыллар ягына күчәргә димләп, агитация алып баручы большевикларны тотуда катнашкан.

Колчак Уфада чагында подполковник Солодовников дәүләт алтынын уңга да, сулга да сибә. Аның кул астында эшләүче подпоручик Хәсән дә өлештән калмый — бер потка якын алтын җайлый һәм дөньялар буталып торудан файдаланып калырга уйлый. Яшерен рәвештә алтынны этисенә кайтара. Туган авылына кайтып җиткәнче өч ат яндыра ул, мәгәр үз дигәненә ирешә. Тик гомере генә кыска булды подпоручикның. Иртән чыгуы һәм олы юлга төшүе була, Хәсәнне кемнеңдер пулясы куып җитә.

Җайдаксыз ат ишегалдына кайтып кергәч, Хәсәнне эзли чыктылар. Мәетне Гайзулла тапты. Подпоручикка ау мылтыгыннан атканнар, ул юл өстенә аркылы килеп төшкән. Гәүдәгә кагылучы булмаган, якынтирәсендә эзләр юк иде. Тик икенче көнне генә Рәхим байга җиткерделәр: имеш, шул көнне таң беленер-беленмәстә мылтык тотып, кичүдән чыгып килүче Әюпне күргәннәр.

Ләкин, ни галәмәттер, Рәхим бай Әюптән үч алырга ашыкмады.

Рәхим бай Гайзуллага да улы Хәсән турында тиз генә чишелмәде. Киявенә ышанып җитмәве идеме, әллә башка берәр сәбәбе бар идеме. Шул вакыйгадан соң Гайзулла да йомыла төште, аның күңеленә шом инде. Иске заман кайтып, Рәхим бай аны куып чыгарса?

Шулай ни кыларга, нидән башларга белмичә аптырап йөргәндә көннәрдән беркөнне авылга аклар килеп керде.

Сентябрь ае булса да, көннәр җылы, бакчаларда пәрәвез оча, үләннәр яшәреп үсеп утыра иде.

Аклар килүен ишетү белән, Рәхим бай капканы ачарга әмер бирде, атлас чапанын киеп, аларны каршы алырга чыкты, казаклар белән исәнләште, ипи-тоз чыгарттырды, күз алдында яткырып ике сарыгын суйды, ишегалдына казан астырды.

— Рәхим итегез, әфәнделәр, ирек алып килүчеләргә мал да, җан да җәл түгел...

Мул итеп табын әзерләнде, әрҗә-әрҗә Мәкәрҗә аракысы чыгарылды. Алгы өйгә казаклар тулды, идән-сәкегә тезелеп, стаканлап аракы эчәргә, түтәрәме белән ит ашарга тотындылар.

Ә ак өйдә Рәхим бай белән офицер гәп тотып утырды.

— Беләсеңме, Рәхим князь, ни өчен килдек без сезгә? — диде офицер, ул сүзне озынга сузарга теләми иде.

Рәхим бай сагая калды, итәк-чабуларын җыя төште. Янәсе, баш өсте, кем, ваше благородие.

— Без ишеттек, сезнең улыгыз подпоручик Хәсән бирегә һәлак булган дип. Ә ул дәүләтнең бер пот алтынын алып киткән иде. Ул алтын, Рәхим князь, дәүләт кулына кайтарылырга тиеш. Менә бу — дәүләт даирәләренең әмере. Мин шул алтынны алырга килдем,— дип, офицер аңа бер кәгазь күрсәтте.

Рәхим бай яшел-сары кәгазьгә машинка белән төшерелгән юлларны, кәгазьгә сузылган ике башлы сәмруг кош сурәтендәге мөһерне, бит тутырып куйган имзаларны күрүгә коелды да төште. Йөзе киндер төсле агарып китте, чалара башлаган сакалы селкенеп-калтырап куйды. Ләкин шундук исенә килде. Карале, ул бит боларны кызылларны куарга килгәннәр дип уйлаган иде, Советларны куып, иске тәртип урнаш-

тырып йөрүчеләр дип өметләнгән иде. Ялгышты микәнни? Болай булгач, юк инде, энем, Рәхим байны төп башына җиңел генә утырта алмассың. Ул алтын өчен минем улым җанын бирде, җанын!

— Булмас, ваше благородие, юк сүздер ул. Аңарда хәзер алтын кайгысы юк инде, гүр иясе булды ул. Советлар атты.

Рәхим бай күзен читкә алды, чапан чабуы белән йөзен каплады. Офицер ышанмады, байның чандыр кулыннан кысып тотты да:

— Ялганлама, карт, Хәсән гүргә керердәй кеше түгел. Ул үзе егермеләп большевикның башына житте. Хәсән кызыллар яклы була алмый. Һәм ул бездән дә качты. Кая ул, кемгә хезмәт итә?!

Офицер башын күтәрә төшеп торып басты. Бу — минем сүзем бетте, инде чарасын күрә башлыйк дигән кебегрәк килеп чыкты.

— Берни дә белмим мин. Әнә, ышанмасагыз, киемнәрен карагыз.

— Киемнәрен калдырып китүе дә бар аның!

Офицер Хәсәннең киемнәренә борылып та карамады.

— Ярый,— диде Рәхим бай, аягүрә басып.— Каберен күрегез, инде анда да ышанмасагыз, күрше-тирәдән сорагыз. Аннары менә,— Рәхим бай улының хәрби киемендәге кан каткан төшләрне, ядрәләр кергән тишекләрне күрсәтте. Моңа кадәр ваемсыз гына кыланган офицерның камчы тоткан кулы җиңелчә генә калтырый башлады.

— Бик сәер. Чынлап та һәлак булдың микәнни, подпоручик?

— Ышаныгыз! — диде Рәхим бай, йөзе буйлап аккан күз яшен сөртмичә.

— Кызыллар моннан еракмы?

— Ике сәгатьлек юл булыр.

— Ничек уйлыйсың, князь, без авылга кергәнне кызылларга хәбәр иттеләр микән?

— Булмас. Халык бередә томана, аңа башы житмәс.

Рәхим бай офицерның җил кискән йөзенә карады. Аның ирен тирәләренә җыелган җыерчыклары җәелә барып, битенә, күз тирәсенә күчте: Колчак галиҗәнабләренең ялчысы Рәхим бай уйлаганча ук, батыр түгел, шомлана, курка иде.

— Менә нәрсә, князь, без авылдагы барлык активны, большевикларны җыеп китәбез, ә син безгә Хәсән алып кайткан алтынны бирәсең,— диде офицер, ат тире исе килеп торган кулын Рәхим бай җилкәсенә салып, картның күзләренә текәлде.

Рәхим бай уйга калды. Түр яктагы түшәмнән идәнгә кадәр житкән сәгатькә карап торды. Караңгы төшеп килә иде. Ул тәвәккәлләде. Үч алырга хакы бармы аның, әллә юкмы? Мондый җай аңа яңадан килерме?

— Ярый, әфәндем, вәгъдә, алайса. Инде көч белән алырга телисез икән — булмас ул. Мин инде яшисен яшәгән, ашыйсын ашаган, тәкъдир-үлемнән курыкмыйм. Малаем әнә ять-яшь көенә дә башын салды.

— Исемнәрен язып бирегез, белгән кеше кирәк булыр.

— Киявемне алырсыз. Һәммәсен белә,— диде Рәхим бай житдиләнеп.— Күп түгел алар. Нибарысы ун-унбиш кеше. Тәмам узындылар. Җиде кибетемне, тегермәнемне тартып алдылар. Бер май заводым утырып калды. Анысын да договор белән эшләтәләр. Үз малыма үзем хуҗа түгел.

Рәхим бай торган саен зәһәрләнә барды, яшьле күзләреннән чаткылар сибелгәндәй булды. Әйе, менә, ниһаять, ул алардан, йорт-мөлкәтен талаучылардан үч алачак. «Дөнья — куласа, әйләнә дә бер баса» икән ул. Рәхим бай каләм алды да бер бит тутырып авыл активларының исем-фамилияләрен тезеп чыкты.

Рәхим бай кешеләре һәм атлы казаклар активларны тотып алыр өчен авылга таралды. «Барлык активларны судсыз-нисез атарга!» — дип боерылган иде аларга. Шомлы төн иде бу.

Әүвәл Совет Фәризунга туктадылар. Ул инде качкан булып чыкты. Ярлылар комитеты председателе тимерче Әюпкә юнәлделәр.

Җил капканы ат күкрәге белән бәреп ачып, йортка керделәр. Берничәсе ат өстеннән төшеп, өйне камап алды.

Авылда урта хәлле исәбенә керсә дә, ярлы иде Әюп. Рәхим байдан алган аты, сыеры, биш сарыгы, ике кәҗәсе бар иде. Байны талаганда Әюп усал кыланды: келәтләрен ачып, йөзләгән капчык онны мир халкына таратты, кибет йозакларын каерып атты. Улы Хәсәннең башына житүче дә бер дә бүтән түгел, Әюп кенә, диделәр. Рәхим байның Әюп белән чуты зурдан иде шул.

Әюп өйдә юк иде. Гайзулла, ике казакны ияртеп, өйдән Әюпнең имчәк баласы күтәргән хатыны Гөлзифаны алып чыкты. Гөлзифа куркып калган, дер-дер калтырый. Көмеш төсле ай яктысы аның арык гәүдәсен яктыртып, күкрәгенә кыскан бала битенә төшкән иде.

— Әюп кайда?

— Чаганлыга китте, Зиннур абзыйларга.— Шунда аның күңеленә өмет-юаныч килде. Үз авылдашы, Әюп белән бергә үскән Гайзулла казаклардан мыскыл иттермәс, иншалла.

— Ялганлама, бүген өйдә иде ич! — дип җикерде Гайзулла һәм Гөлзифаның аркасына чажылдатып камчы белән сукты. Ана кулындагы бала чырылдап елап җибәрде. Гөлзифа бөгелеп җиргә иелде, гәүдәсе белән баласын капламакчы булды.

— Зинһар өчен, балама тимәгез!..

— Әйт, ирең кая китте?

Гөлзифа баласын күкрәгенә яшерә-яшерә ант итте, бала хакына булса да, аңа тимәүләрен үтенде. Гайзулла тагы сукты. Бу юлы Гөлзифа җиргә үк сыгылып төште.

— Балама... Уф! Атасы!..

— Атып үтер үзен, этне,— диде Гайзулла казакларның берсенә.

Казак каты итеп хатынның аркасына сыдырды. Гөлзифа җидегә бөтерелеп, баласын күкрәгенә кыса-кыса, йөзе белән җиргә сыенды.

— Белмим мин аны. Чаганлыга китте ул. Алла хакы өчен кызганыгыз. Балам хакына, алла хакына.

Казак мылтыгын алды. Затворын тартып куйды. Ләкин атып өлгермәде, озын гәүдәсе түнтәеп китте дә, мылтыгын кулыннан төшереп, йөзе белән ат ялына капланды.

Көтелмәгән бу хәлдән бер мизгелгә барысы да аптырап калдылар. Гөлзифаны кыйнау белән мавыгып киткән казаклар — яшеренгән җиреннән чыгып, ике җәпле көлтә сәнәге белән казакның аркасына кадаган Әюпне күрми калдылар, ахры. Тик икенче җайдак бер якка кырынаеп ава башлагач кына казаклар арасында ыгы-зыгы купты. Алар Әюпне күрделәр. Мылтык шартлады. Әюп, сөрлеккән шикелле, бер тын катып торды, аннары, кисеп ташлаган көнбагыш сабагыдай, йөзтүбән капланды. Казак аңа тагын бер тапкыр атты да кычкырып җибәрде:

— Чыгыгыз йорттан!

Җайдаклар атларын капкага таба бордылар.

— Алыгыз үлекләрне!

Күз ачып йомганчы, казаклар, ике гәүдәне ат өстенә салып, йорттан чыктылар.

Тик берәү генә атына атлана алмыйча торды. Бу — Гайзулла иде. Әюп соңгы селтәнүендә сәнәк белән аның йөзен яралады. Гайзулла күлмәген ертып ярасын каплады. Кемдер аңа атка атланырга ярдәм итте.

Шау-шу һәм ыгы-зыгы вакытында Гөлзифаны онытып җибәрделәр. Гөлзифа шул җайдан файдаланып, келәт астына кереп ятты һәм тын

алырга да куркып, күзенә кан сауган килеш, йортка карап торды. Еласа яман буласын сизгәндәй, бала да тынып калды.

Казаклар шаулашып ишегалдында уралдылар-уралдылар да китеп бардылар.

Ат тояклары тавышы ерагая төшкәч, Гөлзифа келәт астыннан чыкты. Чыкты да, аякларының атлавын тоймыйча, Әюп гәүдәсе янына килде.

Тулган ай энә табарлык итеп бөтен йортны яктырткан, ай яктысында Әюпнең йөзе тагын да агарып киткән иде. Гөлзифа тезләнде дә, калтырана-калтырана, күз яшен имчәк капкан баласы битенә тамыза-тамыза, ире күкрәгенә капланды, сулыгып-сулыгып үкси башлады. Кулы әле суынып та өлгермәгән лайлалы канга тиде. Бөтен тәне өшеп китте. Әйтерсең йөрәге туктады. Бер тын өнсез калып торды да янә үкереп елап җибәрде.

— Әюп җаным, нишләттеләр, нишләттеләр үзеңне! Тор әле, тор, Әюп бәгърем!..— дип тәкърарлый башлады ул үзәк өзгеч тавыш белән.

Шул вакыт ат тоягы тавышлары ишетелде. Гөлзифа, ни эшләргә дә белмичә, баласын җиргә куеп, Әюпне келәт астына сөйрәмәкче булды. Кузгата алмады, көче җитмәде. Баласын янә күкрәгенә кысты да бәрәңге бакчасына таба йөгерде.

Җайдаклар яңадан йортка килеп керделәр. Берсе һавага мылтык атты. Кайсыдыр салам түбәле өйгә ут салды. Коры саламга эләккән ут дөрләп яна да башлады.

Бу хәлне күреп торган Гөлзифа һушсыз калды. Әле аның ярдәмгә чакырып аваз саласы килде, әле, шуннан үзенә, баласына ни буласын уйлап, иренен тешләде. Нигәдер аның күз яше кипкән, тик сулышы кысылып, нәфрәте генә үсә бара иде. «Кайтырлар, килерләр, безнекеләр дә килер,— дип пышылдады,— ул.— Нишләттеләр сине, Әюп бәгърем, кая алып киттеләр?!»

Казаклар Әюп гәүдәсен алдылар да түбән очка таба чаптылар. Ат өстендә селкенеп барган гәүдәне капка, читән ярыкларыннан карап калучылар да булды. Җайдаклар арасында сул яңагын яулык белән бәйләгән Гайзулла да бар иде. Гаҗәп, ул бит абзарга ут салырга баргач, бәрәңге арасындагы Гөлзифаны күрде. Күрде, әмма нигәдер казакларга әйтмәде. Әллә соң Әюпне кызгануы булдымы? Юкка, юкка калдырды Гөлзифаны, бер тотынгач, тамыры белән юк итәсе булган. Шунда эшен бетергән булса, ичмасам, бүген тал арасында куркып утырмас иде ул...

Казаклар унөч активның дүртесен юк итеп, Рәхим байга кайттылар һәм дөньяларын онытып бәйрәм итә башладылар. Бераз торгач, сакчы да кереп эчте.

Мулдан җибәрде Рәхим бай. Бер нәрсәсен дә кызганмады. Әрҗә-әрҗә аракысын кертте. Ашадылар, эчтеләр, гел дөньяларын онытып җибәрделәр. Офицер да исерде. Рәхим байны кочарга, үбәргә үрелде. Бай сакланды, чамалап кыланды.

Гайзулла табынга утырмады. Иске өйгә чыгып, Таҗылбанат белән сөйләшеп торды.

— Банат, бабай алтынын кая яшерде икән?

— Нигә безгә ул алтын, Гайзулла җаным?

— Дөнья көтәргә. Бабайның күп торасы калмаган, ә безгә яшисе дә яшисе әле.

Нәкъ шул чак алар янына Рәхим бай үзе килеп керде.

— Кияү,— диде ул, сузып кына тамак кырды,— сиңа сүзем бар иде.

Ишегалдына чыктылар...

*Дәвамы бар.*

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**МАЙ, 1974 ЕЛ**

Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше штабына бер хат килеп төште. Конвертына Норильск печате сугылган. Хатта Заполярьедагы шәһәрнең яшь монтажчылары үзләренең уңышлары турында язганнар һәм Чаллыда торак йортларны монтажлаучы бригадаларның берсен социалистик ярышка чакырганнар.

Норильск монтажчылары белән СМУ-61 идарәсенең Александр Баскаков җитәкчелегендәге монтажчылар бригадасы ярышка чыкты. Бу бригада хәзер 360 квартиралы торак йортны монтажлый.

«Сезнең чакыруны кабул итәбез. Хәзер «В. И. Ленин исемендәге комсомолга 50 яшь тулу көненә 50 удар көн!» девизы астында эшлибез. Бу хезмәт вахтасы иң югары җитештерүчәнлек вахтасы булыр! Дуслык кулы сезгә, иптәш Норильск»,— дип язды коллектив Төньяк шәһәренә.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода»**

КамАЗ урамнарында бик күп байраклар җилферди, җырлар яңгырый. Бүген Кама буендагы автомобиль төзүчеләр бәйрәм демонстрациясенә чыкты.

Колонналар өстендә — тугызынчы бишьеллыкның иң зур төзелешендәге казанышлар турында сөйләүче лозунглар, транспарантлар. Ә бу казанышлар бик гыйбрәтле. Менә аларның кайберләре.

Автомобиль комплексының беренче заводы — ремонт-инструменталь заводы— көннән-көн җитештерү куәтен арттыра. Быел бу завод коллективы, ВАЗ автомобиль төзүчеләре белән ярышып, КамАЗ һәм аны төзүчеләр өчен һәр айда миллион сумлык промышленность продукциясе җитештерү рубежына чыкты.

Соңгы, алтынчы заводның — пресс-рам заводының — каркасы монтажланып бетте. 27 апрельдә аның иң соңгы — 725 нче блогы монтажланды. В. Деребизов, А. Анашкин, В. Чиркин монтажчылары һәм «Стальконструкция» трестының башка коллективлары Беренче май бәйрәменә зур хезмәт бүләкләре әзерләделәр.

Автомобиль заводларының төзелеш мәйданнары һәм автоград трамвай юллары белән тоташтырылды, миллионынчы квадрат метр торак мәйданы эксплуатациягә тапшырылды. Киләсе миллион квадрат метр торак мәйданын төзүчеләр ике мәртәбә кимрәк вакыт эчендә өлгертергә сүз бирәләр.

Демонстрантлар арасында СССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат Р. Сәләхов, В. Филимонов, А. Клюев, Р. Сабирҗанов, Н. Зотов удар бригадалары членнары атлый.

1974 елның беренче кварталында камазлылар 82 миллион сумлык капиталь салымны үзләштерделәр. Бу — бирелгән заданиедән артык. Май алды вахтасының уңышлы үтәлүе хезмәттә яңа казанышлар өчен нигез булып тора.

**«Советская Татария», Казан.**

1973 елгы планнарны, социалистик йөкләмәләрне үтәүдә һәм арттырып үтәүдәге уңышлары өчен Ватаныбызның иң югары бүләге — Ленин ордены белән:

КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Рәис Кыям улы Беляев;

«Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең «Автозаводстрой» комплексы бригадасы бригадиры Константин Иванович Новицкий;

«Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең «Соцкультбытстрой» комплексы бригадасы бригадиры Николай Иванович Пелевин;

«Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең механизация идарәсендәге экскаватор машинисты Борис Александрович Царев бүләкләнә.

КамАЗ төзүчеләренең зур группасына югары хөкүмәт бүләкләре бирелә.

**(СССР Энергетика һәм электрификация министрлыгы предприятиеләре, оешмалары эшчеләрен, инженер-техник хезмәткәрләрен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләү турында СССР Верховный Советы Президиумы Указыннан.)**

Минскидагы өченче махсус конструкторлык бюросының тәҗрибә заводы Чаллыдагы автогигант өчен төп конвейерның беренче чиратын вакытыннан 15 көнгә элек өлгертеп җибәрде.

Бу конвейер линиясе — уникаль конструкция. Аның озынлыгы гына да 600 метрдан артык. Анда һәрберсе аерым хәрәкәт итә торган берничә җыю участогы бар.

**ТАСС, Минск.**

Житмешенче еллар комсомолы биографиясендәге героик сәхифәләрнең берсе — КамАЗ. Күптән түгел генә «Молодая гвардия» нәшрияты чыгарган «Автоград» исемле фото-рәсемнәр китабы Кама автомобиль гигантын төзүчеләргә багышланган. Авторлары — Г. Копосов белән Л. Шерстенников.

«КамАЗ нәрсә ул?» — китап авторлары төзелештәге төрле кешеләргә шундый сорау белән мөрәҗәгать иткәннәр.

«КамАЗ — тугызынчы бишьеллыкның бөтен халык төзелеше... Бер үк вакытта завод та, шәһәр дә салына. Иң мөһиме: төзүчеләрнең һәм монтажчыларның менә дигән коллективы үсеп чыкты һәм формалашты. Шәһәр партия оешмасында — 12 мең коммунист, төзелештә — 30 меңнән артык комсомолец».

**(Рәис Беляев, КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре.).**

«КамАЗ ул моңа кадәр бездә дә һәм беркайда да тиңе булмаган төзелеш».

**(Евгений Батенчук, «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе начальнигының беренче урынбасары.)**

«КамАЗ — эшнең яңа ысулы, яңа технологиясе».

**(Вл. Чирчик, монтажчылар бригадиры.)**

«КамАЗ — сиксәненче еллар автомобиле».

**(А. Кригер, Лихачев исемендәге автозаводның баш конструкторы.)**

Һәм бу җавапларның барысы да төзелештә төшерелгән фотопанорамалар, эшчеләрнең портретлары, индустриаль пейзажлар һәм КамАЗ төзелешендәге башка бик күп төрле күренешләр белән иллюстрацияләнгән.

**«Советская культура», Мәскәү.**

Ел ахырына кадәр проект куәтләренең 40 процентын үзләштерү, 1973 елдагыга караганда хезмәт җитештерүчәнлеген аз дигәндә 30 процентка күтәрү, 6 мең тонна стандарт булмаган җиһазлар җитештерү — ремонт-инструменталь заводның социалистик йөкләмәсе шундый.

РИЗ коллективы бу катлаулы бурычны уңышлы гамәлгә ашыра. Барлык эшләр график буенча алып барыла. Болардан тыш биредә тиздән сафка басачак заводларның эшчеләре, инженерлары практика үтә...

РИЗ машина төзелешендәге фәнни-техник процессның хәзерге көн таләпләренә барлык яктан да җавап бирә... ул бу өлкәдәге үсештә яңа адым.

Хәзерге заман технологик җиһазлары белән тәэмин ителү ягыннан КамАЗ РИЗы СССРдагы һәм чит илләрдәге барлык предприятиеләрдән өстен тора.

Илебезне индустрияләү беренче бишьеллыклар чорында үсеш алды. РИЗ — бу юлда хәзерге чор өчен иң күтәренке этап. Завод коллективы үз предприятиесен эзләнү плацдармы, алдынгы тәҗрибә лабораториясе итәргә омтыла.

**«Советская Татария», Казан.**

Язгы яңгыр явып узды. Төзелеш панорамасы өстендә күк йөзе ачылды. Яшьләр тулай торагындагы тәрәзәләр кебек чип-чиста ул.

КамАЗда яз гөрли. Гидротөзүчеләр проспектында яшь топольләр ямь-яшел яфракка күмелде. Кызлар йөзендә сипкелләр чәчәк атты. Күктә май кояшы көлә. Һәркемдә — язгы хисләр, табигать уяна, табигать яңара.

Дмитрий Марага КамАЗда дүртенче язын каршылый инде. Ул Зяб поселогындагы беренче йортларның нигезе өчен бетон, юллар җәю өчен гравий, вак таш, ком ташыды. Аның күз алдында Кама буенда Шишкин урманнары белән рәттән автогигант төзелеше җәелеп китте.

Бүгенге КамАЗ — йөздән артык квадрат километрга җәелгән гигант төзелеш мәйданы. Бу мәйданны, андагы автомобиль комплексы корпусларын күз күре-

мена гена сыйдырып бетеру мөмкин түгел. Анда әлегә эшләр шактый. Әмма инде КамАЗның беренче заводы — РИЗ сафка басты. Әле күптән түгел генә заводта беренче станокны монтажлаганнар, «КамАЗ» автомобильләренең арткы рессорлары өчен беренче кронштейнны ясаганнар иде. Ә хәзер инде җитештерелгән продукцияләрнең бәясе миллионнарча сумнар белән исәпләнелә.

КамАЗда эшләр кайнап тора. КамАЗдагы төзелешнең ярсулы ритмын, Чаллыда бүгенге эшләрнең бөеклеген күз алдына китерү өчен, анда үзең булу, исәпсез-хисапсыз объектларда йөрү, вахта автобусларына этелеп-төртелеп чират тору кирәк.

Күңелләр көр биредә! Күп кенә төзүчеләрнең поэзия белән мавыгуы юкка гына түгел.

«Ә язлар һәр елны яңача килә», — дип яза «Кама таңнары» газетасында Инна Лимонникова. Бөтенләй үзенчәлекле, бүтән язларга һич тә охшамаган бишьеллыкның дүртенче елындагы май ае.

**«Труд», Мәскәү.**

СССР Художниклар союзы секретариаты карары нигезендә, совет кешеләренең тормышын, аларның Ватан өчен тырыш хезмәтен, социалистик төзелештәге уңышларыбызны сурәтләп рәсем сәнгате әсәрләре иҗат итү максаты белән, илебезнең төрле почмакларына иҗат группалары җибәрелде.

КамАЗ төзүчеләрнең хезмәт батырлыгын үз күзләре белән күрү, миллионнарча совет укучыларына һәм тамашачыларына аларның фидакарь эше турында сөйләү теләге язучыларны, кинематографистларны, журналистларны, композиторларны һәм художникларны Чаллыга тарта.

КамАЗда узган ел 27 кешедән торган художниклар группасы эшләде. Аның составында барлык союздаш республикалардан диярлек вәкилләр бар иде. 1975 елда Мәскәүдә үткәреләчәк IV Бөтенсоюз акварель әсәрләр күргәзмәсе өчен алар бик күп материал тупладылар.

Апрельдә Чаллыда СССР Художниклар союзының икенче группасы эшкә керешә. Группа җитәкчесе, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССР дәүләт премияләре лауреаты, профессор Константин Максимов безгә болай диде:

— Мондый сәяхәтләр художниклар өчен, бигрәк тә тәҗрибәле сәнгать осталары белән кулга-кул тотышып эшләүче яшьләр өчен, бик файдалы. Алар биредә үзенә күрә сәнгать академиясе үтәләр. Мәсәлән, график Владимир Иваненко узган елда КамАЗдагы эшләре өчен СССР Художниклар союзына член итеп алынды.

Безнең группаның максаты — Кама буендагы вакыйгаларны гади рәсемгә төшерү генә түгел, ә фактларны сурәтләү өчен яңа алымнар табу да.

Художниклар рухланып һәм бик мавыгып төзелеш барышын күзәтәләр, автогигант төзүчеләрнең тормышын, көнкүрешен өйрәнәләр, үзләре алдына куелган бурычка тирән җаваплылык хисе белән карыйлар.

П. Малаян (Ереван), В. Новиковский (Киев) КамАЗ алдынгыларының портретларын яза, В. Иваненко (Петрозаводск) шәһәр күренешләрен сурәтләгән пейзаж зарисовкалары өстендә эшли.

Художниклар союзы членнары: акварелистлардан А. Гетманский (Ленинград), Л. Купцис (Латвия), С. Кожаев (Иваново), В. Кузин (Пермь), график А. Кирилло (Мәскәү), кыскасы, группаның барлык членнары КамАЗда бөтен көчләрен җигеп эшкә керештеләр. Минемчә, биредә башкача эшләү мөмкин дә түгел...

**«Пресслужба на КамАЗе», Чаллы.**

«Энергетик» культура сараеның кече залында культура хезмәткәрләренең шәһәр мәктәбе дәресе булды. Анда Мәскәүдән килгән кунак, Гнесиннар исемендәге институтның өлкән укытучысы, Үзәк халык иҗаты йорты методисты Л. М. Морген чыгыш ясады.

Дәрестә үзешчән вокаль-инструменталь ансамбльләрнең эшләренә һәм башкару осталыгына анализ ясалды.

* * *

«Энергетик» культура сарае сәхнәсендә «Воронежские девчата» эстрада ансамбле чыгыш ясады. Концерт программасында бию миниатюралары, рус халык җырлары, аерым музыкаль номерлар бар иде. Чаллы тамашачылары Воронеж артистлары чыгышын яратып кабул итте.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

«Энергетик» культура сараенда Чаллыдагы иҗади яшьләр клубының чираттагы утырышы булып узды. Актлар залына художниклар, архитекторлар, эшчеләр, шагыйрьләр һәм композиторлар җыелды.

Бетончы Зина Фадеева, АТХ-5 механигы Иван Камышиннарның чыгышы тирән эчтәлекле булды. Шагыйрә Н. Кандулина «Чебурашка» дигән балалар әдәби берләшмәсенең эше турында сөйләде. Үзешчән композитор Юрий Лыжин КамАЗ турындагы җырлары белән таныштырды.

**«Советская Татария», Казан.**

# КЫЗЫЛ КОШЛАР ҖЫРЧЫСЫ



1905 елның беренче маенда Казан янындагы Игумнов урманында шәһәр эшчеләренең тәүге маевкасы була. Ирек турында, патша самодержавиесенә каршы аяусыз көрәшү турында ялкынлы сүзләр яңгырый.

Шул ук көнне шәһәр байларында конторщик булып эшләүче Габдулла абзый гаиләсендә бер малай дөньяга килә. Аңа Әхмәт дип исем кушалар.

Беренче рус революциясе яшьтәше Әхмәт Исхак көчле социаль тетрәнүләр барган дәвердә формалашып үсә. Җир шары өстеннән Октябрь революциясенең сафландыргыч ташкыны узганда аңа 12 яшь була. Шигъри йөрәгенең кайнарлыгын кемнәргә, нинди эшләргә багышларга? дигән сорау егет алдына бик иртә килеп баса. Аның беренче большевистик маевка булган көнне дөньяга килүе очраклы хәл булса, ә менә «Кызыл шәрык яшьләре» журналының 1923 елгы саннарында басылган «Кызыл кошлар» исемле шигыренең үк революцион пафослы романтика белән сугарылуы һич тә очраклы күренеш түгел.

**Очабыз күккә!**<br>
**Монда ник**<br>
**Канаты сынган аккоштай ятарга?**<br>
**Без — кызыл көч!**<br>
**Без — кызыл кош!**<br>
**Нигә җирдә ятып, тиргә батарга!**<br>
**... Кызыл кошлар,**<br>
**Кызыл көчләр булып күккә очыйк без!**<br>
**Очыйк күккә,**<br>
**Кояш,**<br>
**Айны кочыйк без!**

Яңа гына татар педагогия техникумын тәмамлаган унсигез яшьлек егет тарафыннан язылган бу шигырь, бер кадәр абстракт һәм риторик стильдә булуына да карамастан, киләчәкне гаҗәп дәрәҗәдә дөрес сиземләве белән игътибарга лаек. Күп еллардан соң, өлгергән шагыйрь булып җиткәч, Әхмәт Исхак совет кешесенең космосны яулавын, айны, йолдызларны «кочуын» күрү бәхетенә ирешә:

**Ракеталар оча,**
**Ракеталар,**
**Урап җирне,**
**Айны,**
**Кояшны...**
**Үз көченә үзе хәйран калып,**
**Карап тора Кешелек дөньясы.**

(«Ракеталар оча», 1960 ел.)

Бу ике шигырь арасында иҗади эзләнүләр, сөенечләр һәм көенечләр белән, киеренке хезмәт белән узган кырык ел гомер ята...

Тыштан караганда, биографиясе шактый гади күренсә дә, Әхмәт Исхакның поэзия өлкәсендәге юлы җиңел булмый. Комсомолның Татарстан өлкә комитеты каршындагы матбугат бүлегендә экспедитор... 1925 елдан Мәскәүдә татар телендә чыгып килгән «Эшче» газетасында әдәби хезмәткәр. Тагын өч елдан Мәскәүдә «Таш урамнар җыры» исемле беренче җыентыгы басыла. Шул елларда ул Мәскәү университеты студенты Муса Җәлил белән танышa, алар арасында ныклы иҗади дуслык башлана. Аннан, Казанга кайтып, «Кызыл Татарстан» газетасы һәм «Чаян» журналы редакциясендә эшли. 1939 елда Язучылар союзына член итеп алынгач, СССР Литфондының Татарстан буенча вәкиле була.

Бөек Ватан сугышы башлануга, ул фронтка китә, взвод командиры була, соңрак «Ватан чакыра» исемле газета редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли, каләм белән дә, мылтык белән дә дошманга каршы көрәшә.

Сугыштан соң поэтик характерының үзенчәлеге аны яңадан «Чаян» журналына алып килә (1963 елдан алып 1968 елга кадәр ул журналның баш редакторы була). Укучылар шаян табигатьле Карәхмәтне (бу — аның әдәби псевдонимы) яхшы беләләр һәм яраталар, аның һәр әсәрен түземсезлек белән көтеп алалар.

Әхмәт Исхакның ярты гасырлык иҗатына күз ташласаң, ул башкарган эшләрнең күләме дә, аның күпкырлы талант булуы да гаҗәпкә калдыра. Бу еллар эчендә шагыйрьнең татар, рус, башкорт телләрендә утыздан артык китабы чыккан. Алар арасында шигырь җыентыклары, поэмалар, әкиятләр, мәсәлләр дә, Тукайның әдәби мирасы турында язылган гыйльми хезмәт тә, герой шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган брошюра да бар. «Каракаш батыр» (1940), «Өч кыз турында әкият» (1941), «Күңелле балачак» (1952), «Ташбака» (1960), «Безнең ишек алдында» (1962), «Сез аларны беләсезме?» (1962) кебек балаларга адресланган китаплар Ә. Исхак иҗатында аерым урын тота. Ул гади һәм мавыктыргыч итеп, кыланмыйча, арзанлы үгет-нәсихәт сатмыйча яза.

Әхмәт Исхак — татар халкының музыкаль культурасын үстерү эшенә дә сизелерлек өлеш керткән кеше. 1951 елда шагыйрь, Г. Бәшировның «Намус» романына нигезләнеп, опера өчен либретто яза (Н. Җиһанов музыкасы). Ул татар теленә бик күп җыр текстлары, романслар, опера либреттоларыннан аерым өзекләр тәрҗемә итә. Аның сүзләренә язылган күп кенә җырларны халык үз җыры дип кабул итте.

Әхмәт Исхакның тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлеге махсус өйрәнүгә лаек. Ул Некрасов, Гейне, Шевченко, Мәхтүм Колый, Җамбул, Тихонов, Щипачев кебек шагыйрьләрнең уннарча шигырь-поэмаларын тәрҗемә иткән кеше. Пушкинның «Руслан һәм Людмила», Навоиның «Фәрхад вә Ширин», Лермонтовның «Демон», Маяковскийның «Бөтен тавыш белән», М. Горькийның «Кыз һәм Үлем» дигән әсәрләре белән татар укучысы башлап аның тәрҗемәләре аша танышты.

Әмма Ә. Исхакның ифрат күпкырлы иҗат эшчәнлегендә төп урынны аның үз әсәрләре алып тора.

Егерменче елларның урталарыннан башлап Әхмәт Исхакның әдәби осталыгы камилләшә, ул риторикадан, коры акыл сатудан котыла башлый, акрынлык белән булса да, үз йөзен таба. Ул — ачыктан-ачык социаль характердагы

шагыйрь. Шагыйрь һәр вакыт ил, халык тормышы белән яши, тормыштагы әһәмиятле вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен белдереп барырга тырыша.

Шагыйрьнең бөек Ленин, партия турындагы иң яхшы шигырьләре дәреслекләргә керде, аларны укып, бик күп укучылар тәрбияләнде.

Әхмәт Исхак — хәтта лирик әсәрләрендә дә публицистик шагыйрь.

Ачыктан-ачык публицистик рух, алга баруыбызны тоткарлый торган күренешләрдән чын-чынлап әрнү Ә. Исхакны сатирага алып килә. Шул өлкәдә ул үз талантының иң көчле якларын ачты. Иң зур уңышка исә ул мәсәл жанрында иреште. «Куян һәм председатель», «Штурмчы этәч», «Гайфи агай һәм кибернетика», «Конфликт», «Язды шагыйрь» кебек әсәрләрен бүгенге сатирик әдәбиятның чын җәүһәрләре рәтенә кертергә мөмкин.

Әхмәт Исхакның иҗади эзләнүләре дәвам итә. 60 нчы елларның азагында ул шигырь сөючеләрне ифрат матур лирик шигырьләр циклы белән куандырды. Шагыйрьнең иҗат мөмкинлекләре зур икән әле, димәк, без аннан тагын да зуррак ачышлар көтәргә хаклыбыз. Әхмәт Исхак шигырьләре, кайчандыр үзе язган кызыл кошлар кебек, гел югарыга үрли.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

## Әхмәт Исхак

# ЫШАНУ

— Безнең эшебез хак. Без җиңәрбез!

Гитлер фашизмы тарафыннан социалистик илебезгә хыянәтчел рәвештә көчләп тагылган һәм тарихта тиңе булмаган дәһшәтле, авыр сугышның беренче сәгатьләрендә үк партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең бөтен илебезгә яңгыраган мөрәҗәгатендәге бу сүзләр халкыбызның күңелендә тирән һәм ныклы ышаныч тудырды, аны фидакарь көрәшкә рухландырды.

Сугыш хәрәкәтләре киңәйгәннән-киңәя барып, фашист яулары илебезнең бер өлкәсе артыннан икенчесен оккупацияләүне дәвам иткән көннәрдә дә халкыбызның җиңүгә булган бу ышанычы бер генә минутка да какшамады.

Хак эшнең кайчан да булса җиңәчәгенә нык ышанган һәм шушы җиңүгә ирешү хакына халкыбызның тарихта шулай ук тиңе булмаган фидакарьлекләр эшләвен күреп торган совет язучылары халык күңелендәге бу ышанычны саклау, көчәйтү һәм тирәнәйтүгә барлык талантларын биреп, сугышның беренче көннәрендә һәм айларында ук бик күп патриотик әсәрләр иҗат иттеләр.

Сугышның иң авыр көннәрендә, 1941 елда, мин дә, алдагы бөек җиңүнең нинди булачагын күз алдыма китерергә омтылып, «Кызыл сугышчыга» исемле шигыремне яздым. Бу шигырьдә җиңүгә ирешүнең җиңел булмаячагы ачык әйтелә: Үтеп чыккач Туган илем зур сынауны, тар-мар иткәч үлем алып килгән яуны... Үч алынгач басып кергән дошманнардан, түләтелгәч һәр тамчыга мең тамчы кан; төзәлгәчтен илнең тирән яралары, яшәргәчтен тапталган кыряланнары... Йөзләреннән курку киткәч балаларның, күзләреннән яшьләр кипкәч аналарның... — диелә ул шигырьдә һәм дәвам ителә:

**Шулай данлы тәмам иткәч сугышны без,**
**Шул вакытта сиңа, кызыл сугышчыбыз,**
**Корычтан да ныграк һәйкәл без корырбыз,**
**Ул һәйкәлгә үткен кылыч тоттырырбыз**
**Һәм куярбыз аны изге чиккә илтеп,**
**Һәр дүрт яктан күренә торган, биек итеп.**

**Торыр шунда күтәреп ул мәгъруp башын,**
**Ерак ташлап кисәтүле күз карашын:**
**«Тагын кемнәр йөри анда?» — дигән төсле,**
**Дәһшәтле бер хәрәкәткә килгән төсле.**

Бу һәйкәлнең образы бөтен сугыш еллары буена минем уемнан чыкмады. Ул минем күз алдыма төрле урында, төрле зурлыкта һәм төрле формада килеп баса иде. Ул — авторның шигъри хыялы гына түгел, бәлки күңелендәге ышану көче тудырган, ерактагы, ләкин реаль образ иде. Һәм мин ул һәйкәлне бер көнне, ниһаять, күрдем: ул Кызыл Армия тарафыннан җиңелгән фашистик Германиянең үзәгендә, Берлин янында корылган мәһабәт һәйкәлнең журнал битендәге фоторәсеме иде. Бер кулына зур кылыч тоткан, икенче кулы белән сабый бала күтәргән совет солдатын күргәч, мин бик озак тетрәнеп һәм сокланып карап тордым. Бу инде минем шигырьдәге үз илен саклаучы һәм дошманнардан арындыручы солдатның гына түгел, ә бәлки, шуның өстенә, бөтен кешелекнең киләчәген дә саклаучы солдатның образы иде. Ул тагын да реальрәк, тирәнрәк һәм көчлерәк образ иде...

Ә шулай да мин ул шигыремне яратам. Бөтен эчке һәм тышкы кимчелекләренә карамастан, ул дәһшәтле сугыш елларында халкыбызның хак эшкә һәм аның ахыр чиктә барыбер җиңәчәгенә ышануын чагылдырган әсәрләрдән берсе иде.

## Билгесез солдат кабере

Билгесез солдатның кабере.
Өстендә мәңгелек ут яна.
Янында җәен дә, кышын да,
Яз кебек, чәчәкләр аллана.

Кабернең өстенә җәелгән
Чуерташ салкыны аркылы
Чыга күк, юл ярып, дөньяга
Солдатның йөрәге ялкыны.

●

Сөйми күңелем сугыш коралларын,
Дөньядагы миллион күңел күк.
Чикләп кенә калмый, җыеп барын,
Мин юк итәр идем бүген үк.

Мин аларның җыеп, музейларда,
Пьедесталда хәтта торганын,
Кояр идем, эретеп домналарда,
Иҗат итү, төзү коралын.

Ә бер тупны, тик шул тупны гына
Мин калдырыр идем урнында,
Бер истәлек итеп токымнарга
Иң мөкатдәс нәрсә турында.

Ул — тарихи тубы «Аврора»ның,
Чик куярга кара елларга.
Мәңге якты, яңа чор туганын
Хәбәр итте бөтен дөньяга.

Уятты ул чын бәхеткә өмет
Бар илләрнең эшчән халкында.
Сугышларга каршы чакырулар да
Яңгырады аның залпында...

Бетәр сугыш, беләм, бер көн җирдә,
Юк ителер барлык кораллар,
Ә «Аврора» тубын, бизәп гөлгә,
Данлы крейсеры белән бергә
Пьедесталга илтеп куярлар.

●

Чәерле урманнар,
Күгелҗем томаннар,
Салкынча иртәләр,
Елымса бураннар.

Иделем агышы,
Күлләрем камышы,
Чәчәкле тугайлар,
Тургайлар тавышы.

Әй, яшел тауларым,
Ак ташлы ярларым,
Учаклы салларым,
Әй, бөдрә талларым.

Әй, алтын комнарым,
Әй, кичкән юлларым,
Әй, минем үткәнем,
Әй, килер елларым.

Әй, туган Казаным,
Тарихым, узганым,
Әй, якты язмышым,
Әй, керсез намусым.

Әй, айлы кичләрем,
Әй, татлы төшләрем,
Улларым, кызларым,
Дусларым, ишләрем.

Сез — бөтен бәхетем,
Сез — бөтен рәхәтем,
Байлыгым, барлыгым,
Шатлыгым, хәсрәтем.

Булсам да еракта,
Кадердә, кунакта,
Җырыгыз — колакта,
Моңыгыз — йөрәктә.

Әй, туган ил генәм,
Әй, җиләс җил генәм,
Кай җирдә йөрсәм дә,
Гел сезгә җилкенәм.

Гел сезгә ашкынам...
Сау булсын баш кынам,
Сынмасын тик канат,
Кайтырмын мин кабат!

●

Мин — динсез, мәгълүм һәркемгә,
Табынмыйм бер аллага.
Табыныр идем табынсам
Бары тик Мадоннага.

Юк, түгел, имештер, алла
Аңардан туган өчен,
Ә бәлки гади бер бала
Анасы булган өчен.

Табынмый алла итеп бит
Католик та аңарга,
Ялварган кебек ялвара
Шәфкатьле бер анага.

Ялвара, сорап ярдәмен,
Килгәндә башка бәла,
Сыенган кебек анага,
Яклавын көтеп, бала.

Ә ана күңеле шундый ул:
Шәфкатьне фәкать белә.
Ул синең өчен суларга,
Утларга барып керә.

Җиде төн уртасында ул,
Уянып җиде кабат,
Җәлләми татлы йокысын,
Төн чыга сине карап.

Салкында — яба өстеңә,
Эсседә — бирә суын.
Ачлыкта — соңгы сыныгын,
Һәр вакыт — яратуын.

Сабыша үзе чиргә ул,
Син чирләп китсәң кинәт.
Берни дә аңа кирәкми,
Саулыгың бары кирәк.

Үләрлек хәлгә җиткәндә,
Сахрада сусыз калып,
Иң соңгы йотым суны да
Бирә ул сиңа салып.

Шатлана синнән бигрәк ул,
Уңышың булса әгәр,
Кайгыдан җуя акылын,
Ул сине җуйса әгәр.

Уннарча еллар үтсә дә,
Югалып яуда эзең,
Ул көтә сине саргаеп,
Юллардан алмый күзен.

Алганда соңгы сулышын,
Ул күбрәк газаплана,
Кайгыртып синең язмышны,
Балам, дип, кемгә кала?

Изгерәк нәрсә бар микән
Дөньяда анадан да?!
Табыныр өчен лаек ул,
Димәк, бар алладан да...

Мин — динсез, мәгълүм һәркемгә,
Табынмыйм бер аллага.
Табыныр идем табынсам
Бары тик Мадоннага.

## Чәчәкләр

Чәчәкләрнең җаны бармы? — Җаны бар.
Кара әнә, алар нинди җанлылар!

Күрә алар, ишетәләр, сөйлиләр,
Баш иҗиләр, чакыралар, кил, диләр.

Сөйгәнеңнән алар сәлам китерә,
Якын дусның җылы хисен җиткерә.

Күкрәгеңә дәртләнешеп куналар,
Йөрәгеңә гыйшык булып тулалар.

Син шатлансаң, карый алар елмаеп,
Син кайгырсаң, карый алар моңаеп.

Кавышканда, бии алар, җырлыйлар,
Аерылганда, боегалар, елыйлар.

Якын итсәң, сиңа хуш ис сибәләр,
Ташлап китсәң, саргаялар, кибәләр.

Нишләр иде кеше, чәчәк булмаса,
Яшәүгә ямь, шатлык биреп тормаса?..

Чәчәкләрне җансыз нәрсә димәгез,
Тупас итеп кагылмагыз, тимәгез.

Җанлы алар. Алар безнең төсләләр.
Күрми моны фәкать җансыз кешеләр!

## Тарихка бер адым

Таулар янсын, ташлар яусын,
Ташлар ярым түгелсен.
*Халык җыры*

Янар таулар безнең җырга
Каян килеп, ничек кергән?
Тау янганын, таш яуганын
Бабайлар соң кайда күргән?

Нәтиҗәсе, минемчә, бер:
Ул бабайлар безнең, димәк,
Бу җирләргә шундый яктан
Күчеп килгән булса кирәк.

Ләкин — кайдан?..

●

Беркайчан да, дустым, ялганлама,
Һәр вакытта сөйлә турысын.
«Әйтмә чынын!» — диеп салганда да
Муеныңа Язмыш кылычын.

Нинди ачы чынлык алдында да
Туры кара, йомма күзеңне,
Гаебем булса, аямыйча када
Күкрәгемә хәнҗәр-сүзеңне.

Тик үтенәм синнән, бер очракта
Эшлә, зинһар, моның киресен:
Сөясеңме бераз, дигән чакта
Ялгышып та әйтмә дөресен!

## Күрмәгән булсам...

Бу дөньяга килмәгән булсам,
Ул барлыкны белмәгән булсам,
Белмәс идем кайгы-хәсрәтне,
Әгәр аны күрмәгән булсам.

Бергә рәхәт чикмәгән булсам,
Иреннәрен үпмәгән булсам,
Бу кадәрле юксынмас идем,
Әгәр аны күрмәгән булсам.

Охшап сусыз сулган бер гөлгә,
Ничә тапкыр килеп һәр көнгә,
Түкмәс идем яшем бу җиргә,
Әгәр аны күрмәгән булсам.

Түз газапка, үкенмә, Әхмәт,
Язмышыңа әйт әле рәхмәт,
Үтәр иде гомерең заяга,
Әгәр аны күрмәгән булсаң.

## Дүртьюллыклар

●

Борчылма син, бу дөньяга ник килдем, дип,
Китәр булгач, хуҗа санап ник йөрдем, дип.
Килү-китү, дустым, синең эшең түгел,
Ә син борчыл, үзем аңа ни бирдем, дип.

●

Әйттең гомер: мин бар әле алда.
Ә мин йөрдем: ул бар ич дип анда.
Бер көн баксам, артта калгансың ич.
Инде, гомер, бүтәннәрне алда!

●

Бакчага дип, бер участок җир бирделәр,
Өч ел вакыт — шуны үзләштер, диделәр.
Кайсыбыз тиз үзләштерер, белмим инде:
Минме — җирне, я булмаса, җирме — мине?

●

Дуслар мактый яхшы ният белән,
Дошман мактый шакшы ният белән,
Кайчак боза, артык мактап, безне
Дошман түгел, дус дип йөргән кеше.

●

Ник үзгәрде кинәт һава, дип уйлама,
Болыт иңде бар дөньяга, дип уйлама.
Дөнья — аяз. Синнән аерылганнан бирле
Мин яшь коям, яңгыр ява, дип уйлама.

●

Күрми калмыйм сине төштә бер төн,
Ә уянсам, юк янымда беркем.
Буталдым ла, һич аера алмыйм:
Кайсысы төш моның, кайсысы өн?

●

Бу чаклы аңламас нәрсә икәнсең!
Сөям дип тә әйткәне юк, дигәнсең.
Күрү белән сине телсез калам ич,
Телсез кеше ничек, нәрсә сөйләсен!

•

Карый-карый сихерле күз карашыңа,
Кереп ләктем чәч-ауларың арасына.
Чыга алмыйм хәзер. Аһ, бу явыз гыйшык
Нинди аулар кормый адәм баласына!

•

Бигрәк гадел нәрсә, һай, бу дөнья,
Хәрәмләшми хәтта чак кына:
Гомереңне бер елга кыскартса,
Шул кадәр үк яшьне арттыра.

## КУНАКТА УЙЛАНУ

Газапламый бер нәрсә дә җанны,
Көн-төн эшләп чөнки яшәдем.
Үз хезмәтем белән тапмаганны
Мин кунакта бары ашадым.

## ЕЛАМАДЫМ

Еламадым ил өчен,
Еламадым тел өчен,
Ил эшенә, тел эшенә
Кереттем үз өлешем.

## ОНЫТЫП БУЛМЫЙ

Яшьлек чагы, искән җил кук,
Тотып булмый.
Тотып булмый һәм шулай ук
Онытып булмый.

## ТИМЕРЧЕ

Шигърияттә бар ювелир,
Бар шулай ук тимерче.
Ювелирлык дәгъва итмим,
Тимерченең мин берсе.

Мостай Кәрим

# МИНЕМ ҖИҢҮ КӨНЕМ

Тугызынчы майның иртә таңы иде ул. Австриядәге Линц каласы янында американнар белән очрашканнан соң, безнең солдатлар машиналарга төялешеп үз частьларына кайтып баралар иде. Арттагы грузовикның кузовына бер яшь кенә солдат (ни сәбәп беләндер) ялгызы туры килгән. Ул бер басып бара, баскан урынында сикергәләп биеп тә ала һәм, күкрәк киереп, бар булган тавышына кычкырып җырлый; үзе җыр уңаена, я яшелләнеп яткан чәчүлекләргә, я юл читендәге Америка солдатларына, я каршы очраган крестьяннарга мөрәҗәгать иткәндәй, кулларын канат сыман җәеп-җәеп җибәрә. Аның бөтен торышын әле дә хәтерлим. Җыры да күңелемдә:

Так будьте здоровы, живите богато,
А мы уезжаем до дому, до хаты...

Хикмәт җырның сүзләрендә генә түгел, ә яшь солдатның күңеленәкъ менә шушы сүзләрне җырларга теләвендә, аның дүрт ел буена котырынган яңгырдан һәм давылдан соң исән-имин калган бөтен тереклек күренешләренә карата изге теләктә булуында. Иген басуларының да, Америка солдатлары һәм Австрия крестьяннарының да — бөтенесенең дә утлы давылда исән калуында үзенең дә катнашы бар дип исәпли иде ул солдат. Чынлап та, ул бик хаклы иде.

Тормыш безне зур шатлыклар кичергәндә дә гамьсез күңелле булмаска өйрәтте, һәм без бик кыйммәт хак түләп алдык бу сабак һәм акылны. Җиңү турындагы сүземне шушы борчулы, ләкин котылгысыз уйлардан башлап җибәргәнмен икән, аның өчен мин баягы сабакка бурычлымын.

Хәтерлим мин аны — тынып калган сугыш яланында Җиңүнең тәүге иртәсе туган чакны. Көнчыгышта — күк гөмбәзенең яртысыннан артыгы тиңдәшсез якты балкыш белән чолганган, Көнбатышта соңгы сыек шәүләләр төссезләнеп тарала. Соңгы кисәү башлары көйрәп ята. Аяк астында — яшеллеккә күмелгән җир, баш очында — төпсез күк зәңгәрлеге. Соңыннан ишетеп белдем: ул көнне Өфедә, озын һәм тынгысыз кышның озын сулышы булып, мамык кар яуган. Өфеләләр: күк йөзе кешенең гайрәте алдында баш иде — ак тукымасын җиргә җәеп салды, дип бер-берсен шаяртып та алганнардыр әле, мөгаен.

Тугызынчы май көнен инде ничәнче тапкыр каршы алдым, ул көн һәр чак кояшлы да булмады, ләкин минем өчен Җиңү көне үзем беренче тапкыр күргәнчә калды. Һәм җиңүнең төсе минем аңыма сеңде. Ул төс кызыл да, ак та түгел, ә яшел, ямь-яшел. Бу төс — яңа гына бөреләнеп чыккан яфраклар, яңа гына калыккан уҗым төсе, өр-яңадан башланган яшәү төсе.

Бу безнең тәмам җиңүебез иде. Ләкин аның тамырлары, аның рухи чыганаклары, аның юл маяклары кайда соң? Аның тамырлары, аның чыганаклары бик еракта. Бик-бик еракта. Минем буын кешеләренең йөрәгенә җиңүгә булган ышаныч беренче комсомол анты белән сеңде.

Туган илебез һәм партиябез һәр вакыт безне искәртеп килделәр: нинди дә булса аерым бер ил белән түгел, ә үзебезнең сыйнфый дошманыбыз, кешелек дөньясының иң явыз дошманы — герман фашизмы белән аяусыз көрәш булачак, шуңа әзер торыгыз, диделәр. Бәлки нәкъ менә шул көндә олы сугыш чыгуы стратеглар карашы буенча көтелмәгән хәл булгандыр. Ләкин ул сугышның җиңәчәген алдан ук тою һәм аңа рухи әзерлек минем яшьтәшләремнең бөтен барлыгын, әхлакый асылын тәшкил итә иде. Без җиңүгә, бары тик җиңүгә генә әзерләндек. Булачак сугыш хакындагы беркатлы кинокартиналар, без күрсәтәчәк батырлыкларны мактаган шалтыравык җырлар, дошман җире буйлап тантаналы рәвештә генә атлап үтәчәгебез хакында теге яки бу әшлекле тарафыннан уйламыйча әйтелгән фразалар тәэсирендә без яулап алыначак Җиңүне кайчакта бик җиңел эш, бары тик үзебезнең ихтыярыбызга гына бәйле нәрсә итеп күз алдына китергәнбездер бәлки. Шул ук вакытта, минем уемча, җиңел җиңүгә омтылу безнең бердәнбер өметебез булып әверелергә өлгермәгән иде. Безнең һәркайсыбызның рухында сугышчы характерын, сугышчы ихтыярын формалаштыра торган эш, өзлексез эш дәвам итте.

Әйткәннәргә бер мисал рәвешендә, үземнең ул чакта яңа гына башланган иҗади биографиямнән бер фактны искә төшереп үтәм. Ул чакта, сугыш башланыр алдыннан, байтак кына шагыйрьләр гражданнар сугышы еллары героикасына һәм романтикасына мөрәҗәгать итә торганнар иде. Аларның әсәрләрендә халык эше хакына батырлык күрсәтү, идеал хакына үз-үзеңне корбан итү җырлана торган иде. 1938 елда мин гражданнар сугышының яшь солдаты турысында — йөрәген һәм комсомол билетын дошман пулясы тишеп үтүдән һәлак булган яшь батыр турысында шигырь яздым. Ул шигырь: «Үлем өчен яшәмәдем, ә яшәү өчен үләм» — дигән сүзләр белән тәмамланган иде. Ул сугышчы минем идеалым иде, мин аның язмышын уртаклашырга әзер тора идем һәм шуңа күрә дә шушы шигыремне язган идем.

Дүрт ел вакыт үткәч, чалт аяз август иртәсендә, дошман минасының ярчыгы минем комсомол билетымны һәм язучылык билетымны тиште, бәхеткә каршы, бу ярчык йөрәгемнән чак кына түбәнрәк үтте һәм мин исән калдым. Минем белән янәшә баручы дустым Фомин шул ук минаның ярчыгыннан үлем ярасы алып һәлак булды. Байтак еллар үткәч кенә, мин бу хакта шигырь яза алдым,— ул чакларда онытылып җитмәгән яраны кузгатуы авыр иде. Чөнки мин Фоминны бик ярата идем һәм әле дә яратам. Ул шигырьдә түбәндәге юллар бар:

Икебезгә тиде берьюлы
Бер минаның ике ярчыгы.
Берсе калды сержант Фоминда
Текә яр читендә — кабердә,
Икенчесе — минем тәнемдә.

Инде шуны раслап әйтеп була: дошман белән алдагы бәрелешләр минем буын егетләре өчен гел тантаналы җиңүләр белән генә бизәлгән гаҗәеп романтика гына түгел иде. Без теш-тырнагыбыз белән янып-ярсып сугышырга һәм, кирәк була калганда, Ватаныбыз өчен канызбызны да, җаныбызны да бирергә әзер тора идек. Сугышта үлемнең кешеләрне сайлап тормавы да билгеле иде безгә. Аннан соң Хасан күле янындагы бәрелеш, Фин сугышы кешеләрне җитди нәрсәләр хакында җитди уйларга өйрәтте. Безне сугыш белән куркытмадылар, өркетмәделәр һәм, минем уемча, шулай итү яхшы да булган. Без сугышның котылгысызлыгына ышана идек: ул чакта сугышның булмый калуы мөмкин түгел иде, чөнки безнең дошманнарыбыз шуны тели иде.

Ә җиңү очкыны инде безнең йөрәкләребездә иде. Менә шуңа күрә сугышның тәүге айларындагы авыр уңышсызлыклар совет кешеләренең күңелләрендә таркаулык, каушау тудырмады, алар коелып төшмәделәр, уңышсызлыклар безне тагын да ныграк, җыйнаграк булырга, ярсурак һәм түземлерәк булырга өйрәтте. Элек ишетелгән шалтыравыклы җырлар да, беркатлы кинокартиналар да, әллә кайчан күрелгән төш кебек, бик тиз онытылды. Солдат үз Ватаны белән йөзгә-йөз, күзгә-күз торып калды һәм ул соңгы елларда инде онытыла да башлаган сүзне беренче тапкыр бөтен барлыгы белән әйтте: ул иленә «Россия» дип эндәште. Бу сүзгә безнең иксез-чиксез Союзыбызны, аның буыннар төпкеленнән килгән тарихын һәм ныгыган социалистик нигезен, аның бөтен җирләрен һәм халыкларын бергә сыйдырып әйтте. Россия!.. Россияне якларга һәм саклап калырга кирәк иде, ә Россия кысылганнан-кысыла бара иде.

Әрнүдән-сызланудан йөрәк кысыла иде. Без бөтен халык фаҗигасе өчен кем гаепле булуын тикшерми идек һәм шунлыктан әрнү һәм ярсу күңелгә тагын да тирәнрәк үтеп керә, безне шашу чигенә җиткерә торган иде.

Ул авыр көннәрдә мин хәрби элемтә училищесында әзерлек үтә идем. Кайсы чакта без үзебезне, шушындый көннәрдә тыныч каланың тын монастыре диварлары эчендә посып ятуыбыз өчен битәрләп, үз илебезгә лаеклы уллар түгелдербез, дип исәпли торган идек. Безнең взводта игътибарлы, ярдәмчел һәм бик күндәм курсант — Киев университетының элекке доценты Заславский бар иде. Ул стенографик тизлек белән яза ала, һәм шуңа күрә дә радиорубкадан көн саен соңгы хәбәрләрне язып алып кайтып, безнең взводны таныштырып тору бурычы аңа тапшырылган иде. Ул көн саен дошман кулына калдырылган дистәләгән калаларның исемлеген алып кайта. Мондый хәл байтак вакытлар дәвам итте. Ике-өч атнадан соң, хәвефле хәбәр ташучы Заславскийга карата бөтен взводта сүз белән әйтелмәгән көчле нәфрәт уянды. Бу яхшы күңелле кеше белән юньләп сөйләшми дә башладык. Көннәрдән бер көнне ул үзенең туган каласы Киевның дошман кулына калдырылуы хакында хәбәр алып кайткач, аны юатып җылы сүз әйтүче дә булмады. Безнең һәрберебез яман хәбәр китерүче чапкынның башын кисеп ата торган көнчыгыш ханы сыманрак булып киткән иде. Заславский моны белеп тора, түземлелек күрсәтә һәм тапшырылган бурычны үз-үзен аямый үтәвен дәвам итә. Ул безнең гаскәрләребезнең Мәскәү янындагы беренче җиңүенә кадәр түзде. Беренче әйбәт хәбәрне алып кайтты да яңадан радиорубкага йөрүдән баш тартты. Без барыбыз да иркен тын алдык, ләкин Заславский алдында бик уңайсызландык. Аның теге чактагы хәле ничек булганлыгын әйтеп бетерерлек кенәмени! Әмма без дә гаепле түгел идек бит инде. Йөрәкләребез әрнүдән шулай булганбыздыр. Шушы

эрнү һәм нәфрәт безнең җиңүгә булган ихтыярыбызны ныгытты да инде.

Һәрбер сугышчының — гади солдатмы ул, әллә маршалмы — кайчакта бик шәхси генә булып күренгән аерым җиңүләреннән бердәм олы Җиңү барлыкка килде. Минем үзем өчен олы Җиңүгә юл, курку белән йөзгә-йөз очрашып, аны җиңеп чыгудан башланды. Курку ике тапкыр минем бугазымнан алды. Беренче тапкыр, авыр яраланган килеш, иптәшләремнән аерылып бәрәңге бакчасында ятып калганда булды. Баш очымнан гына кап-кара бомбалар, күңелне болгатып, ажгырып үтә. Һәр бомба минем өскә генә төбәп ташланган сыман. Мин, бәрәңге сабаклары арасына поскан килеш, җиргә ышыкланыр оялары булган коңгызлардан көнләшеп яттым. Икенче тапкыр куркуга калуым, балыкчы көймәсенә утырып, дошманның пулемет уты астында Днестр аша чыкканда булды. Ул чакта, хәрби корреспондент йомышын үтәр өчен, миңа елганың уң як ярындагы бәләкәй генә плацдармга эләгергә кирәк иде. Әҗәл белән менә-менә очрашабыз дип барганда, мин ботак очларына тиклем суга күмелгән талларга көнләшеп карадым. Аларга ут та, пуля да тими сыман иде. Уйлап карасаң, теге юлы да, бу юлы да курку мине җиңә алмады. Мин шулай дим. Бәлки ул башкачарак уйлыйдыр. Уйлый бирсен, әйдә. Мин һәр очракта да үз эшемне дәвам иттердем, бурычымны үтәдем.

17 нче мото-укчылар бригадасында хезмәт иткән чакта, минем бер иптәшем — комбат Савельев тик бер генә тапкыр хәрби җиңү яулап алды. Комбатны яхшы белә идем. Ул кырык беренче елда ил чигеннән үк чигенгән, кара көзгә хәтле чигенгән, каты яраланган. Кырык икенче елның язында тагын да фронтка әйләнеп кайткан. Без Орел юнәлешендәге Липцы районында оборонада тора идек. Савельев батальонына көннәрнең берендә — иртәгә таң белән һөҗүмгә күчәргә һәм дошман кулындагы бәләкәй генә бер авылны сугышып алырга дигән боерык бирелде. Һөҗүмгә әзерләнгәндә Савельев — болай да озын һәм зифа буйлы бик сылу егет — тагы да үсеп, матурланып киткәндәй булды. Аның күзләрендә моңа тиклем миңа таныш булмаган очкыннар уйный башлады. Ел буе диярлек оборонада торганнан соң тәүге тапкыр һөҗүмгә күчәргә! Уен эш түгел бит. Беренче һөҗүм!

Иртәнге әңгердә батальон бик каты сугышлардан соң әлеге авылга бәреп керде. Дошман чигенә башлады. Автоматтан ут яудырып, Савельев иң алдан йөгерә иде. Ул карлыккан тавыш белән шашып чиккә җитеп кычкыра: «Җиңү! Җиңү!» Авыл уртасына җитәрәк дошман минасының ярчыгы аның уң беләген өзеп алып китте. Ә ул һаман йөгерә бирде. Үзе йөгерә, үзе кычкыра: «Җиңү! Җиңү!» ди. Батальон авылның аргы очына чыкканда гына бу олы гәүдәле кеше йөгереп барган килеш җиргә ауды. Пуля комбатның башын тишеп үткән иде. Аның чибәр йөзе шунда ук алсу канга манчылды. Моны мин үз күзләрем белән күрдем. Без, комбаттан калышмаска тырышып, инде аның үзе өчен кирәге дә калмаган элемтә линиясен сузып килә идек. Үз гомерен корбан итеп булса да, яулап алынган бу тәүге җиңүне бик-бик тели иде ул. Дусларыбыз соңыннан, комбат бик мәгънәсез һәлак булды, дип тә сөйләделәр. Монда мәсьәлә, мөгаен, катлаулырактыр. Читлектән кинәт иреккә чыккач, очып барган көе йөрәге ярылып үлгән кош шикелле, ярсулы куанудан һәлак булды бугай комбат Савельев.

Сугыш, асылда, бик авыр эш ул. Батырлыктан тыш, көч-куәт, түземлек, сабырлык кирәк. Мин бер элемтәчене беләм: ул, үзенчә итеп әйтсәм, элемтә катушкасы күтәреп, Сталинградтан Берлинга хәтле араны йөгереп үтте... Болай карап торуга йомшак кына

табигатьле, назлы гына кызларның яраланып егылган баһадир гәүдәле солдатларны үз җилкәләренә салып сугыш кырыннан алып чыгуларын да күп тапкырлар күрдем мин.

Миңа артиллеристларның эшен дә, саперларның эшен дә, зенитчикларның эшен дә еш кына күрергә туры килде. «Безнең артиллеристлар әйбәт кенә эшләп алдылар» яки «безнең летчиклар әйбәт эшләделәр» дигән сүзләр фронтта юктан гына әйтелмиләр иде бит. Бу сугышта, батырлык күрсәтү белән беррәттән, совет солдатының батыр хезмәте дә җиңеп чыкты.

Аяусыз канлы сугышка карата әйткәндә, ничек кенә килешсез яңгырамасын, шулай да, минем уемча, рәхимлелек һәм нечкә күңеллелек батырлыкның аерылгысыз юлдашлары булды дип әйтәсем килә. Кайгы-хәсрәтен дә, изге нәфрәтне дә татыган халкыбыз рәхимсез булырга үзенә юл куймады. Рәхимсезлек һәм ерткычлык күрсәтә башлаган армияләрнең котылгысыз рәвештә һәлакәткә юлыгуын тарих сабакларыннан бик яхшы беләбез. Безнең күп миллионлы, күп телле армиябезне сугышчан бер олы дуслык тыгыз берләштерде, бу бөек дуслык төрле милләт сугышчыларының, яшь һәм карт солдатларның, батырлык дәрәҗәләре төрлечә булган кешеләрнең үзара шәхси дуслыкларында да яхшы гәүдәләнде. Яраланган иптәшләренә карата чын күңелдән хәстәрлек күрсәтү, һәлак булганнары өчен хәсрәтләнү, хәтта әсир төшкән дошманыңа рәхимле булу, азат ителгән җирләрдәге ватандашларыңа кулдан килгәнчә ярдәм итү һәм аларның балаларына карата игъмлылык күрсәтү — менә шундый бик әйбәт сыйфатларын Совет солдаты соңгы мылтык тавышлары тынганга тикле югалтмады.

Минем фронт блокнотымда шундый бер язу бар. «1944 ел. Гыйнвар. Украина. Алгы сызыкта булган хәл. Оборонада тора идек. Кичке эңгердә дошман ягында пулемет тыкылдап куйды. Тагы да кабатланды. Озак та үтмәде, безнең окопка җиде-сигез яшьләрдәге бер кыз бала йөгереп килеп төште һәм дошман ягыннан үзләренең өчәүләп качуларын сөйләп бирде. Әнкәсе, үзе һәм икө яшьлек сеңелесе белән бергә качканнар. Әнкәсе яраланган — әнә теге калкулык янында ята икән. Яраланган әнкәсе һәм сабыйны коткарырга рөхсәт сорап, иң элек яшь кенә сержант мөрәҗәгать итте. Аңа ышанмадылар. Кирәгеннән артык кызу егет. Икенче булып урта яшьләрдәге ефрейтор Садри Камалов рөхсәт сорады. Караңгы төшкәч, ул баланы да, әнкәсен дә дошман уты астыннан алып чыкты. Теге яктан автоматлар тырылдавы тынмады. Ана исән иде әле, аны санбатка озаттык. Кечкенә кызларны иртәнгә хәтле землянкада калдырдык. Алар комсызланып ашадылар».

Бу — бик коры гына язма. Ләкин ул фронт тормышындагы бер фактны күрсәтеп кенә калмый, бәлки безнең сугышчыларыбызның үзләренең кешелек бурычларын изге итеп аңлаулары хакында да сөйли. Сугышта кешелек бурычын үтәү безнең хәрби җиңүебезне бөтен кешелек дөньясының уртак тантанасына әверелдерде.

Үземнең коралдаш иптәшләремә тылдан нинди хатлар килүен искә төшерәм, ул чакта үземә килгән хатларны әле укып карыйм. Тыл эшчәннәренең хезмәт батырлыгы фронттагы солдатларның батырлыкларына тиң икәнлеге һәммәбезгә дә билгеле. Әле мин ул хакта әйтмим. Без тылдагы хәлнең авырлыгын, андагы ачлыкялангачлыкны чама белән булса да күз алдына китерә идек. Ләкин үзебезгә килгән хатларның берсендә дә авырлыктан зарлану гына түгел, ул турыда чак-чак кына сиздереп кую да юк иде. Безнең тылдагы туганнарыбыз нитикле түземле булганнар, бөтен авырлыкларны нихәтле сабыр кичерә белгәннәр! Мин үземнең хатымнан 1943 елның язында алган бер хатны укып карыйм: ул,

авылның хәле әйбәт кенә, игеннәр дә уңар дип ышанабыз, бары тик Җиңүне генә көтәбез, Җиңү өчен яшибез, дип язган. Ә бит шул чагында авылда көн саен әллә ничәшәр мәет күмгәннәр. Бер безнең авылда гына илледән артык кеше үлгән, алар арасында минем якын туганнарым да бар. Ачлыктан интеккән авылдашларым көздән басуда ятып калган башакларны җыеп алганнар һәм агулы орлык ашап һәлак булганнар. Септик ангинадан кырылганнар алар. Тылдан килгән хатларда фронттагы солдатка ярдәм итәрлек, аның күңелен күтәрерлек хәлләр хакында гына хәбәр итәләр иде. Билгеле булганча, яман хәбәр җан көйдерә, эшкә комачаулый. Тылдагы рух күтәренкелеге, түземлек һәм сабырлык фронттагы солдатка үз бурычын, ныклы ихтыяр күрсәтеп, тыныч күңел белән үтәргә булышучы бик зур көч булды.

Миңа сабырлыкның чиктән ашуын да күрергә туры килде. Җиңүнең тәүге көнендә Дунай ярында бер карт солдат җиргә капланып үксеп-үксеп еларга тотынды. «Сиңа ни булды?» — дип сорады командир. Солдат туйганчы елады-елады да шуннан соң гына җавап кайтарды: «Минем улым һәлак булды». «Кайчан? Нигә әлегә хәтле әйтми йөрдең?» — дип борчылды капитан. Теге солдат: «42 нче елда»,— дип җавап бирде. Без башта аптырабрак калдык. Ләкин һәммәбезгә дә аңлашыла иде: бу кеше сугышның соңгы минутларына тикле үзенең эшен дә, унтугыз яшьлек улының эшен дә бергә алып барган. Инде үз хәсрәте белән йөзгә-йөз, күзгә-күз торып калган. Аңа ничек ярдәм итмәк кирәк?

Һәркемгә бердәнбер Җиңү төрлечә килде. Ул хәтта төрле вакытларда килде. 28 апрельдә үк әле Венада берничә эшче парламент бинасының түбәсендәге кара чуен козгынны — фашистик свастиканы мәйданга җыелган гаять күп халык төркеменең күз алдында җан ачуы белән куптарып алып җиргә ыргытты. Мин бу күренешне күзәткәндә, янәшәдә генә торган Афина Палладаның мәрмәр сынына әйләнеп карадым — аның йөзен таш сынга хас булмаган җылы елмаю балкытып үтте шикелле. Мөгаен, бу сынга ул чакта кояш нурлары төшкән булгандыр.

Минем өчен Җиңү көне һаман да үзем нәкъ менә шул көнне күргән төсле булып кала: көнчыгышта күк гөмбәзенең яртысыннан артыгы тиңдәшсез якты балкыш белән чолганган, көнбатышта соңгы сыек шәүләләр төссезләнеп тарала, соңгы кисәүләр көйрәп ята; аяк астында яшел җир, баш очында күкнең төпсез зәңгәрлеге, һәм Җиңүнең төсен күрәм мин: ул төс — яшел, ямь-яшел. Яңа гына бөреләнеп чыккан яфраклар, яңа гына калыккан уҗымнар шундый төстә була. Өр-яңадан башланган яшәү төсе бу.

*«Безнең батарея сугышчылары» китабыннан*

## Нури Арсланов

# УЗГАННАРНЫ ХӘТЕРЛӘГӘНДӘ



Нури Арсланов. Калинин, Төньяк-Көнбатыш фронтларында сугыша. 1946 елны тыныч хезмәткә кайта. Хәрби чины — өлкән лейтенант.

*Сугыш турында сугышка кергәнгә кадәр бик күп хыялланганга, аны җәһәннәм базы кебек сурәтләгәнгә, бөтен сугыш мәйданы янгын, шартлаулар, уклар сызгыруыннан шаулап, тимердәй кызып, кергән бер сугышчыны көйдереп, йотып тора, дип уйлагангадыр, ахрысы, миңа беренче тапкыр һөҗүмгә бару бер дә дәһшәтле булып тоелмады. Хәтта мин бер кадәр гаҗәпләнеп, канәгатьсезләнеп:*

*— Шулай гынамыни моның дәһшәте? Кырык-илле метр ераклыкта снарядлар, миналар шартлый, анда-санда гына тирәңнән пуляләр сызгырып үтә, мондыйга гына түзәргә мөмкин,— дип уйладым. Ул чакта дәһшәтләрне бар дип тә белмәдем.*

*Ә менә хәзер, утыз елдан соң, шул Ватан сугышының кайбер эпизодлары искә төшкәндә тән чымырдап, сискәнеп китә, чәчләр үрә тора: ничек шулай коточкыч хәлләрдән исән чыгылган да, ничек үлем белән уйнарга кодрәт җиткән! — дип хәйран каласың.*

*Безнең буын сугыш авырлыгын тулысынча башыннан кичерде. Безнең илдә генә дә күп миллионлап кеше газиз хәятыннан аерылды. Кайсыдыр бер иренмәгән җанның соңгы биш мең ел эчендә җир шарында өч ярым миллиард кешенең сугышларда һәлак булуын исәпләп чыгарганлыгы мәгълүм. Нинди фаҗига! Нинди кичерелмәслек вәхшилек! Кешелек дөньясына нинди юылмаслык кара тап!*

*Күптән түгел телевидениедән «Хайваннар дөньясында» дигән бер тапшыруда, төркемнәргә оешып яшәүче гамадрилларның, үзләренә һөҗүм кылган башка ерткычларга карата сугышчан, гайрәтле булуларына карамастан, үз нәселдәшләре белән беркайчан да сугышмаулары турында әйткәннәре колакка чалынган иде. Андый мөнәсәбәтнең дөньяда, кайчан да булса, кешеләр арасында да булачагына ышанасы килә.*

*Узганнар искә төшкәндә хәзерге хәлләр турында уйланам мин. Чили патриотларының көрәш байрагын һаман да нык тотулары, грек халкының фашист хунтасын яңадан җиңүе, илле ел буена фашизм коллыгында газап чиккән Португалиянең демократик илләр сафына басуы... Болар барысы да мине тирән дулкынландыра, шатландыра. Мин, карт солдат буларак, боларда безнең Ватан сугышында зур җиңүебезнең яктысын күрәм. Шул җиңү үрнәгендә планетабызның барлык почмакларында азатлык өчен кискен көрәшләр көчәйгән заманның шаһиты булуыма шатланам. Шуңа күрә дә*

*мин шигъриятемдә әледән-әле шушы бөек тема ялкынында кабынам, дөнья халкларыннан читтә кала алмыйм.*

*Югарыда мин сугыш дәһшәтләре турында язганда яшьлек батырлыгы, аның үлем алдында да каушамавы турында әйтеп үткән идем. Бездән соңгылар — хәзерге һәм киләчәк заман яшьләре — яшьләргә генә хас булган тәвәккәллек һәм батырлыкларын безнең кебек сугышларда түгел, ә тыныч тормышта, хәзергедән дә катлаулырак, гаҗәбрәк хезмәт фронтында: төзелешләрдә, ачышларда, иҗат-осталыкта күрсәтсеннәр иде. Бу утыз ел тынычлык, мәңгелек тынычлык башы булып, өч йөз елдан соң да, өч мең елдан соң да сугыш булмасын иде!*

## Әдип Маликов

# СОЛДАТ ШИГЫРЬЛӘРЕ

*Окопта, приваллар арасында, ниндидер вакыйга уңае белән туган, артык көчәнмичә язылган гади һәм кырыс юллар. Аларда шыңшу, зарлану дигән нәрсә юк.*

*Ул шигырьләрдә мәхәббәт һәм сагыну хисләре белән янәшә, «ура!», «алга!» сүзләре яңгырап китсә, бер дә гаҗәп түгел. Чөнки бөек Ватан сугышы барышында бер генә биеклек тә, бер генә авыл һәм шәһәр дә «урра» кычкырмыйча алынмады.*

*«Алга!» сүзе белән олы мәхәббәтебезне раслап, көрәшү минутларын якынайттык. Ул безнең яшәү лозунгыбыз иде.*

*Солдат шигырьләре. Соңгы юл итеп, язылу датасы, елга, авыл, станция яки шәһәр исемнәре куелган. Ватан язмышы — азат ителгән авыллар, калалар саны белән исәпләнгән чак. Ул шигырьләр аша илебезнең канлы биографиясен танып була.*



Әдип Маликов. Ерак Көнчыгыш фронтының Сахалин укчы-тау дивизиясендә разведчиклар отделениесе командиры булып сугыша. 1946 елның маенда өлкән сержант чинында сугышны тәмамлый.

*Без, «самурай менә бүген, менә иртәгә ил чиген җимереп керер» дип, юеш окопларда, дотларда куnып яшәгән Ерак Көнчыгыш фронты солдатлары, Бөек Ватан сугышының Тын океан ярларында тәмамланачагын белә идек. Шуңа әзер тордык. Берлин урамнары тынып калуга, азатлык һөҗүме Амур аша сикереп үтте, Сахалин һәм Куриль атауларына күчте. Миңа ул сугышларда полк разведкасында отделение командиры буларак катнашырга туры килде.*

*Моннан утыз ел элек «солдат хуҗалыгы»ма төйнәп куйган шигырьләремнең берничәсен журнал укучылары игътибарына тәкъдим итәм.*

## Ил язмышы—ир язмышы

Ул игенче иде.
Кырда үсте,
Җырлап үсте иркен сулышка.
Арышлары белән саубуллашып,
Китеп барды канлы сугышка.

Бер гомергә торыр «хезмәт кене»н
Фриц башы белән исәпләп,
Кыр патшасы — пехотачы бүген
Азат итә җирен кисәкләп.

Күтәрмәсә бергә ил язмышын,
Ир булуда мәгънә бармы соң?
Алып кайтыр егет иңнәрендә
Җиңү иртәсенең нурлысын!

Сахалин, Кара елга поселогы, 1942.

## Походта

Әнә таш кыялар!
Очып арган
Акчарлаклар анда ял итә.
Диңгез күкрәгеннән
салмак кына
Ак томанны куып җил исә.

Тәмле таң йокысы сәгатьләрен
Салам матрасларда калдырып,
Рота ышанычлы адым белән
Юлда каршы ала таң нурын.

Күп чакрымнар әле үтәсе бар
Юлсыз тайга, таулар аркылы.
Киртәмени кайнар йөрәкләргә
Чиркандыргыч сулар салкыны?!

Бу гүзәл җир —
диңгез уртасында,
Һәрбер метры аның кадерле.
Батыр солдат,
Походларда чыныгып,
Утрауда да җиңү хәзерли.

Сахалин атавы.
(1944 ел, ноябрь санында «Тревога» газетасында басылды.)

●

Китми йөрәгемнән сылу кызлар.
Тальян моңы... Яшьләр биюе...
Әткәемнең мине озатканда:
«Хуш, сынатма, улым!» диюе.

«Сынатма, улым...»
Юеш окопларда
Догам булды шушы сүзләре.
Кузгалганда канлы атакага
Озата барды әткәм күзләре.

Тойохарэ (хәзерге Южно-Сахалинск).
Сентябрь, 1945.

Шулай килеп чыкты,
Сине, Атау,
Азат иттек шактый кичегеп.
Килмешәкләр кул сузмаслык итеп,
Бикләп куйдык Океан ишеген.

Сине яклап —
Илне сакладык без,
Синдә яшьлек данга күмелде.
Үпкәләмә, Атау,
жырлар язсам,
Төштә күрсәм сагынып Иделне...

Көньяк Сахалин,
1945, сентябрь.

## Хәй Вахит

*
* *

*Мин сугышны солдат булып үттем. Артиллерия разведчигы. Гади солдат. Командирларым кая куйса шунда булдым, нинди вазифа йөкләнсә — шуны үтәдем. Белоруссияне, Польшаны фашит басып алучыларыннан азат итүдә катнаштым.*

*Яшьләр белән очрашып сугышта күргәннәр турында сөйләгәндә еш кына бер сорау ишетергә туры килә иде:*

*— Ут эченә кергәндә куркыныч түгелме? — дип кызыксына иде алар, — шүрләп-каушап калмыйсыңмы?*

*Сугыш — шул ук хезмәт ул. Бөтен тырышлыгың белән, барлык көчеңне салып, кирәк икән акылыңны, үткенлегеңне җигеп үз өстеңә төшкән бурычны үтәргә омтыласың. Курку турында уйлап торырга вакытың да калмый. Буш вакытың булдымы, ял итү, йокы туйдыру, кием-салымыңны бөтәйтү, сугыш коралыңны әзер хәлгә китерү ягын карыйсың.*



Х. Вахит. 1 нче Белоруссия фронтында артиллерия разведчигы. Җиңү көнен Польшада каршылый.

*Янымда сугышчан иптәшләреңнең иңнәрен тоеп йөрү, үз эшеңнең хаклы эш икәнлеген аңлап, җиңеп чыгарыбызга тирән ышану күңелгә дәрман, рухка күтәренкелек биреп килде. Ул чакта аерым солдат телендә дә, бөтен халкыбыз күңелендә дә бер девиз: «Наше дело правое, мы победим!» дигән ышаныч какшамаслык булып кереп урнашкан иде. Сугыш Идел ярларына килеп җиткән көннәрдә дә солдат күңелендә икеләнү булмады. Җиңеп чыгачагыбызга тамчы да шикләнмәдек.*

*— Безнең эшебез хаклы, без җиңәчәкбез!*

*Юк, куркуны белми солдат. Ә мене сугышта кичерә торган бер тойгыны минем үземә дә татып карарга еш кына туры килгәләде. Бер сүз белән әйтергә кирәк булса, бәлки аны горурлык дип атарга да булыр иде. Ләкин ул бер сүз эченә генә сыеп бетәр микән! Сугыш кырында кечкенә генә бер заданиене уңышлы итеп үти алсаң да, эчке бер сөенү кичерәсең, син үзеңнән канәгать, күңелең күтәрелеп китә, түбәң күккә тигән. Ни өчен болай бу? Моның сәбәбе бик ачык: син эшеңнең нәтиҗәсен күреп торасың, шундый җаваплы моментта, илеңнең язмышы хәл ителә торган көннәрдә халкыңның гаять зур изге эшенә, титаник көрәшенә синең дә кечтеки генә бер өлешең керүенә ышану — солдат өчен шуннан да зур сөенеч булырмы?! Дөрес, тыныч хезмәттә ирешкән уңышлар өчен дә сөенеч килә, әмма сугышта башкачарак.*

## Мөхәммәт Садри

# МӘСКӘҮ — БЕРЛИН



Мөхәммәт Садри 1941 елдан алып сугышның ахырына кадәр Көнбатыш һәм Беренче Украина фронтларында башта артиллерист, аннары танкист, кыр складында кораллар бүлеге башлыгы һәм татар телендә чыккан «Ватан намусы өчен» фронт газетасының корреспондент-оешытыручысы булып хезмәт итә. Хәрби чины — майор.

*Сугыш газабын миңа беренче тапкыр Көнбатыш фронтта, Смоленск өлкәсендә Ельня шәһәре өчен, сугышчылар теле белән әйткәндә, Мәскәү капкасы өчен бик авыр сугышларда кичерергә туры килде. 1941 елның июль башыннан октябрь ае башына кадәр шунда булдым. Командование миңа аеруча зур, җаваплы эш йөкләде: 1393 номерлы хәрби кыр складында кораллар бүлеге начальнигы вазифасын үтәдем. Йөз көн, йөз төн ял-йокы, җылы аш күрмичә, алдынгы сызыкны танкка каршы ата торган снарядлар, автоматлар, пушкалар белән тәэмин иттек. Төнлә мин — автоколонна начальнигы: йөз йөк машинасына утырган батыр шоферлар белән алгы сызыкка снарядлар илтәм. Яктырганчы трофей төяп кайтабыз. Дошман снарядларын аерым урынга урнаштырабыз һәм көндез автоматларны, винтовкаларны ремонтлап, чистартып, яраклы хәлгә китерәбез. Төнлә, станциягә килгән вагоннардан снарядларны, туплларны автомашиналарга төяп, яңадан алгы сызыкка ашыгабыз. Һәр көнебез һәм төнебез әнә шундый киеренке эштә үтте. Дошман самолетлары безне бик эзләделәр, ләкин таба алмадылар: шәп яшеренгән идек, үзебез дә исән, кораллар да нык сакланды.*

*Минем ярдәмчеләрем рядовой солдатлар — Брянск һәм Орел шәһәрләре тимер юл деполарының өлкән эшчеләре иде. Яшь булсам да, өлкәннәрнең мине «иптәш начальник» дип олылап эндәшүләренә уңайсызланып, олырак күренергә тырышып мыек үстердем.*

*Ельняны саклаучы совет солдатлары дошманның котырган һөҗүмнәренә бирешмәделәр, фашистлар Ельняны сугышып ала алмады. Тик аларның соңгы һөҗүм сугышлары башлангач, командование приказы буенча, трофей снарядларын шартлатып, дошманга бер нәрсә дә, хәтта сугыш коралларын чистарта торган чүпрәкләрне дә калдырмыйча, Гжатскига юнәлдек.*

*Сугыш турындагы беренче шигырьләрне Нарофоминск янында, аннары Мәскәүнең Измайлов культура һәм ял паркына урнашкан вакытлы складта яза башладым.*

*1943 ел ахырында, язучы Александр Фадеев ярдәмендә, Беренче Украина фронтында татар телендә чыгарыла торган «Ватан намусы өчен» газетасының хәрби корреспонденты-оештыручысы итеп билгеләндем. Бу газетада эшләү иҗатымны активлаштыруга аеруча зур ярдәм итте. Анда бик күп шигырьләр, очерклар, сатирик строфалар, зарисовкалар яздым. Сезгә тәкъдим ителә торган шигырьләрнең берсе Мәскәү янында, икенчесе Берлинны алгач иҗат ителде.*

## Сугышчы хаты

Татарстан, кайнар сәлам сиңа
Изге җирдән — бөек үзәктән,
Арысландай батыр егетләрең,
Кызларыңнан, бөтен йөрәктән!
Татарстан, синдә туып-үскән
Егетләрең, батыр кызларың
Башкалабыз Мәскәү яннарында
Туздырышты дошман яуларын.

Әй, туган җир, син ышанып безне
Чакырдың да корал алырга,
Куштың, кызыл гаскәр сафына басып
Сугыш кырларына барырга.
Без, чынычып авыр сугышларда,
Фашистларның җанын алабыз,
Ил, партия, халык кушканынча
Җиңү яулап алга барабыз.

Тиздән-тиздән бөтен җирләребез
Азат булыр инде тагын да,
Сөенә-сөенә синең кочагыңа
Кайтырбыз без бәйрәм таңында.
Бүген йөрәк нәкъ ут кебек яна,
Бүгенгә без сугыш кырында,
Бөтен уебыз, бөтен теләгебез
Тик бер генә: җиңү турында!

Мәскәү — Нарофоминск, 1941.

## Берлинда

Бункерлары асты өскә килде,—
Мәкер ерткыч посып ятмасын!
Каерып ачты совет солдатлары
Җитмеш катлы Берлин капкасын!..

Солдат булып, утлар өермәсен
Соңгы тапкыр кичкән көнемдә
Кайчандыр бер тик төшемә кергән
Җәһәннәмне күрдем өнемдә.

«Теге дөнья» менә шушы икән:
Көл-пычракка, канга күмелеп,
Ята явыз дәһшәт төрмәсенең
Палачлары сасып, күбенеп.

Күрәм әнә: кулсыз һәм аяксыз
Фашист ерткыч улый, шашына...
Котырган ул кан эчүче вәхши
Шушы көнгә һәм үз башына.

Сез ничә ел кеше канын эчеп:
— Освенцимга, шнейль [1] — дидегез.
Безнең нәфрәт, безнең хаклык көчен
Я, татыгыз инде үзегез!

Кудам [2] ята көл-күмергә батып,
Тәкәбберлек беткән тапталып;
Үтә аннан Урал танкистлары
Прагага яңа юл салып.

Түбәсенә мендем мин рейхстагның,
Аста пыскый кара дивары;
Изге Кызыл байрак янында ук
Басып торам бүген югары!

Егерменче гасыр вәхшиләрен
Калдырмаска иде берсен дә!
Автоматым әле уң кулымда,
Күз карашым — Берлин өстендә.

Явыз өннең кара бер язмышы
Миңа моннан ачык күренә:
Фашист рейхы [3] оча төтен булып,
Көл-чүп булып янып сүрелә.

Кояш чыга Идел буйларыннан,
Нур сибелә Мәскәү күгеннән:
Азат таң бу, безнең Җиңү таңы
Бөтен җирдә балкыр бүгеннән!

1945, Берлин.

## Геннадий Паушкин



*Геннадий Алекасндрович Паушкин Ватан сугышын пограничник булып ил чигендә каршылый. Ул һөҗүм итүче Совет Армиясе частьлары белән бергә Румыния, Болгария, Югославия, Венгрия һәм Австрияне азат итүдә катнаша. Сугышны старшина-радист, полк рациясе начальнигы булып тәмамлый.*

*
* *

Кургаш ява яңгырмыни —
Кичәбез киң Дон аша.
Ярсу дулкын төпкә тарта —
Әҗәлме якынлаша?..

Омтылдым мин ярга таба
Соңгы көчемне җыеп.
Үлем чиген кичеп уздым,
Җирем сулышын тоеп.

[1] Шнейль — тиз бул.
[2] Кудам — Берлинның иң бай, купшы урамы исеме.
[3] Рейх — империя, дәүләт.

Көтмәгәндә юлыктым мин
Ярда янган учакка.
Иң кадерле рәсемеңне
Кулга алдым шул чакта.

Йөртәм аны гел янымда,
Йөрәк түремдә һаман.
Ни могҗиза! Рәсемең бит
Тамчы да чыланмаган.

Мәхәббәтең мине алга
Гел әйдәп барса иде,
Ярда янган учак кебек,
Җылытып янса иде.

Төньяк Кавказ, 1942 ел.
Г. САДӘ тәрҗемәсе.

## Сәет Шәкүров

*Мин дә булдым сугышта. Дүрт ел эчендә байтак килеп сарырга туры килде. Окоптан госпитальгә, госпитальдән окопка. Хәтта... ялгышып китеп, штрафнойга да эләгеп алырга туры килде. Нишлисең бит — яшьлек!*

*1944 елның җәе иде. Госпитальдән резервка эләктем. Безнең гаскәрләр Германия җирендә, көн саен дистәләгән шәһәрләр алына, башкалада һәр көн салют яңгырый. Кинәт сугыш бетеп. Җиңү көнен резервта каршыласаң, моннан да үкенечле булуы мөмкинме егет кешегә?! Ничек кенә булса да тизрәк сугышка эләгү чарасын күрергә! Тырыша торгач, тәки максатыма ирештем.*



Сәет Шәкүров. 3 нче Белоруссия һәм 1 нче Ерак Көнчыгыш фронтларында сугышты. 1946 елны тыныч тормышка кайтты.

*Өченче Белоруссия фронты, 184 нче дивизия. Кенигсберг юнәлешендәге бер тимер юл станциясен штурмлыйбыз. Станция янындагы урман уттан туралып бетте диярлек, ә станциягә үтеп булмый. Пулемет, аннан — власовчы ата. Аның аркасына автоматын терәгән немец. Теләсәң нишлә, ләкин бер адым да алга ыргылу мөмкин түгел. Шулай да җаен таптык. Пулеметы-ние белән власовчы күккә очты, немец станциядән чигенде. Каты сугыштан соң була торган тынлыктан файдаланып, без тимер юл буендагы бер склад бинасына кереп, сабын ящиклары өстендә ашап-эчеп алырга булдык.*

*Мөгаен, ике тәүлек сугыш нәтиҗәсе булгандыр инде, бераздан мин шул ящиклар арасында йоклап киткәнмен. Моны күрүче һәм әһәмият бирүче булмаган. Мин шунда йоклаган да йоклаган. Ә кичкә таба немец, көчен туплап, контратакага ташланган. Станцияне яңадан алып, безнекеләрне чигенергә мәҗбүр иткән. Станцияне ул алты сәгать буе үз кулында тоткан. Ике яктан да каты сугыш барган һәм, ниһаять, таң алдыннан безнекеләр яңадан станциягә бәреп кергәннәр. Шунда минем дустым Васька Чусовой (ул шул шәһәрдән иде) иң беренче булып әлеге складка ташлана һәм сабын*

*ящиклары арасында мине таба. Бу хәл шулай үткән дә булыр иде, ләкин взводный күреп ала. Нихәл итәсең, мин штрафнойга эләгәм... Төнге «ауга» барып бер «тел» алып кайткач, иртәгесен, гөнаһларымны ярлыкап, мине яңадан дустым Васька Чусовой янына кайтардылар. Җиңү көнен инде без Кенигсберг хәрабәләрендә каршыладык.*

## Мәхмүт Хөсәен

# ТУГАН ИЛ ӨЧЕН!



*Бөек Ватан сугышы башлангач, ике көннән соң, әтине сугышка алдылар. Берничә айдан соң, үзем теләп, мин дә фронтка киттем. Ил авыр көннәр кичерә иде: Ленинград утлы камалуда, Мәскәү янында каты бәрелешләр бара, Белоруссия, Украина, Молдавия җирләре дә, Дон буйлары да, Сталинград далалары да дошман кулында. Без, фронтовиклар, туган яклардан өзелеп хәбәр көтәбез. Ниһаять, миңа да хат килде. Адресыннан таныйм: әнидән. Ачып тиз генә укый башладым һәм... конвертым җиргә төшеп китте. Әтием һәлак булган... Туганнар каберлегенә күмгәннәр...*

*Әтинең үлеменә бер ел тулганда, зур һөҗүм алдыннан, шушы шигыремне яздым. Ул фронт газетасында басылды. 1945 елда Ленинградта басылган беренче җыентыгым «Туган ил өчен» дип, шул шигырь исеме белән чыкты.*

Белермен дип хәлен, өметләнеп,
Хәбәр көтәм аннан кич-иртә.
Ник язмый ул:
Сугыш каты микән?
Нигә болай мине тилмертә?

Мин аңардан күптән хәбәр көтәм.
Кош теле тик бер хат килсәче!..
Хат ташучы кереп блиндажыма:
— Әткәңнән бу... мә ал! — дисәче,

Мин зарыгып аннан сәлам көтәм.
Ник язмый ул?
Аңа ни булды?
Уйлый микән әллә бар хатларын
Җибәрергә миңа берьюлы?
. . . . . . . . . . . . . .

Ахры, җитте ул көн — мин хат алдым.
Тик аңардан түгел, әнкәмнән.
«Атаң үлгән, улым» дигән дә ул,
Бүтән... бүтән берни әйтмәгән.

Әткәй... Әтием!..
Хуш, бәхил бул, бәгърем!..
Баш очыңда илең сак тора.
Әрнеп тамган һәрбер яшь бөртеге
Иң рәхимсез үчкә чакыра.

Кан өчен кан!
Үлем өчен үлем!
Юлымнан мин кире борылмам:
Йөрәгемә туплап үч давылын,
Арысландай утка ыргылам!

Әй, туганнар!
Һәрбер тамырымда
Кайнар каным ташып торганда,
Газиз әткәм ил бәхете өчен
Зур сугышта һәлак булганда,
Нинди көчләр туктаталыр икән
Шашкын хисле йөрәк тибешен?
Мин Берлинга ашыгам җиңү даулап
Әткәм, халкым, туган ил өчен!

1943, Хәрәкәттәге армия.

## Ибраһим Гази

# КУЕН ДӘФТӘРЕННӘН

*Ибраһим Газиның яшьтән үк күзләре ерактан начар күрә. Шул сәбәпле ул мәҗбүри хәрби хезмәттән азат ителгән була, сугыш башланганда хәрби исәптә тормый.*

*Сугыш башлангач, хәрби исәпкә алына, ләкин медицина комиссиясе аны һаман калдырып килә. Әмма ул фронтка китәргә барыбер әзерләнә, гаиләсен авылга озата. Ниһаять, 1942 елның мартында аны командирлар хәзерли торган курсларга җибәрәләр. Курслар Сталинградта оештырылган була. Аны биредәге врачлар комиссиясе дә үздырмый. Ул яңадан Казанга әйләнеп кайта.*

*1942 елның көзенә таба фронтта татар газеталары чыга башлый. 1943 елның гыйнварында Ибраһим Гази, командировка алып, шул газеталарның берсенә китә.*

*Башта 4 нче Украина фронтында эшли, Карпатка җиткәч, аларның газеталары чыгудан туктый. Ибраһим Гази Белоруссия фронтларының берсенә күчереп, Я. Ярмәки, Г. Тукай һәм Г. Галиев белән бер газетада хезмәт итә.*

*Түбәндә без укучыларга аның фронт газеталарында эшләгән елларында куен дәфтәренә теркәп барган кайбер язмаларын тәкъдим итәбез.*

*А. СЕРДИНСКАЯ.*

13/III-42.

Беренче тәэсирләр.

Кичә беренче тапкыр очрашып, әле бер сүз дә әйтешергә өлгермәгән кешеләр, бүген, алынгач, очрашканда күптәнге танышлар кебек, елмаешып баш ияләр, кул биреп күрешәләр, ә үзләре әле бер-беренең исемен дә белмиләр.

Шаярган, ваемсыз сүзләр сөйләгән булалар, ләкин күңелләрендә борчылу, әерылышу кыенлыгы, алда торган билгесезлектән пошыну аларның йөзләренә чыккан, кайберләре ачыктан-ачык:

— Я, шаярган булдык, көлешкән булдык, ләкин күңелдә шаярырга теләү юк,— дип әйтәләр.

Бөтенләй икенче дөньяга күчкән шикелле, әле кичә генә сине кызыктырган нәрсәләр, бүген синең өчен ят, син дә ул дөньяга ят, ләкин, ни өчендер, үзеңнең кичәге кадерле дөньяңны кызгану да юк кебек: күңел бүгенге белән тулган.

— Иптәш военный! — дип дәшә башладылар. Кием хәрби, ләкин эчтән, күңелдән мин әле бөтенләй гражданский.

Үбешү, кочаклашу, яшерен-яшерен күз яшьләре дә ялтырап куя, бер-береңнең күзләренә карап сүзсез генә бер-береңне аңлашу...

Һич таныш булмаган кешеләр балаларының, хатынының саулыгын сорый.

Куркыныч алдыннан кешеләрдә суеверность көчәя, кешеләр төшләрен юрый, гадәттә яхшы якка юрый башлыйлар. Мәсәлән, сугышка керер алдыннан...

22/IV-42.
Яз. Җир ачылган: анда-санда тирән чокырларда, кипкән елгаларда гына агарып кар күренә. Ашыгып, куцелле гөрләвекләр ага; тургай сайрый; җирдән җылы пар күтәрелә; кара каргаларның моңлы тавышлары ишетелә; тиресләрдә тавыклар тарана; кырда, кояш астында атлар йөри; төнлә кибеп өлгергән ермаклардан көндез яңадан шаулы йөгерек сулар ташып ага...

Ераграк торган телеграмм баганалары, башларын горур күтәреп, салмак кына үтәләр; якындагылары, каядыр ашыгып чапкан малайлар кебек, йөгерешеп уза.

7/V-42.
Яз, ләкин көн шундый — катыкка манып ташласаң, мәче ашамас: җил аяктан ега, бозлы яңгыр битне яңаклый, кошлар, оча алмыйча, тизрәк җиргә сыеналар, ә тургай (гаҗәеп!) каядыр һавада һаман сайрый.

Урманнан җил соры яфракларны себереп алып чыга да камыллы басулар өстеннән өерелдереп алып китә.

Урман яланнарында үлгән яфракларны күтәреп, умырзая чәчәкләре килеп чыкканнар; әллә нинди кызыл-комач үләннәр борын белән төрткән; бака яфрагы үзенең түгәрәк яфрагын чыгарып куйган; умырзая күк, шәмәхә башмакларын асып, гомеренең кыскалыгына кайгыга талган кебек, үзенең матур башын салындырган; үлгәннәр җиргә төшәлгән, ә яшьләр, яңа дөньяга килүчеләр, үлгәннәрнең өстенә калкып, яшәү даулыйлар... Алар үзләренең итләч сабакларына таянып, шәмәхә... күк башларын югарыга, кояшка таба күтәрәләр...

Яңа гына кар астыннан чыккан кырмыска ояларына җан кергән: кырмыскалар йөгерешеп чыгалар да кояшта җылыналар, алар әле хәлсезләр. Ниндидер кошлар чут-чут сайрый. Сары күбәләкләр оча; юеш җиргә сыенып озынборыннар тирбәлә.

Башка, җилкәгә килеп төшәргә теләгәндәй, сүрән, соры күк йөзе асылынып тора; кояш чыга да аны җиңел генә күтәреп ташлый. Җир йөзе, бөтен җан иясе, бөтен тереклек — кыскасы, бөтен дөнья җиңел сулап җибәрә һәм кояш астында балкып тора башлый.

29/V-42.
Берәү белән уртак бүрәнәләре була. Киссәң — әрәм. Ярсаң — акчасы кирәк. Нишләргә?

— Карале, Галиуллa, шушыннан үзеңә кадәр күтәреп китә алсаң — бүрәнә үзеңнеке! — дигәннәр.

— Ярый! — дигән Галиулла.

Каен бүрәнәсен урта бер җиреннән алган да эһ тә итмичә иңбашына салган. Бара, ди, урман эчләп, аяклары тубыктан бата, ди. Ике делянка җирне илткән дә ташлаган. Әле барып җиткәч иплән кенә төшерү урынына, җилкә белән чөеп, каен бүрәнәсен әллә кая атып ташлаган, ди.

Башланган эш — беткән эш.

3/VIII-42.
Юл буендагы борчак шикелле, бөтен узган-барган кеше мине йолыккалап, төрткәләп узды. Юл — үлгән, һич җан әсәре юк. Күңел алар янында калды, үзем бирегә кайттым; юл буе тамагымнан яшь китмәде. Юлда яңа ат тизәге, димәк, күптән түгел ат үткән, күңеллерәк булып китте. Каядыр еракта этләр өрә, якында гына тавык җырлый, мин аңладым: велосипедым иярененң пружиналары шыгырдый икән. Девятово урманы... «А где мой папа?»

Авыллар үлгән, урамда барлыгы бер-ике ыштансыз малай белән күшәп яткан бер-ике бозау гына күреп була.

5/XII-42.
Алар яныннан кайтканда юл буе күңелдән татлы газап китеп тормады. Күрәсең, һәртөрле газап (бигрәк тә рухи газап) кешене яңарту өчен, яхшырту —

облагораживать итү өчен бирелгән. Газап тойгыларны сафландыра, күңелне сафландыра. Вак-төяк дрязгалар бик әһәмиятсез булып, мәгънәсез булып калалар... «Тәңгә мунча, җанга юк», дию белән Тукай хаталанган булса кирәк. Җанга да мунча бар. Газап!

Мин тау күтәрелеп артыма борылып караганда, кояш чыгып килә иде. Күк итәге бордо ачык сары, чем-зәңгәр буяуларга буялган булса да, аңарда ниндидер суровость, караңгы чырайлылык бар иде. Еракгагы дәһшәтле вакыйгалар табигатькә дә йогынты ясый кебек. Алда күк карага якын зәңгәр иде, мрачно иде. Күңел каушап, растеряться итеп китте...

Сокурода көчкә кунарга керттеләр. 8 балалары бар! Әтиләре, бер уллары сугышта икән. Өй эче кырмыска оясы кебек — мыж итә. Улымны аеруча газаплы сагыну белән сагынам: үлеп китәр шикелле... Улым... Мин аның турында яза да алмыйм. Аны уйлаганда минем күңелемдә сплошной сызлау, ягъни бу газапны сүзгә әйләндереп тә булмый... Шулай ук ул да минем шикелле...

Фронтта эшләр бераз алга бара шикелле: Сталинградтан төньяктарак һәм көньяктарак безнекеләр 60—100 чакрым эчкә кергәннәр. (Бүгенге көнгә 64 мең пленный бар.)

Чыгып китәр алдыннан улым шыпырт кына: «Поцелуй меня, папа», диде. Аңлап түгел, әлбәттә...

12/XII-42.

Әйберләрнең беркадәресен җыйдым. Грушенцам бәйләгән ак оекбашны ямадым. Бу юлы мине җыеп озатып калучы да юк. Бер караганда яхшырак та. Үзем генә газапланам. Аерылышу бик авыр! Алар әле бернәрсә дә белмичә тыныч яшиләр.

15/XII-42.

Бүген соңгы тапкыр буларак Казанның күңелгә якын урыннарын, шул исәптән Пушкин урамын, Казанка буйларын әйләнеп кайттым. Ике тәрәзә... Шул ике тәрәзә каршында бик озак басып тордым. Ике тәрәзә артында булып үткән, хәзер күңелемне телгәләп торган вакыйгалар берәм-берәм күз алдыннан үтте...

25/XII-42.

Бүген Шәриф абзыйны җирләп кайттык. Хәтеремдә, 7 декабрь булса кирәк, Маннур кичәсенә килгәндә баскычтан йөгерә-йөгерә менеп килә иде. Мин аның болай егетләрчә йөрүенә гаҗәпләнеп:

«Әйбәт, Шәриф абзый, артыңнан җитеп булмый!» дидем. (Мин аның артыннан менеп килә идем.) Ул, гадәтенчә, междометие белән генә җавап бирде дә кереп китте. Кичәдә бик бодро утырды, һәм, бераз кызып киткәч, берничә тапкыр сикереп торгалады: «Яшә, Маннур!» дип кычкырды. Таҗи Гыйззәтнең сугышның әдәбиятка тәэсире турындагы ялгыш чыгышын төзәтте. Бик күтәренке рух белән сөйләде, гадәттә, ул сүлпәнрәк кеше иде. Ә бүген ул инде салкын туфрак астында.

31/I-43 ел. Мәскәү, юлда.

— Я, ничек соң анда?

Ул, кашларын җыерып, йодрыклары белән һаваны чүкечли башлый. Янәсе, кыйныйбыз! Кыйныйбыз! (Ул теле белән әйтә алмый. Алмый, чөнки авызы тулы икмәк — ашыйсы килгән...)

19/II-43.

Менә 23 көн инде, һаман юлда. Нинди генә җирләрдә булмадык, нинди генә идәннәрдә кунмадык, нинди генә чырайлар күрмәдек. Ашарга беткәнгә әллә ни гомер, әлегә хәтле аннан-моннан юнәтеп килдек. Бар шундый авыллар, ашарга түгел, эчәргә су алып булмый. Менә бүген дә. Ахтүбә дигән авылда туктадык.

Коеларының тирәнлеге 19 метр. Су ала алмыйлар, чөнки озын бау юк. Кар эретеп эчәбез.

Шунысы тагын, утын табып булмый. Камышинда дүрт-биш көн гел газета яктык... Йокларга ятсак, капчык-капчык солдат хатларын мендәр урынына баш астына салабыз.

23/II-43.

Зимовники. Биредә сугыш эзләре ярылып ята. Янган, җимерелгән йортлар. Үлгән атлар. Җимерелгән машиналар. Янган немец паровозлары. Янган җиңел машиналар.

27/II-43.

Кичә улымның туган көне иде. Мин төн буе кунар җир таба алмыйча, тездән пычрак сөреп, квартира эзләдем. (Дөресрәге, эзләдек.) Дөнья тулы солдат. Баш тыгар урын юк, берьяры кертмиләр. Төнге сәгать берләрдә шәһәрдән 2—3 чакрым бер авылда Сталинградтан качкан бер татар агай-энесе кунарга кертте. Чишенүгә егылып йокыга киттем. (Алдан ике төн вагонда бер тамчы йокы күрмәгән идем.) Торып, бар булганы белән тамак туйдыргач, киез итек белән пычрак сөреп комендантка квартир дауларга киттек. Ниһаять, бер ташландык йорт бирделәр. Тәрәзәләре ватык, ягылмый. Хуш исле печән өстендә шушы сүзләрне язып утырам. Безнекеләр Орелны алганнар.

Кайчан, ничек китәбез — билгеле түгел.

24/II-43.

Оҗмах нәрсә дип сорауга бераү:

— Оҗмах ул ягылмый торган бер йорттыр ки, аның идәненә печән җәелгән була, рәхәтләнеп йоклый аласың,— дип җавап биргән, имеш.

Икенче бераү:

— Оҗмах ул кайнар су бирә торган урын,— дип әйткән, ди.

Зимовникидан самолет белән Ростовка килдек. Аннан җәяү Батайскига. Ростов өстендә кара сөрем. Бөтен нәрсә яндырылган. Кара көйгән йортларның скелетлары гына ыржаеп тора. Яньчелеп беткән немец самолетлары ауный. Телефон чыбыклары пәрәвездәй булып буталып беткән. Ярылмаган авиабомбалар. Бомба ясаган тирән чокырлар. Янган вагоннар. Чатан этләр. Шартлатылган күперләр. Сугыш бу җирдән өермә төсле үткән. Үз юлындагы барлык нәрсәне немец яндырган, җимергән, таптап-изеп киткән. Шәһәр яңа гына терелеп килә.

Ниһаять, үзебезнекеләрне эзләп таптык. (Батайскида икәннәр.) Дон елгасын аркылы чыкканда (боз иде әле), патруль:

— Каян киләсез? — дип туктатты. Окружениедән кайтмыйсыздыр бит?

Документларны тикшерде. Берничә ай буе юлда килә-килә, безнең өс-баш, кыяфәт шундый хәлгә килгән, чырайларыбыз шундый ябыккан, саргайган, безне окружениедән чыгучылар дип белде. Батайскида редакция эшенә тотындык. (Бусын хәзер өстәдем — И. Г.).

1943 елның февраль ахырында самолет белән Ростовка килеп төштем. Кар бетеп бара. Шәһәр өсте күгелҗем томанмы, төтенме белән капланган. Минә самолетның тәгәрмәчләре җиргә тиделәр. Моторлар, гөрелдәп, самолетны аэродром янына тарталар.

Шәһәрнең тетелгән булуы өстән үк күренгән иде. Хәзер бөтен детальләре белән күз алдында: менә аэродром янында ук боеприпас төягән берничә немец вагоннары өстенә бомба килеп төшкән. Вагоннарның кайсы кырын яткан, кайсы чәрдәкләнгән, авиабомбалар атылышып җиргә сибелгән, ләкин ни өчендер ярылмаганнар. Кырыкка бөгелеп, бөтерелеп беткән тимер-томыр тавы өелеп калган. Взрывная волна якындагы өйләрне ишеп ташлаган.

Без тыкрык белән шәһәргә чыгабыз. Аяк астында телефон чыбыклары чуала, патроннар, снарядлар, гранаталар аунап ята. Янган, кырыкка бөгелеп куркыныч төскә кергән танклар, автомашиналар: кайбере үләксә шикелле сузы-

лып ята, кайберләре үлем алдыннан, үлем газабы белән газапланган кебек, арт «аякларына» басып, бөтен гәүдәләре белән алга ыргылып торалар.

Без, тимер чыбыкларга абына-сөртенә, шәһәрнең җимереклегенә таң калып барабыз.

Без барасы җир биредән 12 километр җирдә. Бирелә гомумән кызык: бераүләр әйтә 8 километр, ди, бераүләр — 12; кай вакытны барасың-барасың, һаман 8 километр кала, барасың-барасың, һаман 8...

Боз өсләп Дон аркылы чыкканда патруль туктатты: өсләребез коточкыч иде. Үткәрде. Киттек. Бик озак эзләп йөри-йөри, ниһаять, таптык.

Ике-өч көннән соң Батайскидан без яңадан Ростовка күчтек. Без узган юлы Ростовның үзәген күрмәгән икәнбез әле. Ләкин үзәкнең исеме генә калган — үзе юк инде. Бер генә исән йорт калмаган: кара тәрәзәләр (дөресрәге, тәрәзә урыннары), саламдай бөгелгән тимер балкалар, ишелеп төшкән түшәмнәр, чәлпәрәмә килгән пыяла... тау-тау кирпеч — менә шул бөтен калган әйбер.

Халык гадәтләнгән. Янган красавица-йортларга берәү дә күтәрелеп карамый. Тик без генә аһ-уһ дип барабыз. Памятниклар ватылган, бакчалар киселгән, тапталган, магазиннар яндырылган, бөтен җирдә: тимер дә кирпеч, тимер дә кирпеч. Әнә кызлар көлешә-көлешә таган атыналар... Берәүләр мәктәптән кайтып килә.

Ростовта әлегә водопровод эшләми, электричество юк, мунча юк, трамвай юк.

Кичә политотделның кадрлар бүлегенә — Ростовтан 35—40 километр җиргә (һәм аннан ары хуҗалык бүлегенә) бардык... Баштанаяк пычракка манчылдым. Машинада утыра-утыра тәмам каттым.

Бүген ике сәгатьләр чистарынгач, ниһаять, пальтоларым, чалбарларым, бүрек, ботинкаларым бераз адәм рәтенә керде.

4/III-43.

Ростовта тора башлаганга да байтак вакыт үтте. Өч номер газета, бер-ике листовка чыгардык. Ләкин соңгы көннәрдә күңелне ниндидер бер корт өзлексез кимереп тора. Һичбер күренеп торган сәбәбе юк, ә эч поша да поша. Кичәлебүгенле бу «корт»ның сәбәбен таптым. Туган-үскән җирне сагынам икән!.. Бүген сугышлар бетеп шунда кайтсам, мостовой ташларына хәтле үбәр идем мин аның.

Бирелә дә безнең җир, үз шәһәребез, үз табигатебез, ләкин Гурий Николаевич бакчасындагы топольләр, Мирәтәк урамындагы сазлык, пычрак, ындыр артындагы грива, Казан белән Мирәтәк арасындагы озын юл миңа чиксез якын. Чөнки мин шунда яшәгән, шунда минем хатыным, балам, бөтен тормышым минем шунда калган. Мин хәзер ничектер ике тормыш белән яшим: үзем бирелә, күңелем анда. Алар бүген анда нишлиләр, Валерик нәрсәләр сөйли, ниләр эшли — гел шул турыда уйлыйм, «корт» һаман кимереп тора, эшләргә, яшәргә ирек бирми.

Хәзер үз илеңдә, үзең теләгән эш белән мәшгуль булсаң икән!

Бирелә инде яз! Ләкин бу яз да түгел, кыш та түгел — недоразумение! Бездәге аяк астында шыгыр-шыгыр килә торган кар бирелә юк. Яз көне бездә кар йомшап, боламыкка әйләнеп китә дә, суга әйләнеп, җәелеп ята, яисә гөрләп ага башлый, ә бирелә әллә нәрсә шунда — үз ягың түгел диген дә бетер инде. Без, йөреп керергә дип, урамга чыктык. Ростовның иң тетелгән, ләкин кайчандыр иң матур урамнарыннан йөреп арыгач, кайтып ашадык та, мин газета алып ятып кына торган идем, тагын башланды. Башта карарга гына дип, йөгереп чыктык: шундый матур булып тезелеп киләләр, ә зениткаҗың тәтене, ак чәчәк шикелле, таралмыйча бик озак тора. Мин авызны ачып карап торам. Халык чабыша башлады. Гөрс-гөрс шартлый, сызгыра, безне төрткәләп подвалга төшерделәр. Бомбежканың нәрсә икәнен бераз аңлый башладым... Әле бүген дә урамда ятучылар бар — җыеп бетермәгәннәр.

Бүген тагын килделәр. Әле миңа — бомба астында булмаган кешегә — кызык. Ләкин шулай да подвалда яхшырак. Бер партия үткәндә мин подвалда

идем, икенче, өченче волналарны өйдә кичердем. Сипте — борчак урынына. Гел тирә-күрше урамнарга эләкте, бу юлы безгә эләкмәде. Барып карадым — атларның эчләрен актарып ташлаган. Кешеләр ята. Өйләрнең тәрәзәләрен, ишекләрен, түбәләрен туздырып ташлаган. Бөтен урам чуп-чар белән тулган.

22—23/III-43.

Кызык күренеш. Ике бомбежка арасында урамда шаулашып балалар уйный, таган атыналар; бомба тавышы ишетүгә, җил очырып ташлаган кебек, юкка чыгалар. Бераз тынгач — тагын: көлгән, уйнап-куышып йөргән тавышлар.

25/III-43.

Кичә, бүген сыерчык сайраганны тыңладым. Аларның да, бичараларның, ояларын өфертеп төшергән.

Тиреслек башыннан (Ростовта) бер немец солдаты мәетен табалар. Шушы мәет өчен немецлар тиреслек яныннан узучыларны автоматтан атып үтереп торалар.

Ростов-Донда торганда машинада кайтып киләбез. Ябышкак буран. Кыр уртасында ялгыз бер ат башын җиргә төртеп тик басып тора. Тире белән сөяктән генә гыйбарәт. Ташлап калдырганнар.

Бер кыз көянтә-чиләкләр белән суга бара. Буш чиләкләрен шыгырдатуы, малай чакларны искә төшереп, күңелләрне әллә нишләтеп җибәрде.

Винтовкамның мушкасында фрицның газраилен күрәм (бер снайпердан ишеттем).

Яз. Кояш балкый. Чәчәккә күмелгән бакчаларда шыпырт кына үлем йөри.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява. Язгы, җылы яңгыр астында агачлар рәхәтләнеп, оеп утыралар. Һавада чәчәк исе. Яңгыр туктап та өлгермәде, кояш килеп тә чыкты. Яфрак очларындагы яңгыр тамчылары ялтыр-йолтыр килеп тора башладылар.

Ябыктым. Юарга бит калмады.

Снайпер Жидяев мондый хәйлә кулланган: немецлар озак вакыт күренмәгәч, немец ДЗОТы янындагы чуп үләннәренә ата да үләннәр дөрләп яна башлый. Тегеләр, бу ни хәл дип, йөгерешеп ДЗОТтан чыгалар. Снайпер шул арада боларның берничәсен чүкеп өлгерә.

Икенче тапкыр мондый хәйлә: үзе белән автомобиль гудогы алып бара. Гудокны кычкыртуга фриц траншеядан башын күтәреп карый. Жидяев шунда аны атып ега.

Машина безне очырта гына: артта тузан бураны айкалып кала. КПКда бер генә минутка туктатып, документларыбызны тикшерәләр дә (алгы сызыкка барганда гел тикшерәләр иде) без тагы алга, көнбатышка таба чаба башлыйбыз.

Машина түбән китә башлады, алда тар гына елга күренде. Елга буена тәбәнәк тау сузылып яткан. Шушы тауга сыенып, кечкенә генә авыл утыра. Авылга кергәч, машина туктады. Шофер чиләген алып суга йөгерде. Мин карап торам. Бер кыз яшелчәләргә лейка белән су сибеп йөри. Тавыклар тирестә тараналар. Алар арасында, күкрәген киереп, әтәч басып тора. Тыныч тормыш. Ә бит фронтның борын төбендә диярлек!

Шофер су алып килде. Кузгалдык. Авылдан чыкканда кызлар, кулларындагы сирень чәчәкләрен болгап, машинаны туктаттылар да безгә чәчәкләр бирделәр. Кайтышлый безгә кагылыгыз, мунча кереп чыгарсыз, диләр. Шаярып әйтәләр дип торам, чынлап икән:

— Клаваны сорасагыз, бөтен кеше күрсәтер. Бездәге кебек мунча берьяры юк,— дип калдылар.

Армиягә килеп җиттек. Врачта кундык. Яшь кенә кыз. Безгә витаминный экстракт белән чәй эчерде.

Сталинградта (бер капитан сөйләде): Идел яры. Блиндаж. Җиде сугышчы. Өстәрәк тагын блиндаж. Анда немецлар. Ике блиндажның да суы беткән. Эчәселәре бик килә. Немецлар язу ташлыйлар:

— Әйдәгез, сез дә, без дә суга барабыз! Атышмыйк!

Ике блиндаждан да котелоклар күтәреп чыгалар да Иделгә төшеп китәләр. Бер як та атмый. Күзәтеп кенә торалар. Безнеке ятып эчә дә ике кулындагы ике котелокны суга чумыра. Аннары кайтырга чыга. Немец та чумырып алып кайтырга чыга. Икесе дә кайта башлыйлар. Менеп җитәрәк безнеке ташка абынып суын түгә, кире йөгереп төшеп китә. Немец инде кайтып җитте, блиндажга кереп китте. Ә безнеке әле менеп кенә килә. Немецлар атармы, юкмы? Ике кулына ике котелок тотып, тауга менеп килүче солдатны атып егу аларга хәзер бик ансат.

Атмыйлар. Егет кайтып керә. Суны эчмиләр, авыз чылату өчен генә тоталар.

Инспекторский смотр вакытында бер яшь кавалерист бер фигураны ясый алмый. Атны матур биетеп барырга кирәк — анысын эшли. Янып торган киртә аркылы сикерергә кирәк — сикертә. Соңгы фигура — зур өстәл, өстәл кырыйларына шешәләр тезеп куйган. Шушы өстәл аркылы сикергәндә башыннан фуражкасы очып төшеп кала. Яшь кавалерист бик хурлана:

— Рөхсәт итегез! — ди ул командирына. Бөтен көчкә чабып килгән уңайга фуражканы җирдән алып кияргә рөхсәт сорый. Бирәләр. Ул бер кулы белән атның ялын чорнап тота да аягын атның сыртына эләктерә. Томылып чабып барганда фуражкасын алып башына кия. Гөр килеп кул чабалар. Манеждан чыгып барганда, бер кыз моңа чәчәк бүләк итә. Кавалеристка чәчәк бүләк итү кызлар башына гына килергә мөмкин!

*

* *

Менә без инде Таврида далаларында...

Румыннар бик каты җиңелгәч, румын солдаты плен калган. Плен калса да, ул ничектер иректә йөри, аны әле безнекеләр җыештырырга әллә өлгермәгәннәр, әллә йөри бирсен, дип чыгарып җибәргәннәр... Арык. Өс-башы тетелгән. Бер сыер җитәкләгән дә бара... Бездә молдаван егетләре бар иде, шулар моңардан сорыйлар:

— Кая барасың болай?

Тегенең җавабыннан молдаваннар егылып көлә башладылар. Сугыш бетте, өемә кайтып барам, ди, имеш. Румыннар җиңелгәч, димәк, сугыш беткән була, бу өенә юнәлгән. Хуҗалыгында сыеры да юк икән, кырда йөри торган бер сыерны да иярткән.

Кырымга безнең гаскәр апрель (1944 ел) башларында килеп керде. Апрель ае — елның матур вакыты, бигрәк тә Кырымда. Безнең редакция Симферополь шәһәрендә урнашты...

Һич көтмәгәндә редакциягә шагыйрь Әхмәт Фәйзи килеп керде! Аны безнең редакциягә эшкә җибәргәннәр. Газета чыгару ансатлашып китте, чөнки Әхмәт нинди генә эшне дә менә дигән итеп эшли. Каштаннар чәчәк аткан чак иде, Әхмәт каштан чәчәкләре хакында шигырь язды. Басарга булдык. Русчага тәрҗемә итеп полковникка күрсәттек (кагыйдә шундый, татар газетасының барлык материалы русчага күчерелеп, полковникка бирелә). Полковник әйтә, бу шигырь артык нечкә, моны укыгач, сугышчының күңеле өзелеп китмәгәе, ди. Алай да басарга рөхсәт итте.

Әхмәт Фәйзи дә күзлекле, мин дә күзлекле — икебез дә төнлә бик начар күрәбез, төнге тревогалар вакытында Зәки безне җитәкләп йөртә. Әлбәттә инде, абынулар, егылулар, зур начальникны танымыйча, честь бирми калулар була.

Май ае. Тагын сыерчыклар килде. Кырымда да сыерчыклар. Аларның килүе безгә дә шатлык булды: алар безнең яшьлегебезне искә төшерделәр. Сыерчыклар бомба астында йомырка салды; бомба астында бала чыгарды; бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр корт ташып, аларны туйдырдылар. Кайвакыт карап торганда мин таңга кала идем: шул кадәр тырышып, ашкынып хезмәт итүдән алар ничек арымыйлар икән! Менә берсе ашкынып кайтты да, кортын

тиз генә каптырып, үз телендә нәрсәдер кычкырды. Шыр-шыр килеп торган балалары тып-тын булдылар. Нәрсә диде ул аларга? «Тын гына ятыгыз, дошман килеп тотмасын»,— дидеме? «Алга бик сузылмагыз, егылып төшәрсез»,— дидеме? Ул, атылган кара таш кебек, күздән югалды.

Иртәгесен юынырга чыксам, сыерчык балалары юк — аларны мәче менеп ашаган. Никадәр хезмәт әрәм китте! Никадәр ана мәхәббәте, никадәр йөрәк җылысы, никадәр акыл һәм мускул көче явыз мәченең үткен тешләре астында һәлак булды.

Ә ул, бичара ана, башын салып, сызгырынгалап оясы янында утыра. Ул һаман оясын ташламый. Ул яңадан йомырка салмакчы, сары авызлы балалар чыгармакчы буладыр әле. Әйдә, чыгара бирсен! Җәй алда әле. Ләкин мәченең дә тешләре исән, тырнаклары үткен!

Немецлар Севастопольдән куылып бетмәгән чактарак безнең өскә бомба ташлаулар шактый еш була иде (чөнки фронт штабы Симферопольдә), Севастопольдән сөрелеп, немец Румыниягә олаккач, бомбага тоту сирәгәйде.

Сирәк булса да төшә торган бомба безнең бер таныш танкистыбызны үтерде: капитан Сәлим Мәгъсумов әле кичә генә исән иде, без аның белән Кырым кояшы астында сөйләшеп утырган идек, аның турында газетабызга да язып чыгарган идек, ә бүген ул инде юк. Үлде дип, газетага бер-ике җылы сүз дә яза алмыйбыз, хәрби газеталарга үлем турында язу гадәте юк. Сугышта солдат үлемне минут саен күреп тора, тагын газета битләреннән дә үлем хакында уку авырга китәчәк.

Хәтеремдә, капитан Мәгъсумов Арча ягыннан иде шикелле. Кечкенәдән ятим калгач, атасының энесе Хәниф агай Сәлимне үз семьясына алган. «Көндез каз көтүе көттем, кичләрен гармун колагы тарттым», дип сөйләгән иде ул миңа. Үзен «улы» итеп өенә керткән, артык кашык итеп түгел, ә үз баласы итеп тәрбияләгән Хәниф абзыйны һәм аның ягымлы карчыгын Сәлим минем алдымда бик якын сүзләр белән искә төшергән иде, аларга хатлар язып, акчалар җибәреп торуын әйткән иде.

...Сугыш җирендә кешенең үлүе табигый хәл булса да, Сәлим Мәгъсумовның көтмәгәндә һәлак булуы, җитмәсә инде, Кырымда сугыш беткәч, җитмәсә, елның иң матур чагында — яз көне, бөтен дөнья чәчәк атып утырган чакта, җитмәсә, кичә генә безнең белән сөйләшеп утырган яшь, таза кешенең шулай очраклы үлем белән (бомба төшеп) үлеп китүе бик фаҗигале булды...

Кырымнан Карпатка күчтек. Карпаттан ага торган суда коенып мендек. Әйдә инде, без коенмаган су калмасын. Биредә аткан тавыш әллә ничә кат булып, әллә кайларга гөрелди. Фәйзи (Әхмәт Фәйзи) җырлап караган иде, аныкы гөрелдәмәде.

Карпат таулары итәгендә, куе үлән арасында утырабыз. Тау елгасының салкын суы ташлар арасында сикерә. Баш өстендә имәннәр моңлы шаулыйлар. Әллә нигә бер гөрселдәгән туп тавышлары, таудан-тауга бәрелеп, әллә ничә катлы булып, озак яңгырап тора.

— Кайчаннан бирле сугышам дисезме?

Ул үзенең сүзен шулай башлап җибәрде. Ул дигәнем — минем яңа танышым, гвардия өлкән сержанты Әбсәләмов Мөхәммәтгәрәй дигән егет. Без аның белән шушы елга буенда очраштык.

...Ташлар арасыннан үкереп аккан салкын суда ничек кирәк алай коенып чыктык та, бер карт имән төбенә утырып, сөйләшә башладык.

— Беренче көннән бирле ут эчендә йөрим,— ди ул. Һәм, тәмәкесенең әче төтененә төренеп, әкрен генә сөйли башлады.

— ...Ростов буенда авыр яраланып, бик озак госпитальдә яттым. Терелеп яңадан фронтка килгәндә, кырык дүртенче елның феврале җиткән иде инде. Өзлексез ике ай өйрәндек: ДОТларны ничек алырга, ут валы артыннан ничек барырга, граната сугышы, төнге сугыш, көндезге сугыш... Бөтенесен дә өйрәтteләр. Борылырга да вакыт юк. Мин инде кичә генә фронтка килгән яшь солдат түгел, күпне күргән карт сугышчы, шулай да, яшерен-батырын түгел, шактый көчәнергә туры килгәләде. Шунсыз мөмкин дә түгел — Кырымны азат

итәргә җыенабыз бит! Инде бөтенесен дә беләбез кебек. Йокларга ятсам, төшемдә дә граната сугышын күрәм, яисә ДОТны штурмларга барам.

Көтә башладык. Ниһаять, сәгать сукты. 10 апрельдә безнең дивизия һөҗүмгә күчте. Керчьтә инде без хәзер. Мин автоматчылар взводында, командирның ярдәмчесе. Башта без көткән каты сугышлар булмады. Без шундый алга чабабыз, кухня безнең арттан иярә алмый. Дошманның Акманай позицияләренә килеп җиттек. Немец — биеклектә, без — аста.

Атака рубежына чыгарга приказ булды. Киттек. Берничә метр атлыгышып киләбез дә, ятып, пластуннарча шуышабыз. Тигез җир. Немец күреп алды да минометтан төкертә башлады. Сикереп тордык, атылышып, ут астыннан чыктык. Сугышчыларны дәртләндереп иң алдан үзем йөгерәм: шинельне җилгә җибәрдем; бер кулда — автомат, икенчесендә — граната.

— Вперед! Вперед!

Колакта җил сызгыра — шундый атлыгабыз. Килеп җитәрәк яттык. Безнең взвод бик алга чыкты — арттагыларны көтәбез. Селкенергә дә ярамый, немец дигәнең ата да башлый.

Пулеметчы Никифоровка әйтәм:

— Әнә теге ячейкадагы автоматчыларны тончыктырырга барам, минем өскә ата күрмә, ундагы фрицларга яудыр, башларын күтәрә алмасыннар.

Гранаталар кыстырдым да киттем. Барам шуышып! Бәхеткә каршы, күрмиләр әле. Күрмәүләре бик шәп: хәзер бер-ике гранатаны өсләренә тондырам да эшләрен бетерәм. Һәм шулай иттем дә. Ул да түгел, гомуми атакага сигнал булды. Дәррәү күтәрелдек.

— За мной, ребята, вперед!

Мондый вакытта командирның алда булганы яхшы.

Берничә километрга сузылган цепь дошман позицияләре өстенә чаба. Үземнең взвод белән мин дә җилләнеп барам.

Автоматлардан сиптереп, «ур-ра» кычкырып, шундый дәһшәтле киләбез, немецлар окопларыннан чыгып берәм-берәм кача башладылар. Шушы операция өчен Кызыл Йолдыз алдым. Алданрак биреп куйган гаризам бар иде, партия сафына кабул иттеләр.

Шуннан соң Севастопольгә кадәр әллә ни каты сугышларда катнашмадым. Дөресен генә әйткәндә, телгә алырлык каты сугышлар да булмады.

Севастопольдә булганың бардыр инде синең, анда тау да таш. Ул тирәдә сугышлар да икенче төрлерәк барды. Тау сугышы бит.

Көндез бик каты сугышып, немецны берничә авылдан бәреп чыгардык.

Кичкырын бер биеклеккә килеп җиттек. Биеклек артында авыл. Немец биеклекнең теге ягында, без бу якта. Немец тау аркылы безнең өскә мина җибәрә. Окоплар казып өлгермәгән идек — яралanучылар да бар.

Кояш тау артына кереп тә өлгермәде, караңгы да төште. Күрәбез: авыл яна. Димәк, немецлар китәләр. Аларның гадәте шул: чигенә башласалар, яндырырга тотыналар. Безгә приказ: авылны алырга.

— Вперед!

Тын гына кузгалып киттек. Тауны аркылы үтеп, авылга килеп төштек. Тәрәзәләрдән, ишекләрдән ялкын ургылып чыга. Һавада әллә нинди кап-кара кошлар очалар. Күңел шомланып куя. Йортлар, коймалар буйлап авыл эченә агылабыз. Авылны алгач, аңардан чыгып бер 500 метр киттек. Яңа приказ: занять оборону!

Күрәбез, алда дошман юк. Штабка хәбәр иттек. Шундый-шундый эш, рөхсәт итегез алгарак үтәргә. Полк штабыннан әйтәләр:

— Рөхсәт юк! Артподготовкасыз кая барасыз!

Соңрак, күрәсең, генерал рөхсәт иткәндер: безнең полк кузгалып китте. Иң алдан безнең рота бара. Караңгы. Саклык белән генә барабыз. Иртән без инде Түгәрәк Бухта янында идек. Каршыбызда — авыл. Сулда — диңгез. Оборонага яттык. Беләбез, дошман шушында каршылык күрсәтәчәк.

Башта танклар җибәрде. Безнең артиллеристлар аларның кайсын яндырып, кайсын имгәтеп ташладылар.

* * *



Теш врачы Харисов Салихны мин Иске Самборда очратам. Кечерәк кенә буйлы, чандыррак кына гәүдәле бу егет 1920 елны ярлы итекче семьясында дөньяга килгән. Кардәшләре янына Ташкентка китеп, анда теш врачлыгына укып, ул инде сугыш башланганчы ук армиядә эшли. Сугыш аның профессиясен бераз үзгәртеп, катлауландырып җибәрә. Ул яңа теш кую, искесен ямау кебек, борын-борыннан килә торган гади эш өстенә, яңак сөягенә һәм биткә операция ясау, яңа теш казнасы кую, ертылып, умырылып беткән биткә яңа ит, яңа тире үстерү кебек гаять катлаулы эшләр белән шөгыльләнә башлый. Сугышта нинди хәлләр булмый: берәүнең иренен алып китә, берәүнең тешләрен кырып ташлый, ә берәүнең ияк, яңак сөякләренә зарар килә. Менә шул вакытта врач Харисов Салихның ярдәме авыруларны үлемнән, инвалидлыктан, гариплектән коткарып алып кала.

Сугышта врач кына булу аз, командир да була белергә кирәк. Сугышның беренче елларында Харисовка кешеләрне чолганышлардан алып чыгарга туры килә.

Үзенә тапшырылган алтмыш ике кешене ияртеп сигез көн, сигез төн буенча, тирән сазлыклар аша, куе урманнар аша үтеп, көзге салкын яңгырлар астында шинельсез, палаткасыз йөреп, алган сухари беткәч, җиләк, гөмбә белән туенып, дошман очраса, аның белән сугышып, тугызынчы көн дигәндә ул алтмыш кешене үзебезнекеләр янына алып чыга. Икесе, яраланып, юлда үлә. Харисов үзе шешенгән була — аны госпитальгә салалар.

Терелеп чыккач, аны Кавказга җибәрәләр. Сазлыклар, мүк җиләкләре яныннан килгән кешегә Кавказ — мәһабәт таулар, таулардан сикереп төшә торган шаулы елгалар, төбе күренми торган тарлавыклар матур тоела, ләкин сугыш кайда да бер. Ул тагын врач, тагын операцияләр ясый... Бер вакыт алты сәгать буена бомба астында операция ясарга туры килә. Соңыннан карасалар, палатка әллә ничә урыннан бомба кыйпылчыгы белән тишелгән була.

...Бер тапкыр, шул ук Кавказда, берничә дистә яралыны ашыгыч рәвештә госпитальгә озатырга кирәк була. Бердәнбер юл бер тау аркылы үтеп, төпсез тарлавык буйлап сузыла. Көндез аннан һич үтәр хәл юк, күрше биеклектән немецлар машинаны түгел, ялгыз кешене дә үткәрмиләр — атып калалар. Ә төнлә белән ут кабызмыйча гына үтүе тагын читен — машинаң-иең белән тарлавык төбенә егылып төшүең мөмкин. Анда төшсәң, сөякләреңне дә җыя алмассың. Ә авыруларын һич кичекмәстән озатырга кирәк. Нишләргә?

Караңгы төннең берендә врач Харисов башына ак сөлге урап төпсез чокыр янындагы юлга чыга. Ул таяк белән төрткәләп, ак чалмасы белән юл күрсәтеп, алдан атлый, алар артыннан яралылар төялгән машиналар бара.

Шулай итеп, алар таңга кадәр байтак яралыларны күчереп өлгерәләр.

Сугыш Кавказдан Кубань далаларына, аннан Украинага, Днепр буена, ниһаять, Днепрны үтеп, уң як Украинага килеп чыга, биредә безнең гаскәрләр һөҗүм итәләр. Сумаладай пычрак аяк та атларга ирек бирми. Машиналар үтә алмыйча юл буе тезелеп калалар. Яралыларны артка күчерү өчен медсанбатның транспорты җитми башлый. Бу эшкә тагын врач Харисов тотына. Күрше авылга барып хатын-кызларны җыя, хәлне аңлатып бирә һәм ярдәм итүләрен сорый.

Иртәгесен носилкалар күтәреп өч йөзләп авыл хатын-кызлары медсанбатка киләләр. Яралыларны төреп носилкаларга салалар һәм пычракка-нигә карамастан, сигез километрдагы госпитальгә күтәреп алып китәләр...

Сугышка тәҗрибәсез һәм яшь врач булып килеп кергән Харисов хәзер инде утны-суны кичеп, көрәш һәм авырлыклар эчендә чыныгып, тәҗрибәле, белемле, үсеп бара торган врачка әйләнгән.

Татар халкы үзенең мондый уллары белән мактанырга хаклы.

*

* *

4 октябрь, 44 ел.

Польша. Тел белмибез. Хәтта мәчесе дә «пес-пес» дигәнгә әйләнеп тә карамый. Көз җитте. Яфрак коела. Аяк астында зәгъфран төсле сары яфрак түшәлеп ята. Көн саен яңгыр. Анда да, монда да су җыелып ята. Ә кояш безне онытты. Табигатьнең көзге моңсулыгы, көннең ямьсезлеге, баш өстендә торган кара болытлар күңелне таш кебек изә.

Бүген сыерчыклар үзләренең оялары белән саубуллаштылар. Канат җилпегән булалар, сайраган булалар. Яз көннәре искә төште. Кырымда йөргән көннәр. Күңелле кояшлы көннәр. Күңел талпынып, сикереп куйды. (Кырымны безнең фронт алган иде.)

Ләкин кошчыклар соңгы җырларын җырлап бетерделәр дә бөтенләйгә китеп бардылар. Алар китте, без калдык. Алар язлый тагын әйләнеп кайтырлар, ә без... үз ояларыбызга әйләнеп кайта алырбызмы?..

Сентябрь, 44 ел.

Минск шәһәре.

Ачыгып, каңгырап, Мәскәүдә йөри торгач, бүген таңда Минскига килеп төштек. Минск шәһәреннән сөремләнгән таш тартмалар гына калган.

Юл газабы — гүр газабы. Вагонда йокысыз, ач килеш тәүлекләр буе аяк өс килә-килә тәмам ябыктык. Көзгемә карасам, бер биш еллык картайганмын...

Вокзал каршындагы мәйданга туктап, көзгене чыгарып, бритваны учка кайрап, урам уртасында сакал кырдым. Алда башланмаган юл.

*

* *

...Мин тау битеннән менәм. Баш очымда картайган сары яфрак оча. Авыр болытлар җилкәгә орынырлык булып йөриләр. Яңгырдан бөтен табигать арыган: ярым ялангач агачлар, башларын бөгеп, тын гына торалар. Арыганнар. Мин дә арыдым. Бөтен нәрсәдән: агач ботакларыннан, коелып бетмәгән сары яфраклардан, минем күпне күргән фуражкамнан...

Хәтта борын очымнан, ияк очымнан тамчы тама.

Бомбежка вакытында авыздан тимер тәме килә. Сапун гора өстендә бер миномет полкы гына 14 вагон мина ата.

...Көне-төне сары яфрак катыш яңгыр. Салкын яңгыр. Җир шары болыт белән томанга уралды. Айны, кояшны, йолдызны күрмәгәнгә әллә ни гомер...

Борынгылар шикәргә карап чәй эчкәннәр. Поляклар чөгендер икмәгенә карап бәрәңге ашыйлар.

Михалина килсә, кояш чыккан кебек була. Мин хәзер вакытны төнгә, көнгә, айга бүлмим, «Михалина килгән көн», «Михалина килмәгән көн» дип, яисә «Михалина килмәгәнгә ике көн булды» дип бүлеп йөртәм.

Михалина — чибәр кыз. Ул керсә, пычрак өйдә нур балкый. Аның тавышы мине пружинадай турайта. Без аның белән сөйләшәбез. Мин тирләп чыгам. Ул мине аңламый. Мин аны аңламыйм. Ләкин безнең күзләр бик аңлашалар.

*

* *

Колакка чалынган сүзләр (бер офицер әйтә):

— Мин ужасно бал яратам! (Әйтерсең аны бүтәннәр яратмый.)

— Минем хатын роза чәчәген ужасно ярата! (Әйтерсең бүтәннәрнеке яратмый.)

«Хәлимне» язганда (язарга насыйп булса), үземне һич авызлыкламаска, барлык фантазиягә ирек куярга. (Бөтен фантазиягә ирек куеп яза алмадым — бусын бүген өстәдем. И. Г.)

Матур кешегә кызлар бөтенесен дә гафу итә. Матурлык — деспотлык.

Ярату белән куралмау (ненависть) янәшә яши: алар урын алмашалар.



*
* *

...Тузанлы урамнар, таш йортлар, Казанка буе... Ничә тапкыр ташлап киттем инде мин сезне! Ләкин яңадан һәм яңадан сезне сагынып кире кайтып кердем.

Сәгать саен, минут саен күңелемнән ташып торган, иртән, көндез, кичен, көн буе күңелемнән китми торган матур, җылы сүзләрне кемгә әйтим, сагынулы карашларымны кемгә теким, хәлдән таярлык булган, алҗыган минутларымда...

Аерылып калган шәһәрнең тузанлы ташлары сагындыралар. Нигә икән? Билгеле инде: аның урамындагы һәр ташка кадәр (минем өчен) берәр кадерле истәлек белән бәйләнгән. Ят кеше өчен телсез, колаксыз булган нәрсәләр: ябык агачлар, урам ташлары минем өчен җырлап торалар, минем уйларыма кадәр ишетәләр.

Ниһаять, шушы тузанлы таш шәһәрдә минем йөрәгемнең яртысы өзелеп калганны да онытырга ярамый. Шул үзе генә дә җитәрлек түгелмени?..

*
* *

Кичен йокыга ятканда уйлыйм: бүген төш күрмәмме, төшемдә үземнең дусларымны күрмәмме, дим. Күрсәм, көн буе күңелләнеп, бөтенләй икенче кеше булып йөрим.

Кайвакыт мин төшемдә үземнең китапларымны күрәм. Рәхәтләнеп, ятып укыйм, имеш.

21/XI-44.

Польша.

Костёлга барышлый ул минем яныма керә; аның кесәсендә кечкенә генә изге китап; аның ул китабыннан хушбуй исе, кыр чәчәкләре исе аңкый. Ул үзе дә кыр чәчәге кебек... Аның үзеннән дә чәчәкләр, кырлар, урманнар исе аңкый. Бу чибәр поляк кызының зәңгәр күзләреннән мин күзләремне ала алмыйча йөдәп бетәм.

Миңа ул кулларын бирә. Аның куллары каты, ул күп эшли. Бүген ул житен талкыган. Аның үз чәчләре дә җитен кебек. Күзләре — зәңгәр чәчәк кебек. Ул миңа ниндидер матур хикәядән төшеп калгандыр шикелле тоела.

Мин бер ярлы поляк өендә ятам. Монда килгәч, минем яраларым ачылды. Мин ихтыярсыз ятып калдым. Бик күңелсез миңа монда яту. Тышта көне-төне салкын яңгыр ява. Агачларның соңгы яфраклары коела — сары, күңелсез яфраклар... Җир шары алама болытка төрелгән: якты кояшны күрмәгәнгә әллә ни гомер...

Минем бәхеткә каршы, Михалина еш кына килеп чыга. Ул керү белән өй эче яктырып китә. Мин инде аның зәңгәр күзләреннән бүтәнне күрми башлыйм. Аның күңелле тавышыннан бүтәнне бөтенләй ишетмим...

3/IV-45.

Мин савыга башладым. Яраларым йомылалар. Врач әйтә, тиздән-тиздән, ди.

Михалина мине костёлга ияртеп бара. Без сөйләшми генә барабыз. Шулай рәхәтрәк. Кайвакыт безнең бармаклар очрашалар. Без карашып алабыз да, елмаешып, әкрен генә бара бирәбез.

— Мин алла белән кеше юкта гына сөйләшергә яратам,— ди ул. Шуңа күрә без ашыкмыйбыз. Кеше саркып бетсен әле, дибез.

Кереп янәшә утырабыз.

— Сиңа карап торырга ярыймы? — дип сорыйм мин. Ул елмая да кашларын җиңелчә җыерып куя. Мин аңа карап торам...

20/IV.

Германия җирендә, Берлиннан ерак түгел бер нарат урманында торабыз. Югарыдан әйтүләренә караганда, безнең гаскәр бик зур тизлек белән бер-ике көндә Берлинга барып җитәргә тиеш... Ләкин алай булмады. Аның каравы, Берлиннан көньяктарак безнекеләр шактый алга китеп, хәзер Дрезден капкасы төбенә җиттеләр. Тиздән союзниклар белән кушылу булачак.

22/IV.

Күңелсез көн. Эчем поша. Безнекеләр Берлин кырыенда сугышалар.

25/IV.

Бүген безнең гаскәрләр Берлинны урап алдылар! Сөенечнең чиге юк. Ләкин «вакытсызрак» булды: безнең полоса бозылды!

19/V.

Франкфуртта булдым. Матур шәһәр — яшеллек бик күп. Качкан немец хатын-кызлары кире кайталар.

Кюстринда булдым. Бөтен шәһәр, таш кисәкләренә һәм тузанга әйләнеп, җирдә ауный.

20—25/V.

Берничә көн Дрезденда булдым.

*
* *

Кояш чыгып, дөнья яктылык белән тулгач, күңелемне шатлык коча. Үз гомеремдә мин кояш чыкканны, кояш баеганны аз күрмәдем, ләкин күргән саен табигатьнең бу гади күренеше минем күңелемне сихерли.

*
* *

Мәңге, мәңге яшисе иде. Ахыр чиктә бер сары чәчәк яисә әнә шул яфрак булып кына яшәргә дә риза булыр идем мин. Әй бит кем белә: минем үлемем бәлки шушы минутта минем артымнан атлап киләдер.

## Нәсерләр

### Синең хатларың

Мин синнән еракта, еракта... Дошманны куып, дошманны җиңеп, чит-ят туфракларга аяк бастык без. Баш очымда — ят күк, ят йолдызлар. Ят чишмәләр суын эчәм мин; ят һава сулыйм; ят җырлар тыңлыйм...

Әй сез, туган-үскән җирләр, карт Иделнең күңелле дулкыннары, таныш күкнең җем-җем йолдызлары һәм син — йөрәгемнең өзелеп калган яртысы — сез хәзер миннән еракта, еракта...

Сез еракта, ләкин минем күңелем һәр вакыт сезнең белән. Мин сезне бервакытта да телемнән төшермим. Мин сезне сагынам, юксынам. Мин сезне җырларымда җырлыйм.

**Төнлә төшләремдә күрәм,**
**Көндез әллә кайда сез,**

— дип җырлыйм мин.

Кайвакыт тынгысыз хыялым мине яңадан сезнең янга алып кайтып китә. Кайчандыр үткән тузанлы юллардан гүя тагын үтәм мин; кайчандыр эчкән салкын чишмәдән гүя тагын эчәм мин; кайчандыр кулларымны кыскан җылы кулларны гүя тагын кысам мин; кайчандыр үпкән кайнар иреннәрдән гүя тагын үбәм мин.

Эх, хыял, татлы хыял... Син мине алдыйсың ич: алар миннән еракта, еракта...

Ләкин еректан миңа күңелле хатлар килә. Мин аларны зарыгып көтеп алам. Әгәр яңалары озак килми торса, мин синең иске хатларыңны кесәмнән чыгарам да, окоп стенасына сыенып, йөз дә беренче кат аларны укый башлыйм.

Син миңа матур хатлар язгансың. Ул хатларыңда мин синең күз караш-ларыңны күрәм; синең ягымлы тавышыңны ишетәм; синең елмаюыңның җылысын тоям.

Бу авыр сыналу елларында кайбер хатын-кыз үзенең күңел сафлыгын саклап кала алмады: ирен, баласын онытып, биргән вәгъдәләрен онытып, үзенең йөрәк җылысын җиде ятка бүләк итте. Син алай булмадың. Шуның өчен мин синең саф кулларыңны, саф күзләреңне, саф иреннәреңне үбәм.

Хатларыңны ешрак яз, бәгърем. Синең хатларыңны укыгач, бөтен кайгыларым тарала минем. Синең хатларың минем күңел азыгым бит. Алар минем дусларым, сердәшләрем бит.

Өстемә салкын яңгыр коеп торсын; елан кебек сызгырып, колак төбемнән өче җил иссен; баш очымнан чинап миналар очсын, бөтенесе берни түгел, тик син бәгъремнән хатлар гына килсен дә, синең йөрәк җылың салкын окопта мине җылытып торсын.

Күрешү көннәре ерак түгел инде. Туган-үскән илгә кайтып, синең саф кулларыңны, туган җирнең изге туфрагын үбәр минутлар якынаялар.

**Польша, 1945.**

## Синең батист яулыгың

Әллә кемнән көнләшеп, син минем кулъяулыгымны алып калдың. Алдың һәм аның урнына үз кулың белән каеган кечкенә генә батист яулык бирдең.

Поезд мине еракларга алып китте. Син мине озатып, еракларда калдың.

Шул вакыттан бирле, батист яулыгыңны кулыма алган саен, синең күзләрең, синең кулларың, әйткән сүзләрең исемә төшә дә, күңелемне, ялкын шикелле, газап чолгап ала. «Бу яулыкны ул тоткан иде»,— дип уйлыйм мин. «Бу яулыкка аның күз нурлары сеңеп калган», — дим һәм, күзләремне яулыктан аерып ала алмыйча, бик озак карап торам.

Күтәрсәң Җидегән йолдызга җитәрлек озын юллар үттем инде мин. Аларның тузаны минем битем аркылы кечкенә яулыкка күчте. Яулык каралды, ләкин мин аны һаман юмадым. «Аның бармаклары тоткан бит моны»,— дип уйладым мин. «Кайчандыр мин берәм-берәм үбеп чыккан, мине иркәләгән һәм мин яраткан бармаклар тоткан бит аны»,— дип уйладым.

Сердәшем дә, уйдашым да шул яулык минем. Көзге тын кичләрдә, шаулап коела торган яфрак астына утырып, кулларыма алам да мин аны, саташкан кеше кебек, аңа үземнең серләремне түгә башлыйм. Мин әйтәм: «Яулыгым, җансыз батист кисәгем, син бәхетле: син ялгызлыктан газап чикмисең, сагыну

әчесен белмисең, бирәү өчен дә саргаймыйсың... Сине каеган кадерле бармакларны тагын үбәр көннәрем булыр микән!»
9/X-44 ел. Польша.

## Сыерчыклар

Күз җитте. Сары яфрак коела. Юлда пычрак сулар җәелеп ята. Кояш безне онытты.

Сыерчыклар бүген оялары белән саубуллаштылар. Шушы кечкенә генә кошчыкларның да ярату, сагыну кебек илаһи тойгылары бар бит!

Сайраган булдылар. Канат җилпегән булдылар. Ләкин язгы кояш урынына өстеңә салкын яңгыр шыбырдап торганда ничек сайрамак, талпынмак кирәк!

Менә ул канатларын төзәтте. Бөтен каурыйларын туздырып кагынды, кабарынды. Аннары як-ягына карап, кызганыч итеп бер чыркылдады да очып китте. Быелга ул бөтенләйгә китте инде. Алар китте — без калдык. Алар язлый тагын әйләнеп кайтырлар, ә без... без үз оялрыбызга кире әйләнеп кайтырбызмы?

**Киткән кошлар кире кайта,**
**Кайтырбыз без, дускайлар,**

— дип җырлаган бер моңлы солдат. Мин дә шулай дип җырлап, күңелемне юатам.

**10/X-44. Польша.**

## Улым

Улымны сагынам. Үзем яшьтән үксез калып, бер сынык икмәккә табынып үскәнгәме, бичараның үксез калуыннан куркам.

Күзләрем туйганчы күрә дә алмадым үзен. Башта — ул читтә, аннары — үзем, аннары бу сугыш... Ул мине онытты. Ул хәзер мине юксынмый да торгандыр инде: әллә әтисе бар, әллә юк аңа...

Соңгы кайтуымда ул миннән бигрәк, мин биргән икмәккә шатланды. Ул мине оныткан, ә икмәкне ул ничек онытсын! Икмәк аңа туйганчы әләкми булса кирәк. Нәзек бармаклары белән икмәк кисәген йомарлап алгач, аның ябык йөзендә елмаю кебек бер нәрсә күренде: ул инде яхшылап елмая да белми иде, ахры...

**1944. Польша.**

# СУГЫШЧАН СӘЛАМ БЕЛӘН

*Тарихи җиңүебезгә 30 ел тулу уңае белән, дәһшәтле сугыш елларын искә төшереп, архивымда сакланган хатларны укып утырам. Фронтлардагы каләмдәш дуслардан килгән хатлар бар. Алар аркылы язучыларыбызның, — яшьләре булсын, өлкәннәре булсын, — ватан авыр еллар кичергән чакларда нинди фидакарьлек белән хезмәт иткәннәрен, алардагы бөек патриотлык көчен, нечкә гуманлык, кешегә карата гаделлек, дуслык, туганлык, мәхәббәт хисләрен күреп сокланасың, алар белән горурланасың. Хат авторлары арасында — бар сугыш кырында ятып калган иптәшләр, бар сугыштан соң арабыздан киткәннәре; бар, әле дә исән булып, тынычлыкта үткән 30 ел эчендә дә әдәбиятыбыз күгендә якты йолдыз булып балкуда дәвам иткән иптәшләр.*

*Әйе, ул хатларга карап. горурланасың да, кайберләрен укыгач, — нинди көчләре, шундый матур, өметле киләчәкләре булган кешеләребезне вакытыннан элек арабыздан алып китте бит бу сугыш! — дип, ачынасың да...*

*Олы бәйрәм көннәрендә мондый хисләрне ялгыз кичерү авыр. Мәрхүм иптәшләрдән килгән кайбер хатларны укучыларга да күрсәтәсем килә.*

*МИРСӘЙ ӘМИР.*

## Нәфыйк Яһүдин хатлары

Сугыш алды елларында Казан педагогия институтын тәмамлап чыгып, Арча ягында укытып йөрүче Нәфыйк Яһүдинне мин язучылар сафына ышанычлы адымнар белән килүче, әдәбиятыбызны яңа образлар белән баетырга тиешле өметле каләм иясе дип белә идем. Миңа аның тәгәлләнеп бетмәгән бер романы белән танышырга туры килде. Роман Оренбург ягында яшәүче татар казаклары тормышын гәүдәләндерә иде. Гражданнар сугышы чорына багышланган бу әсәр мине, әдәбиятыбызга яңалык алып килүе белән генә түгел, теле, стиле ягыннан да үзенчәлекле булуы белән бик нык кызыксындырган иде. Аны әдәби яктан тиешле дәрәҗәгә җиткерү өчен авторга үз киңәшләремне әйттем. Ул аларны хуп күрде һәм әсәрен камиллләштерү өстендә бик ныклап эшләргә кереште. Ләкин тәмамларга өлгермәде, сугыш башланды...

Нәфыйк сугышның башыннан ахырына кадәр хәрәкәттәге армия сафында булган, бүләкләр, яралар һәм җиңү алып, туган иленә кайткан. Ләкин, хатында үзе әйткәнчә, «дүрт ел буена урманнарда, окопларда» үткән солдат тормышы эзсез калмаган, күрәсең, кайткач ул озак яши алмый, вафат була. Менә аның миңа һәм тагын берничә иптәшкә, гомумән, барлык язучыларга адресланган, сугышның безнең өчен иң авыр чорында язылган

**БЕРЕНЧЕ ХАТЫ**

Мирсәй Әмир, Сибгат Хәким, Идрис Туктаров иптәшләр һәм татар совет матур әдәбияты өлкәсендә хезмәт күрсәтеп килгән барлык каләм мастерлары!

Бүген, җирәнгеч немец фашистларына каршы көрәш вакытында, күрсәткән хезмәтләрем өчен награда алган, «За боевые заслуги» медале белән бүләкләнгән көнемдә, мин сезгә үземнең шушы хатымны язам. Сезгә үземнең кайнар сәламнәремне җибәреп, сәламәт яшәвегезне, татар совет матур әдәбиятын үстерүдә, аны алга җибәрүдә яңадан-яңа уңышларга ирешүегезне теләп калам.

Үзем сәламәт. Кабахәт ерткычларга, кешелек дөньясының гомуми дошманнарына каршы көрәш фронтында миномет командиры булып хезмәт итәм. Дошман өстенә чуен һәм корыч ялкыннары яудырганнан тыш, буш сәгать һәм минутларда занятиеләр үткәреп, үземнең расчетымда булган сугышчыларның барысының да наводчиклар була алуларына ирештем. Сугышчыларымның кырык процентын кирәк булган вакытта үземнең урыныма миномет командиры була алырлык итеп әзерләдем.

Дошман кулы белән башкарыла торган чиксез ерткычлыкларны үз күзләрең белән күргән саен, кайнар йөрәктә дошманга ачу, гүзәл туган илебезгә, сөекле юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталинга мәхәббәт ялкыны көннән-көн ныграк кабына бара. Мин агитатор булып эшлим. Үземнең тәрбиямә тапшырылган сугышчыларда бөек патриотик рух тәрбияләүгә нык игътибар бирәм...

Татар совет матур әдәбияты өлкәсендә сезнең дә хезмәт күрсәтүегезгә, уңышлыкларыгыз һичшиксез бар булуына ышанам. Ул уңышлыкларның тагын берничә мәртәбәләргә кабатлануын телим.

Әдәбият өлкәсендә актив катнашып килгән иптәшләрне беләсем, Ватан сугышы чорындагы татар совет әдәбияты белән — өстән-өстән генә булса да — танышасым килә. Иренмичә хат язарсыз, «Совет әдәбияты» журналының 2—3 номерын җибәрерсез, арага кыстырып беркадәр кәгазь дә салырсыз дип ышанып калам.

Иптәшләрчә һәм сугышчан сәлам белән:

Яһүдин Н. К.

3/VII-42.

### ИКЕНЧЕ ХАТЫ

Мирсәй туган!

Сиңа үземнең дусларча кайнар сәламнәремне җибәреп, сәламәт яшәвеңне теләп калам. Андагы агай-эне һәм дус-ишләрнең барысына да миннән күп-күп сәламнәр тапшыруыңны үтенәм.

Менә, туганкай, бу сиңа Берлиннан сәлам! Мин кичә Берлин шәһәренә килеп чыктым. Монда мин командировкага килдем (безнеңчә, районнан Казанга килгән шикелле). Бүген эшемне бетереп, иртәгә кайтып китәргә тиеш идем (кайту дигәч тә, Казанга түгел инде, Познань шәһәренә). Ләкин, минем бәхеткә каршы дигәндәй, бүген ял көне — якшәмбе икән, учреждениеләр эшләмиләр. Шуңардан файдаланып, бүген мин көннең-көн буенча Берлин шәһәрен карап йөрдем. Иртә белән сәгать тугызда чыгып киттем, кичке 9 да кайтып кердем (торуым — Карлехорст шәһәрендәге кызылармеецлар гостиницасында. Искиткеч яхшы гостиница! Йомшак кроватьлар, йомшак урындыклар, дигәндәй, дүрт елга якын урманнарда — землянкаларда яшәгән солдат моның кадерен яхшы белә инде).

Бүген мин 100 чакрымнан артык йөрдем. Башта, трамвайга утырып, Берлин кырыендагы шәһәрләрнең үзәк урамнарын карап чыктым: Карлехорст, Шейнвейде, Кёненик, Уленхорст, Фридрихсферден шәһәрләрендә булдым. Монда яхшы гына зур-зур йортлар бар. Һәм алар, әйтергә мөмкин, бер дә ватылмаган-җимерелмәгәннәр. Бу районнарда немецлар да шактый күп: урам тулы хатын-кызлар, бала-чага һәм карт-корылар. Шунда ук кызылармеец һәм офицерлар ыгы-зыгы йөреп торалар. Трамвайда да шулай ук: алар халкы да, безнең кешеләр дә.

Трамвайда миңа нык тәэсир иткән ике вакыйга булды.

Менә трамвай КППга (контроль пропуск пунктына) җитеп туктады. Җилкәләренә автоматлар аскан кызылармеецлар кереп, немецларның паспортларын тикшерә башладылар. Ата немецларның гына паспортларын карыйлар, ана немецларның, күрәсең, юктыр инде, паспортларын карамыйлар. Менә шул

солдатлар арасында, үзенең йөзенә-битенә һәм мыек рәвешенә караганда, берсе татарга охшый. Ни булса да булыр, дидем дә, тоттым да сәлам бирдем мин моңар. Татар икән. Куанычыннан нәрсә эшләргә дә белми, мескен! Сөйләшәсе килә, ләкин вакыты юк. Уфадан ерак түгел бер авылдан икәнен, Габделвәли Миңлеәхмәтов булуын гына әйтеп өлгерде.

Трамвай һаман алга бара. Трамвай эчендәге ана немецларның үзара мыгырдanулары мине бер дә кызыксындырмый. Алар янында мин үземне-үзем тәкәббер тотарга тырышам һәм тәрәзәдән карап барам. Минем артта гына бер ана немец утыра. Аның кулында бала, ап-ак йөзле кечкенә генә бала. Менә шул бала, минем җилкәм аша, тәрәзәгә үрелә, минем гимнастерка җиңемнән тота, үз телендә нәрсәдер сөйләнгән кебек итенә. Анасы, елмаеп, бармагы белән миңа күрсәтә һәм нәрсәдер әйтә...

Мирсәй! Менә шушы урында син булсаң нишләр идең? Бу минутлар минем өчен гаять авыр кичерешле минутлар булдылар. Минем йөрәктә ачу кайный. Ләкин, балага ачулы караш ташлап, ата һәм ана немецлар арасында дәрәҗәне төшерәсем килми. Үз дәрәҗәң генәме әле? Без монда һәркайсыбыз үзебезне туган илебезнең вәкиле итеп сизәбез бит. Менә мин балага елмайган сымак итеп карыйм. Ах, авыр! Аларга кешечә күз сирпеп карау бик авыр! Ләкин, нишлисең бит, безнең җиңүчеләр булуыбыз зур шатлык һәм бу бөек исемне лаеклы рәвештә акларга кирәк... Ә алар, якты йөз күрсәттеңме, сыланырга гына торалар. Менә теге бала да, якты чырай күрсәткән сыман итеп карагач та, бөтен гәүдәсе белән миңа үрелә һәм җиңемнән тагын да ныграк итеп тота. Ләкин, никадәр бала җанлы булуыма, күпме генә бала яратуыма карамастан, бу баланы алу өчен, минем кулларым һич тә сузылмыйлар.

Минем урынымда дустым Иван Климчук булса нишләр иде икән? Аның баласы белән хатынын, авылларындагы бер йөз утыз биш хатын-кыз һәм балачагалар белән бергә, немецлар сарайга япканнар һәм керосин сибеп ут төрткәннәр иде. Менә шул Климчук бу немец калдыгының авызына сугып җибәрмичә түзә алыр идеме икән?.. Түзәр иде. Иван Климчук кебекләр Берлин шәһәрендә күпләр һәм алар үзләрен тиешенчә горур тоталар. Минем дустым Леонид Акамов әйткәндәй, — безнең егетләрдә арыслан һәм хатын-кыз йөрәге бар бит. Кызгану һәм гафу итү дигән нәрсә бездә көчле. Барыннан да бигрәк, намус саклау, үз халкыңның намусын саклау дигән нәрсә бездә көчле. Бу, әлбәттә, начар сыйфат түгел.

Берлинның үзен — үзәген күрергә кирәк иде. Анда трамвай йөрми, ике катлы зур автобус йөри икән. Безнең халык өчен чират-фәлән юк... Ике катлы зур автобусның түбәнге катына утырып киттем. Тәрәзәдән карап барам. Менә монда инде хикмәтләр! Америка, Англия солдатларының да, безнең егетләрнең дә таза эшләре күренеп-ялтырап ята. Монда — барлык урамнар һәм тыкрыкларда да — бөтен йортлар җимерелгән, һәммәсе дә кирпеч өемнәренә әйләнеп беткәннәр. Автобус бара да бара. Унда да, сулда да — ватык-җимерекләр. Кирпеч-тузан өемнәрен күреп шатланасыгыз килсә, Берлин шәһәренә килегез! Украина һәм Белоруссия ватык-җимерекләрен күреп сызланудан арыган йөрәкләр монда ял итәләр...

Александр-плац мәйданында төштем. Мәйдан безнең юлбашчыларның рәсемнәре белән бизәлгән. Уртада иң зур рәсем — маршал формасында иптәш Сталин рәсеме. Әлеге ана немецлар: «Шталин! Шталин!» — дип, бармаклары белән мәйдан уртасына төртеп күрсәтәләр. Монда инде мин әлеге ана немецларга чын күңелдән елмаеп карамыйча булдыра алмадым... Минем күңел биреп елмаюымны күргәч, янымдагы өч-дүрт немец хатыны бөтенләй канатланып китте. Куана-куана:

— Шталин! Шталин! — дип кабатлыйлар. Мин аларга баш иеп куям: — «Дөрес, беләсез икән шул!» — имеш.

Рейхстагка кадәр өч чакрым җәяү барырга кирәк иде. Эзләп йөрмәле түгел. Безнең сугышчы һәм командирлар шунда таба яки аннан кирегә таба агылалар. Кирпеч өемнәре читкә ташланып, урам урталары йөрерлек хәлгә китерелгән...

Бу өч чакрым юлда мин нәрсәләр күрдем? Бер хатта гына язып бетермәле түгел. Син язучы кеше бит, укырга иренмәссең. Мин сиңа тагын бер хат язармын.

Сәлам белән: Нәфыйк Яһүдин.

*Бу хатның датасы куелмаган. Ләкин аның безнең армия җиңү тантанасын кичергән көннәрдә язылганлыгы эчтәлегеннән күренеп тора. Авторның немецларга, Берлин хәрабәләренә карата булган тойгылары бүгенге яшь укучылар өчен беркадәр сәер тоелуы мөмкин. Ләкин ул вакыт өчен, Нәфыйк хәлендә булган солдат өчен алар бик табигый. Шунысы әһәмиятле: шундый хәлдә дә, немец илбасарларына каршы чиксез нәфрәт хисе белән сугарылган, үз иленә, үз идеалларына фанатикларча бирелгән аяусыз сугышчы йөрәгендә олы гуманистлык тойгылары өстенлек итә.*

*Кызганычка каршы, Яһүдин вәгъдә иткән өченче хат миңа килмәде.*

## Нур Баян хаты

Әмир дус!

Хәтерлә, 1941 елның июне иде. Без синең белән, Волга, Кама ярлары буйлап, районнарга чыгып киттек. Безнең матур маршрутыбызны гитлерчы бандалар җимерде. Мин озакламый көрәш сафына киттем. Дүртенче ел инде мин сездән — әдәбият дөньясыннан аерым яшим. Украина далаларын кичтем. Карпат таулары аша үтеп, Венгриянең... (шәһәр исемен хәрби цензура бозган.— М. Ә.) шәһәренә килеп кердем. Казанда йөргәндә заграницада аз гына булса да сәяхәттә йөрү безне кызыксындыра иде. Ләкин бу илләрнең кызыгы аз. Тик мине Ватан сугышында катнашуым гына тынычландыра. Күп материал җыйнадым. Икенче төрле әйткәндә, мәктәп үттем. Төрле авырлыклар, куркынычлы вакыйгалар баштан кичердем. Дошман белән якага-яка килеп сугыштым һәм шуның өчен хөкүмәт тарафыннан Кызыл Йолдыз һәм Беренче Дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләндем. Ике айлап госпитальдә ятып чыкканнан соң, хәзер резервта ятам. Тагын кая җибәрерләр — билгесез. Майорларны кече урынга җибәрмиләр; күрәсең, полк командиры урынбасары булырга туры килер.

Синең эшләр уңышлы бара диләр, яхшы, — уңышлык телим. Барыгызны да күрәсе, сөйләшәсе килә. Разинга, Кәшшафка һәм Кавигә — гомумән, мине сораучыларга фронт сәламе.

Кулыңны кысып, Нур.

30. 2. 45.

## Ибраһим Гази хатлары

22/XI-43.

Мирсәй!

Карале, чукынган урыс, сиңа мин сәламнәр дә күндереп карадым, запискалар да җибәргәләдем кеше аркылы... Ә син ни вау-вау... Ни хруша, брат.

Мин сезне тизәк яккан калай мич янында калдырып киткәннән соң, байтак вакыт үтте түгелме? Мин Казаннан Днепрга, Кырымга хәтле барып җиттем. Әй, малай, дөнья күрдем, сугыш хикмәтләрен күрдем, тәҗрибәгә баедым. Син анда утырып коры каласың бит. Берәр газетага урын булса, тот та кит тизрәк. Анда — тылда кафетерий шулпасын эчеп ятканчы, монда рәхәтләнерсең бер.

Күп яза алдым дип, мактаныр хәлем юк, алай да кое-что бар, кое-что булачак.

Карале, Мирсәй! Минем «Кызыл Тат-н»да әллә нигә бер чыга торган әйберләрнең кайберләрен радиодан кычкыргаласаң, минем күңел булыр иде. Шушы

көннәрдә «К-Т»га «Азат ителгән Украина буйлап» дигән ни очерк, ни мәкалә җибәргән идем. Анда радио өчен кызык нәрсәләр бар. Үзеңнең оста кулың белән бераз кыскартып (юкса сезнең прокруст караватына сыймас ул), кычкыр әле шуны радио буйлап, ярыймы?

Карале, карт дус! Хат яз, үпкәлим ато! Бөтен Казан хәлләрен сиңа гына хас юмор белән тырнаштыр әле, зинһар.

Бик сагынып үзеңне: Ибраһим.
PS. Шадра малайга сәлам!

1/III.-44

Мирсәй!

Ындыр табагыннан бераз гына кечерәк хатыңны алып, бик сөендем. Алай икән алайса сездә? Иҗат командировкалары, бер кочак гонорар, өмет һәм перспектива... Фәрештәнең амин дигән вакытына туры килсен, чынлап та булып куйса, ни әйтерсең...

Хикәяң[1] — матур. Көлештек бер рәхәтләнеп. Сиңа шундый нәрсәләр бик удаются (дияр иде урыс булса). Хәзер нишләп ятасың соң? Авылдан кайттыңмы? Казанда нинди хәбәрләр? Иренмичә бөтен ыбыр-чыбырына хәтле язып җибәр әле. Белмисең син, малай... Читтә торучының бик хат аласы килә аның... Ә сез безне бик баловать итмисез хат белән.

Үз хәлләрем? Солдат солдат инде: бүген монда, иртәгә тегендә... Һаман шул бер нәрсә: мимечне сүгәбез, мимечне тиргибез, аны үтерергә өйрәтәбез, өндибез...

Я, саулык телим үзеңә. Карчыгыңа сәлам. Кызың зур булдымы инде?

Ибраһим.

6/XII-44

Мирсәй! Рәхмәт, малай. Рәхәтләнеп көлдем, рәхәтләнеп укыдым[2]. Күптән адәм рәтле нәрсә укыган юк иде. Младис! Башланып китә — замечательно! «Булмаган... Тормаган... Алмаган...» — шәп! Минә ни өчен синең Сталинградта калмавың кирәк иде. Сиздеңме инде?! Ә син (мужик!) лыгырдаган булдың ул вакытта (хәтереңдәдер, кабатлап тормыйм).

Бу — хат. Рецензия түгел. Тулы обзор көтмә. Теге әйбәт җирен, бу матур урынын әйтмәгән дип уйлама. Бөтенесен дә күрдем, сиздем, төшендем — рәхәтләндем. Дөресрәге, рәхәтләндек. Эш өзелебрәк (прорыв түгел, перерыв) торган чак иде. Кычкырып укып торып җибәрдем, Ярмәки дә, Гариф Гали дә бик яратып тыңладылар. Ярмәки, иреннәрен ялмап, «Эх, теле!» дигән була. Телең шәп! «Умри, Денис!» дип әйтәсем килми, «Не умирай, Денис!» диясем килә. Бу соңгысы телгә генә карамый, әлбәттә.

Дөресен әйтим, з а м а н а пьесасы булыр дип курыккан идем. Хаталандым һәм хаталанып шәп иттем.

Без хәзер чын Польша туфрагында йөрибез. Эш күп, торабыз бик кысан (вагонда барганны хәтерлә), борылыр да хәл юк. Димәк, язарга мөмкинлек — ата мәче күз яше. Түл җыеп йөрибез, кайчан йомырка салырга вакыт булыр — билгесез.

Туктале! Мин бит әле пьесаның яртысын гына укыдым лабаса. Калганын кайчан укырбыз?

Сәлам белән: Ибраһим.

Карчыгыңа сәлам әйт. Син бәхетле — кызың янында, ә минем малай әллә кая!..

---

[1] «Мөстәкыйм карт йокысы» турында.
[2] «Миңлекамал» турында сүз бара («Совет әдәбияты»нда чыккан иде).

*Атаклы рус совет язучысы Михаил Александрович Шолоховка 70 яшь тулды.*

*Гражданнар сугышы чорындагы зур тормыш вакыйгаларын, катлаулы кеше язмышларын сурәтләгән «Тын Дон» эпопеясе, 30 нчы еллардагы күмәкләшүче авыл тормышына багышланган «Күтәрелгән чирәм» романы М. Шолоховны талантлы художник, үзенчәлекле зур әдип буларак бөтен дөньяга танытты.*

*Шолоховның һәр әсәрендә халык тормышында зур борылыш-үзгәрешләр тудырган социаль вакыйгалар тасвирлана, һәм ул сурәтләгән тормыш картиналары, аның образ-геройлары чын сәнгатьчә осталык, тормышча дөреслек белән гәүдәләндереп бирелә.*

*Илебез язмышы өчен каты сынау булган Бөек Ватан сугышы темасы да М. Шолохов иҗатыннан читтә калмады. Ул сугышка каршы нәфрәт һәм сугыштан газап-михнәт күрүче гади кешеләргә карата тирән гуманизм хисе белән сугарылган «Кеше язмышы» исемле хикәясен иҗат итте. Матбугатта әдипнең яңа әсәре «Алар Ватан өчен сугыштылар» исемле романының аерым бүлекләре басылып чыкты. Биредә ул, киң эпик планда, узган зур сугыш картиналарын, каты сынау алдында калган совет солдатының батырлыгын, җиңүгә китергән зур мораль-рухи көчен күрсәтә.*

*М. Шолоховның иҗаты киң катлау татар укучыларына яхшы таныш. Аның «Тын Дон» һәм «Күтәрелгән чирәм» исемле романнары, «Алар Ватан өчен сугыштылар» романының аерым бүлекләре, «Кеше язмышы» дигән хикәясе һәм башка хикәяләре татар теленә тәрҗемә ителеп басылып чыкты.*

## Михаил Шолохов

# АЛАР ВАТАН ӨЧЕН СУГЫШТЫЛАР

Романнан өзек



Күк йөзе аяз, матур, зәп-зәңгәр. Снарядлар актарып бетергән җир өстенә карап, кояш инде шактый биек күтәрелгән, җанга рәхәт бер тынычлык биреп, далада кызган әрем исе аңкый башлаган иде. Шул вакытны рәшә дулкынына күмелгән Дон буе калкулыклары артыннан тагын танклар килеп чыкты һәм немец пехотасы өченче тапкыр атакага кузгалды...

Дон кичүенә бара торган юлларны саклаучы берләшмә сугышчылары дошманның алты тапкыр ябырылып килгән атакасын кире кайтардылар, немецларның пехотасы белән танклары калкулыклар артына кире чигенде, һәм төш җитәрәк сугыш кырында беркадәр вакытка тынлык урнашты.

Җирне-күкне дер селкетеп күкрәгән артиллерия канонадасы, гөрс-гөрс итеп шартлап торган снаряд, мина, бөтен алгы сызык буйлап чатыр-чотыр килгән пулемет, автомат тавышларыннан соң сугыш кырының шулай тынып калуы Звягинцевка бик сәер, бик гаҗәп бер хәл булып тоелды... Ул, кулын әкрен генә күтәреп, башыннан каскасын салды, тузан катыш шабыр тиргә баткан йөзен гимнастерка җиңе белән сөртеп алды, шуннан соң, бертөрле рәхәтлек белән үз тавышына колак салып:

— Менә, тынып та китте... — дип куйды.

Бу рәхәт тынлыкны ул бөтен җаны белән тойды, балаларча бер кызыксыну белән, башын кыңгыр салып, бруствердан кыштырдап коелган ком, балчык тавышын озак кына тыңлап торды. Окоп кырыеннан аска, су шикелле агылып, ком һәм каткан балчык бөртекләре коела, алар туп-туры окоп төбенә төшеп, Звягинцевның аяк астында аунап яткан буш гильзаларга бәреләә дә гильзалардан, җир астына яшерелгән нингидер нәни кыңгыраулардан килгән сыман, нечкә генә чеңләгән аваз ишетелә иде. Кайдадыр, шушы тирәдә генә, чикерткә сайрый башлады, Звягинцев бу яңа тавышка таба да борылды. Гитараның бушаган юан кылы шикелле дуылдаган тавыш чыгарып, кызгылт-сары бер төклетура окоп өстеннән әйләнде дә, очып килешли үк йөнтәс кара тәпиләрен җәеп, бруствердагы ромашка сабагына кунды. Звягинцев, күзләрен челт-челт йомгалап, гомерендә беренче тапкыр күргәндәй исе китеп, тузанлы ромашка сабагына, гаҗәп матур төклетурага карады, аннары тагын гаҗәпләнеп башын күтәрде: каяндыр ерактан, йомшак кына исеп торган җил уңаеннан, чирттереп-чирттереп бытбылдык сайраганы ишетелде...

Кояш кызуыннан көйгән үлән сабакларының җилдә әкрен генә кыштырдавы, ак таҗ яфраклары белән күңелгә ямь биреп утырган гади ромашка, эссе һавада очып йөргән төклетура һәм бала чактан ук күңелгә якын булып калган бытбылдык тавышы — кодрәтле тереклек дөньясының шушы кечкенә генә кисәкләре Звягинцевны бер үк вакытта сөендерде дә, хәйран да калдырды. «Бөтенләй сугыш булмаган да кебек бит, менә хикмәт! — дип исе китеп уйланды ул. — Әле генә бөтен тирә-якта коточкыч сугыш мәхшәре кайный иде, ә хәзер гаҗәпкә калырлык: тыныч дөньядагы шикелле бытбылдык кычкыра, башка бөҗәкләр дә берни булмаган кебек үз эшләре белән мәш киләләр... Әйтерең бармы, исең-акылың китәрлек могҗиза бит бу!»

Әнә шулай аптырашлы кыяфәттә тирә-юненә каранып торган Звягинцев бу минутта яңа гына авыр төш күреп, өнгә килүенә сөенгән бер кешене хәтерләтә иде. Бу тынлыкка тәмам күнегеп, иялəшеп җитү өчен тагын бераз вакыт кирәк булды әле аңа. Ә бу тынлык яшенле яңгыр алдыннан була торган борчулы, шомлы бер тынлык шикелле иде, һәм ул тагын бераз дәвам итсә, Звягинцевның, мөгаен, җаны пошына да башлар иде. Ләкин озакламый сул як флангта тыррт-тыррт итеп пулемет тырылдарга тотынды, калкулык артыннан немецның авыр минометлары атарга керешүе, һәм кинәт кенә башланган тынлык юкка да чыкты.

Патрон ташучы яшь кенә бер егет — Звягинцевка бигүк таныш булмаган кызылармеец — арт яктан окоп янына шуышып килде һәм мышный-мышный:

— Боепитание китердем. Я, сакалбай, патроннар аласыңмы? — дип сорады.

Звягинцев кызгылт сакал баскан битен кулы белән сыпырып карады да хәтере калган кебек:

— Ниткән сакалбай булыйм? Карт кеше дип белдеңме әллә мине? — диде.

— Картмы, түгелме, — барыбер шул чама, адәм карамаслык дәрәҗәдә сакал баскан үзеңне. Әйдә, үз өлешеңне бушатып ал.

— Сакал баскан, имеш... Бу рәвешле чигенгән чакта чибәрләнеп торырлык вакыт юк, ансын аңларга тиешсең, ә яшем минем бик карт түгел әле, — дип, Звягинцев, патрон букчасына авыр, җылы-шома патроннар тутыра-тутыра, ризасыз бер тавыш белән сөйләнде.

Патрон ташучы егет исә сүзен төзәткәнгә әһәмият итмәде, үзенчә сөйләнә бирде:

— Әти кеше, нигә син шулай гөнаһлы бәндә шикелле окобыңнан баш күтәрми бөгелеп утырасың? Немец күренми бит әле, чынлап торып атарга керешкәннәре дә юк. Кояш күзенә чык, карт сөякләреңә бераз җылы үтсен!

Аның «әти кеше», «карт сөякләрең» диюе Звягинцевка ошап бетмәде, күрәсең, ул чыраен сытып куйды да егеткә төрттереп әйтте:

— Немец күренмәгәч, атыш та азайгач, син үзең, егетем, нигә корсагыңа ятып шуышып киләсең соң?

— Анысы минем иске гадәт инде, — диде егет көлеп. — Беләсеңме, бу эштә йөреп шул хәтле кәлтә елан шикелле шуышырга гадәтләнгәнмен — үз аягым белән йөрүемне бөтенләй онытып җибәрмәгәем дип куркам. Гел корсагыма ятып шуышасым гына килеп тора...

— Ахмак гадәткә өйрәнүе әллә ни авыр түгел анысы, йөрүеңне онытуың бик ихтимал, — дип җөпләде Звягинцев егетнең сүзен.

Эче пошканнан бу күңелле егет белән аның бераз сөйләшәсе килә иде, шуңа күрә ул, гадәттә яшь сугышчылар белән сөйләшкәндәгечә, беркадәр үз иткән, кечелекле тавыш белән:

— Син, егет, өченче ротадан түгелме? — дип сорады. — Чыраең таныш кебек.

— Әйе, өченче ротадан, — диде егет.

— Фамилияң ничек соң?

— Утишев.

— Син өйләнгәнме әле, Утишев?

Егет юк дип башын чайкады, көлемсерәп куйды.

— Яшь әле мин, сугышка кадәр өйләнергә өлгермәдем.

— Өлгермәгәнсеңдер шул... Менә һаман шулай патрон ташый торгач, йөрүеңне дә онытырсың. Сугыш беткәч, өйләнергә ниятләрсең. Кеше шикелле ике аягың белән атлап барасы чакта, сугыштагы гадәтеңне исеңә төшерерсең дә кызыңны яучыларга корсагың белән шуышып китәрсең. Ә кыз, мескен, моны күрер дә һуштан язып егылыр. Кызның әтисе, таяк алып, сыртыңны каезларга тотыныр. «Хур итеп йөрмә минем кызымны! Адәм шикелле, аягың белән атлап йөр, фәлән-фәсмәтән!» — дияр.

Утишев патрон тартмасын бавыннан тотып үзенә таба тартты һәм елмайган итенеп:

— Сакалбай булсаң да, хәйләкәр икәнсең... Телеңә салынып сөйләнгән булма. Мин синең сүзеңне тыңласам да, күпме патрон алганыңны санап торам. Заправка бетте! Башкаларга да атарга патрон кирәк! — диде.

Звягинцев егетнең бу сүзенә каршы нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин Утишев күрше окопка таба шуышып китте һәм башын бормыйча гына, акыл өйрәткән җитди бер тавыш белән кинәт әйтеп куйды:

— Син, сакалбай, патронны бәрәкәтлерәк тот, төзәбрәк ат, юкса, борчак урынына гына сибәсең бугай. Ә карт башың белән кызлар турында азрак уйла, шуннан соң кулың да азрак калтырар...

Көтелмәгән бу сүздән хәтере калып, Звягинцев ни дип җавап бирергә дә белмәде, беравык уйланып торганнан соң гына егет артыннан:

— Ничек атарга икәнен әбиеңә өйрәт син, маңка малай, яме?! — дип кычкырып калды.

Утишев әйләнеп тә карамады, патрон тартмаларын өстерәп, көлемсерәп китеп барды. Звягинцев аның тап-тап булып ак тоз утырган аркасына, кояшта уңып беткән гимнастеркасына, җилкәсе аша тарттырып кигән баугa ачу белән карап калды. «Каян килә мондый адәмнәр, шайтан белсен, әллә нинди халык! Барысы да юкны-барны лыгырдарга Петька Лопахиннан өйрәнгәннәр диярсең. Их, Микола Стрельцовның булмавы бик кызганыч, җүнле сүз сөйләшерлек кеше дә юк, ичмасам», — дип пошынып уйланды.

Әнә шулай дустын юксынып бераз кайгырып алганнан соң, Звягинцев үзенең солдат хуҗалыгын тәртипкә китерде: аяк астында аунап яткан гильзаларны окоптан алып ташлады, скаткасын рәтләде, котелогын үлән белән чистартып, окоп стенасындагы куышка куйды; окопны бераз тирәнәйтә төшимме әллә дип уйлаган иде дә, таш кебек кибеп каткан җирне көрәк белән чокып казырга туры киләчәген күз алдына китергәч, бөтен җаны-тәне бу эшкә риза булмады, куллары кинәт чуен шикелле авыраеп, хәлсезләнеп калды, һәм Звягинцев бу уеннан шундук ваз кичеп: «Болай да ярар әле, кое казымыйм лабаса! Тәкъдиреңдә язылган булса, әҗәл ул сине коедан да эзләп таба»,— дип фикер йөртте.

Көнчыгыш якка таба, мәһабәт бер салмаклык белән, сирәк-сирәк ак болытлар агыла. Нур белән үтәли яктыртылган ап-ак болыт кисәге әллә нидә бер аз гына вакытка кояшны каплап ала, тик шунда да көн эссесе кимеми, ут кебек кызган җирдән кайнар сулыш бөркелә, хәтта окопның күләгәле ягы да сөяләсе килмәслек дәрәҗәдә җылынган иде.

Окоп эче кызу итеп ягылган мунча шикелле эссе, бөркү; каяндыр чебеннәр килеп чыкты — бәйләнчекләнеп безелдәшә башладылар. Звягинцев, эсседән мәлҗерәп, беравык шинеле өстендә утырды, торып, йокыдан йомыла башлаган күзләрен кул аркасы белән угалады, немецның янган танкларына, далада аунап яткан дошман мәетләренә карады, Дон елгасы буйлап көнчыгышка таба тезелеп киткән калкулыклар артында бик еракта соры бер койрык сыман сузылып барган тузанга күз салды. «Нидер маташтырырга ниятлиләр бу явыз фрицлар, — дип уйлады Звягинцев, күчеп барган тузан койрыгын күзәтеп. — Аларга өстәмә көч китерәләрдер — әнә нинди тузан очырталар. Көч китереп, яңадан тупланырлар да, яраларын ялап-төзәтеп, тагы ябырылырлар. Ул ләгънәтләр әрсез алар, бик әрсез! Без дә, анысы, балчыктан әвәләнмәгән, без дә аларның авызборынын кан белән юарга остардык — сөртеп кенә өлгерсеннәр. Кырык беренче ел түгел инде хәзер! Баштарак бик узынганнар иде, җитте — булды!» — дип күңеленнән сөйләнде Звягинцев, үз-үзен тынычландырырга тырышып. Шуннан соң карашын Лопахин җимергән танкка күчерде.

Әле кайчан гына утлы дәһшәт чәчеп килгән соры танк, туп көпшәсен ыржайтып, яны белән борылып туктап калган. Люктан сикереп чыгуга автомат уты белән кистерелгән беренче танкист, кулларын җәеп, танк чылбыры буенда ята, җилдә мундир итәге селкенгәли; икенчесе — Звягинцев атып үтергәне — танктан читкәрәк шуышып өлгергән. Сирәк әрем сабаклары аша Звягинцев аның коңгырт чәчле баш артын, алга таба сузып салган кулын, терсәк тиңентен сызганган соргылт күлмәк җиңен, кояшта ялтырап торган шоп-шома ботинка дагаларын һәм ботинка олтанындагы түгәрәк ак кадак башларын күрде.

— Менә бу мин дөмектергәне дә, башкалары да мондый кызуда

кичкә хәтле күбенеп сасый башлаячаклар... — дип, ни өчендер үз алдына сөйләнеп куйды Звягинцев һәм җирәнеп йөзен чытты.

Яз башыннан бирле сугыш-бәрелешләрдә һәм кучу вакытларында полкка юлдаш булган күңел кайтаргыч төче мәет исен хәтерләгәч, бөтен аркасын чымырдатып «каз тәне» йөгерде, һәм Звягинцев, калтыранып куеп, җилкәләрен җыерды.

Аның тәҗрибәсез яшь бер солдат чагындагы үзе атып үтергән дошманының йөз-кыяфәтен күрергә тырышу гадәте әллә кайчан оныттылган иде инде; хәзер ул әнә теге, үзе атып үтергән, кулларын җәеп яткан озын буйлы танкистны бар дип тә белми, бары тик бер генә нәрсә тели ул: алты сәгать буена тәмам җанны талкып, туйдырып бетергән шушы тар окоптан тизрәк чыгып котыласы да берәр җирдә яңа суккан арыш саламы эскертенә чумып, тоташ ике тәүлек уянмыйча, туйганчы йоклыйсы иде.

Яңа суккан арыш саламының төчкелтем бер тәмле, рәхәт исен бик тиз хәтеренә китерде ул, йөрәк маен сыза торган татлы хатирәләр тәэсиреннән ямансулап көрсенеп куйды һәм яңадан окоп төбенә чүгәләде дә, башын артка ташлап, күзен йомды. Аның күз кабакларын авырайтып йокы баса, хәзер ул шушы йокы сөременнән арыну өчен, һич югы, Лопахин белән булса да рәхәтләнеп бер сөйләшер, юк-бар сүз белән тел чарлар иде, әмма янында Лопахин юк, немецларның дүртенче атакасыннан соң ул запас окопка күчкән, моннан шактый ерак иде.

Звягинцев, шул хәлендә йокыга куерып китеп, төшендә хатынын, балаларын, үзе атып үтергән соры күлмәкле танкистны, МТС директорын, ургылып-кайнап аккан сай сулы ниндидер бер елга, елга төбендә шоп-шома чуерташлар күрде... Текә ярлары арасына кысылып котырына-котырына аккан бу елганың тавышы торган саен көчәя-якыная барды, һәм шул мәлдә Звягинцев бик авырлык белән уянып китеп, күзләрен ачты: аның турысында күктә, бик биектә, безнең алты истребитель очып бара, зыңгылдап-шыңгырдап торган мотор тавышлары, байтак арага калышып, самолетлар артыннан ияреп килә иде.

Звягинцев, практик акыллы бер кеше булганга, үзебезнең авиацияне гомумән яратудан бигрәк, безнең самолетлар өстән торып аны дошманнан саклаганда яисә аның күз алдында немец позицияләрен бомбага һәм штурмга тотканда ярата иде; шуңа күрә бу юлы ул, тиз-тиз үтеп барган безнең истребительләргә йокымсыраган күзләре белән салкын гына карап, ачу белән болай дип сөйләнде:

— Тагы соңгардылар! Немецлар безнең баш түбәсе турысында, ... ып куйган шикелле, бомба яудырып торганда, сез кофе эчеп утыргансыздыр, эт тиресеннән теккән итекләрегезне киеп маташкансыздыр, ә хәзер инде, эш узгач, җил куып йөрисез, дәүләт ягулыгын әрәм итәсез... Дошманны кыручылар түгел, бензин кыручылар сез!..

Ул эчендә кайнаган ачуын әйтеп бетерергә өлгермәде: немецлар артиллерия хәзерлегенә керешеп, алгы сызыкта берьюлы шундый каты ут давылы куптардылар — Звягинцев шул минутта ук истребительләрне дә, башкасын да онытты...

Йөзләгән снаряд һәм мина, кайнар һаваны ярып, калкулыклар артыннан чыелдый-улый очып чыга да окоплар янына килеп төшеп, металл ярчыклары катнаш кара балчык һәм төтен фонтаннары бөркә, болай да актарылып беткән оборона сызыгын астын-өскә китереп аркылыга-буйга сөрә иде. Снарядлар гаҗәеп бер тизлек белән бер-бер артлы явып тора башлады, шартлау тавышлары тоташ кушылды, һәм дер селкенеп, тетрәп торган җир өстен гөрселдәгән, уһылдаган, улаган-чинаган авазлар басып китте.

Звягинцевның мондый каты ут астына күптән эләккәне, хәзерге кебек, йөрәкне, тынны кысып ала торган дәһшәтле бер курку тойгысын күптән кичергәне юк иде инде... Баштарак ул чыдарга, бирешмәскә тырышты, әмма әкобы тирәсендә берөзлексез мина һәм снарядлар шартлый, бөтен тирә-юнь торган саен катырак булып дөбер-шатыр актарыла, кайный башлагач, түзмәде — күңеленә: «бу мәхшәрдән исән калмам» дигән уй кереп утырды.

Йокысыз узган төннәр, алты сәгать буена сугышып тәмам хәлдән таюы үзенекен итте, күрәсең — сул тарафта, окоптан чак кына арырак, эре калибрлы снаряд шатырдап ярылуга, сугыш гөрелтесен телеп әче бер аваз белән яралы күршесе кычкырып җибәргәч, Звягинцевның эчендә кинәт нindидер бер тамыры өзелеп киткән кебек булды. Һәм ул, калтыранып куеп, күкрәге, кулбашлары, бөтен гәүдәсе белән окобының алгы стенасына сыенды, бармак очлары агарыр дәрәҗәдә кулларын кысып йомарлады, күзләрен тутырып ачты. Дөбер-шатыр килеп күкрәгән авазлардан җир арлы-бирле чайкала, дерт-дерт итеп сикерә сыман тоелды, һәм Звягинцев, тыелгысыз бер хәлдә калтырана-калтырана, үзе шикелле үк калтыранган җиргә тагы да сыена төште, шунда җанын саклап калырдай ышык урын табарга тырышты, әмма таба алмады, һәм шушы минутта ул, туган җир башка берәүне коткара алмаса да, мине, ягъни Иван Звягинцевны, барыбер үлемнән саклап калыр әле, дигән ышанычын-өметен югалтты...

Бары тик бер мизгел арада гына күңелендә: «Окопны тирәнәйтә төшәргә иде», дигән анык бер уй чагылып китте, шуннан соң инде, йөрәгенә сапкан дәһшәтле курку тойгысыннан башка, бернинди бәйләнешле уй, бернинди хис-тойгы калмады. Шартлау авазларыннан колагы тонган, шабыр тиргә баткан хәлдә, Звягинцев күзләрен йомды, кәрәктәй дәү куллары хәлсезләнеп ике тез арасына салынып төште, башы аска иелде, һәм ул үт әчесе шикелле әче төкереген көчкә йотты да, агарынган иреннәрен кыймылдатып, белгән догасын укырга кереште.

Бик күптән, бала чагында, авылдагы приход мәктәбендә укыганда, бәләкәй Ваня Звягинцев бәйрәм көннәрне әнисе белән чиркәүгә йөри, барлык догаларны яттан белә иде. Шуннан бирле аның күп еллар буена ходайга ялварып бернинди теләк теләгәне булмады, барлык догаларны онытып бетерде — менә хәзер инде ул үзенчә, ике-өч сүз белән генә: «Я раббым, коткар! Әҗәлдән саклый күр, ходаем!..» — дип, бер үк доганы кабатлый.

Бик озак булып тоелган берничә минут вакыт үтте. Дошман атудан һаман туктамый иде әле... Звягинцев кисәк кенә башын күтәрде, тагын бармак буыннарын шыгырдатып кулларын йомарлады һәм, ачудан ялт-йолт иткән күзләрен окоп стенасына төбәгән хәлдә, кычкырып әллә нинди сүзләр белән сүгенергә кереште. Аның шушы сүгенүен Лопахин ишетсә, хәтта ул да көнләшер иде. Ләкин сүгенгәнгә карап Звягинцевның хәле барыбер җиңеләймәде. Шуннан ул тынды. Әкренләп күңеле берни тоймас булып катып калды... Звягинцев тиргә юешләнеп, чиләнеп беткән каска бавын иягеннән ычкындырды да башыннан каскасын салды. Кызгылт сакал баскан яңагын окоп стенасына терәп, арыган-талчыккан, бар нәрсәдән өмет өзгән хәлдә: «Үтерсәләр, тизрәк үтерсеннәр иде инде...» — дип уйлады.

Ә тирә-якта, төтен, тузан, дары ялкыннары белән буталып, бөтен дөнья актарыла, дөбер-шатыр килә. Кешеләре ташлап качкан хуторның бер башыннан икенче башына хәтле тоташ ут капкан. Зур төтен болыты дөрләп янган йортлардан һавага таба озын кара канатларын сузган, окоплар өстеннән агылган әче дары сөременә янган-көйгән агач һәм салам исе килеп кушыла иде.

Артиллерия хәзерлеге ярты сәгатьтән аз гына артыграк дәвам итсә дә, шул вакыт эчендә Звягинцев яңа бер гомер кичергән кебек булды. Ахырга таба аның күңелендә акылын җуйган кешеләргә хас бер теләк тә кузгалып куйды: окоптан сикереп чыгасы, бирегә таба тоташ стена шикелле балчык фонтаннары куптарып килгән снаряд шартлауларына каршы йөгерәсе килде, тик бу акылсызлыктан соңгы көчен җыеп кына тыелып калды.

Немец артиллериясе утны оборонаның түренәрәк күчереп, снарядлар гөрс-гөрс итеп хутор өстендә һәм аннан арырак уйсу җирдәге сирәк, тәбәнәк имән урманы турысында шартлый башлагач, шушы ярты сәгатьлек мәхшәр вакытында тәмам чырае сулып, ябыгып киткән Звягинцев аңсыз рәвештә генә башына каскасын алып киде, винтовкасының тузанга баткан затворын һәм прицель рамкасын җиңе белән сөрткәләде, аннары башын сузып окоптан карады.

Ерактагы калкулыклар итәгеннән, танкларга ышыкланып, рәт-рәт тезелгән немец пехотасы төшеп килә иде. Звягинцев ерактан тоныграк булып шаулаган моторлар гөрелтесен, атакага килүче немец солдатларының төрле тавыш белән кычкыруларын ишетте һәм, үзе дә сизмәстән, тын кысылуы бетте, бөтен гәүдәсенә хәл керде. Йөрәге әле һаман тигезле-тигезсез еш-еш типсә дә, баягы курку-каушавының инде әсәре дә калмаган иде. Чокыррак җирләрдә йомшак кына иңепчайкалып алучы танклар, акырып-шаулап, үзләренә гайрәт бирергә тырышучы немецлар — болары инде күзгә күренеп килгән куркыныч, моңа каршы көрәшергә мөмкин, боларына инде Звягинцев күнегеп, гадәтләнеп беткән. Монысы Иван Звягинцевның үзенең булдыра алу-алмавына да бәйле; һич югы, ул хәзер, эсседән мәлҗерәгән берәр немец наводчигы җибәргән снарядның окопка килеп төшкәнен көтеп утырмыйча, үз-үзен яклый, сугыша ала...

Звягинцев флягасыннан дуен тәме килеп торган җылы су эчте һәм тәмам айнып киткән кебек булды: беренче тапкыр өзелеп тәмәке тартасы килгәнлеген тойды, тәмәке төреп, ике-өч кенә суырырлык та вакыт калмавын кызганып куйды. Әле генә нинди курку кичергәнлеген, догалар укыганлыгын хәтерләп, чит бер кеше турында фикер йөрткәндәй: «Менә бит кешене нинди хәлгә төшерәләр, хәшәрәтләр!» — дип уйлап куйды. Шуннан соң Лопахинның мыскыллы бер елмаюын күз алдына китерде дә: «Бу хәл турында андый-мондый сүз ычкындырырга ярамас, Петрга сөйләсәң, күзеңне ачтырмас, тереләй ашап бетерер үземне! Минем ише беспартийный кешегә андый дога уку тыелмый тыелуын да, шулай да ни... бигүк килешле килеп чыкмады...» — дип, бу хакта сер сакларга булды.

Бая кичергәннәрен уйлагач, Звягинцевка бик уңайсыз, ничектер оят булып китте, ләкин үзен-үзе акларлык нигез эзләргә аның вакыты да, теләге дә юк иде, шуңа күрә ул моңа күңеленнән генә кул селтәде, уңайсызланып, тамак кыргалады да үз-үзенә ачуы килеп сөйләнеп алды: «Һәй, исең киткән, дога укыган, имеш. Әллә ни күп укымадым да бит әле... Башыңа төшсә, аннан яманракны да эшләрсең! Әҗәл ул — туган апаең түгел, ул явыздан бөтен кеше курка — партийные да, беспартийные да, башка-башкасы да...»

Немец артиллериясе утны яңадан алгы сызыкка күчерде, ләкин хәзер инде Звягинцев тирә-ягындагы хәлләргә баягыча ук шаккатмый иде: дошманның артиллерия уты да ул чаклы каты кебек түгел, снарядлар да, бая тоелганча, бер аның окобы тирәсен генә актармый, бәлки немецка хас төгәллек белән, оборона сызыгының буеннан-буена таралып ява иде...

Ут өермәсе артыннан ияреп, немец пехотасы окопларга якынлаша башлады. Солдатлар, иелмичә, туры басып, кызу-кызу киләләр. Танклар барган җайга да, туктап-туктап та атып алалар. Звягинцев си-

зуенчә, безнең артиллериянең боларга каршы уты шактый кимегән кебек иде. Шул сәбәпле ярдәмгә безнең авыр артиллерия килде. Әллә кайда, Дон аръягында, еракта күк гөлдерәгән сыман, дүрт катлы булып гөрселдәү авазы ишетелде; снарядлар, күзгә күренмичә, окоплар өстеннән бик биектә сызгырып-улап уздылар да берьюлы немец пехотасы алдына килеп төшеп, һавага биек-биек кара балчык баганалары чөйделәр.

Танклар, ату зонасыннан тизрәк чыгу өчен, алга омтылдылар. Немец пехотасы да алардан калмаска тырышып йөгерә башлады.

Сирәгәя барган дошман солдатлары, снаряд төшеп шартлауга, җиргә авалар, читкә тайпылалар, снаряд чокырларын як-яктан әйләнеп узалар. Шул рәвешчә, алар бик тиз якынаеп киләләр. Күбесе, йөгергән шәпкә, тырылдатып автоматтан ут сиптерә иде. Звягинцев, тынын кысып, аларны күзәтеп торды... Һәм, һич көтмәгәндә-уйламаганда, моңарчы тып-тын яткан безнең алгы сызыкка җан керде! Дошман батареяларының уты күптән инде монда бер җан әсәре калдырмаган, җир белән тигезләп, актарып-сөреп киткәндер кебек иде. Әмма исән калган ут нокталары барысы берьюлы эшкә керештеләр һәм немец пехотасы өстенә, кыйгачлап, пулеметлардан үлем яңгыры яудырырга тотындылар. Немецлар җиргә ятты, ләкин беравыктан, бер йөгереп, бер ятып, тагын якынлаша башладылар.

Звягинцев бер мизгелгә генә күзен күтәреп һавага карады — соңгы ярты сәгатьтә анда, һавада, берни үзгәрмәгән: күк йөзе баягыча ук зәп-зәңгәр, мәһабәт-тыныч; төпсез зәңгәр тирәнлектә, баягыча ук, кояш кызуында көеп, чит-читләре чак кына төтенли башлаган сыман ак болытлар салмак кына агыла, баягы кебек үк йомшак кына искән талгын җил аларны көнчыгыш тарафка авыштыра... Звягинцев кояш яктысына чумган бу зәңгәр дөньяның бер читен генә күреп калды, әмма шул бер карауда күргән кадәресе дә, кайгылысагышлы елмаю кебек, аерылышканда күз яше аша елмайган хатынкыз чырае кебек, аның йөрәген сыкратып, күңелен ямансулатып алды...

Звягинцевның бите янында, күз турысында гына, карарга комачаулап, тузанга баткан ромашка, аксыл әрем сабаклары чайкала, шуннан арырак, чуалышып беткән үлән сабаклары аша, аермачык булып ярым иелгән дошман гәүдәләре күренә — алар минут саен зурая һәм котылгысыз рәвештә якыная баралар иде...

Әнә туп-туры Звягинцев окобына таба сигез немец солдаты килә. Алдан, каты җилгә каршы иелгән сыман гәүдәсен бөгә төшеп, җәһәт-җәһәт офицер атлый. Ул, бер дә борчылмаган шикелле, кулындагы таягын селкеп килә иде. Менә офицер яртылаш борылды да ниндидер команда бирде, ахры: солдатлар аны узып, лап-лоп чабышып киттеләр.

Звягинцев офицерны мушкага алды да, аз гына тынын кысып торып, атып җибәрде. Офицерны шундук авар дип көткән иде, ләкин ул берни булмаган кебек атлый бирде. Офицерның курыкмавына исе китеп һәм үз-үзенә ачуы килеп, Звягинцев икенче, өченче тапкыр атты, каушый-каушый, тагын ике пуля җибәрде... Офицер, сихерләгән кебек, һаман атлавында булды, тик бераз адымын гына кызулый төште, таягын баягыча, сәйранда йөргән шикелле селтәп, солдатлар артыннан нәрсәләрдер кычкырып әйтте.

«Исерек ич бу, мәлгунь!» — дигән уй килде Звягинцевның күңеленә, калтыранган бармаклары белән ашыгып обойма керткәндә, ярсудан тешен кысып: «Тукта, хәзер мин сине җиргә яткырам! Калганын шунда кылкынырсың...» — дип сөйләнде.

Ул винтовкасын корган арада сержант Никифоров, — ашыкмыйча, сабыр гына, — кыска-кыска ике очередь биреп, «батыр» офицер

белән өч солдатны атып екты. Калган бишесе, исләренә килеп, тиз-тиз генә снаряд чокырларына төшеп яттылар һәм, барлык патроннарын берьюлы атып бетерергә тырышкандай, автомат обоймаларын тиз-тиз бушатырга керештеләр.

Танклар гөрелтесе кайдандыр уң яктан килә иде. Сугыш шавы эченнән Звягинцев лейтенант Голощековның карлыккан әче тавыш белән:

— Танкларны уздыр! Танкларны уздыр! Пехотага ат! — дип кычкырганын көчкә ишетеп калды.

Рота билгән оборона участогының буеннан-буена, шулай ук күрше участокта да (дошманның төп удары шунда юнәлтелгән иде) танкларыннан аерылган немец пехотасы җиргә ятарга мәҗбүр булды, аннары алга узучы танклар артыннан, хәлиткеч бәрелешкә хәзерләнеп, әкренләп шыыша-шуыша, һаман якынлаша, үрмәли бирде.

Немецлар бик якын иде инде. Звягинцев немецча әйтелгән команда сүзләрен — йөрәктә нәфрәт уята торган явыз дошман сүзләрен — һәм бөтен күкрәк читлеген тутырып йөрәге дөпелдәгәнен аермачык ишетте. Ул, винтовкасыннан ата-ата, ямансу бер тойгы белән, сержант Никифоровның кинәт кенә тынып калган пулеметы яңадан тукылдый башламаганмы, дип, шул якка колак салгалады, ләкин пулемет атканы ишетелмәде. «Хәзер штыкка кузгалабыз», — дип уйлап куйды Звягинцев, котылгысызлыктан хиссез калган бер хәлдә, — тирләгән юеш кулы белән гранатасын капшап карады. Дулкынланудан аның тыны буыла, ерак юл чабып кайткан ат шикелле, ул борын канатларын киереп, гөр-гөр сулу ала иде.

Бер минуттан немецлар шаулап-кычкырып җирдән күтәрелделәр. Звягинцев аларның соргылт-яшел мундирларын томан аша күргән кебек кенә шәйләде, лап-лоп атлауларын, кул гранаталары гөрселдәвен, шарт-шорт итеп мылтык шартлауларын һәм тыррр-тыррр иттереп өзеп-өзеп пулемет атуларын ишетте... Аптырашлы бер төс белән як-ягына каранды: окоплардан берәм-берәм аның иптәшләре, гомерлеккә туганлашкан якын дуслары сикереп чыга иде; алар күп түгел, ләкин аларның сыек кына «ура!» тавышы элеккечә үк батыр һәм дәһшәтле яңгырый иде.

Звягинцев бер талпынуда окоптан сикереп чыкты — гәүдәсе үзалдына очып китәрдәй кебек булып, гаҗәп дәрәҗәдә җиңеләеп калган иде, — винтовкасын иңләп тотты да, тешен кысып, якындагы немецка маңгай астыннан текәлгән хәлдә, алга омтылды; винтовкасының бөтен авырлыгы штык очына төшкән кебек булды.

Ул окобыннан берничә метр гына китеп өлгерде. Артта яшен уты сыман сызылып ялкын бөркелде, колак тондыргыч шартлау ишетелде, һәм Звягинцев, коточкыч авыртуга түзә алмыйча күзләрен киереп ачкан хәлдә, төтендәй актарылып кайнаган караңгылык эченә йөзтүбән авып төште.

ЯХЪЯ ХАЛИТОВ тәрҗемәсе.

Илдус Ахунҗанов

# МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ ҖЫРЧЫСЫ

**Фатих Кәримнең иҗат портретына эскизлар**

1927 елда Казан шәһәренең газета-журнал редакцияләре тирәсендә билгесез бер егет күренә башлый. Кара керпе чәчле, җыйнак, ябык гәүдәле. Өстендә юнгштурмчылар кия торган форма. Кесәсендә гади дәфтәр битенә язылган шигырьләре. Киләчәктә аңардан шагыйрь чыгармы-юкмы, ул чагында моны өзеп кенә берәү дә әйтә алмагандыр, ихтимал. Яшь чагында кем каләм тибрәтеп бакмаган да, кем шигырь язып карамаган... Егет җир төзү техникумында укый, шул ук вакытта җәмәгать эшләренә бик теләп катнаша икән.

Әмма алга таба ул җир төзүче булып түгел, татар халкының күренекле шагыйре булып китә. Дөресрәге, ул поэзия өлкәсендә җир төзүче булып кала. Аның «Карбыз кебек» дигән шигырен кем генә белми икән.

**Карбыз кебек кап урталай**
**Ярып идем дә бу Җир шарын,**
**Ике ярым шарны бер-берсенә бәреп,**
**Кояр идем бөтен чүп-чарын.**

Бүген менә, тормыш һәм иҗат юлына җентекләбрәк күз ташлау белән, аның нәкъ менә шагыйрь булып китәргә тиешлегенә тагын бер кат инанасың. Фатих Кәримнең балалык еллары әдәби талант ачылу өчен ифрат уңайлы шартларга туры килә. Ул 1909 елның 9 январенда тугандаш Башкортстан республикасының Бишбүләк районы Ает авылында туа, шунда аның балалык, яшьлек еллары уза. Дөрес, Ает үзе салам түбәле өйләрдән торган тузанлы гади бер татар авылы була. Аның каравы, авыл яныннан гына мәһабәт Дим елгасы агып узган. Ихтимал, Дим шагыйрь туып-үскән якның бердәнбер горурлыгы саналгандыр. Әти-әниләренең үз балаларына тиешле белем бирергә житәрлек байлыгы булмый. Әмма бу гаиләдә дөнья малыннан өстенрәк башка байлык — әдәби иҗат эшенә хиреслек зур була. Дөрес, шигъри сүзгә мәхәббәт — безнең халыкка элек-электән хас сыйфатларның берсе. Татар авылларында егетләр, кызлар бер-берләренә чәчәкләп-чуклап мәхәббәт хатлары язалар. Авыл кешеләре якыннарына һәм туганнарына шигъри хатлар җибәрәләр. Фатих Кәримнәр гаиләсендә исә халык җырларына, китап сүзенә мәхәббәт аерата көчле була.

Автобиографиясендә шагыйрь үзе бу турыда түбәндәгечә яза: «Егет чагыннан ук сукыр булган әтиемнең үзе өчен язган шигырьләрен безгә укыштыргалаганын ишетү, апам Мәрьямнең үз дәфтәренә Дим буе табигатен тасвирлап язган күп кенә шигырьләрен башкалардан яшереп миңа гына укуы, революция еллары башлангач, абыем Ярлы Кәримнең матбугатта чыгып барган шигырьләрен уку — болар минем әдәбият өлкәсенә таба юнәлеш ясавыма төп һәм башлангыч этәргеч булдылар». Әтисе, апасы, абыйсы шигырьләренә ияреп, Фатих Кәрим дә беренче әсәрләрен яза. Шулай шигъриятькә юл ачыла. Ләкин бу — авыр, катлаулы юл булып чыга. Тавышы тәмам формалашып, ныгып җиткәнче, аңа еллар буе укырга һәм өйрәнергә, армый-талмый үз өстендә эшләргә туры килә.

Фатих Кәримнең беренче әсәрләрендә халык шагыйре Габдулла Тукай тәэсире нык сизелә. Аның шагыйрь булып формалашуында шулай ук Байрон, Лермонтов, Маяковский һәм Такташ кебек шагыйрьләр иҗаты зур роль уйный. Нәкъ менә Такташ һәм Маяковский аны көн кадагына суга торган шигырьләр язарга, актив рәвештә заман рухына үтеп керергә өйрәтә.

Әдәбият мәйданына ул комсомол шагыйре буларак килеп керә. Аның яшьлек күтәренкелеге белән язылган беренче шигырьләрендә заманның көчле пафосы, социализм җәмгыяте төзү өчен барган көрәш авазы яңгырый:

**Янар таулар көчле —**
**Җирне тетрәтәләр,**
**Тик вакытлы — алар сүнәчәк.**
**Ә мин менә**
**Комсомолда**
**Озак еллар өчен үсәчәк...**

**Нинди бәхет!**
**Эш дәверендә тудым,**
**Эшне сөям!**
**Мактанырга кирәк түгел дә,—**
**Өмет ялкыннары,**
**Артезиан күк,**
**Атылалар минем күңелдән.**

*(«Безнең һәйкәл».)*

1928 елда шагыйрь әнә шулай яза: «Ә мин менә комсомолда озак еллар өчен үсәчәк». Бу юллар шигъри ант, иҗади иман кебек яңгырый. Һәм ул бу антына ахырга кадәр турылыклы булып кала.

Техникумны тәмамлагач, Фатих Кәрим Казанда чыга торган газета-журнал редакцияләрендә эшли. Заманның иң актуаль, иң мөһим мәсьәләләренә багышланган шигырьләр, очерк һәм мәкаләләр яза. Яшьтәшләренең хезмәттәге батырлыкларына дан җырлый, дуслык, мәхәббәт хисләрен зурлый. Аларның байтагы ашыгыч төстә, газетаның теге яки бу саны өчен махсус языла. Ләкин, моңа карап кына, алар бер көнлек шигырьләр булып калмыйлар.

Шулай еллар уза. Еллар белән бергә, тәҗрибә һәм әдәби осталык килә. Утызынчы елларда инде шагыйрь әдәбиятның күп көч һәм тәҗрибә сорый торган зуррак жанрларына мөрәҗәгать итә. Уралга чираттагы иҗат командировкасына барып кайтканнан соң, ул «Җиденче мич» исемле мәгълүм поэмасын яза. Бу — татар әдәбиятында индустриаль хезмәт темасына багышланган иң уңышлы поэтик әсәрләрнең берсе. Моңа кадәр безнең поэзиядә бу темага игътибарга лаеклы ике генә зур күләмле әсәр язылган була. Мин Хәсән Туфанның «Урал эскизлары»н һәм «Бибиевләр»ен күздә тотам.

«Җиденче мич» поэмасында, тормышларын куркыныч астына куеп, җимерелгән мартен мичен төзәтергә алынган эшчеләрнең батырлыгы турында сөйләнә. Әсәр белән танышканда, безнең күз алдыннан бөтен бер образлар гале-

реясы уза. Алар арасында без эшче сыйныфының революцион традицияләрен гәүдәләндергән Таҗины, инженер Митрофановны, завод парторгы Ширнинны, Россиягә иске тәртипләрне кайтару турында хыялланып яшәгән корткыч Минжининны һәм дистәләрчә башка персонажларны очратабыз. Поэмадагы һәр персонаж шагыйрь тарафыннан үзгә бер осталык белән тасвирланган.

«Җиденче мич» Фатих Кәримне күренекле татар шагыйрьләре рәтенә чыгара. 1936 елда ул үзенең «Тавышлы таң» исемле икенче яңа поэмасын тәмамлый. Әдәби җәмәгатьчелек бу әсәрне дә җылы каршылый. Бу юлы инде шагыйрь катлаулы, психологик темага мөрәҗәгать итә. Болай әсәрнең сюжеты гади генә. Хезмәт дисциплинасын бозган өчен, колхозчыларның гомуми җыелышында Җиһаншаны бер атнага эштән куалар. Җиһанша бу җәзаны ифрат авыр кичерә. Шагыйрь Җиһанша аңында вак милекчелек калдыклары белән коллективизм хисләренең үзара көрәшен, рәхимсез тартышуын күрсәтә. Әсәр ахырында ул үзенең ялгышларын аңлый һәм яңадан иптәшләре сафына кайта:

> Әй, таптың, Җиһанша,
> Син колхозның юлын аңладың.
> Чорыбызның көче,
> Күкрәгеңә бәрелеп,
> Чуен тавышы кебек яңгырады...

Бу поэмада Фатих Кәрим шагыйрь Һади Такташ салган эздән бара. Ләкин аны гади кабатлау белән генә чикләнми. Җиһанша образы — «Киләчәккә хатлар»дагы Мохтар картның дәвамы да. Такташның Фатих Кәрим иҗатына булган йогынтысы бу әсәрдә аеруча нык сизелә.

Шагыйрьнең сугышка кадәр язылган әсәрләре арасында иң әһәмиятле һәм зур күләмлесе — «Аникин» исемле поэма. Аның иҗатында зур урын тоткан халыклар дуслыгы темасы бу әсәрдә аеруча тулы гәүдәләнә. Совет чик сакчыларының батыр һәм авыр хезмәтенә багышланган бу поэмада Михаил Аникин белән Галим Ибраһимовның эчкерсез дуслыгы турында сөйләнә. Диверсантлар белән бәрелештә, иптәшен коткарам дип, Аникин үзе һәлак була. Поэма алга таба Фатих Кәримнең күп кенә әсәрләрендә урын алачак зур мәсьәлә турында — үлем һәм үлемсезлек турында уйланулар белән тәмамлана:

> Еллар үтәр, ләкин бу кабергә
> Бертуктаусыз чәчәк салыныр,
> Һәрбер шагыйрь аңа карап язган
> Җыры белән илгә танылыр;
>
> Бу җыр аша, үткән ялкыннардан
> Романтика кабыныр яшьләрдә,
> Өйрәнерләр яшьләр хыялларны
> Тормыш итү өчен яшәргә.

Татар совет әдәбиятында «Аникин» поэмасы батырлыкка чакырган әсәр булып яңгырады. Берничә ел узгач, совет халкы фашист илбасарларына каршы көрәштә тиңдәшсез батырлык үрнәкләре күрсәтте. М. Җәлил, Н. Баян, Ә. Фәйзи, С. Хәким, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗи кебек шагыйрьләр белән бергә, Фатих Кәрим дә шул батырлык турында ашкынып җырлады.

1941 елда ул гади солдат булып фронтка китә. Кулына корал тотып фашистларны кыйный-кыйный, гади солдаттан Совет Армиясенең офицерына кадәр зур юл уза. Аның поэзиясе дә алгы сафта, сугышның ут сызыгында була. Ватан сугышы елларында аның таланты әдәби осталыкның иң югары ноктасына күтәрелә. Вакыйгаларның асыл мәгънәсенә төшенү, тормыштагы хәлләрне тирәнрәк аңлау өчен, шагыйрьгә «вакыт аралыгы» кирәк булмый. Беренче көннәрдән үк аның каләме ил, халык язмышына аһәңдәш яңгыраш ала. Без монда, барыннан да бигрәк, шагыйрьнең фронтка киткәндәге уй-хисләрен

чагылдырган «Дусларга» исемле шигырен күз алдында тотабыз. Шагыйрьнең фронт лирикасы шушы әсәрдән башлана. Аның фронт лирикасына хас төп ике хис — мәхәббәт һәм нәфрәт хисе дә— башлап шушы шигырьдә аеруча тулы чагыла.

Фатих Кәрим поэзиясе Ватанны чын улларча ярату хисе белән сугарылган. Аның лирик герое, аерылмас җепләр белән, халык тормышына бәйләнгән. Нәрсә турында гына язмасын, шагыйрьне халык, Ватан язмышы турындагы уйлар борчый. Һәм ул уйлар гел шатлыклы, күтәренке тоннарда гына булмаска мөмкин. Шагыйрьнең фронт лирикасы чакыру, лозунг характерындагы әсәрләрдән генә тормый. Авыр сугыш елларында иҗат ителгән ул шигырьләрдә моң-сагыш та, борчулы хисләр дә җитәрлек. Әгәр аларны рәттән укысак, безнең алга күп кайгы һәм авырлык күргән, кырыс фронт тормышының бөтен кыенлыкларын үз җилкәсендә татыган гади солдат образы килеп басар. Кайбер минутларда аның күңелен авыр сагыш каплый, ул еракта калган туган җирен, сөйгән ярын уйлап моңлана:

**Тәрәзәмә кунган ак күгәрчен**
**Гөрли-гөрли канат кагына,**
**Кагына да уйнап очып китә**
**Син яшәгән шәһәр ягына.**

**Нигә мин дә ак күгәрчен түгел,**
**Ярсып очар идем шул якка,**
**Очып барып иркәләнер идем,**
**Сыеныр идем синең кочакка.**

Мондый хисләрнең тормышчан нигезе бар. Бу — рухи хаерче кешенең өметсезлеге дә, бөтенләй төшенкелеккә бирелү дә түгел. Биредә шагыйрь күңеленә бөтенләй башка хис, кешене күтәрә, горурландыра торган патриотизм хисе, Ватан белән бергә булу, аның бәйсезлеген яклап көрәшкә чакыру хисе кагылып уза. Фатих Кәримнең «Сибәли дә сибәли» исемле икенче бер шигырен дә тыныч күңел белән укып булмый.

...Көзге төн, салкын, шыксыз җил исә, вак яңгыр сибәли. Ул солдатларның өс-башын чылаткан, аларны туңдырып-өшетеп бетергән. Шул яңгыр астында солдатлар, бернигә карамый, берни сөйләшми, үлгән иптәшләренә кабер казыйлар...

Әмма бу шигырьдә дә өметсезлеккә бирелү әсәре юк, чөнки беренче юлларыннан соңгы юлына кадәр шигырь хәрби бурычны тирәнтен төшенү, сугышның корбансыз булмавын аңлау хисе белән сугарылган. Хәтта шагыйрьнең үз үлеме турындагы фикерләр дә (алар Фатих Кәримнең фронт лирикасында шактый еш очрый) авыр тәэсир калдырмый. Чөнки биредә дә без, беренче чиратта, үлемнән коты очкан куркак җан белән түгел, ә халык язмышы өчен борчыла торган батыр йөрәкле кеше хисләре белән очрашабыз:

**Никтер бүген кайгы басты мине,**
**Искә төште бер көн үләсем;**
**Син, билгеле, минем бу сүзләрдән,**
**Юатмакчы булып, көләсең.**

**Кайгырам мин, гаять кыска гомер**
**Ялкынланып янсын иде дип;**
**Үзем үлгәчтен дә, хезмәтләрем**
**Җанлы булып калсын иде дип.**

Менә «Ватаным өчен» исемле шигырь. Әле генә телгә алган шигырьдәге кебек, биредә дә шагыйрь яшәү һәм үлем турында уйлана. Һәм бу юлы да поэзиянең мәңгелек темасы кешелекнең якты киләчәге өчен барган көрәшнең

үлемсезлегенә, мәңгелегенә нык ышанган совет кешесе позициясеннән торып хәл ителәэ:

**Бәлки бу хат соңгы хатым булыр,**
**Иң дәһшәтле утка керәмен,**
**Шулай булып калса, кояшны да**
**Бүген соңгы тапкыр күрәмен...**

**Үләм икән, үкенечле түгел**
**Бу үлемнең миңа килүе,**
**Бөек җыр ул — Бөек Ватан өчен**
**Сугыш кырларында үлүе.**

Фатих Кәримнең фронт лирикасы эмоциональ төсмерләргә ифрат бай булуы белән аерылып тора. Бүген без аның ул чор иҗатын сугыш елларындагы иң матур, иң үзенчәлекле шигъри документларның берсе төсендә кабул итәбез, аның иҗатында без рәхимсез дошманга каршы авыр көрәштә җиңеп чыккан совет кешесенең бай рухи дөньясы белән очрашабыз. Хәлбуки, шундый вакытлар бар иде, шагыйрь лирикасының нәкъ менә шул диапазон киңлеге, совет кешеләре өстенә төшкән кайгылар һәм сагышлар турында кыю итеп, әчкерсез итеп яза белүе аерым тәнкыйтьчеләрне аптырашта калдыргалады. Андый тәнкыйтьчеләр фикеренчә, сагышлы мотивлар, үлем турындагы уйлар, имештер, шагыйрь иҗатының сугышчан рухын киметәләр иде. Бүген исә, вакытлар узганнан соң, андый карашларның урынсыз булуы ачык күренә. Кырыс фронт тормышын тасвирлаганда, бары чын дөреслек кенә укучыны дулкынландыра, аны үз артыннан ияртә ала. Сугыш елларында совет әдәбиятының алгы сафына чыккан поэзия тәҗрибәсе шуны күрсәтә. Фронтовик шагыйрь, Социалистик Хезмәт Герое К. Симонов бу хакта түбәндәгечә яза: «Сугыш, һәр көн куркыныч астында яшәү кешеләрдә бер-берсенә ышаныч һәм дуслык хисләре тәрбияли. Бергә сугышта булган, бергә куркыныч астында калган кешегә икенче көн үк дус дип дәшәләр. Шул ук вакытта сугыш, һәр чак янәшәңдә йөргән үлем, аның белән бәйле барлык тойгылар бернинди ялганга урын калдырмый. Аларның шатлыклы һәм кайгылы, күңелле һәм сагышлы тормышлары турында дөресен, бары дөресен генә язу — солдат шагыйрьдән иң элек шул таләп ителәэ».

Фатих Кәрим шулай эшли дә. Әле сугышка хәтле үк, 1939 елда, тәнкыйтьнең үз лирикасының киңлеген чикләргә маташасын сизгәндәй, ул «Син кызганма йөрәгеңне...» дигән шигырь яза. Ул — шагыйрьнең кешегә хас бөтен нәрсәләрне сурәтләргә хакы булуы турында:

**Син кызганма йөрәгеңне,**
**Янсын ул, янсын.**
**Кешеләргә факел булып,**
**Алдында барсын.**

**Богаулама хыялыңны,**
**Җәйсен канатын.**
**Менеп айкасын ул күкне,**
**Йолдызлар артын.**

Сугышның буеннан-буена гади солдат белән иңгә-иң барган Фатих Кәрим батырлыкның ни икәнен әйбәт белгән. Коры шапырыну гына батырлык түгел әле, чын батырлык рухи ныклыкта, иң авыр кайгыдан, иң тирән сагыштан чыга белүдә күренә. Фатих Кәрим талантының бөек гуманистик көче нәкъ шунда.

Фатих Кәрим поэзиясенең гуманизмы тирән фәлсәфи характерда. Совет халкының фашизмга каршы көрәше, безнең бөтен поэзиябездәге кебек үк, аның иҗатында гуманизм белән кешелексезлекнең кискен бәрелеше төсендә сурәт-

ләнә. Көнбатыш Белоруссиядә, Припять елгасы буенда, шагыйрь кеше үтерүче явыз фашистны очрата. Менә аның портреты:

**Менә аны... аны китерәләр,**
**Тора дар агачы янында,**
**Түбән игән башын, йөзе кипкән,**
**Кешегә хас җылы караш беткән,**
**Тик вәхшилек калган канында.**

Кылган вәхшилекләре өчен җинаятьче хөкемгә тартыла. Шул бер кеше мисалында бөтен вәхшилек, кешелексезлек, фашизм хөкем ителә. Бу ерткычтан үч алуны хәтта табигать үзе дә хуплый кебек...

Билгеле булганча, шигърият узаманнары иҗатында пейзаж һәр вакыт актив роль уйный, ул тормышта барган вакыйгаларга битараф булмый. Ләкин пейзажның тәэсир көче төрле шагыйрьдә төрлечә. Берәүләрдә пейзаж образлар системасында иллюстрацияләү вазифасын гына үти, икенчеләрендә, Фатих Кәрим иҗатындагы кебек, әсәрнең төп идеясен ачыклый торган көчкә әйләнә. Поэтик форманы, аерым алганда, пейзаж формасын шулай тирән сиземләү очракларын без тагын М. Җәлил, Ә. Фәйзи, С. Хәким әсәрләрендә, шулай ук иҗатлары белән фашизмны җиңү өчен көрәшкән башка шагыйрьләр иҗатында күрәбез.

Совет шагыйре буларак, Фатих Кәрим ике система арасында башланып киткән дөнья сугышына битараф карый алмый иде. Шагыйрь иҗатының гуманизмы — сугышчан характерда, аның гуманизмы кешелек язмышы өчен шәхси җаваплылык хисе белән сугарылган. Асылда Фатих Кәримнең бөтен иҗаты иске тормышның чүп-чарына каршы юнәлдерелгән. Сугышка кадәр язган шигырьләрендә ул мәхәббәтне зурлый, хезмәт поэзиясенә дан җырлый, шунда ук дошманнарга каршы көрәшергә әзер булырга, уяу булырга чакыра. Һәм менә хәзер, ул көрәш бөтен кискенлеге белән башланып киткәч, шагыйрь Ф. Кәрим алардан аяусыз үч алырга чакыра. «Хәнҗәр» — шул хакта сөйли торган шигырьләрнең берсе. Анда шагыйрь үз эшенең хаклыгына тирән ышанган халык исеменнән:

**Авыр язмышыңны хәл иткәндә,**
**Мин читтә түгел, илем;**
**Йөрәгең тотып, немец ава артка,**
**Кулымда хәнҗәр минем,**

— ди. «Мин — гуманист» шигыре дә шундый. «Хәнҗәр» шигыре кебек, аңа да М. Горькийның: «Әгәр дошман бирелмәсә, аны тар-мар итәләр», дигән канатлы сүзләре эпиграф була алыр иде. Шуның белән бергә, бу шигырьне шагыйрьнең бөтен фронт лирикасы өчен программа характерындагы әсәр дип санарга була.

**Мин — бер шагыйрь, тойгы, хис кешесе,**
**Яратам мин кошлар сайравын;**
**Мин — гуманист, сөям дөньяны,**
**Акмасын, дим, җирдә кеше каны,**
**Гуманизм — минем байрагым...**

**Фашистларны кем күбрәк кырса,**
**Ул үзенең туган илендә**
**Чын гуманист булып мактала,**
**Даны җырга күчеп кабатлана**
**Ирек сөйгән халык телендә.**

Фашизмга, караңгылык дөньясына карата бу кадәр нәфрәт, дошманлык хисләренең чыганакларын шагыйрьнең коммунистик карашлары ныклыгыннан, аның көрәшче һәм трибун характерлы булуыннан эзләргә кирәк. Аның лири-

касының гражданлык көче хис һәм омтылышларының әнә шундый масштаблы булуында чагыла. Фатих Кәримнең сугыш елларында лирикадан поэзиянең эпик формаларына җиңел күчеп китә алуын да шуның белән аңлатырга кирәк. Шәхси кичерешләре белән генә юанып яшәгән шагыйрьләргә мондый күчеш бөтенләй биремле яки бик авыр бирелә. Фатих Кәримнең лирик «мин»е исә кешеләргә, замандашларына һәр вакыт йөз белән карап яшәде. Ул алар белән бергә яшәде, замандашларын, үзен белгән кебек үк, тирәнтен белеп һәм аңлап яшәде. Аның фронтта дуслары бик күп иде, алар турында тагын да күбрәк җырлау өчен шагыйрьгә бары бер нәрсә — вакыт җитмәде.

Шагыйрьнең эре күләмле әсәрләре арасында «Тимер һәм тимерче» балладасы аерылып тора. Анда совет солдатының монументаль образы иҗат ителгән. Олы яшьтәге колхоз тимерчесе Саттар фронтка китә һәм беренче сугышта ук дошман танкысы белән йөзгә-йөз очраша. Хикәя искиткеч киеренке төстә башланып китә. Буйдан-буйга кабатланып килгән рефрен вакыйгаларның киеренкелеген тагын да көчәйтә төшә:

**Тимерчеме тимер тавына,**
**Тауны тимерчегә бәрелер...**

Дошман танкысы белән бәрелештә тимерче Саттар җиңеп чыга:

**Яна дөрләп ләгънәт утында,**
**Яна танк — кара тәреле;**
**Тимерчегә килеп бәрелде**
**Тимер тавы сугыш судында.**

Балладаның соңгы юллары фашистларның тәмам тар-мар ителәчәгенә ныклы ышаныч булып яңгырый:

**Танк ватыкларын сандалга**
**Салыр бер көн безнең тимерче,**
**Чүкеч үтә йөртеп бар көчен,**
**Богау ясар һәрбер вандалга.**

Фатих Кәримнең «Идел егете», «Кыңгыраулы яшел гармонь», «Партизан хатыны», «Үлем уены», «Өмет йолдызы» кебек поэмалары да совет поэзиясенең югары казанышлары рәтендә тора.

Зур булмаган очеркта аның бөтен әсәрләрен санап чыгу мөмкин түгел. Фронтта ул, шигырь, поэмалар белән бергә, «Разведчик язмалары»н һәм «Язгы төн» исемле повестен яза. Шунда ук «Шакир Шигаев» исемле драмасын иҗат итә. Әгәр аңа хас шигъри күремне искә алып фикер йөртсәк, аның яңадан-яңа әсәрләре өчен сюжет һәм темаларны ничек табуы җиңел аңлашылыр. Ул үз иҗатына ташламалар ясарга яратмый. Аның каләме астыннан чын оста кулы белән эшләнгән тулы канлы сәнгать әсәрләре чыгып тора. Һәм аларның берсе дә тыныч булмә шартларында, яшел абажурлы лампа куелган язу өстәле янында түгел, ә сугыш обстановкасындагы авыр шартларда, һөҗүм сугышлары тынып торган буш араларда, сукыр лампа яктысында язылган. Бу шулай ук батырлык — хезмәт батырлыгы иде. «Кереш җыр» исемле шигырендә шагыйрь үзе болай ди:

**Мин рядовой солдат бу сугышта,**
**Тик бер нәрсәм белән аерылам;**
**Рядовойлар төнен йоклаганда,**
**Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.**

**Бер минут та башка тынгы бирми,**
**Окоп почмагында утырам,**
**Аламын да куен дәфтәремне,**
**Янып җыр язарга тотынам.**

Фатих Кәримнең фронт лирикасы ниндидер моментларда Муса Җәлилнең Ленин премиясе белән бүләкләнгән Моабит шигырьләре белән авазлаш яңгырый. Чыннан да, сугыш елларында алар татар поэзиясенең иң якты йолдызларына әйләнәләр. Ләкин ничектер шулай килеп чыкты, без ул йолдызларның икенчесенә — Фатих Кәримгә игътибар биреп җиткермәдек. Фатих Кәрим иҗатын пропагандалаучылар бармак белән генә санарлык. Бу әдәби тәнкыйть алдына аерым бурыч куя: икенче йолдызның иҗат тәҗрибәсен дә ныклап өйрәнергә һәм шул юл белән татар поэзиясенең диапазонын киңәйтә төшәргә кирәк.

Туп тавышлары күптән тынды. Әмма Фатих Кәримнең сугыш турындагы шигырьләре еллар узу белән тоныкланмый гына түгел, киресенчә, укучы йөрәгенә тагын да кадерлерәк, якынрак була бара. Аның язганнарын укыганда, безнең алга гади һәм тыйнак, чын йөрәктән халкын яраткан шагыйрь үзе килеп баса. Ул шигырьләрне укыганда безнең күз алдына шагыйрь туган якларның матур табигате, зәңгәр һавалы иксез-чиксез киңлекләр, мәһабәт Дим елгасы килеп баса. Шагыйрь шунда, Дим елгасы буенда туган. Ул аны бик яраткан, үзенең җырларында мактаган. Ул элеккеге Кенигсберг янынннан гына агып узган Дейм елгасын да күрергә өлгермәгән. Өлгермәгән, чөнки дошманны тәмам тар-мар итеп бетерергә берничә атна гына калып барганда, сугышчан заданиене үтәгәндә, әлеге елга янында һәлак булган. Үзара рифмалашып килгән шигырь юллары кебек, исемнәре бер-берсенә ифрат якын булган шушы ике елга арасына зур шагыйрьнең бөтен тормышы сыеп бетә. Сыеп бетә... Ләкин бу бары географик яктан караганда гына шулай. Аның поэзиясенең әһәмияте исә бу географик киңлекләр белән генә чикләнми, әлбәттә. Үзенең «Теләк» исемле шигырендә шагыйрь болай яза:

**Тәвәккәллек, батырлыкта**<br>**Җыр булып калсам иде.**

Олы шагыйрьнең бу изге теләге тормышка ашты.

Альберт Айнетдинов

# ЮЛЛАР БАТЫРЛЫККА ЧАКЫРДЫ

## КУРСК ДУГАСЫНДА БЕЗНЕҢ ЯКТАШЛАР

Идел буенда тар-мар ителгән немец-фашист гаскәрләре җәйге һөҗүмгә әзерләнә. Яңасе, яңа «тигр»лар, «пантера»лар, «фердинанд»лар җиңү алып киләчәк. Дошманның мәкерле һөҗүм планы Совет Армиясе командованиясенә үз вакытында билгеле була һәм аңа каршы зур хәзерлек алып барыла.

1943 елның 5 июлендә фашистларның 2700 танкысы һәм штурмлау орудиеләре Орел һәм Белгород районыннан Курскига һөҗүм ясыйлар. Ләкин аларга каршы Совет командованиесе 3500 танк һәм үзйөрешле орудие сугышка кертә.

Фашистларның беренче һөҗүмен укчылар салкын канлылык белән каршылыйлар. Менә фронт газетасы битендә басылган бер хәбәр: «...Кече лейтенант Камалетдинов взводы дошманның терәк пунктыннан ерак түгел урында сугышчан сакта тора иде. 5 июльдә, иртә белән 4 сәгать 30 минутта, артиллерия һәм авиация хәзерләгеннән соң, немецлар һөҗүм башладылар. Өч танк һәм 150гә якын гитлерчылар туп-туры Фәррах взводына таба киләләр иде. Сугышчылар, командир үзен тыныч һәм ышаныч белән тотуын күргәч, дошманны тиешенчә каршы алырга хәзерләнделәр.

Фашистлар «тигр»ының берсе миналанган кырга килеп керде һәм шунда ук шартлады, ләкин калган икесе килүләрендә дәвам иттеләр. Танкларның берсе 15 метрга ук якынлашкач, Камалетдинов аны граната атып зарарлады. Икенчесен аның ординарецы Шокуров зарарлады.

Танклар белән эшне бетергәч, батыр Камалетдинов залп белән ут ачарга приказ бирде, һәм дошман солдатлары ятарга мәҗбүр булдылар. Аннары сугышчылар гранаталарны ходка җибәрделәр. Немецларның беренче төркеме тулысынча кырылды. Ләкин ерактан яңадан дошман танклары һәм пехотасы килгәнлеге күренде. Камалетдиновның аягы яраланган иде, әмма ул сугышка җитәкчелек итүен дәвам иттерде. Дошман танклары якынлаштылар. Камалетдинов уртадан килә торган танк астына граната ыргытты һәм аны стройдан чыгарды. Сугышчылар да үзләренең командиры күрсәткән үрнәк буенча эш иттеләр. Танкларның барысын да зарарладылар. Винтовкалардан, автоматлардан һәм пулеметлардан ут ачып, немецлар пехотасын кырдылар.

Бу бәрелеш бернечә тапкыр кул сугышына күчте. Фәррах, яраланган булуына карамастан, бу сугышта үзе 7 гитлерчыны дөмектерде.

Батыр сугышчылар бу бәрелештә, үзләренең гайрәтле командиры җитәкчелегендә, 7 танкны сафтан чыгардылар һәм 2 ротага якын немец пехотасын юк иттеләр...»[1]. Ватан өчен сугышларда Фәррах Камалетдинов 14 мәртәбә яралана. Аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Камалетдиновның батырлыклары турында татар халкы җырлар чыгара һәм аның белән горурлана.

Курск дугасындагы бәрелешнең беренче көннәрендә укчылар белән беррәттән артиллеристлар «тигр»ларның юлын кисәләр. Капитан Әхәт Таһиров дивизионына кергән дүрт батарея күп тапкырлар фашистлар атакасын кире кайтара. Сугыш кырында дошман 34 танкысын калдырып чигенергә мәҗбүр була. Капитан Әхәт Таһировның артиллеристлары, күп югалтуларга карамастан, бер адым да артка чигенмиләр[2].

1943 елның җәендәге сугыш Мансур Абдуллинга дан китерә, аңарга Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

10 июльдә Молотычи авылы янында артиллерист Абдуллин, туры наводкадан атып, атакага килүче гитлерчыларның өч танкысын сафтан чыгара. Сугыш аз гына тынып тора да яңадан башлана. Бервакыт орудие янында снаряд шартлый һәм Абдуллин аңын югалта. Каһарман сугышчы госпитальдә өч көннән соң гына аңына килә. Аңа, 8 дошман танкысын юк иттең, дигәч, врач сүзенә ышанмый, көлемсерәп куя. Шуның өстенә Абдуллин йөзләгән гитлерчыларны дөмектергән. «Мәңгелек дан сиңа, татар

Дәвамы. Башы 4 санда.

[1] «Суворовчы», 28 апрель, 1944 ел.
[2] «Җиңү байрагы», 17 сентябрь, 1945 ел.

егете Абдуллин»,— дип язылган «Ватанны саклауда» дигән газетада.

Фронт газеталары битләрендә совет танкистларының Курск дугасындагы каһарманлыгына сокланып язылган мәкаләләр күп. Мисал өчен Мөхәммәт Садриның «Яшь офицер Салих Җамалиев» очеркын алыйк. Республикабызның Кырык Садак авылында туып үскән Салих Җамалиев үзенең танкысы белән татар генералы Сафиуллинның укчыларына Крутой Лог районында ярдәмгә килә. Шунда Җамалиев үзенең «Т-34» танкысы белән 13 «тигр»га каршы көрәш башлый: «...Командир маневр ясауга күчә. Танкны ул бер алга, бер артка таба, бер уңга, бер сулга таба йөртергә, бер дә туктатмаска куша һәм дошман танкларына атуын дәвам иттерә. Гитлерчыларның тагын бер танкысын ут һәм төтен сырып ала.

«Тигр»лар совет танкысына каршы атака ясый алмыйлар. Җамалиев аларга бер генә метр алгарак килергә дә мөмкинлек бирми. Шулай итеп, сугыш кыры янган танкларның төтеннәре, «тигр»ларның авыр снарядларыннан актарылган җир-туфрак тузаннары белән каплана. Инде дошманны күзәтүе дә читенләшә. Немецлар, сугыш кырында әле алга, әле артка, яки уңга, яки сулга таба бертуктаусыз йөреп ут яудырып торган совет танкысына «тигр» снарядларын тидерә алмагач, аңа атака ясар өчен исерек автоматчыларын җибәрәләр... Частьта Салих Җамалиев экипажын дуслары зур шатлык белән каршылыйлар. Күп тә үтми, аларны командир чакырып ала.

— Сезнең батырлыгыгыз, күп кенә гитлерчыларны юк итүегез, 3 «тигр»ны яндыруыгыз һәм бернichә «тигр»ны зарарлавыгыз миңа билгеле,— ди полковник.— Шуның белән бергә сез дошман танкларына атакага ташланырга ирек бирмәдегез һәм командованиегә әһәмиятле тактик бурычны үтәргә булыштыгыз. Дүртегезне дә хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итәм!» [1].

Дошман июль башындагы һөҗүмендә зур югалтуларга дучар ителә. Меңләгән «тигр»лар, «пантера»лар, «фердинанд»лар сугыш кырында хәрәкәтсез кала. «Цитадель» операциясе чәлпәрәмә килә. Совет гаскәрләре Курск дугасының төньягында 12 июльдә, ә көньягында 15 июльдә контрһөҗүмгә күчәләр. Ул көннәр турында старшина Х. Саттаров фронт газетасына менә нәрсә язган:

«Иртәнге караңгылык тарала башлаганда безнең укчы подразделениеләр атака рубежына тупландылар.

Артиллерия позицияләрендә дә сугышчылар соңгы хәзерлек чараларын күрделәр. Инде орудиеләр ачык позицияләргә тартып чыгарылганнар. Һәр расчет кайда ут ачарга кирәклеген, дошман окопларының беренче рәте алынгач, утны кайда күчерергә кирәклеген белә. Батарея командиры өлкән лейтенант Заһир Сөнгатуллин барысын да карый, тикшерә, киңәшләр бирә.

Иртәнге тынлыкта орудиеләрнең беренче залплары яңгырады. Бу ату тавышлары бернichә секунд эчендә тоташ гөрселдәүгә әверелде. Унбиш минуттан орудиеләр уты дошман оборонасының эченәрәк күчерелде. Немец окопларында ярылган снарядлар төтене таралырга да өлгермәде, укчылар атакага күтәрелделәр.

Бу сугышта өлкән лейтенант Заһир Сөнгатуллин артиллеристлары дошманның 5 пулемет оясын, күзәтү пунктын, ике блиндажын җимерделәр. Пехотага алга барырга ярдәм итеп, һич кичекмәстән, яңа позицияләргә күчтеләр...» [2]




Һөҗүмгә баручы сугышчылар рәтендә Казан студенты, яшь офицер Хәсән Мөхетдинов, рус егете Иван Тимеров белән бер-берсенә ярдәм итеп, дошман өстенә ут ачалар. Хәсән танкысыннан атылган беренче снаряд «тигр»ны сафтан чыгара. Шул ук вакытта Иван да залп бирергә өлгерә — тагын бер дошман танкысы яна башлый. Курск дугасында алар гитлерчыларның тугыз танкысын җимерәләр [3].

Җирдәге гаскәрләрнең һөҗүмен саклауда һәм аларга ярдәм итүдә совет очучылары да тиңдәшсез батырлыклар күрсәткәннәр. Менә шундый бөркетләрдән безнең якташлар, ике мәртәбә Советлар Союзы Герое Н. Г. Столяров һәм һава укчысы Хатип Хафизов бер экипажда Белгород өчен барган бәрелешләргә катнаша. Ибраһимов Гази һәм Г. Шәрипов «Ватан намусы өчен» газетасында «Һава баһадиры» исемле хәбәр язганнар.

«1943 елның июль көнендә Хатип Хафизов дошман белән беренче тапкыр Белгород күгендә очраша. Дүрт совет штурмовигына алты немец истребителе ташлана. Хафизовлар самолеты өстенә өч истребитель килә. Очучы укчы Хафизовка карый: сынатмассыңмы? Ул очередь бирә. Беренче дошман самолеты яна башлый. Ул күрше экипажга һөҗүм итүче истребительне дә бәреп төшерә...

...Столяров Н. Г.— очучы, Хафизов — укчы. Столяров Хафизовның мәргәнлегенә, аның белән югалып калмаячагына, ә Хафизов геройның самолетын теләсә нинди шартларда да осталык белән ут астыннан алып чыга белүенә ышана... Күп авырлыкларны бергә кичерделәр, дошман үлем белән янаган шартларда да

[1] «Ватан намусы өчен», 18 апрель, 1946 ел. Гвардия капитаны Салих Җамалиев Курск дугасыннан Германиягә кадәр, үз экипажы белән дошманның 30 лап танкысын һәм үзйөрешле орудиеләрен яндыра. Совет хөкүмәте аны I һәм II Дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкли. Хәзер ул фәннәр кандидаты, Харьковта укыта.

[2] «Совет сугышчысы», 10 январь, 1944 ел.

[3] «Ватан намусы өчен», 27 ноябрь, 1944 ел.

бу ике йөрәк куркуны белмәде һәм алар һәр кайчан җиңеп чыктылар» [1]...

Белгород өчен барган сугышларда катнашучы гвардия майоры Закир Рәхимов турында хәрби журналист А. Әсхат очерк язган. Менә шуннан бер өзек:

«...Җир өстенә алтын нурларын сибеп, ерак көнчыгыштан кызарып кояш балкып килгәндә, Рәхимовның эскадрильясе һавага күтәрелде.

Гаять җаваплы задание иде бу...

— Миңа якынрак килергә һәм сафны тыгызрак ясарга! — дип, приказ бирде Рәхимов радио аша. Аның лачыннары шунда ук командирны куып җиттеләр һәм бер-бере белән янәшә генә булып оча башладылар.

— Сак булыгыз, фронт линиясен үтәбез! — дип искәртте тагын Рәхимов. — Хәзер бераүгә дә артта калмаска...

Юлларның берсендә дошманның һөҗүмгә ташланырга хәзер торган танк колоннасы булырга тиеш. Рәхимов картада билгеләнгән урынны җир өстендәге ориентирлар белән чагыштырып алды да самолетын уңгарак бора төште. Дошман танклары инде юлда түгел, бәлки алда күренгән калын урман читенә җитеп ял итәргә туктаганнар иде. Рәхимов аларны бу урыннан ата башлаган зениткаларга карап белде. Шунда Рәхимовның башында бер хәйләле уй туды. Ул, һич тә исе китмәгәндәй булып, самолетын тагын да уңгарак бора төште дә, үзен бөтенләй башка объектны бомбаларга җыенган кеше итеп күрсәтеп, зениткалардан читтәрәк алга үтте. Дошманның зениткалары атудан туктадылар.

— Атакага барам, — дип искәртте Рәхимов үзенең очучыларына һәм үз самолетын кинәт сулга борды да танклар өстенә пикировать итте. Очучылар командирның алымын кабатлап, түгәрәк ясап, бер-бер артлы пикега керделәр...» [2]

Менә шулай гвардия майоры Рәхимов тылдан кечкенә улы Рәшитнең: «Әти, Гитлерны үтер дә өйгә кайт инде, сине бик сагындык», — дигән хатына җавап бирә. Ул дошман өстенә йөзләгән бомба яудыра.

Орел һәм Белгород шәһәрләрен азат иткәндә очучы, Советлар Союзы Герое И. Г. Газизуллин [3], гвардия старшинасы, радист Шамил Гайнетдинов [4], артиллерист, гвардия сержанты Гафур Шәрәфиев [5], минер Габделхәй Кәбиров [6], артиллерист, өлкән сержант М. Хисамов [7], разведчик, гвардия өлкән сержанты Габдуллаҗан Каюмов [8] һәм бик күп башка якташларыбыз, башка халыкларның уллары белән бергә, тиңдәшсез каһарманлыклар күрсәткәннәр.

Орел-Курск дугасында халыклар дуслыгы, социалистик стройның өстенлеге җиңүгә алып килде. Илебезнең барлык халыклары да баһадирларча сугыштылар. Курск дугасындагы сугышлар өчен 180 кешегә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Шулар арасында: руслар — 133, украиннар — 25, татарлар — 4, белоруслар — 3, үзбәкләр — 2, әрмәннәр — 2.

## ДНЕПРНЫ КИЧКӘНДӘ

Совет гаскәрләре Днепрны кичүгә Курск дугасындагы һөҗүмнәр вакытында ук нык лап әзерләнделәр. Дошман Днепр ярын совет сугышчылары үтә алмаслык терәк пункты дип игълан итә. «Көнчыгыш валы» турында фронт газеталары битләрендә карикатуралар басылган. Шуларның берсе астында Шәйхи Маннурның түбәндәге шигъри юллары бирелгән:

**«Пыгытма гаять нык, биек һәм калын,**
**Ул безне давылдан, афәттән саклар!» —**
**Иырделәр шулай дип «көнчыгыш валы»н,**
**Чарасыз гитлерчы — әйләнчек башлар.**
**Көл булып, хур булып ялкын-тимердән,**
**Керделәр күпләре туфрак астына.**
**Вал күчте Деснадан, күчте Днепрдан**
**Һәм күчәр бервакыт Неман артына** [9]**.»**

Кыска гына вакыт эчендә безнең гаскәрләр елганың аръягында 23 плацдармны кулга төшерәләр. «Днепрны икенче тапкыр кичәргә әзерләнүче понтончы ефрейтор Н. Садыйков:

«Украинаны азат итү — минем туган илемне азат итү ул. Изге ирекле җиребез өчен мин җаным-тәнемне кызганмам, — ди.

Садыйков бу сүзләре белән үзенең иптәшләре — рус егете Родов, украин Шелоньдюк, үзбәк егете Саидов һәм казакъ егете Сымбаевның да уй-тойгыларын әйтте... Татар егете Н. Садыйков Днепрны кичкәндә биргән сүзен намус белән үти», — дип яза хәрби журналист Хәсән Хәйри [10].




1943 елның 21 сентябрендә 13 нче Армия сугышчылары Припять тамагыннан төньяктарак Днепрга чыгалар һәм шунда ук елганы кичә башлыйлар. Дошманның ярдагы уты да, һавадан ташланган бомбалары да өлкән лейтенант Л. Сибгатуллинның кыю сугышчыларына киртә була алмый. Политрук Сибгатуллин

[1] «Ватан намусы өчен», 8 декабрь, 1944 ел. Г. Шәрипов шул ук газетада 1945 елның 19 августында «Лачыннар» хәбәрендә Хафизов турында яза. Ул Кызыл Байрак, I һәм II Дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

[2] «Совет сугышчысы», 20 август, 1944 ел.

[3] «Ватан намусы өчен», 6 ноябрь, 1944 ел һәм 19 август, 1945 ел. И. Г. Газизуллин 1944 елның маенда һәлак була.

[4] «Ватан намусы өчен», 19 август, 1945 ел.

[5] «Ватан намусы өчен», 25 октябрь, 1944 ел. Г. Шәрәфиев Курск дугасында бер «тигр»ны, үзйөрешле орудиене сафтан чыгара, унлаган фашистны дөмектерә.

[6] «Фронт хакыйкате», 29 декабрь, 1944 ел. Курск дугасында Г. Кәбиров 5 мең мина зарарсызландыра, ә 1941—1944 елларда — 15 меңне. Г. Кәбиров республикабызның Күлле Киме авылында туган.

[7] «Кызыл Армия», 9 сентябрь, 1945 ел.

[8] «Ватан намусы өчен», 4 апрель, 1946 ел. Г. Каюмов ике Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән. Ул Берлинны штурмлауда катнашкан.

[9] «Ватан өчен», 28 октябрь, 1943 ел.

[10] «Совет сугышчысы», 7 ноябрь, 1943 ел.

флангтан дошманның станоклы ике пулеметына һөҗүм итә һәм аларны җимерә. Бер төркем сугышчылар белән Сибгатуллин Гуд хуторына бәреп керә. Бу бәрелештә Сибгатуллин үзе гитлерчыларның станоклы пулемет урнаштырылган автомашинасын шартлата һәм урам сугышында немец офицерын һәм 5 солдатын дөмектерә. Шунда дошманның кораллар склады да кулга төшерелә. Шушы батырлыгы өчен Л. С. Сибгатуллинга Советлар Союзы Герое исеме бирелә [1].

13 нче Армиянең сул ягындагы Ясногородка һәм Бородянка районында Днепрны генерал Черняховскийның 60 нчы Армиясе сугышчылары штурмлый, уң яктан, Любея районында генерал Беловның 61 нче Армиясе баһадирлары елганы кичә. Шушы армияләр составында безнең якташларыбыз бик күп була.

Днепрның уң як ярында 231 нче гвардия укчы полкының автоматчысы Сәлим Айткулов үз теләге белән берничә мәртәбә дошман урнашкан Янгогородка авылына разведкага барып, фашистлар турында кыйммәтле мәгълүматлар алып кайта. 29 сентябрьдәге сугышта Сәлим Айткулов үзенең батырлыгы белән башкаларга үрнәк күрсәтә. Менә взвод командиры сафтан чыга, ул, җитәкчелек итүне үзенә алып, автоматчылар белән дүрт мәртәбә атакага бара, ә дошман контратакасын 7 мәртәбә кире кайтара. Икенче көнне дә гитлерчылар һөҗүмнәрен дәвам итәләр. Айткулов ике мәртәбә яралана, ләкин сугыш кырыннан китми. Бервакыт аны немец укчылары камап ала. Сәлим озак уйлап тормыйча, үзеннән ерак түгел граната шартлата һәм 4 фрицны дөмектерә, ләкин шунда үзе дә каты яралана. Сәлим Айткулов каһарманлыгы автоматчыларны һөҗүмгә чакыра һәм алар үз бурычларын намус белән үтиләр [2].

Днепрның уң ягында яралы сугышчыларга ярдәм итүдә санитарлар аруныталуны белмиләр. Алар үлем уты астында йөзләгән яралыларның тормышын саклап калалар. Мисал өчен бирничә газета материалына тукталыйк.

«...Кечкенә җирдә» көн-төн сугышлар бара иде. Әле полк докторы өлкән лейтенант Хәерниса Хәмитова үзенә билгеләнгән урынга барып та җитә алмады, немец самолетлары килеп чыктылар. Алар башта яндыргыч бомбалар ташладылар. Аннан соң бөтен Днепр буен яңгыратып фугаскалар ярыла башлады. Хәерниса подразделениегә ашыкты. Докторга бу якта әш тагын да күбрәк иде. Ул алгы сафка ук барып җитте, аяусыз үлем уты астында яралыларга беренче ярдәмне күрсәтте, аларны вакытында тылга озатуны оештырды.

— Сезгәерактарак булырга кирәк иде,— дип, Хәернисаны икенче эшелонга күчерергә үгетләп карады подразделение командиры,— монда артык куркыныч...

Хәерниса кырт кисте:

— Ә сезгә куркыныч түгелмени?..» [3]

Плацдармда күрсәткән батырлыклары өчен командование Хәерниса Хәмитованы «Батырлык өчен» медале белән бүләкли.

Воронеж фронты дивизияләре 23 сентябрьдә Днепрга килеп җитәләр һәм аны кичә башлыйлар. 255 нче укчы полкның взвод командиры ярдәмчесе Фәйзулла Әгъләтдинов һәм 957 нче укчы полкның взвод командиры Салих Вәлиев беренче булып Днепрны кичәләр һәм плацдарм өчен көрәш башлыйлар. Бу ике командир 30 дан артык гитлерчыны дөмектерә. Дошманның 9 һөҗүме кире кайтарыла һәм плацдарм, төп көчләр килгәнче, кулда тотыла. Бу ике каһарманга Советлар Союзы Герое исеме бирелә [4].

Киевтан төньякта сентябрь аенда «Кечкенә җирдә» 38 нче һәм 47 нче армия сугышчыларыннан гвардия лейтенанты Мансур Хәсәншин [5], кече лейтенант Ибраһим Беркутов [6], Әлимкәй Абдершин [7], кече лейтенант Мидхәт Салихов [8], өлкән сержант Хәмит Неатбековлар [9] зур батырлык үрнәкләре күрсәтәләр һәм аларның һәркайсына Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Днепрны кичкәндә Казанда төзелгән 69 нчы укчы дивизия саперлары У. Кадыйров, М. Шәйхуллин бер төндә, дошманның көчле уты астында, елганы понтонда 8 тапкыр кичәләр һәм бер ротага якын сугышчыны ары якка чыгаралар. Шушы ук дивизиянең артиллеристы, Саба районы егете М. Хуҗиев бер сугышта гына гитлерчыларның 6 пулеметын, күзәтү пунктын, автомашинасын һәм 15 солдатын юк итә. Ул Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Татарстан егетләре офицер Мөхетдинов, Якупов, артиллеристлар Сәетов, Хәсәнов, Хәлимовлар һөҗүмдә кыюлык һәм хәрби осталык күрсәтәләр.

3 нче Украина фронтының «Совет сугышчысы» газетасында Днепрны кичкән каһарманнардан Советлар Союзы Герое сержант Фахрази Галиев, сержант Тәүфыйк Галиев, өлкән лейтенант Гайфетдин Гыйльметдинов, снайпер Хәлим Әхтәмов һәм башкалар турында төрле жанрдагы материаллар бирелгән.

2 нче һәм 3 нче Украина фронтларының Днепрдагы уңышлары 1 нче Украина фронты гаскәрләренә Киевны азат итү шартлары тудыралар. Киев өчен барган сугышта генерал П. С. Рыбалко танкистлары дан казана.

5 ноябрь төнендә Гали Шәмсетдинов ротасы Киев шәһәре урамнарына бәреп

---

[1] «Ватан намусы өчен», 28 март, 1944 ел. Сибгатуллин Л. С. Үзбәкстанда туган.

[2] Үзәк хәрби архив, ф. 33, 793756 тасвирлама, 3 эш, 203 бит. 1943 елның 17 октябрендә СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән С. Н. Айткуловка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

[3] «Совет сугышчысы», 1 май, 1944 ел.

[4] Үзәк хәрби архив, ф. 33, 793756 тасвирлама, 3 һәм 8 эш, 53, 162 битләр.

[5] «Ватан намусы өчен», 7 январь, 1945 ел.

[6] Үзәк хәрби архив, ф. 33, бүләкләү кәгазе.

[7] «Ватан намусы өчен», 18 январь, 1944 ел.

[8] «Ватанны саклауда», 13 январь, 1945 ел.

[9] Үзәк хәрби архив, ф. 33, 793756 тасвирлама, 43 эш, 295 бит.

керә һәм дошманның орудиеләрен, пулеметларын таптап уза. Танкистлар утлары белән укчыларга ярдәм итәләр [1]. 6 ноябрь таңында Киев азат ителә. Сугыш барышында тамырдан борылыш ясала. Бу көрәшләрдәге батырлыклары өчен татар халкының илледән артык улы һәм кызы Советлар Союзы Герое исеменә лаек була.

## ХӘЛИТКЕЧ СУГЫШЛАРДА

1943 елның хәрби һәм политик йомгаклары фашистларның сугышны инде оттырган булуы турында ачык сөйли.

1944 елда совет гаскәрләре Ленинград янында дошманны тар-мар итеп, Белоруссия, Көнбатыш Украина, Балтик буе, Польша җирләрен азат итү сугышлары алып бардылар.

Өч ел буе гитлерчылар белорус халкын газапладылар: 2 миллионнан артык кешене атып, асып үтерделәр. Ләкин палачлар халыкны куркыта алмадылар. Халык көрәште, фашист баскыннарын бәрәмләп һәм күпләп юк итте.

Совет армиясенең һөҗүме алдыннан Белоруссия партизаннарының дошман оккупацияләгән территориядәге тимер юлларны шартлатуы турында хәрби корреспондент Шәрәф Мөдәррис «Партизан» дип исемләнгән мәкаләсендә болай дип язган: «Котдус Әхмеров яраланып пленга эләгә, җиде айдан соң Могилев өлкәсендә, лагерьдан качып, партизаннарга килеп кушыла. Алар белән бергә күп кенә дошман өйләрен яндыра, полицайларны дөмектерә. 23 июньдә Әхмеров ике иптәше белән Минск белән Могилев арасында булган тимер юл күперен шартлата. Сугышчан бурычны үтәгән өчен К. Әхмеров «Ватан сугышы партизаны» медале белән бүләкләнә. Батыр йөрәкле сугышчы Беренче Балтик буе фронты сугышчыларының азатлык алып килүен зур шатлык белән каршылый» [2].

22 июньдә көчле артиллерия әзерлеге үткәргәч, Полоцк районында генерал-лейтенант Ермаковның 23 нче гвардия укчы корпусы дошманны кысрыклый. Казан егете өлкән лейтенант В. Тыржанов үзен оста командир итеп күрсәтә, аз югалтулар белән дошманның Радьково-Орехово ныгытылган терәк пунктын ала. Шунда ук Тыржанов җитәкчелек иткән пулемет ротасы Көнбатыш Двина елгасын кичә һәм 201 нче гвардия укчы полкының алга баруын тәэмин итә. Өлкән лейтенант Тыржанов автоматчылары Голыһи һәм Троицк авылларын азат итәләр, фашистларның берничә атакасын кире кагалар, ә батыр командир бер сугышта гына 9 гитлерчыны дөмектерә. Белоруссия җирендә күрсәткән батырлыгы өчен В. Тыржанов Ленин ордены белән бүләкләнә [3].

Көнбатыш Двина елгасына 43 нче Армия дә килеп җитә. Беренчеләрдән булып капитан Булат Янтимиров сугышчылары елганы кичәләр һәм Витебск шәһәреннән көнбатышка таба сузылган олы юлны кисеп, немецларның коммуникацияләрен өзәләр. Гитлерчылар, камалудан чыгу өчен, һөҗүм арты һөҗүмгә киләләр, ләкин көнбатышка үтә алмыйлар. Белоруссия җирендә барган сугышта Янтимиров каты яралана һәм һәлак була. Үзе үлгәннән соң аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. «Татар халкы үзенең бу батыр улын мәңге онытмас!» — дип яза майор М. Гимадиев «Алга, дошман өстенә» газетасында (14 сентябрь, 1944 ел).

Беренче Балтик буе фронты белән бергә Икенче Белоруссия фронты да дошман оборонасын өзеп алга омтыла. Шушы фронт газетасының корреспонденты Гамир Насрый һөҗүмгә катнашкан өлкән лейтенант Гариф Харисов сугышчылары турында яза.

«Язгы һөҗүм, 1944 ел. Өлкән лейтенант Харисовның батареясы дошман орудиеләрен юк итеп, укчыларга юл ача, бер көндә 36 км юл үтә. Менә елга янына барып җитәләр. Харисов күпернең минадан шартлатылырга тиешлеген белгәч, батареясын тиз генә елганың икенче ягына чыгара. Күпер шунда ук шартлый. Җитмәсә, бер ротадан артык немецлар аларны камап ала, ләкин артиллеристлар үзләре һөҗүмгә күчеп дошманны изеп ташлыйлар. Берничә көндә Г. Харисов батареясы сугышчылар белән 80 км Белоруссия җирен үтә» [4].

8 нче үзйөрешле артиллерия бригадасы 15 көн эчендә 400 км юл үтеп, Белоруссиянең башкаласы Минскины азат итүдә катнаша. Шушы бригаданың дивизионы, капитан Габдулла Җиһаншин җитәкчелегендә, дошманның 3 танкысын, 23 орудиесен, 11 минометын, йөзләгән укчысын юк итә.

Минск урамында Җиһаншин сугышчыларыннан каһарманлык күрсәтүчеләр арасында сержант Г. Гайсин, старшина Г. Гарипов кебекләр күп була. Санитар Нурулла Хәбибуллин 7 каты яралыны сугыш кырыннан алып чыга. Гамир Насрый Кукмара районы егете капитан Г. Җиһаншинның сугышчан тормышына багышлап очерк та язып бастыра [5].

3 июльдә Минск шәһәрен тулысынча азат итеп бетергәч, безнең гаскәрләр үз ударларын Белосток шәһәренә юнәлдерәләр. Ләкин дошман Осовец шәһәрен крепостька әйләндереп, совет гаскәрләрен тоткарлап торырга уйлый. Осовец крепосте дошманга Белосток белән Варшава арасындагы тимер юлны сакларга ярдәм итә. Шунлыктан Осовец крепостен кулга төшерү бурычы туа. Разведчик Даян Булатов Осовец шәһәрендәге сугышта дошман танкысын шартлата

[1] «Ватан намусы өчен», 8 ноябрь, 1944 ел.
[2] «Фронт хакыйкате», 19 июль, 1944 ел.
[3] Үзәк хәрби архив, ф. 33, 686040 тасвирлама, 25 эш, 204 бит. В. Т. Тыржанов сугышка кадәр Казанда, Бутлеров урамы, 26 нчы йортта торган.

[4] «Фронт хакыйкате», 25 сентябрь, 1944 ел.
[5] «Фронт хакыйкате», 29 июнь, 1944 ел.



Бөек Ватан сугышында корал белән көрәшкән, фронт газеталарында эшләгән су
Х. Госман, Р. Ишморат, Г. Бакиров, А. Шамов, Г. Минский, Ә. Исхак, Т. Журавлев.
С. Сабиров, Н. Гайсин, М. Ногман, А. Расих, Н. Дәүли, С. Шәкүров.

һәм аның экипажын пленга ала. Ул үз отделениесе белән фашистларны йортлардан бәреп чыгара. Шушы батырлыгы өчен Чистай районында туып үскән Даян Булатов Беренче Дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә. Гамир Насрый аңа багышлап «Данлыклы егет» дигән мәкалә яза [1].

Белосток районындагы сугышларда күрсәткән каһарманлыгы өчен лейтенант Ягъфәр Әхметшинга Советлар Союзы Герое исеме бирелә [2], орудие командиры Илһам Хафизов [3] һәм өлкән лейтенант Фәйзи Галиуллин [4] Ленин ордены белән бүләкләнәләр.

Август ахырында Белоруссияне азат итү сугышлары йомгаклана. Бу сугышларда безнең дә бик күп якташларыбыз һәлак булалар. Белорус халкы корбан булган сугышчыларның исемнәрен ихтирам итеп искә ала, аларның каберлекләре өстенә чәчәкләр куя. 334 нче дивизиянең Казанда яшәүче ветераннары Витебск шәһәрен азат итүгә 25 ел тулу уңае белән, бу шәһәрдә кунакта булып кайттылар. Бу турыда элеккеге хәрби журналист Б. Корбанов һәм университет профессоры И. М. Ионенко «Социалистик Татарстан» газетасында мәкалә белән чыктылар.

[1] «Фронт хакыйкате», 3 июнь, 1945 ел.
[2] Үзәк хәрби архив, ф. 33, 686039 тасвирлама, 3 эш, 332 бит.
[3] Шунда ук, ф. 33, 686049 тасвирлама, 10 эш, 66 бит.
[4] Шунда ук, ф. 33, 686043 тасвирлама, 104 эш, 136 бит.

Львов шәһәрен азат итүдә катнашкан Советлар Союзы Герое Әхмәдулла Хаҗи улы Ишмөхәммәтов турында Газиз Иделленең «Совет офицеры» очеркы «Ватан намусы өчен» газетасында басылган. Менә шушы очерктан бер өзек: «...1944 елның 23 июлендә батальон Львов шәһәренең үзәк өлешен сугышып алды һәм зур йортларның берсе түбәсенә Кызыл Байрак күтәрде.

Львов шәһәре урамнарында һәм йортларында өч көн буе барган сугышларда Ишмөхәммәтов батальоны дошманның 900 солдатын һәм офицерын юк итте, «сс» полкының 30 солдатын, радиоприемнигы белән бер немец шпионын пленга алды, 10 пулеметны һәм 1 танкны кулга төшерде. Немец коллыгында булган 5 000 совет кешесен азат итте...» [5].

Львов шәһәрен азат иткәндә Советлар Союзы Герое Гали Шәмсетдинов [6], өлкән лейтенант Нәҗип Фазлыев [7] һәм бик күп башка якташларыбыз зур батырлыклар күрсәткәннәр.

Август башында Беренче Украина фронты гаскәрләре Висла елгасы ярларына килеп җитәләр. Генерал М. Е. Катуковның танк армиясе разведчиклары елганың уң як ярына чыгалар. Алар арасында комсомолец Миннулла Гыйззәтуллин да була. Кыю разведчиклар дошманның терәк пункты турында мәгълүматлар җыеп, радио аркылы безнең

[5] «Ватан намусы өчен», 27 ноябрь, 1944 ел.
[6] «Ватан намусы өчен», 8 ноябрь, 1944 ел.
[7] Шунда ук, 20 август, 1944 ел.



гышчылардан бер төркем. Сулдан уңга (утырганнар): М. Садри, Н. Арсланов, (Басканнар): Б. Гыйззәт, М. Рафиков, А. Кәримуллин, Х. Вахит, З. Шәһиморатов, 1975 елгы рәсем.

штабка җиткерәләр. Генерал Катуков Армиясе елганы кичә башлагач, разведчиклар атакага күтәреләләр. Гвардеец Гыйззәтуллин берүзе генә дә һөҗүм вакытында 20 дән артык гитлерчыны дөмектерә. Аңа сугышчан приказны кыю һәм үрнәкле үтәгәне өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелә [1].

Фронт газеталарында Висланы кичеп, Сандомир плацдармын киңәйтүдә батырлык күрсәткән сугышчыларга багышланган материаллар бик күп басылган. Мәкаләләрдә, очеркларда татар егетләреннән гвардия сержанты Габдулла Едиханов [2], коммунист Фәйзи Галиуллин [3], разведчик Миргарифан Гәрәев [4], лейтенант Сөләйман Ибраһимов [5], өлкән сержант Аббас Измайлов [6], гвардия сержанты Абдулла Мотыйгуллин [7] һәм башкалар телгә алына.

Сандомир плацдармында көрәшкән сугышчыларга Советлар Союзы Маршалы И. С. Конев: «Мин фронт сугышчыларының плацдармны саклаганда күрсәткән хәрби осталыгына һәм героизмына сокланып баш иям» [8],— дип бәя бирде.

[1] «Ватан намусы өчен», 19 октябрь, 1944 ел.
[2] Шунда ук, 1 ноябрь, 1944 ел.
[3] Шунда ук.
[4] Шунда ук, 11 декабрь, 1944 ел. М. Гәрәев Мөслим районында туган.
[5] Шунда ук, 23 декабрь, 1944 ел.
[6] Үзәк хәрби архив, ф. 15, 10/34 эш, 354 бит.
[7] «Ватан намусы өчен», 26 март, 1945 ел. А. Мотыйгуллин Саба районында туган.
[8] «Бөек азат итү походы», Мәскәү нәшрияты, 1970 ел, 32 бит (рус телендә).

Совет гаскәрләренең Белоруссиядәге уңышлары Беренче Балтик буе фронтының һөҗүменә уңай шартлар тудыра. Удар Шауляй шәһәренә юнәлдерелә. Хәрби журналист Абдулла Әхмәт «Олы юлда» хәбәрендә менә нәрсә яза: «Ул көнне Шауляй — Тильзит юлы өстендә аеруча каты сугышлар булды. Дошман оясына бара торган бу киң юлга асфальт җәелгән. Бу юлның, билгеле, стратегик әһәмияте гаять зур. Шуңа күрә дә дошман анда аеруча зур каршылык күрсәтте. Немецлар юлга артиллериядән, минометтан өзлексез атып тордылар.

Шундый көчле ут астында гвардия кече сержанты Фәтхулла Нәфыйковлар расчеты юл янына туры наводкага куелды.

Күп тә үтмәде, немецларның бронетранспортерлары күренде. Расчет командиры аларны 250—300 метрларга кадәр якын җибәрде дә шуннан соң ут ачарга команда бирде. Наводчик Нәфыйковның оста төзәве аркасында дошманның ике бронетранспортеры юк ителде, 20 дән артык солдат һәм офицеры кырып ташланды. Безнең пехотачыларның алга китүләре тәэмин ителде...» [9]. Шушы батырлыгы өчен Ф. Нәфыйков Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Татарстанның Балык бистәсе районы, Яңа Ырга авылы колхозчысы, Дан ордены кавалеры Хәсән Нәҗмиев Шауляй

[9] «Алга, дошман өстенә», 14 ноябрь, 1944 ел.

юлында үзен онытылмаслык дан белән күмә. Аның турында фронт газетасында болай язылган:

«...Бронебойщик сержант Нәҗмиев фашистларның ике машинасын яндыра, граната ыргытып, бер танкларын сафтан чыгара. Дошманның калган танклары кача башлыйлар, ләкин алар качып өлгерә алмыйлар, үз йөрешле орудиенең уты белән яндырылалар.

Хәсән Нәҗмиевләр машинасы туктамыйча һаман алга баруында дәвам итә. Машинаның пулеметчылары юл буендагы канауларга качкан немецларны туктаусыз кыра. Йөздән артык немецны чәнчелдерәләр. Бу героик машина бөтен берләшмәгә юл ача. Бу кыю егетләр шул көнне Балтик диңгезенә таба 70 километрдан артык юл үтәләр һәм шул көнне үк ике шәһәрне азат итәләр...»[1].

Сентябрь аендагы һөҗүмнәр көнендә Икенче Балтик буе фронты сугышчысы Рәшит Рәхимов «Суворовчы» газетасына «Наказны намус белән үтим» дигән мәкаләсен җибәргән. «Мин туган авылымнан киткәндә, — дип яза ул, — Маһирә, күзләрен сөртә-сөртә:

— Рәшит, син сугышка барасың. Мине сөйсәң, сугышта батыр бул, немец мәлгуньнәрне аяусыз кыр, — дип наказ бирде.

Туганнарымнан аерылганыма өч елдан артты инде. Алар — фронтта, сугыш кырларында үткәрелгән еллар булдылар. Мин Мәскәү оборонасы сугышларында катнаштым, героик Ленин шәһәрен саклау өчен сугыштым. Ә хәзер Рига култыгы ярларына таба һөҗүм итеп алга барабыз, Совет Балтик буе җирен немец-фашист илбасарлардан чистартабыз. Мин һәркайчан, атакага барганда, сөеклемнең наказын истә тотам. Аның әйткән сүзләрен Ватанымның, халкымның наказы дип беләм...

Гитлерчылар каты каршылык күрсәттеләр, ләкин аларның маташулары барып чыкмады. Без аларны траншеяләреннән куып чыгардык һәм һөҗүмне дәвам иттердек. Шулай ук немецларны юл кырыендагы обороналарыннан да бәреп чыгардык. Мин бу юлы дүрт гитлерчыны үтердем»[2].

Танклар десантына укчы Сабир Кәримов катнаша. Ул сентябрь сугышында 18 фашистны юк итә, ә алтысын пленга ала. Сугыш кырыннан авыр яралы лейтенант Изотовны алып чыга. Алгы сызыкта, атулар тынганда, аны партия сафына алалар. Кыю коммунист С. Кәримов Дан ордены белән бүләкләнә[3].

«Суворовчы» газетасы редакциясе Икенче Балтик буе фронты командующие Армия генералы А. И. Еременкога мөрәҗәгать иткән һәм аның «Балтик буе сугышлары геройларына мактау һәм дан!» исемле зур мәкаләсен бастырган.

Күренекле полководец А. И. Еременко: «Бу мәкаләмдә мин данлыклы татар сугышчылары турында сөйләргә телим»,— ди. Һәм ул М. Горькийның: «Мин татарларны бик яхшы беләм. Алар намуслы халык, батыр йөрәкле халык, нинди генә героик батырлыкка да сәләтле халык», — дигән сүзләрен китерә. «Татар халкының бик күп уллары,— дип яза аннары Армия генералы А. И. Еременко, — фронтта үзләренең исемнәрен дан белән бизәделәр». Шушы мәкаләдә Балтик буендагы батырлар турында да шактый тулы әйтелгән.

Пулеметчы Бикмөхәммәтов участокларның берсендә, немецлар контратакага күчкәч, үзе сугышып алган җирдә нык тора. Дошман солдатлары аңа өч тапкыр ташланалар һәм өч мәртәбә чигенергә мәҗбүр булалар. Дүртенче контратакада да Бикмөхәммәтов җиңеп чыга.

Икенче бер рубежда сержант Камалетдинов, берничә сугышчы белән бергәләп, немецларның ныгытмаларын әйләнеп үтеп, траншеяга бәреп керә. Шул вакыт Камалетдинов өстенә өч немец ташлана. Ул беренче немецны мылтык түтәсе белән сугып үтерә, ә икенчесен атып ега, өченчесе кулларын күтәрә һәм пленга бирелә.

«Татар халкының дан казанган уллары, — дип, мәкаләсен тәмамлый командующий, — дошманнарны әнә шулай кыйныйлар. Совет ватанының дошманнарына каршы куркусыз сугышучы батырларга — Балтик буе сугышлары геройларына мактау һәм дан!» [4].

## ФАШИСТ ӨНЕНДӘ

1945 ел башында сугышлар Германия җирендә бара иде инде. Бу сугышларга катнашкан гвардия өлкән лейтенанты Ш. Хөснетдинов «Кызыл Армия» һәм «Ватанны саклауда» газеталары редакцияләренә бик кызыклы хәбәр җибәргән. Ул «Немец җирендә татар көе» дип исемләнгән.

«Каты сугышлардан соң, техниканы тәртипкә китерер өчен, гвардеецлар берничә көнгә Н. авылында тукталдылар. Сугышчылар таш капчыкларга охшаган немец өйләрендә урнаштылар һәм эшкә башладылар.

Машиналарга перетяжка ясалды, кораллар чистартылды.

Сугышчылар мунча керделәр, өс-башларын алмаштырдылар. Кешеләр дә, техника да яңа һөҗүмгә керергә, яңадан Берлинга таба хәрәкәт итәргә әзерләр иде.

Кич белән мин туган авылны искә төшерә торган, Идел буйларын хәтерләтә торган гаҗәп матур көй ишеттем. Кемдер гармунда татар көе уйный иде. Мин ямьле авазлар ишетелгән якка ашыктым һәм бер өйгә килеп кердем. Мин килеп кергәндә, анда 20 гә якын сугышчы бар иде инде. Минем иске танышым — гвардия капитаны Ярулла Саюков та шунда иде. Ул миңа аңлатып бирде.

[1] «Алга, дошман өстенә», 9 август, 1944 ел.
[2] «Суворовчы», 30 сентябрь, 1944 ел.
[3] «Суворовчы», 16 сентябрь, 1944 ел.

[4] «Суворовчы», 13 октябрь, 1944 ел.

— Трофей итеп немец аккордеоны алган идек, — диде ул, — уйнаучы юк иде. Хәзер табылды. Миңнулла Фәттахов русча да, татарча да менә дигән итеп әйттерә!

Гвардия рядовое Фәттахов кыстатып тормады. «Кара урман», «Галиябану», «Сарман», «Сибелә чәчәк» көйләре уйналды, хәтта «Әпипә» дә калмады.

Сугышчылар да, капитан Сәюков та бик моңланып тыңладылар. Фәттахов гармунны тезләреннән алып өстәлгә куйды һәм, капитаннан рөхсәт сорап, тәмәке тарткан...
— Беләсезме, без хәзер кайда? — дип, капитан Ярулла Сәюков сугышчыларга сорау бирде.

— Сөйләгез, иптәш капитан, — диделәр сугышчылар.

— Без хәзер моннан 185 ел элек рус гаскәрләре торган немец шәһәрендә, — дип, Сәюков сөйли башлады. — Данлы рус гаскәрләре, Фридрих II гаскәрләрен тар-мар итеп, 1760 елны Берлинга кергәннәр иде. Ул елларны, рус халкының батыр уллары белән бер сафта торып, татар халкы уллары да немецларны кыйнаганнар. Менә тагын кыйныйбыз...

Капитан Сәюков беседасын сугышчылар кызыксынып тыңладылар. СССР халыкларын мәңгелек коллыкка төшерергә теләгән гитлерчыларның бүген бөтенләй җимерелү алдында торулары турында әйткәннән соң, Ярулла Сәюков үзенең сүзен болай дип тәмамлады:

— Йөрәккә ягымлы көйләрне үзебезнең җиребездә, үз авылларыбызда, үз шәһәрләребездә, үз су буйларыбызда тыңлау күңелле. Шул шатлыклы көннәрнең килүен тизләтү өчен, без тагы да остарак, тагы да батыррак сугышырга тиешбез.

Миңнулла Фәттахов яхшы сугышчы булу белән бергә, яхшы музыкант та икән. Ул Салих Сәйдәшевнең «Кызыл Армия маршы»н уйнады һәм без иртәгә булачак һөҗүм сугышлары турында уйланып урамга чыктык»[1].

«Берлин урамнарында» дигән корреспонденцияне «Кызыл Армия» газетасының махсус хәбәрчесе Гариф Галиев язган. Менә ул тарихи сәхифә:

«Берлин тетри, Берлин яна, Берлин шартлый. Безнең дәһшәтле артиллериябез аны кварталлары-кварталлары белән һавага күтәрә. Совет пехотачылары: пулеметчылар, автоматчылар һәрбер йорт, һәрбер подвал, һәрбер урам чаты өчен көрәшәләр. Дошман ярсып каршы тора. Үзенең үлемен берничә көнгә генә булса да кичектерергә, безне Берлинның үзәгенә җибәрмәскә тырыша. Ләкин Сталинград урамнарында чыныккан совет сугышчылары Берлин урамнарында да ничек хәрәкәт итәргә кирәклекне бик яхшы беләләр.

Менә пехота, йорттан йортка күчеп, алга үтә. Арттан кинәт немецлар ут ачтылар. Ләкин взвод командиры сержант Зәки Мөфаззалов, бу хәлнең булуын истә тотып, бер төркем автоматчыларны йорт стенасы кырыенда калдырып киткән була. Автоматчылар, немецларның кайсы тәрәзәдән атуларын күреп алалар да йорт эченә гранаталар ыргыталар һәм, яңгыр суы ага торган трубалар буенча балконнарга менеп, автоматлардан сиптерә башлыйлар. Эчке яктан немецларны бүтән автоматчылар кысрыклый, тыштан Мөфаззалов сугышчылары ут яудыралар. Менә икенче кат тәрәзәсендә берничә немец күренә — алар кулларын күтәргәннәр. Мөфаззалов аларга сикерергә ишарә итә. Немецлар тротуарга лап-лоп сикерә башлыйлар. Бер автоматчы аларны тезә һәм тылга озата.

Менә без минометчы лейтенант Кәшшаф Хәйретдинов батареясының ут позициясендә. Минометчылар алдына дошманның 300 метр гына ераклыкта булган пулемет ноктасын бастыру бурычы куелган.

— Берлинга 501 нче минаны атам, — ди төзәүче Гайфулла Фәтхуллин. Расчет берничә мина җибәрү белән, дошманның ут ноктасын җимерә. Шул арада ут позициясенә, ящик-ящик миналар тавына дошман снаряды төшеп ярыла. Рядовой Нигъмәтҗан Нишанов, бу хәлне күреп алу белән, окоптан атылып чыга да мина ящикларын яшен тизлеге белән таратып ташлый.

Расчет яңа бурыч биргәнне көтә. Төзәүче коммунист Фәтхуллин вакытны бушка уздырмый. Батарея командирыннан рөхсәт алып, сугышчыларны бер подвалга җыя һәм Нишановның әле яңа гына урам сугышында күрсәткән батырлыгы турында беседа башлап җибәрә.

Нишановның бүген көндез Берлин урамында күрсәткән батырлыгы кичкырын батареяның барлык сугышчыларына барып ирешә.

Батарея командиры лейтенант Хәйретдиновның яңадан командасы яңгырый. Минометчылар, дәррәү подвалдан чыгып, яңа ут позициясенә — иске бер каберлек эченә күчәләр һәм шундук Берлин урамнарындагы дошман автоматчыларына ут ачалар.

Алда, кара төтен эчендә, җимерек квартал араларыннан йөгерә-йөгерә качып баручы немец солдатларының шәүләләре күренә. Як-якта безнең артиллерия, безнең минометлар үкерә: Берлин урамнарында җирләр актарыла, биналар җимерелә, завод морҗалары ава, тимер юл рельслары бөгәрләнеп һавага күтәрелә. Берлин тетри, Берлин үзе кабызган сугыш утында үзе яна»[2].

Әйе, барлык совет халыкларының уллары бердәм булып дошманны өнендә кыйнадылар һәм җиңеп чыктылар.

«Менә ул рейхстаг...— дип яза Берлинны алуда катнашкан гвардия лейтенанты Зәкәрия Әхмеров, — козгыннар оясының үзәге. Явыз башкисәрләр шуннан торып, бөтен җир шарын коллыкка төшерү планнарын корганнар.

---

[1] «Кызыл Армия», 1 март, 1945 ел.

[2] «Кызыл Армия», 1 май, 1945 ел.

Ул хәзер җимерек. Түбәсе ишелеп төшкән. Аның янып, каралып беткән ташларыннан сасы ис аңкып тора.

Рейхстагның стеналарын безнең сугышчылар язып тутырганнар. Әле хәзер дә килеп, үзләренең фамилияләрен куеп китәләр. Әнә, Ленинград егете, ахры, «Мы с Ленинграда», — дип язып ята. Өч орденлы яшь офицер, югарыга ук менеп, нәрсәдер яза.

«Без дә Берлинда. Бәхет һәм ирек өчен Россиядә үк корбан булган иптәшләрне дә ихтирам белән искә алыйк! Бу язу минем сугышчан дусларым Әминев һәм Гаязовка һәйкәл булсын.

Кече лейтенант Алексашкин.»

Без, өч иптәш, тырышып-тырышып язган кече лейтенант янына бардык. Әминев һәм Гаязовның кемнәр булуы белән кызыксындык. Ул озак көттермәде. Кесәсеннән папирос чыгарып кабызды да, сөйли башлады.

— Мин Мотыйгулла Әминев белән Орел-Курск дугасында барган каты сугышларда дуслаштым. Әминев ул чакта станоклы пулемет расчетының командиры, ә мин аның наводчигы идем...

1943 елның 15 декабрендә, Жлобин шәһәре өчен барган каты көрәшләрдә, Әминев буш калган пулеметка барып ятты һәм ата башлады.

Сугыш тынганда Әминевнең батырлыгы турында бөтен полк белә иде инде: ул бер ялгызы дошманның биш контратакасын кире какты. Ләкин мин аны исән килеш артык очрата алмадым инде. Әминев, куллары белән пулеметны кысып тоткан килеш, кан эчендә ята иде.

— Әминев кебек иптәшләрдән аерылуы авыр, — диде Алексашкин һәм күзләренә йөгергән яшьләрен сөртеп куйды.

Шуннан соң без, Алексашкинның кулын кысып, рейхстагның җимерек стеналарыннан чыгып киттек»[1].

Җимерелгән рейхстагны күрү бәхетенә ирешкән хәрби журналист Шәрәф Мөдәррис «Рейхстаг стенасы» исемле мәкаләсендә: «Рейхстаг стеналарында рус исеме белән янәшә үк үзеңә кечкенәдән таныш булган татар исемен дә очратасың. Алар гаять күп, саный китсәң очына чыга алмассың», — дип язган.

Сугышта җиңеп чыгу совет халкына тыныч көннәр алып килде. Әмма татар язучылары, хәрби журналистлар өчен тагын да кызу эш башлана. Фронт газеталарын чыгару дәвам итә. Язучылар, журналистлар Бөек Ватан сугышы батырларын эзләп табып, аларның тарихи истәлекләрен язып алуны үзләренең иң зур бурычлары итеп саныйлар. Алар 1945—46 елларда да газета битләрендә баһадирлар турында меңләгән очерклар, мәкаләләр язып калдыралар. Халкыбыз хәрби язучыларның һәм журналистларның зур патриотизм һәм иҗади хезмәтләре белән горурлана.

[1] «Кызыл Армия», 6 декабрь, 1945 ел.

## БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЧОРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЧЫККАН ГАЗЕТАЛАР, АЛАРДА ЭШЛӘГӘН ЯЗУЧЫЛАР ҺӘМ ЖУРНАЛИСТЛАР:

**«Ватан өчен».** 1942 елның 10 июлендә Төньяк-Көнбатыш фронтында чыга башлый. Газета хезмәткәрләре: Х. Госман, А. Әхмәдиев, Ш. Мөдәррис, А. Салаев, Г. Насрый. 1944 елның 24 февраленнән Икенче Белоруссия фронтына күчерелә. Шушы ук редакциядә татар телендә **«Фронт хакыйкате»**, **«Җиңү байрагы»** газеталары да чыгарыла.

**«Алга, дошман өстенә»** — Калинин фронты газетасы. Газета хезмәткәрләре: М. Гыймадиев, Ш. Маннур, А. Шамов, А. Әхмәт, К. Әхмеров, Колмөхәммәтов. 1943 елның 20 октябрендә Беренче Балтик буе фронтына күчерелә.

**«Ватан намусы өчен»** — Воронеж фронты газетасы. Газета хезмәткәрләре: Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Г. Хуҗи, М. Садри, З. Шаһиморатов, Г. Бакиров, А. Ямангулов, Г. Шәрипов, Ә. Юныс. Соңрак бу газета Беренче Украина фронтына күчерелә.

**«Ватанны саклауда»** — Ленинград фронты газетасы. Газета хезмәткәрләре: З. Исхак, И. Әргәнәев, К. Юлдашев, И. Сәйфетдинов.

**«Суворовчы»** — Икенче Балтик буе фронты газетасы. Газета хезмәткәрләре: М. Шәймәрданов, Р. Баһау, И. Гурьев, Л. Хәлфиева һ. б.

**«Кызыл сугышчы»** — 1943 елның гыйнвареннан Мәскәү хәрби округында чыга башлый. 1944 елның октябрендә Беренче Белоруссия фронтына бирелә һәм **«Кызыл Армия»** исемендә чыга. Газета хезмәткәрләре: Я. Ярмәкиев, М. Максуд, Г. Галиев, М. Садри, И. Гази.

**«Фронт хакыйкате»** — Волхов фронты газетасы. Газета хезмәткәрләре: Г. Хәбиб, Ә. Фәйзи һ. б.

**«Ватан өчен сугышка»** — Карелия фронты газетасы. Газета хезмәткәрләре: Б. Корбанов, Г. Хәбиб[2], Г. Әпсәләмов, М. Җамалиев, М. Савельев, Г. Габидуллин, К. Иманкулов, А. Герасимов.

**«Совет сугышчысы»** — Өченче Украина фронты газетасы. Газета хезмәткәрләре: М. Максуд, М. Кәрим, Г. Әхметшин, А. Әсәдуллин, В. Вәлиев.

**«Сталин байрагы»** — Көньяк һәм Дүртенче Украина фронтлары газетасы. Газета хезмәткәрләре: Г. Клеблиев, И. Гази, Ә. Фәйзи, К. Хисмәтуллин.

[2] Кайбер язучылар һәм журналистлар вакытлыча төрле редакцияләрдә эшлиләр, шуңлыктан аларның исемнәре төрле газеталарда күрсәтелә.

oooooooooooooo

## Тәлгат Насыйров

# ВАТАН СУГЫШЫ ҺӘМ КИТАП

Фашист Германиясе гаскәрләре басып кергәч, илебезнең барлык эшләре хәрби шартларга җайлаштырып корылды. «Барысы да фронт өчен! Барысы да җиңү өчен!» — көн үзәгенә әнә шул бурычны куйды партия.

Китап бастыручылар да совет халкын дошманга отпор бирергә туплау юнәлешендә эш итәргә тиеш иделәр. Әмма моны үтәү җиңелдән түгел иде. Чөнки күп кенә нәшриятлар һәм полиграфия предприятиеләре гитлерчылар басып алган районнарда калган. Хезмәткәрләрнең сугышка ярардайлары фронтка киткән. Ә алар урынына калган хатын-кызлар, яшүсмерләр һәм пенсионерларның бу эштә тәҗрибәсе җитәрлек түгел. Кәгазь, китап төпләү өчен кирәк булган тукыма һәм башка төр материаллар белән тәэмин итү мәсьәләсе дә кыен хәл ителә. Шуның өстенә тагын китап язучы авторларның да күбесе фронтта булганлыктан, бастыру өчен яхшы яңа әсәрләр кытлыгы да сизелми калмады.

Санап үтелгәннәр тулысынча безнең Татар дәүләт нәшриятына да кагыла иде, әлбәттә. Директор Ш. Арсланов, сектор мөдирләре К. Шәйхетдинов, Т. Әхмәдиев, редакторлар Фатих Кәрим, Нур Баян, К. Басыйров, Х. Гафаров, художник Г. Мусин, актив авторлардан Муса Җәлил, Гадел Кутуй, Абдулла Алиш, Рахман Ильяс һ. б. сугышка киткәннәр иде.

Нәшрият басма продукциянең тематикасын тиз арада сугыш таләпләрен тәэмин итүгә — халыкны дошманга нәфрәт, җиңүгә дәрт рухында тәрбияләү максатына кискен юнәлтте. Ул елларда нәшриятта М. Мангушев, М. Гайнуллин, З. Тинчурин (управляющийлар), Ф. Махиянов (баш редактор), А. Хәсәнова, Г. Кашшаф, И. Гази, А. Шамов, Х. Хәйри, А. Гомәров (өлкән редакторлар), Б. Әлменов (художник), С. Фәйзуллин, Г. Нугайбеков (тәрҗемәчеләр) иптәшләр эшләде.

Сугыш авырлыгы басма продукциянең кимүенә дә сәбәп булды. Татар дәүләт нәшрияты 1940 елда гомуми тиражы 6 миллион данәдән артык булган 402 исемдәге китап һәм брошюра бастырып чыгарган булса, 1945 елда ул гомуми тиражы 3,6 миллион данә булган 208 исемдәге китап һәм брошюра гына бастыра. Әмма ул еллар өчен бу һич тә аз түгел. Моны түбәндәге сан бик яхшы исбатлый: сугыш елларында Казанда гомуми тиражлары 24 828 160 данә тәшкил иткән 1741 китап һәм брошюра басылып чыккан.

Алар нindирәк китап һәм брошюралар иде соң? Әлбәттә, күпчелеге, ягъни 670 исемдәгесе, иҗтимагый-политик һәм хәрби-политик әдәбият була. Аларның гомуми тиражы 10 миллионнан артыграк.

Фәнни коммунизмга нигез салучыларның герман нацизмының асылын ачып бирүгә багышланган әсәрләрен, партия Үзәк Комитеты каршындагы Марксизм-ленинизм институты әзерләгән аерым әсәрләр һәм җыентыкларны татарчага тәрҗемә итеп бастыруга да зур әһәмият бирелде. Мисалга «Маркс һәм Энгельс реакцион пруссак-

лык турында» («Маркс и Энгельс о реакционном пруссачестве») дигән җыентыкны китерергә була (Х. Кәрим тәрҗемәсе). В. И. Ленинның сугыш һәм Ватанны саклау проблемаларына багышланган әсәрләреннән 1941 елда ук «Барыгыз да Деникинга каршы көрәшкә!» («Все на борьбу против Деникина!») һәм «Социалистик Ватанны саклау өчен!» («На защиту социалистического Отечества!») исемле хезмәтләре тәрҗемә ителә. Шулай ук татар телендә академик М. Митинның «В. И. Ленинның хәрби васыятьләре» («Военные заветы В. И. Ленина») һәм П. Федосеевның «Социалистик Ватанны саклау турында В. И. Ленин» («В. И. Ленин о защите социалистического Отечества») исемле брошюралары унар мең тираж белән халкыбызга җиткерелде.

Фашистлар партиясе һәм аның җитәкчеләренең реакцион йөзен фаш итүгә, вакытлыча басып алынган җирләрдә гитлерчылар кылган җинаятьләр һәм кыргыйлыкларны күрсәтүгә багышланган материаллар шулай ук күп була. 1942 елда, мәсәлән, шундыйлардан: «Миллә̄тче-социалистлар» кемнәр алар?» («Кто такие «национал-социалисты?»), «Гитлер, Геринг, Геббельс, Гиммлер — XX гасыр кеше ашаучылары» («Гитлер, Геринг, Геббельс, Гиммлер — людоеды XX века»), «Фашизм — совет халкының явыз дошманы» («Фашизм — заклятый враг советского народа»), «Гитлерчылар безгә кайгы-хәсрәт, азап һәм үлем алып киләләр» («Гитлеровцы несут нам горе, страдания и смерть») исемле китап һәм брошюралар күп тираж белән татар һәм рус телләрендә чыгарылган. И. Эренбургның «Кеше ашаучылар» («Людоеды»), Е. Кононенконың «Балаларны үтерүчеләргә — үлем!» («Убийцам детей — смерть!»), В. Горбатовның «Майданек лагере» («Лагерь Майданека») исемле документаль очерклары, «Фашизмга үлем!» («Смерть фашизму »), «Канга-кан» («Кровь за кровь») исемле пьесалар җыентыклары да шул ук проблеманы яктыртуга багышланган.

Кызыл Армиянең фронтлардагы җиңүләрен, Мәскәү тирәсендәге, Иделдәге, Днепрдагы сугышларны сурәтләгән әсәрләрне вакытында укучыларга ирештереп баруга зур игътибар ителә. «Ватан сугышы Геройлары» дип аталган масса-политик сериядә Н. Гастелло, В. Талалихин, З. Космодемьянская, Л. Чайкина, панфиловчы геройлар һәм Краснодон комсомолецларының батырлыклары турында брошюралар даими бастырып барыла. «Коммунистлар — фронт геройлары» («Коммунисты — герои фронта»), «Совет партизаннарының героик көрәше» («Героическая борьба советских партизан»), «Патриоткалар, Совет хатын-кызлары фронтта һәм тылда» дигән китапларда (1942 елда чыкканнар) совет кешеләренең батырлыгына дан җырлана. Әле сугыш бетмәс борын ук рус һәм татар телләрендә «Геройлар китабы»н (төзүчесе Кави Нәҗми) бастырып чыгару шулай ук нәшриятның оператив һәм актив эшчәнлеге турында сөйли.

Совет кешеләренең рус халкының героик үткәненә, аның хәрби тарихына игътибары артуын искә алып, илебез нәшриятлары, шул исәптән безнең Татар дәүләт нәшрияты да, Александр Невский, Дмитрий Донской, Дмитрий Пожарский, Козьма Минин, Александр Суворов, Михаил Кутузов, Павел Нахимов кебек бөек полководецлар турындагы популяр брошюралар чыгаруны оештырдылар. Аларны күренекле галимнәр һәм әдипләр язды. Кутузов һәм Нахимов турындагы брошюраларны, мәсәлән, ул елларда Казанда яшәгән академик Е. В. Тарле яза.

Тылдагы героик хезмәт кешеләрен сурәтләгән китаплар шулай ук оператив төстә чыгарылалар. А. Воробьевның «Өч норма» («Три нормы») исемле китабы (1942 ел) — шундыйларның берсе. Ул социалистик ярышның Ватан сугышы елларында туган яңа формасы — өчйөзчеләр хәрәкәте турында сөйли.

Сугыш елларында нәшрият гомуми тиражы миллион ярымнан артыграк булган 220 исемдә матур әдәбият китабы бастырып чыгара (бу санга балалар китаплары кермәде). Аларның күпчелеге заман темасына багышланган булалар, авторлары исә — дошманга каршы сугышларда үзләре катнашкан, яисә фронт газеталарында корреспондент булып хезмәт иткән әдипләр.

Вакыйгаларны көнендә, сәгатендә чагылдырып барырга кирәк булганга,

сугыш еллары китапларында кече күләмле әсәрләр: шигырьләр, хикәяләр һәм сатирик әйберләр күбрәк урын алып тора.

Әдипләребез бөтенесе бер теләк белән илһамланып халык күңелендә патриотизм хисен көчләрәк дөрләтү, ватандашларны сугышта һәм хезмәттә батырлыкка рухландыру өчен иҗат итә.

Иң популяр әдәби жанр — әлбәттә, очерк жанры була. Ә нәшрият исә ул очеркларга «яшел ут»ын яктыртып торды һәм Г. Бәшировның «Үч», «Гармунчы егет», А. Шамовның «Нәфрәт көче», М. Максудның «Үч һәм нәгъләт», А. Әхмәтнең «Безнең танк», Г. Әпсәләмовның «Төньяк балкышы» исемле очерклар һәм хикәяләр җыентыкларын бастырып чыгарды. Шул ук елларда чыгарылган шигырь китапларыннан М. Җәлилнең «Тупчы анты», Ф. Хөснинең «Урман сукмаклары», Ш. Маннурның «Җиңүчеләргә сәлам!», С. Батталның «Туган ил — ана» һ. б. әйтергә мөмкин. Бик үк күп булмаса да, зуррак күләмле проза әсәрләре дә язылды. Ф. Кәримнең «Разведчик язмалары», Х. Госманның «Ялкынлы йөрәк», Г. Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» дөнья күрде. 1945 елда Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы, А. Алиш әкиятләре рус телендә чыгарыла.

Сугышчылар белән тыл хезмәтчәннәренең элемтәсен ныгытуны күздә тотып язылган «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хаты» (1943) һәм «Икенче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хат» (1945) ларны да нәшрият рус һәм татар телләрендә аерым китаплар итеп бастырып чыгарды. Каләм осталарыбызның уртак иҗат җимеше булган ул хатларның һәм сугышчыларга, һәм тылда хезмәт итүчеләргә патриотик тәэсире чиксез зур иде. Алар җиңү көнен якынайтуга хезмәт иттеләр.

Ул елларда аерым академик басмаларны чыгару да тукталмады. 1942 елда нәшрият Г. Камал һәм Ш. Камалның сайланма әсәрләрен бастырып чыгарды. 1943 елда тугыз мең данә тираж белән рус телендә Г. Тукайның сайланма әсәрләренең беренче томы, ә 1945 елда, тууына 120 ел тулу уңае белән, К. Насыйриның сайланма әсәрләре басылды.

Нәшриятыбыз шулай ук тугандаш халыклар әдипләренең әсәрләрен бастырып барырга да мөмкинлек тапты. И. Крылов мәсәлләрен, Н. Гогольнең «Ревизор»ын, В. Василевскаяның «Винтовкалы хатын»ын, Б. Горбатовның «Буйсынмас кешеләр»ен һәм Украина шагыйрьләреннән ун кешенең шигырьләре тупланган (М. Рыльский, П. Тычина, М. Бажан, В. Сосюра, М. Стельмах, А. Малышко һ. б.) «Украина үч ала» исемле китапларны бастырып чыгарды.

Нәшрият мәктәп балаларын дәреслекләр белән мөмкин кадәр тулы тәэмин итү өчен дә бөтенесен эшләде. Нәтиҗәдә ул елларда гомуми тиражы 6 076 750 данә булган 243 исемдәге дәреслек басылып чыкты.

Фәнни-техник әдәбият бастыру исә сугыш елларында бик нык артты. Беренче бишьеллыкларда (1929—1940) Казанда 2 263 340 данә фәнни-техник китап басылган булса, 1941—1945 елларда басылган фәнни-техник китаплар саны 2 465 280 данә тәшкил итте. Моның сәбәбе шул: СССР Фәннәр академиясе нәшрияты ул елларда үзәктән Казанга эвакуацияләнгән иде.

Сугыш елларында бездә 700 000 данә тираж белән чыккан 161 исемдәге китап һәм брошюра авыл хуҗалыгы темасына — агротехника, терлекчелек, бакчачылык, корткычларга каршы көрәш, мөгезле эре терлекләрне тарту көче итеп файдалану кебек җитди мәсьәләләрне яктыртуга багышланганнар иде.

Сугыш еллары республикабызның башкаласы Казанны китап басуның чын мәгънәсендә зур үзәге итте. 1941 елның көзендә Казанга Мәскәүдән һәм Ленинградтан үзәк нәшриятлар: СССР Фәннәр академиясе, Хәрби (Воениздат), Медицина (Медиздат) һәм «Совет язучысы» («Советский писатель») нәшриятлары да эвакуацияләнгән иде. Илебезнең йөзгә якын зур галимнәре дә гыйльми эшләрен шул чорда Казанда дәвам иттерделәр. Алар арасында, мәсәлән, СССР Фәннәр академиясе академиклары һәм член-корреспондентлары О. Ю. Шмидт, Г. М. Кржижановский, С. И. Вавилов, Е. В. Тарле, Б. Д. Греков, А. Н. Несмеянов һ. б. бар иде.

Күренекле совет һәм чит ил язучылары Алексей Толстой, Демьян Бедный, Александр Фадеев, Константин Федин, Самуил Маршак, Леонид Леонов, Жан Ришар Блок, Джованни Джерманетто һ. б.лар да сугышның беренче елларында безнең республикабызда эвакуациядә булдылар.

Безнең нәшрият үзәк нәшрият хезмәткәрләре белән тыгыз элемтәдә булды һәм китаплар тематикасын билгеләгәндә күренекле авторларның практик ярдәменнән файдаланырга тырышты. Хәрби нәшрият һәм Татар дәүләт нәшрияты күп кенә китапларны бергәләп чыгардылар. 1941 елда «Кызылармеец китапханәсе» дип аталган махсус сериядә, мәсәлән, совет сугышчыларын җиңүгә рухландыруны күздә тотып язылган популяр брошюралар чыгару юлга салынды. М. Шолоховның «Нәфрәт гыйлеме» дигән атаклы очеркы 1942 елда шул сериянең беренче карлыгачы була. Ике нәшрият бергә дошман танкларына каршы ничек көрәшергә икәнен, маскировка чараларын, пулемет һәм граната төзелешен аңлаткан төрле белешмә-брошюраларны да бик күп бастыралар.

«Совет язучысы» нәшрияты да Казанда шулай ук күп кенә әдәби әсәрләр бастырды. 1942 елда гына да Б. Горбатовның «Иптәшкә хат», С. Алымовның «Барысы да җиңү өчен!», С. Щипачевның «Фронт шигырьләре», П. Антокольскийның «Ярты ел», М. Матусовскийның «Фронт», В. Вишневскийның «Балтфлот сугыша», А. Гайдарның «Ракеталар һәм гранаталар» исемле китапларын һәм татар шагыйрьләренең «Фронтовик туганнарга» исемле шигырьләр җыентыгын унар-кырыгар мең данә тираж белән укучыларга җиткерде.

Фронттагы һәм тылдагы мөһим хәлләрне тиз арада халыкка ирештерүдә политик һәм хәрби плакатларның да әһәмияте зур булды. Шуны искә алып, сугышның тик бер елы эчендә генә дә Татар дәүләт нәшрияты биш йөз меңнән артык данә плакат бастырып таратты. Ә сугыш елларында барлыгы йөз җитмеш төрле плакат чыгарылды. И. Бобровицкий, Н. Сокольский, Б. Әлменов, Р. Сәйфуллин, Э. Гельмс, А. Прытков һ. б. художниклар эшләгән бу плакатлар сугыш елларында халык күңеленә бик хуш килүләре белән популяр булдылар.

# УЙЛАНУЛАР, БОРЧЫЛУЛАР

Соңгы елларда язучылар тарафыннан язылган тәнкыйть китаплары күбәеп бара. Күптән түгел генә С. Хәкимнең «Үз тавышың белән», М. Әмирнең «Үзебез турында», Г. Ахуновның «Әдәби язмышлар» исемле җыентыклары басылып чыккан иде. Хәзер бу исемлеккә тагын бер китап өстәлде. Сүз Гомәр Бәшировның «Бүген дә, иртәгә дә» дигән мәкаләләр җыентыгы[1] турында бара.

Җыентыкка күренекле әдипнең төрле елларда язылган публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре, истәлекләре тупланган. Жанрларына, характерларына карап, автор аларны аерым-аерым бүлекләргә бүлеп урнаштырган. Беренче бүлекнең үзәгендә иҗтимагый мәсьәләләргә караган төрле характердагы мәкаләләр тора. Аларның иң зур күпчелеге публицистик рухта язылган.

Язучыны башлыча татар халкының тарихи язмышы, рухи сыйфатлары, борынгыдан килгән гореф-гадәтләре һәм милли бәйрәмнәре кызыксындыра. «Нинди ул — Татарстан?» исемле мәкаләдә автор туган якның сокландыргыч табигате, урман-кырлары, болын-сулары хакында горурланып сөйли. Әдип Татарстанның төрле якларында булган, ул күп кенә районнарның табигатенә, көнкүрешенә хас үзенчәлекләрне яхшы белә. Үз халкының тыйнак холкы, киң күңеллелеге, юмартлыгы, ул тәрбияләгән уннарча ил батырлары да әдип игътибарыннан читтә калмый, билгеле...

Китапка язган кереш сүзендә автор: «Биредә урын алган мәкаләләр арасында нәрсәнедер кайгыртып, укучы белән борчуны уртаклашу, бергәләшеп чарасын күрү өчен җәмәгать фикере туплау нияте белән язылганнары да очрар,— дип искәртеп үтә.— Ләкин күңел әле бөтенләй үк тыныч түгел: мин аларны укучыны да уйландырырлык, анда теләктәшлек фикере уятырлык итеп яза алдыммы икән соң?» (3—4 битләр).

Әгәр җыентыктагы мәкаләләрнең «Нинди ул — Татарстан?» дигән беренчесе гомуми кереш вазифасын башкарса, «Гореф-гадәт законнан өлкәнрәк» дигән икенче мәкалә нәкъ менә, автор үзе әйткәнчә, «җәмәгать фикере туплау нияте белән» язылган. Автор сүзне халыкның күркәм традицияләреннән, гореф-гадәтләреннән башлый. Борынгыдан калган матур традицияләр акрынлап төрле үзгәрешләр кичерәләр, заманалар үзгәрү белән аларның кайберсе халыкның көндәлек тормышыннан төшеп кала, онытылалар. Алар урынына матур-матур яңа гореф-гадәтләр, традицияләр барлыкка килә. Татар халкының элеккедән килгән милли бәйрәме — сабан туе әнә шул рәвешчә безнең көннәрдә төрле халыклар арасында таралып, интернациональ төс алды.

Гасырлар буе халык арасында зур тантана буларак уздырылган бу бәйрәмгә язучы махсус мәкалә дә багышлый. «Сабан туе» дип исемләнгән ул мәкаләдә авторны әлеге бәйрәмнең төп үзенчәлекләре, халыкның «эшчәнлек, тырышчанлык, тормыш сөючәнлек кебек күркәм сыйфатларыннан табигый рәвештә килеп тууы» һәм совет чорында беркадәр яңаруы, заманча яңгыраш алуы кызыксындыра...

Туган авыл һәм туган шәһәр табигате, аның гүзәллеген, матурлыгын саклау... «Исраф», «Авыллар ямьле булсын», «Әйдәгез, уйлап карыйк!» кебек мәкаләләрдә сүз әнә шул хакта бара. Бөтенләй башка мәсьәләгә багышланган «Гөлҗамал» да, нигәдер, шушы ук бүлектә, әле генә күрсәтелгән мәкаләләр белән рәттән урын алган. Темасы, эчтәлеге ягыннан ул беренче

[1] Г. Бәширов. Бүген дә, иртәгә дә. Әдәби тәнкыйть, публицистика, истәлекләр. Казан. 1974 ел.

бүлеккә «сыймый», әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә багышланган алдагы бүлеккә керергә тиеш иде.

Моннан берничә ел элек Гомәр Бәшировның «Уйланулар» дигән язмасы басылып чыккан иде («Казан утлары». 1972 ел. 4 сан). Шул ук мәкалә тикшерелә торган җыентыкта да урын алган. Хәтта китапның икенче бүлеге үзе үк шул исем белән аталган. Биредә төп урын әдәби тәнкыйть мәкаләләренә бирелгән. һәм аларның байтагы истәлек рухы белән сугарылган.

Язучы халык иҗатына, әкият-мәзәкләргә, җыр-бәетләргә, мәкаль-әйтемнәргә зур ихтирам белән карый, аларны язучылар, сәнгать әһелләре өчен илһам чыганагы дип исәпли. Бу аңлашыла да, чөнки Г. Бәширов — күп еллар буе халык иҗаты әсәрләрен, бигрәк тә әкиятләр белән мәзәкләрне җыюда һәм бастырып чыгаруда турыдан-туры катнашып килгән кеше. Моннан нәкъ 35 ел элек аның үзе язып алган әсәрләрдән торган беренче фольклор җыентыгы — «Халык әкиятләре» басылып чыккан иде (Казан. 1940 ел). Бу әһәмиятле эшен әдип алга таба да дәвам иттереп килә. Ул «Татар халык иҗаты» антологиясен (1951 һәм 1954 еллар), «Татар халык әкиятләре»нең ике китабын (1946 һәм 1958 еллар) төзүдә актив катнаша. Алтмышынчы еллар башында басылып чыккан «Туксан тугыз мәзәк» (1960 ел) һәм «Мең дә бер мәзәк» (1963 ел) китапларын күпләр беләдер. Якын арада Мәскәүнең «Наука» нәшриятында татар халык мәзәкләреннән торган «Веселая россыпь» дигән җыентык басылып чыгарга тиеш. Аларның барысы да Г. Бәширов язып алган мәзәкләрдән төзелгән.

Язучы халык иҗатын фәнни өйрәнү турында да даими кайгыртучанлык күрсәтеп килә. Әле генә саналган җыентыкларның кайберсендә һәм газета-журнал битләрендә ул халык иҗатына багышланган мәкаләләр белән чыкты. Аларның иң уңышлылары без тикшерә торган җыентыкта да урын алган. Мәсәлән, «Халыкныкы халыкка» дигән мәкаләдә сүз мәзәкләр турында бара. Аларның иҗат ителү процессын, халык телендә яшәү шартларын, шигъри үзенчәлекләрен һәм тәрбияви ролен язучы яхшы аңлый. Мәкаләнең әһәмиятле ягы шунда, ул әлегә кадәр фольклор белгечләре тарафыннан рәтләп өйрәнелмәгән жанрга багышланган. Автор кайбер теоретик мәсьәләләргә дә ачыклык кертә. Әйтик, мәкаләнең мәзәкләр белән әкиятләрнең аермасын тикшерүгә багышланган урыннары аеруча матур тәэсир калдыра.

Халык әкиятләренә һәм әкиятчеләргә багышлап, автор моңа кадәр дә берничә мәкалә бастырган иде. Китапта урнаштырылган «Тылсымнар дөньясында» дигән мәкаләне элегрәк басылганнарының үзенчәлекле сөземтәсе дип әйтергә мөмкин. Әкиятләрнең төрләре, әдәби үзенчәлекләре, тарихи үсеш этапларына карата биредә әһәмиятле фикерләр әйтелә. Кайбер мәсьәләләргә автор яңача, үзенчә килә. Мисалга, безнең фольклор фәнендә әкиятчеләр һәм аларның репертуарына хас үзенчәлекләр бик аз өйрәнелгән. Г. Бәширов, бу өлкәдә беренче буларак, М. Хәмидуллин, М. Дәүләтшин, Х. Хөсәенов кебек оста һәм бай репертуарга ия әкиятчеләр турында ярыйсы ук киң мәгълүмат бирә.

Шул ук мәкаләдә ачыктыртылган икенче бер мәсьәләгә дә тукталып үтәсе килә. 50—60 елларда совет чоры халык иҗаты хакында киеренке генә бәхәсләр булып узган иде. Сөйләшүләр дәвамында әкиятләр турында да төрле фикерләр әйтелде. Билгеле булганча, XX йөздә әкиятләргә социалистик чынбарлык белән бәйләнгән яңа күренешләр, детальләр килеп керә. Кайбер белгечләр фикеренчә, мондый яңалыклар борынгы әкиятләрнең рухына, стиленә ятышмый. Янәсе, алар борынгы төр халык иҗатының әдәби тукымасын җимерәләр, әкиятләрнең сәнгать әсәре буларак дәрәҗәсен төшерәләр.

Мондый яңа детальләр турында Г. Бәширов та яза: «Дәүләтшин әкиятләрендә геройларның батырлыклары турында «зур гәҗитләргә басалар», кешеләр яши торган урыннардан еракта, караңгы урманнарда торучылар да берсен-берсе «гәҗитләрдә» басылган хәбәрләр аша табып килүләр. Дию пәрие, алтын алма урларга барган җирендә яраланып кайтканнан соң, дәвалану өчен «фиршелгә» китә (106—107 битләр). Ләкин әлеге күренешләргә язучы бөтенләй икенче яктан килә һәм үзенчә аңлата: «Бу мисаллар безгә хәзерге чынбарлыкның халык күңеленә, халык тормышына никадәр тирән кереп урнашуын күрсәтә» (107 бит).

Халык иҗаты турындагы мәкаләләрдән югарыда телгә алынган «Гөлҗамал»га карата да берничә сүз әйтеп китәргә кирәк. Иң элек автор җырның гасырларны берләштергән тирәнлеген һәм киңлеген билгеләп үтә, сүз уңаеннан моң турында кызыклы фикерләр әйтә. Беренче карашка,

биредә сүз тик бер җыр турында гына бара кебек. Әмма мәкаләнең гомуми эчтәлеге аннан киңрәк. Язучы гаять мөһим бер мәсьәлә күтәрә: «Менә беләсе иде бит: моннан йөз, ике йөз, өч йөз яки дүрт-биш йөз ел элгәре шул өйләрдә (ягъни, безнең борынгы бабаларыбыз яшәгән өйләрдә — У. Ф.) нинди «җырулар» җырлаганнар, ничек биегәннәр, ул вакытта нинди уен кораллары булган? Ислам дине кергәнче, ягъни мәҗүсилек чорында, халыкның музыкасы нинди булган? Бөек Болгар дәүләтендә нинди җырлар җырлаганнар?» (39 бит)... Әйе, язучы, һичшиксез, хаклы. Соңгы елларда халык җырларының тарихы буенча әһәмиятле эзләнүләр алып барылса да, бу мәсьәләгә карата монографик хезмәтләр юк дәрәҗәсендә аз. «Гөлҗамал», «Иске кара урман», «Сибелә чәчәк» кебек аерым җырларның гына түгел, җыр жанрының тулаем тарихы да әле рәтләп өйрәнелмәгән.

Инде әйтелгәнчә, китапның икенче бүлегендәге мәкаләләрнең төп өлеше аерым әдипләргә багышланган. Менә «Үзебезнең Горький» дип исемләнгән мәкалә. Социалистик реализмга нигез салучы әдип турында меңнәрчә мәкаләләр, йөзләгән китаплар, бихисап диссертацияләр язылган. Инде шуннан соң да Горький турында нинди яңа фикер әйтергә мөмкин, дип уйлыйсың. Шуңа карамастан, Г. Бәширов мәкаләсе зур кызыксыну белән укыла. Язучы үзенчәлекле алымга мөрәҗәгать итә: гүяки ул Казанның Горький исемен хәтерләткән урамнарыннан бара һәм бөек әдип исеме белән бәйле вакыйгаларны исенә төшерә.

Г. Тукай белән Г. Ибраһимовны язучы үзенең олы остазлары дип исәпли. Аларга да аерым мәкаләләр багышлый. Язучының үз замандашларыннан М. Җәлил, Г. Кутуй, Х. Туфан, Ф. Хөсни кебек әдипләр иҗатына карата язылган мәкаләләргә дә тукталып булыр иде. Ләкин бу материаллар белән танышуны укучы ихтыярына калдырып, китапның соңгы бүлегенә күчик.

Биредә автор өч зур мәсьәлә күтәрә. Иң элек — яшь яки башлап язучылар иҗаты, ягъни әдәби алмаш тәрбияләү мәсьәләсе. «Хикәяләр һәм «К. С. б-н» дип исемләнгән мәкаләдә сүз балалар иҗаты турында бара. «Чаткыда ялкын шәүләсе»ндә автор башлап язучыларга төрле киңәшләр бирә, иҗат процессының серләре белән уртаклаша. Мондый мәкаләләр, истәлекләр, минемчә, зур әһәмияткә ия. Алар иҗат процессын, язучының теге яки бу әсәр өстендә эшләвен күзалларга ярдәм итә, әдәбият тарихын җанлы күренешләр белән баета.

Г. Бәшировны кискен тәнкыйть белән мавыгучан әдип буларак күз алдына китерүе кыен. Аның әдәби тәнкыйть репертуарында мондый материаллар бик аз. «Бер хикәя турында» — әнә шундый мәкаләләрнең сирәк үрнәге. Ул язучы Р. Шәйхетдиновның «Көтүче» исемле хикәясенә багышланган. Олы әдип хикәянең эчтәлегенә, сюжетына, төп образына туктала, яшь язучының бик күп кимчелекләрен тәнкыйтьли. Әмма мәкаләнең төп пафосы хикәянең телендәге чатаклыкларга каршы юнәлтелгән. Әлеге мәкалә бүлектә киң яктыртылган тагы бер мөһим проблемага — туган тел мәсьәләсенә күчү өчен үзенчәлекле күпер ролен үти. Әдәби тел турындагы мәкаләләрендә автор үз тәҗрибәсе белән уртаклаша, әсәрләренең телен камилләштерү өстендә ничек эшләве, төрле эзләнүләр алып баруы һәм аларның нинди нәтиҗәләр бирүе хакында яза.

Язучының тел турындагы мәкаләләре безнең көннәрдә аеруча зур әһәмияткә ия. Билгеле булганча, әдәби телнең үсеше җәмгыять тормышы белән бергә атлый. Бүгенге көндә илебездә барган зур иҗтимагый үзгәрешләр әдәби телгә дә тәэсир итми калмый. Хәзерге әдәбиятта промышленность, төзелеш, транспорт, фән белән бәйләнгән мәсьәләләр җитди урын алалар. Димәк, әдәби әсәрләрнең теле дә үзгәрергә, беркадәр яңарырга тиешле. Җыентыкта урын алган соңгы мәкаләдә язучы әнә шул актуаль мәсьәләне күтәрә: «Әгәр без шәһәр тормышын да нечкәлекләргә бай һәм сокланып укырдай, эстетик тәрбия бирердәй матур тел белән язарга җыенабыз икән, хәзерге урта һәм яшь буын язучысы шәһәрнең поэтик тел хәзинәсен өйрәнүне дә үзенең төп вазифаларыннан берсе итеп алмыйча булдыра алмый. Бар бит ул эшче халыкның һәм интеллигенциянең үзенә хас теле, төрле үзенчәлекләргә бай һәм җор теле, бар андый тел!» (170 бит.)

* * *

Күрәсез, китапта күтәрелгән мәсьәләләр ярыйсы ук киң һәм катлаулы. Димәк, андагы мәкаләләрнең рухы, гомуми яңгырашы һәм тел-стиль үзенчәлекләре дә төрлечә булырга тиеш. Әгәр безнең алда әдәби әсәр — роман, повесть яки хикәя

булса, без аның сәнгатьчә үзенчәлекләре хакында уйлана алыр идек. Ләкин әдәбиятта билгеле бер традиция урнашкан — публицистика яки әдәби тәнкыйть мәкаләләренең сәнгатьчә үзенчәлекләре турында сөйләү ничектер сәеррәк тоела. Шуңа карамастан, төрле мәкалә-рецензияләрнең әдәби үзенчәлекләрен: гомуми рухын, тонын, логик эзлеклелеген, ышандыру көчен, композициясен, телен һәм стилен өйрәнергә мөмкин һәм кирәк. Мәсьәләгә әнә шул яктан килсәк, Г. Бәширов китабының кызыклы үзенчәлекләре ачыклана. «Нинди ул — Татарстан?» дигән мәкалә, әйтелгәнчә, көчле публицистик пафос белән сугарылган. Аның теле-стиле дә үзенчәлекле. Әгәр шулай әйтеп булса, ул бәйрәмчә тантаналы стильдә язылган, одамәдхия рухында яңгырый. Мәкаләнең характеры таләп иткәнчә, автор сорау һәм өндәү җөмләләренә, ил, халык, Идел, Алып батыр кебек масштаблы образларга еш мөрәҗәгать итә...

Икенче бер төркем мәкаләләрдә уйланулар, борчылулар алгы планга чыга. Халыкның борынгыдан килгән янсә безнең заманнарда формалашкан гүзәл традицияләрен, табигатьнең матурлыгын, туган теленең гүзәллеген саклау һәм тагы да баету мәсьәләләренә карата язылган мәкаләләрдә бу аеруча ачык күренә.

Китапның кайбер битләрендә ниндидер самими моңсулык өстенлек итә. Мәсәлән, әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез күгендә якты йолдыз булып балкыган әдипләргә — Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Гадел Кутуй, Муса Җәлилләргә багышланган мәкаләләрдә. Мисал итеп Гадел Кутуй истәлегенә багышлап язылган «Гаделша» исемле мәкаләнең соңгы юлларын алыйк:

«Кызганычка каршы, ораторлык осталыгы күп кешедә булмый. Гадел Кутуйда андый сәләт бар иде. Ялкынлы речьнең аеруча кирәклеге сизелгән чакларда һәр вакыт искә Кутуй килеп төшә, ничектер үзеннән-үзе:

— Менә хәзер Кутуй булсачы! — дисең.

Татарча сөйлиме ул, русчамы, шигырь укыймы, хикәяме, Кутуй тыңлаучыларын авызына каратырлык, аларны дулкынландырырлык, шатландырырлык яки борчырлык дәрәҗәдә ялкынлы һәм үтемле итеп сөйли белә иде» (161 бит). Менә бу «иде»ләр мәкаләнең моңсулыгын көчәйтә дә инде... Гомумән, истәлекләрдә исеме телгә алынган кешеләрнең байтагын язучы үзе күргән, үзе белгән, алар белән иҗади планнарын уртаклашкан. Алар турында ул үз итеп, якын итеп сөйли.

Алдарак әйтелгәнчә, Г. Бәширов гомер буе халык иҗатына тирән ихтирам, аның әдәби мөмкинлекләренә зур ышаныч саклап килгән әдип. Аның фольклористик эшчәнлеге генә түгел, әдәби әсәрләре дә шул хакта сөйли. Хикәя-романнарында, бигрәк тә соңгы елларда язылган «Туган ягым — яшел бишек» повестенда ул халык иҗатына еш мөрәҗәгать итә. Язучының мәкаләләрендә дә халык иҗаты мотивлары киң һәм төрле формаларда кулланыла. Фикерләрне тирәнәйтү, ышандыру көчен арттыру, мәкаләне җанландырып, яңа бизәкләр белән баету — фольклор төсмерләренең төп функцияләре әнә шунда. Язучы мәкаләләрендә дастан-әкиятләрдән, риваять-легендалардан, халык җырларыннан алынган образларны, өзекләрне очратырга мөмкин. Туган як табигатен зурлаганда, мәсәлән, ул халык җырына таяна:

Һәй, Иделкәй алкын, суың салкын,
Көн дә төшеп синнән су алам;
Шәфәкъ бата, йолдызлар да калка,
Сиңа карап һаман юанам.

Мәкаләләрнең композициясе дә үзенчәлекле. Китапта без төрлечә төзелгән мәкаләләр белән очрашабыз. Аларның һәркайсына тукталып тормастан, кайбер мисалларны гына күрсәтеп үтик. «Уйланулар» мәкаләсенең тәэсир көчен арттыру өчен язучы отышлы бер алымга мөрәҗәгать итә: гүяки ул иске журнал битләрен актара. Шунда аның күз алдына үткән еллар сәхифәләре килеп баса: «Уйлана-уйлана журнал битләрен актарам... Шул саргайган битләр аша каршыма үрә басып торган кара чәчле, каратут йөзле, көләч күзле, хәрәкәтчән Фатих Кәрим килеп баса...» (130 бит).

«Тынгысыз җан» мәкаләсе бер генә эпизодка нигезләнә кебек. Сүз Фатих Хөснинең Эрмитаж бакчасында һава сулап, уйланып йөрүе турында бара. Әнә шул күренеш нигезендә язучы Фатих Хөснинең характерына һәм иҗат эшенә хас төп үзенчәлекләрне ачып сала...

Биредә җыентыктагы мәкаләләрнең башка кайбер сыйфатлары, язучының тел осталыгы һ. б. турында да сөйләп булыр иде. Соңгы сүз итеп шуны гына әйтик: «Бүген дә, иртәгә дә» китабын әдипләр һәм галимнәр генә түгел, киң катлау укучылар да дулкынланып каршы алырлар, дип уйларга кирәк.

**ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

Равил Кукушкин

# ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ОБРАЗ

Сөйләмдә анык тормыш күренешен белдергән сүз, шигъри әсәргә килеп керү белән үк, кинәт тирән һәм зур мәгънә ала, поэтик элемент булып әверелә. Бер карасаң, шул ук гап-гади сүз... ә шигырьдә ул меңләгән күңелләрне тетрәтерлек куәткә ия була. Шагыйрьнең талант көче дә, шәхесенең зурлыгы да поэтик яктан гомумиләштерелгән сүздә ачык чагыла.

Әмма әлеге шигъри информация — поэтик образлар нинди генә бөеклеккә күтәрелмәсеннәр, аларның нигезендә «сигналларның сигналы» — гади сүз ята. Шуңа күрә сүзнең гадәти һәм шигъри мәгънәсен янәшә куеп карау гына сүз сәнгатендәге поэтик сурәтнең көчен аңлауда таяныч нокта була ала.

Шагыйрьне реаль чынбарлык кай яклары һәм нинди сыйфатлары белән кызыксындыра, бу объектлар хәзерге яшьләребезнең иҗатында ничек һәм ни рәвешле чагылалар соң? Безнеңчә, художестволы тасвирларда һәр объектны өч төрле формада күрсәтергә мөмкин.

Беренче юл — объектны телдә гомумиләшкән үзлеге аша тасвирлау. Мәсәлән, без «таң» дибез икән, безнең күз алдыбызга ул үзенең иң гомуми сыйфатлары белән килеп басачак. Бу төрдәге тасвирда объект турыдан-туры атап әйтелә:

**Җирдә күп кешене сөям**
**һәм шулай ук**
**Мин күпләрне сөймим.**
**Ләкин дөресен сөйлим:**
**Мин берәүне — мине сөймәгәнгә сөям**
**һәм берәүне — сөйгән өчен сөймим.**

(Р. Гатауллин.)

Атап әйтелгән әнә шундый «сөям», «сөймим», «сөйлим», «күпләр», «берәү» кебек абстракт төшенчәләрне без, һичшиксез, тоеп күзаллаудан бигрәк, аңыбыз аша үткәреп аңлыйбыз. Сүзләрнең туры мәгънәләрендә килүе бу төр тасвирны гадәти төшенчәле фикерләүгә якынайта. Шуңа да аның гадәттә лирик белдерүгә корылган шигырьләрдә:

**Ямьсезләнеп беттек бу дөньяда,**
**Матурлыкны күбрәк күргәнгә.**

(Рәшит Әхмәтҗанов.)

Шулай ук берәр хикмәтле фикер әйткәндә:

**Нык тораммы, чайкаламмы,**
**Күккә ашаммы, аваммы...**
**Хурлыгымның ахыры бул,**
**Зурлыгымның дәвамы!**

(Р. Фәйзуллин.)

Бу вариант образлары өчен логик фикерләүнең әһәмияте аеруча зур, чөнки биредә логикалылык тасвирлау принципларына үтеп керә. Шуңа бу варианттагы тасвир төшенчәле фикерләү кебек үк гади һәм җиңел аңлаешлы:

**Җилдерде ул дала атларында,**
**Гөслә чиртеп аю биетте.**
**Көрәш белән биеклекләр алды —**
**Заманына лаек биеклек.**

(Зөлфәт.)

Төшенчәле фикерләүдәге кебек үк, образлар биредә сәбәплелек ассоциацияләренә таянып үстереләләр.

**Мин үпкәлим аңа: аңламаган,**
**Сине ташлап киткән;**
**Һәм аклыйм да: яратмавы белән**
**Сине шагыйрь иткән.**

(Р. Гатауллин.)

Беренче вариант образларының төп үзлекләреннән берсе — аларның логик каршылыкка корылуы:

**Еллар миңа миһербанлы булды,**
**Юк, зарлана алмыйм язмышка.**
**Яшьлек баерак, кыйммәтрәк була,**
**Икенче кат килсә тормышта.**

(К. Булатова.)

Яшьлекнең икенче тапкыр килә алуы һәм беренчесеннән баерак булуы... Беренче карашка сәер һәм каршылыклы фикер. Әмма ул реаль тормыш чынлыгына нигезләнгән. Шуңа да без аңа ышанабыз, образ бер укуда ук хәтергә кереп кала. Күрәсең, бу каршылыклар безнең күңелне үзләренең шушы логик чишелешләре белән билэп ала торганнардыр. Ни генә булмасын, алар безне активлаштыра, фикернең җитезлеген арттыра:

**Ул елларны кире даулап булмый,**
**Сагынып кына була.**
**Үткән бөеклеккә кайтып булмый,**
**Табынып кына була...**

(Р. Фәйзуллин.)

Бу төрдәге тасвирның төшенчәле фикерләүгә якынлыгы аларның бер үк нәрсә булуы турында сөйләми, әлбәттә. Ул төшенчәле фикерләүдән иң элек үзенең сәнгать әсәре эчендә килүе, димәк, сәнгать закончалыкларына буйсынуы белән аерыла. Бу вариантның художестволы образ икәнлеген оныту, димәк, аны шартлылык, объектив-субъектив, тасвир-белдерү, гомуми-берәмле һ. б. мөнәсәбәтләрнең берлеге итеп карамау һәр вакыт уңышсызлыкка китерә. Безнең поэзиянең иң зур кимчелекләреннән берсе — безнеңчә, нәкъ әнә шунда.

**Хезмәт булган җиргә якты нур тула,**
**Хезмәт булган җирдә яңа җыр туа.**
**Хезмәт булган җирдә саф җилләр исә,**
**Хезмәт булган җирдә саф гөлләр үсә.**

(К. Булатова.)

Әйе, хезмәт булган җирдә бар нәрсә дә бар. Ләкин бу саналып киткән сыйфатлар аның төп үзлеген ачалармы? Автор алар аша сәнгатьчә тәэсир итәрлек берәр шигъри фикер әйтә алганмы? Әлбәттә, бу сорауларга уңай җавап бирүе шактый авыр. Чөнки тасвир абстракт төшенчәләрне коры санап чыгудан узмый. Коры, риторик белдерүгә корылган шигырьләр турында да нәкъ әнә шуны әйтергә мөмкин булыр иде:

Нинди яхшы!
Икебезнең өскә ява,
Эре, йомшак
Ак кар ява —
Казан кары.

(Р. Мингалимов.)

Образлардагы гомумилекне, мәгънә төсмерләренең күплеген тәгәл әйтелмәгән һәм төрлечә аңларга мөмкин булган сүзләр белән бутарга ярамый:

Сүгендермә мине...
Мин җырчы дип
Күзгә карап алдамыйлар бит.
Оятлары беткән сандугачлар
Талга кунып сайрамыйлар бит...

(Рәшит Әхмәтҗанов.)

Беренче ике юлны биредә дүрт төрле аңларга мөмкин: 1) ник син миңа алдыйсың дип әйтәсең? Мин җырчы һәм алдамыйм; 2) мин җырчы түгел һәм алдамыйм да; 3) алар бит җырчылар һәм алдашмыйлар; 4) алар җырчы түгел һәм алдамыйлар да; Соңгы ике юлдагы «оятлары беткән (?) сандугачлар»ның талга кунып сайрау-сайрамавы шулай ук сәер яңгырый. Шунысы ачык ки, төгәлсезлек аркасында килеп чыккан күп мәгънәлелек белән сәнгатьчә гомумиләштерүләр нәтиҗәсендә туган күп мәгънәлелек арасында бернинди дә уртаклык юк.

Беренче вариант образларының оешу формалары, ясалу принциплары сизелмәслек дәрәҗәдә гадәти һәм гади. Алардагы аерымлык башлыча эчтәлек ягына: яңа тасвир, яңа фикер әйтүгә кайтып кала. Ә безне исә образларның ясалу алымнары күбрәк кызыксындыра. Игътибарны әлеге гомуми принципны төрлечә бозудан килеп чыккан кимчелекләргә юнәлтик. Бу вариант образларының ясалышы ул кимчелекләрдә тулырак ачыла.

Иң еш очрый торган кимчелекләрнең берсе — образ логикасының чатаклыгы. Ул күп төрле булырга мөмкин. Шуларның берсе — образларның гомумән аңлаешсызлыгы:

Киек казлар юлы тагы
Очрар әле дип алда,
Син телән тор, ил-әнкә, дип
Иелгәннәр экранга.

(Т. Камалиев.)

Күпме генә баш ватсаң да, бу юлларны логик фикерләү ярдәмендә аңлау мөмкин түгел. Кайбер шигырьләрдә, гомумән, шигъри мәгънә табу кыен:

Борын-борынгыдан таулар биек,
Үзән җирләр — түбән.

(Р. Гатауллин.)

Образлар ясалышындагы логикасызлык шулай ук тасвирлауның эзлекле булмавында ачык күренә:

**Күзләр тирән булсалар да,**
**Сагыш ул тиз күмелми.**
**Үзем шулай тулганым бар,**
**Аңлыйм синең күңелне.**

(Р. Мингалимов.)

Күзләрнең тирән булуы гына сагышны тиз күмәме икән? Тирән күзләр, киресенчә, моңлы түгелме соң? Соңгы ике юл да авторның үзенә генә аңлашыла булса кирәк: «Үзем шулай тулганым бар». Ә ничек итеп? Әнә шундый төгәлсезлекләр аркасында строфаның гомуми бәйләнеше өзелә. Фикерләүдә логик өзеклек килеп чыга, димәк, образ бер бөтен булып кабул ителә алмый. Р. Гатауллинның «Зур тормышка аяк басу чорым!..» шигыренә карата да шуны ук әйтергә мөмкин:

**Озын бу юл... Туктап көн-чишмәдә**
**Яраларны юар, арса йөрәк.**

Монда, беренчедән, көн белән чишмә төшенчәсен нәрсә бәйләп килүе аңлашылмый; аларның уртаклыгы нигезләнмәгән — ә бу образның ясалмалылыгына китерә. Икенчедән, йөрәкнең аруы — ул җәрәхәтләнү түгел әле. Димәк, бу очракта яра турында сөйләү һәм аны ниндидер көн-чишмәдә юу күренеше логик яктан үзен акламый.

Логикасызлык тасвирда гына түгел, образларның эчке белдерүендә дә очрап куйгалый. Шигырьдә тудырылган эчке халәт үстерелмичә кинәт өзелә, я булмаса хис-фикер үсеше бөтенләй башка юнәлешкә борыла.

**Зураючан түгел зур кешеләр —**
**Биюе дә шуңа, күрәсең.**
**Разведчик бер чыгып биегәннән,**
**Гармунчы дус, син дә үлмәссең.**

(Т. Камалиев.)

Мисалдан күренгәнчә, баштагы ике юлда зураю-зураймау турында барган сүз алга таба өзелә, аның урынына шигырьнең төп үсешеннән читтә торган башка нәрсәләр тасвирлана башлый. Әлбәттә, биредә хикмәт тасвир объектының үзгәрүендә генә түгел. Хикмәт эчке фикернең өзек булуында. Чөнки тышкы тасвир эзлекле үстерелеп тә, белдерүнең үз логикасын югалту күренеше шактый еш очрый:

**Исәнләштек,**
**Елмайдың.**
**Мин сиңа сүз дә ялгый алмадым.**
**Ә син**
**ут сибеп,**
**йолдызлар чәчрәтеп**
**тимерне тимергә ялгадың.**

(Р. Мингалимов.)

Бер-берсенә каршы куелган «ялгау»-«ялгый алмау» биредә бары тик сүз уйнату, тышкы сүз охшашлыгы аша гына бәйләнә. Бу контрастлылык эчке белдерүгә нигезләнмәгән. Шуңа да строфаның беренче ике юлы тудырган халәтне соңгы яртысы дәвам итә алмый. Алар үзара ят булып калалар.

Нәтиҗә итеп, шуны әйтергә мөмкин: беренче вариант тасвирлауның гомуми төшенчәләргә таянган булуы катлаулы тормыш күренешләрен, рухи халәт үзгәрешен,

табигать аисә кешелек дөньясына булган төрле мөнәсәбәтләрне философик, логик планда җиңел генә сөйләп тасвирлау мөмкинлеген тудыра. Ләкин аның бу көчле ягы еш кына көчсез ягына әверелә. Бары тик сөйләп, атап чыгуга корылган шигырьләр шактый күп очрый.

Тасвирлауның икенче формасы объектны тоеп, сизеп кабул иткәнчә чагылдыруга нигезләнә. Биредә тасвирлау объекты гадәттәге исеме белән аталмый, ә нинди дә булса билгесе аша гәүдәләндерелә. Мәсәлән, без таң ату турында «Көнчыгыш як кызарып китте» дибез икән, бу очракта аның гомуми төшенчәсе түгел, ә конкрет бер сиземле үзлеге белдерелә. Инде ул безнең өчен гомумән таң түгел, ә кызарып аткан таң. Шулай итеп, биредә аның сизү органнарыбыз тоя алырлык анык бер сыйфаты сурәтләнә.

Читләтеп тасвирлауга корылган мондый шигырь-образ безнең алга әр-яңа бер серле табышмак сыман килеп баса. Эчке сизенү белән без аның исемен уйлап табабыз, шуңа сөенәбез — эстетик ләззәт алабыз:

Шыр-ялангач урман эчен
Күзге салкын кочып тора.
Ботактагы буш ояда
Бер уч җылы посып тора.

(Гәрәй Рәхим.)

Гап-гади сүзләрдән бер строфалы шигырь. Ләкин андагы сүзләрнең һәрберсе үзләренең мөстәкыйльлеген югалткан. Без аларны билгеле бер настроение тудырган бер бөтен система — поэтик картина итеп күз алдына китерәбез. Биредә сүз «салкынлык» турында да, «җылылык» турында да түгел. Тәрҗемәгә һәм аңлатуга авыр бирелә торган «моң»ның үзедер инде бу! Һәм без аны күреп тә, ишетеп тә тоябыз, хәтта кулыбыз белән сак кына сыйпап куйгандай булабыз шикелле.

Сигнал системасына, ягъни безнең сизү органнарыбыз ярдәмендә тойгы ассоциацияләренә таяну — икенче вариант образларының төп үзлеге. Гомуми төшенчәле сүзләр ярдәмендә сиземле картина тудырылырга тиеш булып чыга. Бу каршылыкны уңышлы чишми торып укучыларның күңелен иркәләрлек чын поэтик күренеш иҗат иту мөмкин түгел. Поэзиянең сиземле яки картиналы булуы сәнгатьнең башка төрләрендәгечә, әйтик, сынлы сәнгатьтәгечә түгел. Әгәр без, мәсәлән, чәчәкне тасвирлыйбыз икән, ул шигырьләрдә билгеле бер мәгънә рәвешен ала, ә сынлы сәнгатьтә бу чәчәк мәгънәсе чәчәк рәсеменә әверелә[1]. Димәк, поэзиядәге «картиналылык» төшенчәсен механик төстә аңларга ярамый. Шигырьдә «сары» яки «зәңгәр» сүзенең булуы гына әле авторның картиналы уйлавы яки төсләрне шигъри бер нечкәлек белән тоюы турында сөйләми. Бу төсләрнең кеше кичерешләренә бәйле төстә тасвирлануы гына художестволы картина тудырачак. Димәк, шигырьнең «төсле» булуы ул иң элек эмоциональ кичереш — эчке халәт. Шигырьләрнең музыкальлеге турында сөйләгәндә дә шуны ук әйтергә була. Тышкы тасвир ягы күзгә бәрелеп тормаган, башлыча лирик белдерүгә караган кайбер шигырьләрне дә картиналы шигырь итеп карарга мөмкин. Шунысы кызыклы: аларның образларында эчке халәт үсеше тышкы тасвирдан һәр вакыт аерылып тора:

Башны салларга салып
Китәсе иде агып.
Дәшәр иде әле дулкыннар
Бер шагыйрь җанны танып.

(Р. Фәйзуллин.)

Менә шушы шигырьне тышкы тасвиры аша рәсемгә әверелдереп карыйк әле. Әлбәттә, рәсем туган очракта да аның белән шигырь арасында берниндн уртаклык

[1] Дмитриева Н. А. Изображение и слово. М., «Искусство», 1962.

булмаячак. Чөнки бу шигырьнең картиналылыгы аның «саллар», «дулкыннар» турында булуыннан түгел, ә кеше рухының поэтик бер мизгелен тотып алып, аны сүзләр дөньясына күчерүдә. Укучы бу сүзләр системасын кабул итеп әлеге кичерешне «таный»... Тойгыларыбыз һәм сизү әгъзаларыбыз аша тәэсир итәрлек эчке халәт картинасы туа. Икенче вариант образларының көче әнә шунда.

Тойгы ассоциацияләренең картина тудыруда тоткан роле бердәй түгел. Кеше үзе кабул иткән бөтен информациянең 90 процентын күзләре ярдәмендә ала[1]. Димәк, образлар ясалышында күрү ассоциацияләренең әһәмияте аеруча зур:

**Көн буена бар урманны айкап йөргән**
**Сунар эте куян куып килә юлдан.**
**Карт сунарчы, мылтыгына башын куеп,**
**Бүтән мәңге ачмас өчен күзен йомган.**

(Г. Рәхим.)

Гади бер рәсем. Ә аның нигезендә яткан тормыш диалектикасы безне төрле поэтик гомумиләштерүләр ясауга этәрә.

Мондый рәсемле шигырьләрне бик күпләп китерергә мөмкин. Ләкин кайсын гына алып карасак та, аны сиземле шигъри образ иткән нәрсә — кешедәге эчке халәтнең конкрет бер талпынышы.

Икенче вариант образларын тудыруда шулай ук ишетү ассоциацияләренең дә әһәмияте гаять зур.

**Укыйм, җырлыйм:**
**— Татарстан, Татарстан...**
**Күңелемдә яңгырау кала:**
**Дастан, дастан, дастан...**

Р. Харисның әлеге шигырендә аваз ассоциациясенең туу мизгеле үзе күрсәтелә. Гомумән, авазларның бәйләнеше поэзиядә бик киң кулланыла. Без аны ритм-рифма оештырылышында да, аллитерация, ассонанс күренешләренең төрле чагылышында да ачык күрәбез.

Шагыйрьләр еш кына башка сизү органнарына да мөрәҗәгать итәләр:

**Һәрбер ташта бар тарих кызуы,**
**Табаның пешә монда кыш көне.**

(Зөлфәт.)

**Шатлыгы киләме бүген,**
**Әллә кайгысы килә!!**
**Нигә әле бу уй башта!**
**Кыр казы исе килә!..**

(Р. Фәйзуллин.)

Алдагы шигырьдә тасвир тән сиземләвенә ишарә ясаса, Р. Фәйзуллин шигырендә исә образ ис тоюга бәйле төстә оеша. Алардагы образларның табигатьтәге чагылышны механик күчерү генә булмавы күренеп тора. «Кыр казы исе килү» турында сүз чыга икән — бу әле укучының кыр казы исен тоярга тиешлеге турында сөйләми. Биредә лирик геройның эчке настроениесен тудыру, аны укучылар чын-чынлап тоярлык итеп җанлы картиналар аша бирү әһәмиятле. Шуны да әйтергә кирәк, әгәр дә автор дөрестән дә «табан пешү», я булмаса «кыр казы исе»н сиземле итеп бирергә тели икән, ул бөтенләй башка чараларга мөрәҗәгать итәр иде.

---

[1] Грегори Р. Л. Глаз и мозг. М., «Прогресс», 1970.

Без алда санап киткән төрле тойгы ассоциацияләре шигъри образлар ясалышында күп очракта бергә кушылып та киләләр. Сизү органнарының бердәм эшчәнлегенә (синестезия) таянып тудырылган образлар аеруча җанлы һәм нык тәэсир итүчән булалар:

**Куккә тигән тупыл ябалдашы...**
**Менә-менә кичке җил өрер.**
**Тупыл ботаклары, шыбырдашып,**
**Йолдызларын коеп төшерер.**

(Зөлфәт.)

Шыбырдашып куйган мәһабәт тупыллар... чекерәеп янган йолдызлар... Ләкин шул гынамы соң? Безнеңчә, монда иң элек туган авылын сагынып кайткан шагыйрьнең бер үк вакытта сагаеп та, бунтарьланып та куйган нечкә күңеле тасвирланган. Шигырьне тулы килеш укып чыгу белән без моңа кабат ышанабыз. Ләкин бу кичереш нәкъ менә әлеге йолдызларның балкып януы, тупыл яфракларының шаулашуына бәйле төстә туа, шулай хәтердә кала.

Эчке кичерешләр сөйләм үзенчәлекләре ярдәмендә дә бирелергә мөмкин:

**— Ә... Синмени! — диде тимергә ул.—**
**Син... сугарга... уйладыңмыни!**
**Врешь, брат! Күпме генә сукма,**
**Кызган чакта ирләр бөгелми!**

(Зөлфәт.)

Күренгәнчә, бу юлларның интонацион төзелеше гаять үзенчәлекле. Кичерешләрнең туры сөйләм аша бирелүе, бу сөйләмнең өзек-өзек итеп алынуы геройның эчке дөньясындагы үзгәрешләрне гаҗәеп бер төгәллек белән ачып салырга ярдәм итә. Мондый сөйләм үзенчәлекләре аша тудырылган халәт картинасы шигырьдә өч җирдә — өч строфа итеп китерелгән. Аларны бер бөтен итеп карау эчке кичереш киеренкелегенең үсешен тагын да ачык күрсәтә. Утлы тимер ташкынын хәтерләткән, нәфрәт, акыл, хис һәм кайнарлыкны бергә җыйган бу строфалар герой характерын ачу ягыннан гына түгел, укучыга тәэсир итү көче белән дә шигырьдә аерылып торалар.

Шагыйрьне объектларның гомуми, яки сиземле үзлекләре генә түгел, аларның бер-берсенә булган мөнәсәбәте дә кызыксындыра. Чөнки теләсә нинди объект башка объектка мөнәсәбәттә килеп, аның эчке хасиятен ачып ташларга мөмкин. Мондый очракларда беренче объектның мөстәкыйль мәгънәсе югала һәм бары тик үзе буйсынып килгән объектка бәйле төстә каралып, ул хәрәкәт иткән логика юнәлешендә генә яши башлый. Тасвирның өченче формасы яки алымы әнә шулай барлыкка килә. Әгәр без «17 дә таң атты» дип әйтәбез икән, биредә инде гомуми төшенчәле «таң ату» революциянең бер асыл сыйфатын ачып бирә. (Бу мисалда «революция» сүзе төшеп калган, әмма ул контексттан бик җиңел аңлашыла.) Шушы ук җөмләдәге фикерне алга таба дәвам итсәк, сүз, һичшиксез, революция турында барыр иде. Ә таң төшенчәсен күпме генә үстерсәк тә, ул үзенең мөстәкыйль мәгънәсенә кире кайтмаячак; бары тик киңәйтелгән метафорага әверелеп, революциянең тулырак картинасын күзаллауга гына ярдәм итәргә мөмкин:

«17 дә таң атты. Кояшның нурлары тәбәнәк өйләрнең караңгы тәрәзәләрен яктыртты» дип тасвирлау безне, һичшиксез, революциягә бәйле төстә билгеле бер символик образлар дөньясына алып керер китә. Димәк, алынган объектларның берсе (революция) фикерне логик планда үстерсә, икенчесе (таң) аны картиналы-сиземле итә.

Күргәнебезчә, биредә аларның функцияләре аерыла. Дөрес, үзара мөнәсәбәттә килгән бу ике объект урыннары белән алышынырга да, яисә һәр икесе башка объект белән килеп, яңа функция башкарырга да мөмкин. Әйтик, «Көнчыгышта таң ут булып

сызылды», яки «Көнчыгышта ут сызылды». Биредә инде гомуми төшенчәле «ут» таңның үзен конкрет бер үзлеге белән ачып килә. Ике объектның әлеге функцияләре алышынып килүе Р. Харисның «Кибән» шигырендә бик ачык күренә:

**Яз көне**
**Кибән-кибән болыт**
**Җиргә сеңгән.**
**Көз көне**
**Җирдә шытып чыккан**
**Болыт-болыт кибән.**

Образларның өченче варианты беренче вариантка хас булган фикер үткенлеген һәм икенче варианттагы эмоциональ тәэсир итү көчен үзендә берләштерә. Өченче вариант тасвирда объектларның мөнәсәбәте бер генә төрле булмаска да мөмкин.

**Йөзә Казан!**
**Гигант кораб сыман,**
**Бәхет гаванена**
**Таң аша.**

(Зөлфәт.)

Китерелгән өзектә төп тасвир объекты, һичшиксез, Казан. Әмма автор бу шәһәрнең бүгенге көндәге иң әһәмиятле үзенчәлеген укучыга җиткерү һәм аңарда билгеле бер настроение тудыру өчен икенче бер объект — «гигант кораб»ка мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә, һәр ике объект үзләренең тулы мөстәкыйльлекләрен югалталар, иң өскә аларның мөнәсәбәте калкып чыга. Шунысы кызыклы, биредә Казан гомуми логик фикер юнәлешен билгеләп торса, кораб аның конкрет үзлеген ачып килә, ягъни, образның картиналы үсешен тудыра.

Алар, капма-каршы куелган ике көзге кебек бер-берсен чагылдырып, безнең тойгы-фикерләребезне чиксез тирәнлеккә этәрәләр.

Өченче вариант образлары нигезендә охшашлык, я булмаса контрастлылык ассоциацияләре ята:

**Томырылдык көрәш уртасына**
**Сабан туе атлары сыман.**

(Зөлфәт.)

«Без» һәм «сабан туе атлары» — бер-берсеннән ерак торган бу төшенчәләрдә автор күпмедер охшашлык-уртаклык күргән. Әгәр дә укучы бу уртаклыкның чынлыгына ышана икән, димәк, ассоциация уңышлы сайланган, уңышлы кулланылган. Шагыйрьнең көче — әнә шундый гадәттә икесен бергә куеп карау кыен булган төшенчә һәм күренешләрнең эчке бәйләнешләрен табып, сәнгатьчә образ тудыруда. Бу ике объект мөнәсәбәтеннән серле һәм көтелмәгән яңа поэтик дөнья туа. Мондый ассоциатив фикерләүнең уңышы — бу бәйләнешнең табигый булуында, аның шушы ике объект хәрәкәтендәге эчке закончалыкларга таянып барлыкка килүендә.

**Ак патшаның кара хатларын да**
**Китергән ул почта атлары.**
**Авыр яраларны ачкан сыман**
**Ачкан хатны илнең картлары.**

(М. Әгъләмов.)

Авыр хәбәр китергән хатны яра ачу белән тиңләп карау, һичшиксез, күңелдә гаҗәп тирән кичерешләр уята. Без бу бәйләнешнең дәрәслеген акылыбыз белән генә түгел, бөтен эчке сиземләвебез аша да тоябыз.

Өченче вариантта тасвирлау үзенең гаять тыгыз һәм катлаулы булуы белән аерылып тора. Аның аша бик аз сүз ярдәмендә чынбарлыкның тирән катламнарына үтеп керергә мөмкин. Аларның төрле метафорик, символик формаларда кулланылуы шул хакта сөйли.

Аңымны юа да мана,
Юа да мана
Замана.

(Р. Харис.)

Гадәттә кием-салым һ. б. шундый нәрсәләрне генә юып манарга мөмкин. Шуңа да, гади җөмлә төзелеше болайрак булыр иде: «Аңымны кер төсле юа да мана... замана». Әмма «кер» төшенчәсе төшеп калган, тик ул үзенең бөтен үзлекләре аша соралып-аңлашылып тора һәм авторның фикерен ачуда төп рольне уйный. Заманаkның катлаулылыгы шигырьдә әнә шундый берничә юл аша гәүдәләндерелә. Тагын бер мисал китереп узыйк:

Без мәңгегә, без мәңгегә монда,
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары.

(Рәшит Әхмәтҗанов.)

Бу строфаның соңгы ике юлына гына игътибар итик: күпме бәйләнеш биредә: йөрәк-бәйрәм, йөрәк-бәйрәмдәге атлар, йөрәк-кыңгыраулы атлар, безнең йөрәк атлары... Күрәсең, әнә шушы мөнәсәбәтләрнең барысы бергә җыелып кинәт кенә төрле каналлар аша тәэсир итүе бездә билгеле бер эстетик эмоция уята торгандыр. Чөнки шигъри ассоциациянең үзендәге хәлиткеч сыйфатларның берсе — кинәтлек, яшен тизлегедәй арада балкып алу. Ясалу тизлеге акрынайдымы, тоткарландымы — шунда ук аның бу хәлиткеч сыйфаты югала, ул ассоциациялелектән чыга, гади аңлатуга әйләнеп кала.

Беренче кар
Кайнар җиргә
Газинурдай ята.
Үзе үлә,
Башкаларга
Җирне салкынлата.

(Р. Харис.)

Күргәнебезчә, биредә ассоциация аҗаганы балкып китә алмый. Кар белән Газинур арасындагы бәйләнеш ышандырмый: кайнар көкрәгән утка куйган Газинурны ничек инде салкын кар белән тиңләп карарга мөмкин? «Беренче» төшенчәсе генә бу ике компонентны берләштереп тотып тора алмый — бу ясалма ассоциация.

Образларның нигезендә яткан мондый ясалма ассоциацияләр шигырьләрдә еш кына очрап куйгалый.

Язгы тамчы
Гүя камчы.
Язгы тамчы
Гүя кайчы.
Кисә бозны,
Ашый карны.

(Р. Гатауллин.)

Камчы суга, ә тамчы тишә... Аларның охшашлыгы нәрсәдә? Кайчының бозны кисүе, я булмаса бозны ашавы шулай ук ышандырмый, ул образларны кабул итү

мөмкин түгел. Образларның ялган контрастлылыкка нигезләнүе дә шундый ук күңелсез нәтиҗәгә алып килә:

**Без, мәсәлән, бик еш ялгышабыз.**
**Кыек юлга кереп китәбез...**
**Ә сәгатьләр исә сирәк алдый,**
**Сәгать кебек булсак икән без.**

(Т. Камалиев.)

Телибезме, юкмы, шигырьдән «сәгать кебек сирәк алдыйк» дигән фикер килеп чыга. Бирелә ялгышу-алдау компонентлары һич кенә дә билгеле бер уртаклыкка буйсынмый.

Е. Эткинд бик хаклы рәвештә: «Метафора бизәк түгел... Шагыйрьгә үзенең тормыш фәлсәфәсен ачарга мөмкинлек бирүче куәтле чара ул»,— дип язды [1].

Ә ассоциацияләрнең тышкы охшашлыкларга гына таянмыйча, эчке халәт үсешенә нигезләнүе һәр вакыт уңышлы образлар тудыруга алып килә. Менә Г. Рәхимнең «Язгы авылдан фрагмент» шигыренә генә тукталыйк:

**Югарочтан түбәночка**
**һәрбер урам чатыннан**
**Гөрләвекләр чыгып чаба**
**Гөрләвекләр артыннан.**

**Югарочтан түбәночка**
**һәрбер урам чатыннан**
**Малай-шалай чыгып чаба**
**Гөрләвекләр артыннан.**

Шигырь, беренче карашка, бер үк сүзләрне ике тапкыр кабатлап чыккан сыман. Ләкин, шунысы гаҗәп, арадан кинәт кенә калкып куйган «малай-шалай» сүзе безнең хисләребезне көтмәгәндә сискәндереп җибәрә: «гөрләвекләр» белән «малай-шалай» сүзләре бергә кушылып, ассоциация тудыра, ә соңгысы исә безнең аңда ниндидер мәгънәле тирәнлек ала. Әйе, малай-шалай гомер буе шулай чапкан һәм чабар. Ул гөрләвек кебек үк гамьсез, ул язны, иреkne ярата. Чынлабрак укып карасаң, бу ике строфаның икесе ике төрле икән, алардагы охшашлык аерымлыкны күпертеп, көчәйтеп тора. Юк, монда яз гына түгел (хәер, «яз» сүзе бирелә телгә дә алынмый)... Бу — сафлык, бу — еректан зәп-зәңгәр булып күренеп торган бала чак иле! Бирелә бер генә сүз дә «чи» материал булып калмаган. Игътибар итегез: «югарочтан түбәночка» сүзләренең бер-берсенә каршы куелуы гөрләвекләрнең юнәлешен билгеләр өчен генә китерелмәгән бит; югыйсә, гөрләвеккә параллель итеп алынган «малай-шалай» түбәннән югарочка да шәп йөгерә ала... Юк, бу юллар бала чакның гамьсез-кайгысыз булуы, балаларның мәңге шулай дөньяларын онытып «җил куып» йөрүләре турында гына да сөйләми... Гөрләвекләр елгаларга кушылыр, аннары диңгезләргә чыгар... Тормыш язында гөрләвекләрдәй шаулашып чапкан малайларның да гомер юллары киләчәктә әллә кайларга китәр...

Шулай итеп, без образлар ясалышында аерылып торган өч вариант булуын карап үттек. Шунысын да әйтергә кирәк, бу бүленеш гаять шартлы. Контекстның аз гына үзгәрүе дә аларны бер варианттан икенчесенә күчереп куярга мөмкин. Әмма күчеш нигездә бер якка, беренче варианттан өченчегә, икенчедән өченче вариантка таба бара. һәм бу аңлашыла да — чөнки һәрбер сүз, һәрбер конкрет үзлек шигъриятта үзенең бердәнбер мәгънәсендә генә калырга теләми. Төрле ассоциацияләр ярдәмендә, ул чынбарлыкның башка күренешләре белән бәйләнешкә кереп гомумилеккә омтыла. Образ вариантларының бу үзлеге бер бөтен образлар системасы булган шигъри әсәрләрдә генә тулы килеш чагыла ала.

---

[1] Е. Эткинд. Разговор о стихах. М., 1970, 135 бит.

# НУР БАЯННЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ



1945 елның 23 апреле.

Альп таулары итәгендә каты сугышлар бара. Немецларның «Империя» һәм «Викинг» дип аталган СС дивизияләре, венгрларның укчы бригадасы Совет Армиясе сугышчыларының һөҗүмен соңгы көчләре белән туктатырга исәплиләр. Австрияне азат итү өчен барган шушы канлы сугышта татар халкының танылган шагыйре, дивизия газетасы редакторы подполковник Нур Баян һәлак була.

Аны газета хезмәткәрләре һәм сугышчылар зур хөрмәт белән күмәләр. Альп таулары итәгендәге кабергә мәрмәр такта куела, анда татар халкының батыр улы, подполковник Нур Галимович Баянның батырларча һәлак булуы турында языла.

Нур Баян 1905 елның 15 маенда Татарстанның элекке Калинин районы (хәзер ул Актанышка керә), Әнәк авылында ярлы крестьян семьясында туган. Нурның әтисе балта остасы булган. Кышларын ул башка авылларга барып эшләгән. Әнисе Мәүлиха апа — авылда тегү-чигү эшләренә оста хатын-кызларның берсе — кышкы озын төннәрдә бишле лампа яктысында йон эрләгәндә уллары һәм кызларын каршына утыртып, аларга әкиятләр сөйләгән, бәетләр һәм мөнәҗәтләр әйткән.

Нур Баянда шигырьгә сәләт бик иртә уяна башлый. Башлангыч мәктәптә укыганда ук ул шигырьләр яза, бәетләр чыгара. Аның турында Әнәк авылында яшәүче Зәйнетдин Бәдретдинов болай сөйли:

«Авылда без Нурны «җырчы малай» дип йөртә идек. Аның әтисе белән без балта остасы булып үз авылыбызда да, башкорт, мари якларында да эшләдек. Мәнә шунда, бүрәнәләр юнып аргач, ял иткәндә ул безгә:

— Минем малай көн-төн укый, бәетләр, җырлар чыгара, үскәч Тукай кебек булыр ул,— ди торган иде.

Нур бик яшьләй читкә китте, аннан Казанда укыды. Җәйләрен кунакка кайта иде. Коммуна төзүне бик мактый иде. Беренче китабы басылып чыккач, миңа үз кулы белән язып, бүләк иткән иде».

1921 елгы ачлык 16 яшьлек Нурны туган авылыннан китәргә мәҗбүр итә. Ул Пермь шәһәренә барып, төрле авыр эшләрдә йөри. Ике елдан соң Казанга килә һәм Татар-башкорт хәрби мәктәбенә укырга керә. Мәктәптә ул алдынгы курсант була, шигъри иҗат эшенә ныклап керешә. Нур Баян исеме матбугатта да күренә башлый.

1926 елда басылган «Шлем кигәч» дигән шигырендә Нур Баян болай дип язды:

**Тукта, дисез,**
**Минем яшь күңелгә,**
**Обмоткама кырын карыйсыз.**
**Әле минем каләм нык очланыр,**
**Солдат егетне дә танырсыз.**

Солдат шагыйрьнең каләме чарлана, һаман шомара барды. Ул егерменче елларның икенче яртысында, утызынчы елларда бик актив иҗат итте, әледән-әле яңа шигырь китапларын дөньяга чыгарып торды. Шул еллардагы татар вакытлы матбугатында шигырьләре, җырлары, мәкаләләре һәм очерклары күп басылды. Бер-бер артлы яңа поэмалары туды. Нур Баян танылган шагыйрь булып җитеште.

Ул бу чорда «Кызылармеец» исемле хәрби газетада һәм «Колхоз яшьләре» журналында эшли. Колхоз төзү, күмәкләшү елларында Чаллы район газетасында редактор була. Шул ук чорда ул матбугатта уңай бәя алган «Яңгырлы төн» поэмасын яза.

Нур Баян балалар өчен дә күп кенә әсәрләр иҗат иткән шагыйрь. «Роберт» поэмасы, җырлары һәм шигырьләре белән ул балалар әдәбиятын үстерүгә билгеле бер өлеш кертте.

Шагыйрь 1932 елда яңадан Казанга кайта, Татарстан язучылары союзы каршындагы оештыру комитетында һәм Татарстан китап нәшриятында эшли. 1938 елда Нур Баян язучылык эшенә генә күчә.

Нур Баянның шагыйрь буларак танылгач иҗат ителгән һәм укучылар тарафыннан җылы каршы алынган «Очрашу», «Туган авылымда», «Онытылган дус», «Иөрәк һәм мин» һәм башка әсәрләрендә, җырларында югарыга үрләп баручы колхоз авылы, туган илебездәге гигант завод-фабрикалар, андагы эшчеләрнең фидакарь хезмәтләре, искелек белән яңаның көрәше, социализмның җиңүле адымнары калку итеп сурәтләнә. Нур Баянның әсәрләре күбрәк авылга, андагы кешеләргә багышланган. Ул авылның үткәне белән хәзергесен чагыштыра, кешеләр психологиясендәге үзгәрешләрне, тормышның яхшыра баруын күреп шатлана. Баянның мондый шигырьләре байтак («Мәликә», «Әхмүшкә», «Зөһрәгә хат», «Елак кызлар турында», «Комбайнчы Гөлсем» һ. б.).

Нур Баянның иҗаты Һади Такташ мәктәбе йогынтысы астында үсә. Такташ шигъриятенең югары пафосын, ялкынлы романтикасын һәм башка сыйфатларын ул иҗади үзләштерә.

Такташның үлүенә өч ел тулу уңае белән Нур Баян «Шагыйрь үлгәч» дигән шигырь язды. Бу шигырьдә без Баянның үсә баруын күрәбез, аның Такташка булган тирән һәм җылы хисләре укучы күңелендә җавап табалар.

**Күккә карыйм:**
**Күктә бер йолдыз да**
**Болытларга мәңге күмелми;**
**Җиргә карыйм:**
**Җирдә зәңгәр күзле**
**Сөйгән шагыйрь Такташ күренми.**
**Сыркыдыда әллә уйчан егет**
**Көтә микән сөйгән казларын...**
**Кая китте?**
**Әллә ул Донбасста**
**Өйрәнәме күмер базларын?**

— дигән юлларны тирән кичереш белән укыйсың.

Нур Баянның «Гөләндәм» поэмасы игътибарга лаек. Татар совет әдәбиятында ул производство темасына язылган зур күләмле әсәрләрнең беренчеләреннән булды. Нур Баян бу поэманы язганда шактый материал туплаган. Семья архивында аның вариантлары саклана.

Шагыйрь күп йөри, күп кешеләр белән очраша. Бишьеллык гигантлары, зур төзелешләр, үсә баручы шәһәрләр һәм авыллар аның шигъри күңелен били, дулкынландыра. Ул әнә шулар турында рухланып яза.

1939 елны Нур Баян Татарстан партия оешмасының өлкә конференциясендә «Ант» шигыре белән чыгыш ясый. Шагыйрь үзенең Советлар Союзы Коммунистлар партиясе члены булуы белән горурлануын һәм, кирәк була икән, Ватаны, халкы өчен гомерен дә бирергә әзер булуын белдерә.

**Мин члены бөек партиянең**
**Һәм күтәреп шушы исемне,**
**Залга килдем бер җырчысы булып,**
**Сөйләр өчен йөрәк хисемне.**

. . . . . . . . . . . . .

**Мин ант итәм сиңа: пычратмаска,**
**Тапламаска синең исемеңне.**
**Һәм бирергә соңгы сулышкача**
**Халкым өчен йөрәк хисемне!**

Гомеренең соңгы мизгеленә кадәр шагыйрь шул антына турылыклы булып калды.

Нур Баян сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китә. Кайсы фронтта, нинди генә шартларда сугышырга туры килмәсен, аның язган хатлары һәм шигырьләре алгы сызыктагы дәһшәтле сугыш картиналарын сурәтлиләр, аларда Туган илгә, партиягә һәм халыкка кайнар мәхәббәт, илбасарларга карата үч һәм нәфрәт көчле чагыла. Тылга 1942 елның 26 сентябрендә җибәрелгән хатында ул болай дип яза:

«Без әле күптән түгел генә шат һәм тыныч тормыш белән яши идек. Колхозлар нык һәм бай тормыш кояшы астында чәчәк атканда, завод-фабрикалар гөрләп эшләгәндә, изге җиребезгә немец фашистлары канлы аяклары белән басып керделәр.

Безнең тормышыбыз бәхетле, шатлыклы иде. Яшьләрнең генә түгел, хәтта картларның да йөрәкләрен яшьлек хисләре чорнаган иде. Ә бүген аналарның, балаларның күз яшьләре ага. Гитлерчылар аяк баскан урыннарда канлы яшь тулган, хәтта елгалар да кан белән ташыйлар.

...Җиребезгә талпан кебек кереп урнашкан немецларны тар-мар китереп, без Калинин фронты буенча алга барабыз. Безнең күз алдыбызда Бөек Ватан, совет халкы тора. Безнең өчен артык чигенү юк! Безнең бурыч — соңгы сулышкача көрәшү, немец оккупантларын тар-мар итү! Киләчәктә балаларыбызның тыныч яшәүләре, яшьләрнең матур мәхәббәтләре өчен, ерткыч фашистларны үтерергә кирәк!

Дусларым!

Немец бандитларын изге җиребездән юк итү өчен, сез безгә күбрәк снаряд, мина, граната, самолет, танк бирегез! Без Ватан өчен биргән антыбызны үтәрбез! Немец оккупантларына үлем! Без беләбез, Ватан һәм бөек партия бер генә адым да кире чигенмәскә кушалар. Безнең бурыч — оккупантларны кыйный-кыйный юк итү һәм туктаусыз алга бару!»

Нур Баян фронтта полк партия оешмасы секретаре, «Ватан өчен» исемле газетаның редакторы кебек җаваплы хезмәтләрне башкара.

Тәнкыйтьче Гази Кашшафка җибәргән бер хатында шагыйрь үзенең күбрәк алгы сызыкта йөрүе, материал туплавы һәм мәкаләләр, шигырьләр язуы турында сөйли.

«Эшемне яраталар,— ди ул хатында.— Бөтен работникларым правительство бүләге белән бүләкләнделәр. Ә моның өчен, Кашшаф дус, эшләргә кирәк. Ә мин күбрәк алгы сафта материал оештырам. Немецка 100 адым калган вакытлар да булгалый. Әгәр исән калсам, озаклап бергә утырып сөйләшербез.

Ә шулай да Ватан сугышына катнашуым белән мин бәхетле! Куркыныч вакытлар күп, ләкин мин шатланам: фронтта булдым, дип әйтә алам. Менә икенче ел фронтның үзәгендә, сугышның әчесен дә, төчесен дә татырга туры килде.

Дускай!

Озакламый мин сиңа шигырьләр җибәрермен».

Нур Баянның фронтта язган шигырьләренең бик азы гына Казанга килеп җитә. Мена шулар арасыннан «Тирә-якта үлән чәчәк аткан», «Минем өстән пуля яуса да», «Окопта», «Уйланганда», «Санитарка», «Үч һәм нәфрәт» исемле шигырьләр. Аларда шагыйрьнең кайнар сулышы бөркелеп тора. Шигырьләрне укыганда кырыс солдат тормышын, сугыш гарасатын, җиңүгә ышанычны ачык тоясың. «Сандугачка» дигән шигырендә Нур Баян үзенең хисләрен болай сурәтли:

**Кызык кош син, сандугачым-дустым,**
**Туп ярыла, ә син сайрыйсың.**
**Тормыш итәр өчен туган илдә**
**Оянң өчен куак сайлыйсың.**
**Матур ил шул безнең илебез,**
**Ал чәчәкле безнең җиребез.**
**Их, яшисе килә илемдә,**
**Һич үләсе килми тигенгә.**

Шагыйрьнең хатларында, шигырьләрендә Украина далалары, Калинин фронты, Донец һәм Дон елгалары телгә алына. Ул үзе дә әнә шул җирләрдә автоматы белән дә, каләме белән дә дошманга каршы батырларча көрәште. Нур Баян фронтта сугышчан бурычны үтәгәндә Советлар Союзы Маршалы К. Е. Ворошилов белән очраша. Бу турыда ул Казанда калган туганнарына һәм улы Робендарга язган хатында хәбәр итә. Хат белән бергә очрашу вакытында төшерелгән фоторәсемне дә җибәрә.

Донец буйларын дошманнан азат иткәндә Нур Баянга командование тарафыннан немецлар кулына эләккән әсирләрдән төзелгән легион солдатларын үзебезнең якка чыгару буенча җаваплы бурыч йөкләтелә. Нур Баян листовкаөндәмә яза һәм аны башкорт телендә чыга торган «Кызыл атлылар» дигән фронт газетасы типографиясендә бастыра. Листовкаларны «У-2» самолетыннан дошман тылына — татар, башкорт, үзбәк, казакъ әсирләреннән төзелгән легион өстенә ташлыйлар. Башкорт язучысы Әхтәм Ихсан белән берлектә, алар төнлә алгы окопларга киләләр һәм, радио аша легиончыларга мөрәҗәгать итеп, аларны үзебезнең якка чыгарга өндиләр. Нур Баян татар телендә, Әхтәм Ихсан башкорт телендә чыгыш ясыйлар. Берничә көннән соң, әсирлеккә эләккән татар һәм башкорт егетләре, немец офицерларын үтереп, үзебезнең якка чыгалар. Аларның күбесенә шагыйрь Нур Баян электән билгеле булган. Әсирлектән котылган солдатлар, Совет Армиясе сафына яңадан басып, немец илбасарларына каршы сугышларда катнашалар.

Әхтәм Ихсан үзенең истәлегендә Нур Баян белән беренче тапкыр очрашуын хәтеренә төшерә:

«1943 елның язында безнең частьлар Донец буенда Кременное шәһәре тирәсендә урнашкан иде. Донец ар ягында — тау башында — фашистлар. Аларның позициясе яхшы, уңайлы, шуның өчен юлларны, урманны контрольдә тота алалар, әледән-әле Кременноега атып торалар.

Егерме икенче март. Иртәнге сәгать алтыларда безнең редакциягә таныш булмаган бер офицер килде. Ул пехотачы киемендә, өстендәге шинеле бераз былчыранган иде.

— Вәт, егетләр,— диде ул исәнләшүдән элек,— вилкага эләктем бит. Җир сөрергә туры килде.— Һәм ул шинелендәге кара тапларга күрсәтте, аннары исәнләште:

— Саумысыз! Нур Баян.

Нур Баянның әсәрләрен укысам да, үзен күргәнем юк иде. Без аның белән бик тиз танышып алдык. Сүз сугыш, семья, татар һәм башкорт әдәбияты турында барды. Соңыннан ул үзенең бездән сул флангта торган 78 нче укчы дивизиядә «Ватан өчен» исемле газетада редактор булып эшләве турында сөйләде.

— Мин сезнең атлылар турында күптән ишеткән идем, — диде Нур Баян. — Сезнең атлы сугышчылар-лачыннар башкорт халкының сугышчан традициясен дәвам иттерәләр.

Бу бик күпне белергә тырышучы, басынкы һәм йөрәкчән кеше башкорт дивизиясе турында кызыклы материаллар язып алды, аннары «Кызыл атлылар» газетасының бер еллык комплектын карап чыкты, типография белән танышты. Шул көннән безнең арада фронт дуслыгы башланды».

...Альп таулары итәгендәге кабергә куелган мәрмәр такта янына бик күп кешеләр килә. Алар татар шагыйре Нур Баян каберенә тере чәчәкләр куялар. Халык үзенең батыр улларын онытмый.

Татарстанның Актаныш районындагы Әнәк һәм Пучы авылларын эченә алган колхоз Нур Баян исемен йөртә. Колхоз идарәсе бинасы каршындагы бакчада шагыйрь Нур Баянның мәрмәрдән эшләнгән һәйкәле тора. Туган авылына ул җыр һәм һәйкәл булып, батырлык символы булып кайтты. Һәйкәл-шагыйрь бүгенге авыл эшчәннәренә карап үзенең шат җырларын җырлый кебек. Авылдашлары — карты һәм яше — шагыйрьне хөрмәт белән искә алалар, һәйкәлгә чәчәк бәйләмнәре куялар. Нур Баян 1939 елны язган бер шигырендә:

**Сандугачы булып шушы илнең**
**Яшәрмен мин гомер-гомергә!**

— дигән иде. Талантлы шагыйрь, коммунист, Бөек Ватан сугышы каһарманы Нур Баян безнең күңелләрдә яшәвен дәвам итә. Нур Баян исемендәге урам, Нур Баян исемендәге колхоз, Нур Баян исемендәге дружина — бу аның мәңге яшәве!

**САМАТ ШАКИР.**

# ШАКИР МӨХӘММӘТОВ

*(1865—1923)*

Шакир Мөхәммәтша улы Мөхәммәтов 1865 елда Буа шәһәрендә ярлы көнкүрешле семьяда туа. Буа мәдрәсәсендә укый. 1880 елларда Оренбург шәһәрендәге бер байда приказчик, конторщик булып эшли. 1900—1901 елларда Харбинга барып чыга. Шунда чакта «Галиәкбәр агай» исемле 20 битлек хикәясе басыла. 1902 елны туган шәһәре Буага кайта. Тагын Оренбургка бара, Хөсәеновларда конторада эшли. «Яңа бәдәвам», «Хан кызы» әсәрләрен бастыра. 1905 елда «Япон сугышы яки Батыргали агай», 1906 елда «Урал буе татар туе», «Яфрак асты» дигән әсәрләре басыла. 1906 елның сентябрендә Оренбургта «Карчыга» исемле сатирик журнал чыгара.

«Карчыга» үзен эшчеләр, крестьяннар, хезмәткәр-приказчиклар мәнфәгатен яклаучы журнал дип таныта. Замандашлары арасында иң демократик юнәлеш ала. Көннең үзәгендә торган политик мәсьәләләрдә революцион демократик караштан чыгып үткен полемика алып бара. Карикатуралары да шул эздән бара, рәсемнәрен һәвәскәр сурәтче Мостафа Лотфуллин башкара (Әхмәт байда хезмәткәр).

1958 елда Татарстан китап нәшриятында Шакир Мөхәммәтовның «Сайланма әсәрләре» басылып чыкты. Язучының иң күренекле әдәби әсәрләре шул җыентыкка тупланган.

**И. РӘМИ**
**төзегән «Әдәби сүзлек»тән.**

# СУГЫШ ЕЛЛАРЫ ЮМОРЫННАН

Юлларда йөргәндә, табыннарда утырганда яки ял сәгатьләрендә, хәтта эш арасында да илебез кешеләре һәр вакыт тапкыр, шаян, көлке сүз әйтеп, мәзәк сөйләп күңел ачарга ярата. Патриотлар характерының үзенчәлекле бу сыйфаты Бөек Ватан сугышы елларында үзенең тагын да күркәмрәк, тагын да яктырак яклары белән ялтырап күренде. Батыр сугышчылар — солдатлар һәм партизаннар — гитлерчы баскыннар белән якалашуның теләсә нинди авыр минутларында да үткен телле һәм шаян, күтәренке күңелле һәм тапкыр булып кала белделәр. Аптырап моңаю, боеклык, күңел төшенкелеге, өметсезләнү дигән нәрсәләр аларга ят иде. Моның классик мисалы итеп уңган һәм куркусыз солдатларның җыелма образы булган Василий Теркинны әйтү генә дә җитә.

Сугыш башланган беренче көннәрдән үк башлап фронт газеталарында күп төрле «җирле» юмор геройлары (әйтик, мәсәлән, Иван Муха, фронтовик Иван Алтаев, солдат Алеша Антапкин, ефрейтор Калистрат, Фома Смыслов, Гриша Танкин, Егор Наводчиков, Хуҗа Насретдин кебекләрнең) иҗатыннан үрнәкләр өзлексез басыла килә. Кыскасы, җиңүчеләр сафында һөҗүм итеп, безнең оптимистик карашыбыз, безнең төшенкелек белмәс күңел сүзләребез — ягъни безнең юморыбыз белән сатирабыз да Берлинның рейхстаг гөмбәзенә Совет әләмен элеште. Алар, бик күп буын ватандашлар йөрәгендә сакланып һәм куллардан кулларга күчеп йөрисе яңадан-яңа җыентыкларга кереп, үлемсез солдатлар буларак, мәңге яшәргә хаклы!

Хөрмәтле укучыларыбызга шушы чиксез бай үзешчән иҗатның бер кадәресе тәкъдим ителә. Арада сугыш елларында илебез рәссамнары эшләгән кайбер рәсемнәргә дә күз салып елмаерга мөмкин.

**ЗӘКИ НУРИ.**

## Яшен тизлеге

**Г**аскәрләрен Совет иленә һөҗүм итәргә куганда Гитлер немецларга яшен тизлегендә җиңү вәгъдә итә. Ләкин сугыш озакка сузыла һәм «тар карашлырак кешеләр» «яшен тизлеге» сүзен бөтенләй икенче мәгънәдә аңлый башлыйлар.

Чит илдән килгән берәү Берлинда ничектер чалбарын ерта да, шуны яматырга дип, мастерскойга керә.

— Күпме вакытта рәтләп бирә алырсыз икән шуны? — дип сорый ул.

— Яшен тизлеге белән! — ди тегүче.

— Алайса, гафу итегез,— ди чит ил кешесе һәм, бик нәзакәтле генә итеп баш иеп, мастерскойдан чыгып китә.

Ә гестапочылар көннәрнең берендә бер немецны кулга алалар. Аңа: «Бу кеше сырхауланып яткан Гитлерның яшен тизлегендә терелүен теләде», дигән гаеп тагалар.

# Баш алдакчы һәм аның шәкертләре



Фашистлар маршы ничек үзгәрә.
Кукрыниксклар рәсеме

**Г**еббельсның фронттагы хәбәрчеләреннән берсе аңа мондый гариза җибәрә: «Синявин тирәсендәге бер һөҗүм вакытында снаряд тиеп кулым өзелде. Сез министр әфәндедән миңа дәвалану өчен биш мең марка акча бирдертүне үтенәм».

Геббельс гаризага болай дип язып кул куя: «Бармагын дәвалау өчен илле марка бирергә».

Геббельсның секретаре исә моны күргәч аптырап кала һәм чиксез гаҗәпләнеп сорый:

— Биредә бит, министр әфәнде, кул... дип әйтелгән.

— Сез балаларча беркатлы кеше икәнсез. Минем хәбәрчем кул дип яза икән, димәк, ул бармагын өздергән. Алар бит барысы да минем шәкертләрем.



# Ике яр арасында

**—А**лло, лейтенант, безнең полк елганың уң як ярына чыгып беттеме?

— Әйе, полковник әфәнде, тик шунысын да әйтергә тиешмен: безнекеләрне ул ярдан партизаннар кысрыклады бит...

— Һәм безнекеләр сул як ярга кире күчтеләрме?

— Юк... Безнекеләр... Димәк ки, ул мәетләр, гафу итегез, безнең полк, ике яр арасында йөзә...

# Ни Мәскәүдә, ни Берлинда

**—Н**ичек уйлыйсың, Вилли, кайчан да булса Мәскәүгә керербезме без?

— Белмим, Отто. Минемчә, без инде беркайчан да Берлинда булмаячакбыз.

# Алсуга манылган сүзләр

**—Я,** әйтегез инде, генерал әфәнде, фронтта уңышлар ничегрәк безнең?

— Аллага шөкер диярлек. Әйбәт бара шикелле. Минем исәбемчә, без җиңүле рәвештә чигенәбез, ә руслар исә тәртипсез сибелеп безнең арттан киләләр.

## Соңгы сорау

— Рус снайперлары чынлап та шулай бик төз аталармыни? — дип сорый фронтка яңа килгән немец солдаты һәм траншеядан башын сузып карамакчы була.

Һәм... Шуннан соң инде ул бүтән бернәрсә дә сораша алмый.

## Алдын-артын уйлый белү

— Франц! Безгә кышкы киемнәр килде.

— Әллә киез итекләр дә бармы?

— Юк. Агач аяклар гына.

## Нәкъ үзәккә тигән җавап

— Капитан Шульц, сезнең солдатларыгыз һаман чигенеп чабалар да чабалар. Моны ничек аңларга соң?

— Әйтергә рөхсәт итегез, генерал әфәнде! Алар сездән бик ерак артта калудан куркалар, юкса, штаб белән элемтә өзеләчәк бит.

## Фриц көндәлегеннән

...Кичә Рудольф миңа үзенең үлү-үлмәү мәсьәләсе әле икеле икәнен аңлатып маташты. Ә бүген бер мина аны дүрт өлешкә өзгәләп ташлаган.




**Гитлерчылар тәбриклэшүе.**

Бор. Ефимов рәсеме

...Безнең фельдфебельнең эше тагын уңды: атакага ташланыр алдыннан ук ике йөз солдатны эчерткән иде, ә баш төзәтергә исә махмырлы ике генә солдат әйләнеп кайтты.

## Күңелсез йомгаклар

— Безнең полковнигыбыз фон Грох Ржев тирәсендәге уңышсызлыклар кайгысыннан хәтсез ябыкты — тиресе белән сөяге генә калды диярлек.

— Ә Великие Луки янындагы сугышлардан соң безнең полковникның хәтта сөякләре дә калмады.

## Инициатива үзгәреше

Гитлер: Я, ничек анда, генерал: Кубаньда инициатива элеккечә үк безнең кулдамы әле?

Генерал: Юк, фюрер әфәнде, инициатива дигән нәрсә безнең аякта хәзер.

## Карелия төне

— Әйт әле, Франц, Карелиядә һәр вакыт шундый ак төннәр буламы?

— Борчылма, Фриц, руслар атакасы башланса, күз алларың минут эчендә караңгыланачак.

## Башсызлар

Генерал: Фюрерның приказы көн кебек ачык бит: башыңны куйсаң куй, әмма чигенмә. Ә ни өчен синең солдатлар һөҗүмнән качалар?

Полковник: Алар бит башларын җуйдылар инде, генерал.


## Соравына күрә

— Фриц, әйтегез әле, сезнең дивизия ни өчен «Үлек баш» дигән исем йөртә?

— Чөнки ул дивизиядә терек җаннар башы инде бөтенләй калмады диярлек.

## Күмеләләр

— Көтелмәгән югалтулар булмасын өчен, окопларны тирәнрәк казып, җиргә күмелергә кирәк, герр обер-лейтенант.



Гитлерга капут шулай эшләнә.



**Немецларча тәгаллек.**

Ганс: Безнең генералыбыз бөтенесен бик алдан, ай-һай, шәп күрә белгән икән лабаса: үзе исән чагында ук гәүдәсенең барча өлешләрен номерлап чыккан. Хәзер аны җыеп укмаштыруы безгә һич кыен түгел.

Ю. Үзбяков рәсеме

— Анысын күмеләбез инде. Әнә кичә генә дә ике ротаны берьюлы күмдек.

## Яңа тактика

— **Н**емец генералы үз солдатларын арт белән алга атларга ни өчен өйрәтә дә, ни өчен мәҗбүр итә?

— Ә беләсезме ни өчен кирәк ул — солдатлар һөҗүм итәләрме яки чигенәләрме икәнен үзләре белмәсен өчен.

## Иң ышанычлылары

— **П**олковник әфәнде, моны ничек аңларга соң инде? — ди оберлейтенант.— Мин ышанычлы солдатлар китертүне сораган идем, ә сез тәп биргән ротагыз бары тик аксаклар да сукырлардан гына тора...

— Соң, бу бит алар иң ышанычлы сугышчылар дигән сүз була түгелме, ахмак: менә күрерсең, һөҗүмнән чигенеп берсе дә кача алмаячак! — ди полковник.

## Немецларга «дус» кеше

**В**аршава урамы буйлап барганда берәү үзалдына болай дип мыгырдана икән:

— Бу немецларга мин бернинди түләү сорамыйча көн саен уникешәр сәгать эшләр идем.

Артыннан килүче немец полицае шул сүзне ишеткәч сорый моңардан:

— Ни өчен син бернинди түләү алмыйча немецларга уникешәр сәгать рәттән эшләр идең? Үзең кем буласың?

— Мин кабер казучы,— дип җавап биргән әлеге кеше.

## Кем булуына карап...

— **С**олдат Поппер, әйтик, лейтенантны честь биреп ничек сәламләр идегез сез?




**Рус иле сыйларын авыз иткәндә.**

Л. Бродаты рәсеме

— Әгәр немецныкы булса — бер кулымны, ә руснықы булса — ике кулымны берьюлы күтәреп...

## Иң белемле кеше

— О бер-лейтенант Круппе! Үз штабына иң белемле офицер китерүне таләп итә полковник. Сезнекеләрдән кемнең фән яки белем белән эш иткәне бар?

— Очучы Ганс Вошке дип әйтер идем мин: ул бомба ташлап ике мәктәп белән бер университетның көлен күккә очырды.

## Үтә белгеч

— Сез, әсир Шульц, Генрих Гейнены беләсезме?

— Ничек белмәскә ди! Ул безнең немец язучысы. Мин аның бик күп китапларын үзем яндырдым.

## Мәгънәле җавап

— Карале, Отто, уң кулың бөтенләй юк килеш сине хәрби хезмәткә ничек алдылар?

— Аның каравы, минем ике аягым да сау-таза, ә Көнчыгышта эшләр хәзергәчә барганда аяк дигән нәрсә бөтенесен хәл итә ул.

## Солдатлар сөйләшүе

— Ә безнең, Ганс, бөтен ротабызга нибары өч пар җылы бияләй бирделәр.

— Ничек соң, шул җитәме?

— Җитмәгән кая. Хәтта бер пары артык та әле.

## Яңа җиңү

— Безнең рота кызылармеецлар төркемен камады, герр Оберст.

— Бирегә алып килегез барысын да!

— Килергә теләмиләр.


— Алайса, үзегез бире килегез!

— Ә алар безне... җибәрми шул.

## Алдан хәзерләнү

— Нигә соң әле бу Карл кулын бер күтәреп, бер түбән төшереп шул хәтле озак маташа? Әллә сигнал бирүче булырга өйрәнәме?

— Әйе! «Әсирлеккә бирелә́м» дигән сигналны үзләштерә ул.



**Һичкайчан да соң түгел.**

— Нишләп болай аякларыңны бик бөгеп чабасың?

— Аяк сузарга мин өлгерәм әле...

Е. Евган рәсеме

## Яңа дәрәҗә

— **К**апитан Карл Киркка минем сәламне матур итеп ирештерегез.

— Гафу итегез, полковник әфәнде, Кирк бит инде капитан түгел.

— Ә кем соң ул? Әллә генерал ук булдымы?

— Юк, ул мәет инде хәзер.

## Юнәлеш белү

— **К**ояшсыз көнне һәм компас булмаганда юнәлешне сез ничек билгелисез, Карл Майер?

— Бу бит бик гади нәрсә, фельдфебель әфәнде: өскә ут яудырган, кысрыклаган як — Көнчыгыш, ә чигенү тарафлары — Көнбатыш була.

— Һмм. Әгәр чолганышта калсагыз?..

— Ул чакта инде, фельдфебель әфәнде, юнәлешне белүнең кирәге дә булмый: кирәк урынга мине руслар үзләре алып барачак!

## Һәр нәрсәнең сәбәбе була

— **Р**услар турында уйласам яки шуны күз алдыма китерсәм, тешләрем тешкә тими башлый.

— Моның киресе бик тә сәер булыр иде, минемчә. Чөнки бит руслар синең бөтен тешләреңне дә күптән койдылар инде.

## Үтергеч яңалык

— **Б**езнең солдатларның, герр Швайне, русларның яңа тубына карашлары ничек?

— Ул яңалык бик күпләрне үтерде.

## Үзен-үзе кайгырта

— **Н**ишләп болай үзеңә кабер казыйсың син, Карл? Кызыллар бездән җәһәннәм шикелле ерак бит әле.

— Ә минем гадәтем шундый: бүген эшләргә мөмкин булганны иртәгәгә калдыруны яратмыйм.


## Һәркемнең үз исәбе

— **Б**езнең обер-лейтенантыбыз фюрер өчен тизрәк җанын бирсә икән.




**Тын Дон буенда.**
Күрсәтмәле хәрби күзәтү
(ноябрь-декабрь, 1942).

Бор. Ефимов рәсеме



**Җиңү нурлары чәнечкесе.**

— Ник алай дисең?
— Чөнки итеге бик әйбәт.

## Дуңгыз

Бер гитлерчы авылда бер хатынның дуңгызын талап алып суйдырта һәм шуны кыздырып өстәлгә куйдырткач кычкыра икән:
— Матка, давай аракы! Дуңгыз хәзер эчәргә тиеш.

## Төгәл белешмә

Р а з в е д ч и к: Әбекәй! Сезнең авылда калган немецлар күбәүме әле?
Ә б и: Күбәү, туганкай, бик күбәү: алар белән бөтен зират тулды инде.

## Серен белеп сөйләүче

— Мин бу урманнан бик куркам, Вилли. Минут саен бер нәрсә көтәсең: менә-менә шуннан партизаннар килеп чыгарлар да һөҗүм итәрләр төсле.
— Әгәр инде көтәсең икән, димәк, аларның һөҗүме булмаячак, әллә партизаннарның һич көтмәгән урында килеп чыга торган гадәтләрен белмисеңме син?

## Теш докторы бүлмәсендә

— Сезнең тешләрегез арасындагы күпер зыянланган икән, яңаны ясарга кирәк булачак,— ди врач немец комендантына.

— Кирәкмәстер дә бәлки,— дип уфтана шул чакны комендант,— чөнки партизаннар аны барыбер шартлатачак бит...

## Немец мәктәбендә

— Әйтегез әле, хөрмәтле мөгаллимебез: Сталинград каласында урамнар бик озынмы?

— Ә моны сорау нигә кирәк булды әле сиңа?

— Чөнки минем абыем Куртның фронттан хаты килде. Алар дивизиясе инде ике ай буена бер урам буйлап һөҗүм итә икән, ә урамның исә әле һаман очы-кырые күренми, дип яза ул.

## Дөрес дәрес

— Ганс Штольц, «чигенү» дигән фигыльне төрләндереп бирегез әле,— ди укытучы.

— Мин чигенәм, син чигенәсең, ул чигенә, без чигенәбез, сез чигенәсез...

— Ә алар?

— Ә алар, мөгаллим әфәндем, һөҗүм итәләр.




**Бурыч түләнде.**
Фашист әйтте көндез крестьянга:
— Сал бүркеңне һәм бир честь...— диләр.
Ә фашистның каска кигән башын
Крестьяннар төнлә кистеләр.

Кукрыникслар рәсеме



**Россиядә иң танылган җыр.**
— Балдагымны югалттым мин...
(Ә балдак-боҗрада 22 дивизия.)

Кукрыникслар рәсеме



**«Искиткеч гүзәл тын Днепр...»**
Долгоруков рәсеме



**Географияле тарих.**
Кукрыникслар рәсеме

## Беркатлылык

— Әти, синең берәр партизанны якыннан күргәнең булдымы?

— Бу соравың бигрәк беркатлы синең, Ганс! Партизанны якыннан күргән кеше бу дөньяда инде бүтән бернәрсәне дә күрә алмый бит ул.

## Нечкә итеп аңлату

— Әни, руслар минем әтине әсир иткәннәр дип ишеттем. Дөресме бу?

— Беләсеңме, балам, әтиең синең русларны үзе пленга алган, ләкин алар бик күп булып чыккан да әтиеңне дә үз якларына алып киткәннәр.

## Мәкальләр һәм әйтемнәр

— Ватан — ана, Ватан — бер, шуны яклап утка кер.

— Илең якын икән сиңа — фашистны катырак кыйна.

— Безнең илгә басып кергән — шул җирдә ятып калыр.

— Күтәрелсәк әгәр бердәм, фашист мәтәлер үрдән.

— Һәркайсыбыз бер җеп бирсәк, Гитлерга элмәк булыр.

— Чучка күк йөзен күрә алмас, Гитлер Мәскәүгә керә алмас.

— Көпшәндә пуляң барында, фрицларның кыр барын да.

— Тапкырлык ул — батырлыктыр, тапкырлыкка ни җитә.

Дошманны тапкырлар кыра, тапкырлар әсир итә.

— Биштәр алганда юлга син күбрәк сал аңа кургашын.

— Аркасын күрим дисәң, дошманның маңгаена бәр.

— Кожедуб, Покрышкин бар җирдә фашист тиз керә тар гүргә.

— Дошманнан саклану өчен иң яхшы чара — һөҗүм.

— Солдат даны — штык очында.

— Әсир булганчы, үлүең хәерлерәк.

— Зирәк һәм батыр солдатның бияләе дә — бомба.

— Пуля — бал корты кебек ул: чигенеп чапсаң — чага.

— Сер саклый белмәгән солдат дошманга ярдәм итә.

— Начар укчының мишене — кухня ишеге булыр.

— Ватан бүләге — намус сафлыгы, Ватан бүләге — йөрәк шатлыгы.

— Дошман поездлары шартлау — партизанның шатлык авазы.

— Партизан күзе ерактан күрә.

— Фашистлар — кырык, без — икәү, булышчыбыз — зирәклек.

— Эт булып өрмәсен дисәң, полицайның башын кис.

— Партизан даны — фашистның койган каны.

— Партизан иң яраткан төн — соңга калып таң аткан төн.

— Куян капкыннан курка, ә фашист — партизаннан.

— Гитлер тузгый, Гитлер шашына — димәк, тиздән дарга асыла.

— Курск дигән дугада дошманның биле бөгелде.

— Патша тажы киеп Гитлер Мәскәүгә кермәк иде.

Бетте Гитлер, бетте гаскәр — гүрләре күмәк инде.

— Илбасарны тар-мар итеп Берлинга килеп кердек.

Гитлерны — фашист сыртланын — шул өндә дөмектердек.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ ТУРЫНДА «ПРАВДА»

«Правда» газетасында февраль ахырында «Казан утлары» журналының эшчәнлеге, аның әдәби процесстагы, культура тормышындагы роле турында мәкалә басылып чыкты.

«Казан утлары» журналының биографиясен, — дип яза «Правда», — чын-чынлап татар совет әдәбиятының аякка басуы, аның социалистик реализм юлыннан үсүен гәүдәләндерүче җанлы тарих дип әйтергә була.

Журналның бер ел, ел ярым вакыт эчендә чыккан саннары әчтәлеге белән танышсак, Россия Федерациясендәге иң зур милли язучылар оешмасының иҗади эшчәнлегендәге төп юнәлешләрне ачык күрәсең».

Аннан журналда соңгы елларда басылып чыккан әсәрләргә бәя бирелә, алардагы уңышлы яклар, кайбер кимчелекләр күрсәтелә.

## КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Республикабызның фән, культура һәм мәгариф җәмәгатьчелеге күренекле галим, әдип, мәгърифәтче һәм педагог Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулуны киң итеп билгеләп үтте. Музейларда, китапханәләрдә аның тормышына, эшчәнлегенә, иҗатына багышланган күргәзмәләр оештырылды, югары уку йортларында, мәктәпләрдә бу уңай белән фәнни конференцияләр, җыелышлар, кичәләр үткәрелде.

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты һәм Казан дәүләт педагогия институты галимнәре, язучылар, культура эшлеклеләре, партия һәм совет хезмәткәрләре, укытучылар катнашында университетның Актлар залында һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы конференц-залында фәнни конференция булды.

Конференцияне КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев ачты. «Каюм Насыйри һәм аның чоры» дигән темага тарих фәннәре докторы, профессор М. Мөхәррәмов, «Күренекле галим һәм язучы» дигән темага филология фәннәре докторы, профессор М. Гайнуллин, Каюм Насыйриның татар милли телен формалаштырудагы эшчәнлеге турында филология фәннәре докторы, профессор М. Зәкиев, «Каюм Насыйри һәм тел белеме» дигән темага филология фәннәре кандидаты С. Акбиев (Дагстан), «Татар әдәби телен үстерүдә һәм камилләштерүдә К. Насыйриның роле» дигән темага Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре И. Абдуллин, «Каюм Насыйри һәм татар теле грамматикасы» дигән темага шул ук институт хезмәткәре Я. Әхмәтгалиева, «Әнмүзәҗ»нең яңа басмасы турында тел белгече Р. Газизов, татар тел белемендә Каюм Насыйри традицияләре турында филология фәннәре докторы В. Хаков, «Каюм Насыйри рус телен өйрәнүнең әһәмияте турында» дигән темага филология фәннәре кандидаты А. Әсәдуллин, «К. Насыйри тарафыннан татар теленең фәнни, укыту-педагогик терминологиясе эшләнүе», «Ләһҗәи татари» — татар телендә беренче аңлатмалы сүзлек», «Халыклар дуслыгы җырчысы», «Татар иҗтимагый-философик фикерләү үсешендә К. Насыйриның роле», «Казан университетында Көнчыгыш белеме һәм Каюм Насыйри», «Каюм Насыйриның педагогик карашлары», «Каюм Насыйриның нәшрият эшчәнлеге», «Каюм Насыйриның Казан татарларының борынгы тарихын һәм археологиясен тикшерүгә керткән өлеше», «Каюм Насыйри — этнограф», «Татар фольклористикасында Каюм Насыйриның тоткан урыны», «XIX йөздә әдәби процесс һәм Каюм Насыйри» дигән темаларга философия фәннәре докторы, профессор К. Фасиев, профессор Я. Ханбиков, тарих һәм филология фәннәре кандидатлары Ф. Фасиев, Ш. Ханбикова, С. Михайлова, Ә. Кәримуллин, Р. Фәхретдинов, Р. Уразманова, Х. Мәхмүтов, М. Гайнетдинов һ. б. ларның докладлары тыңланды.

Профессор М. Мөхәррәмов йомгаклау сүзендә бу конференцияне Каюм Насыйри иҗатын һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеген тикшерү һәм өйрәнүдә яңа адым булараг бәяләде. Шулай ук ул, конференциядә катнашучыларның докладларын һәм чыгышларын шактый яңалыклар белән баетылган һәм югары фәнни-теоретик дәрәҗәдә булуын билгеләп үтте, аларга күренекле татар мәгърифәтчесенең бай мирасын тирәнтен өйрәнүдә яңа уңышлар теләде.

Конференция эшенә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Хәсәнов, партиянең өлкә комитеты бүлек мөдирләре В. Иванов һәм М. Мусин, партиянең Казан шәһәр комитеты секретаре А. Кадыйрова, ТАССР мәгариф ми-

нистры М. Мәхмүтов, ТАССР культура министры Ә. Миндубаев, Казан дәүләт университеты ректоры М. Нужин катнашты.

*
* *

Каюм Насыйрига багышланган конференция шулай ук мәгърифәтченең туган якларында уздырылды. Аны КПССның Зеленодольск шәһәр комитеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты Ачасыр авылы культура йортында үткәрделәр. Конференция эшендә «Совет» колхозы эшчәннәре, укытучылар һәм башка авыл интеллигенциясе вәкилләре катнашты. Күрше колхозлардан дә вәкилләр килгән иде.

Конференцияне кыскача кереш сүз белән партиянең Зеленодольск шәһәр комитеты секретаре М. А. Космодемьянская ачты. Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры урынбасары А. Әхмәдуллин конференциягә катнашучыларны котлады, колхозга һәм Ачасыр урта мәктәбенә бүләкләр — институт галимнәре язган фәнни хезмәтләрне тапшырды. Аннан институтның өлкән фәнни хезмәткәре, философия фәннәре кандидаты Я. Абдуллинга сүз бирелде. Ул үзенең докладында Каюм Насыйриның тормыш юлын һәм күпкырлы эшчәнлеген яктыртты, татар халкының культурасы һәм иҗтимагый фикер үсешендә аның ролен билгеләп үтте.

Институтның өлкән фәнни хезмәткәрләре, фән кандидатлары Х. Мәхмүтов һәм Р. Фәхретдинов чыгышлары мәгърифәтченең тел, әдәбият, тарих һәм этнография өлкәсендәге эшчәнлегенә багышланган иде. Конференциядә катнашучылар шулай ук пенсионер К. Гыйсмәтуллинның истәлекләрен, Ачасыр урта мәктәбе укытучысы А. Собханкулова һәм «Совет» колхозы партокомы секретаре С. Абдуллин чыгышларын да зур кызыксыну белән тыңладылар. Конференциядән соң Зеленодольск шәһәренең «Родина» һәм Горький исемендәге культура сарайлары үзешчәннәре тарафыннан зур концерт бирелде.

*
* *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулу уңае белән тантаналы җыелыш булды.

Җыелышны КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Кадыйрова ачты.

Каюм Насыйриның тормышы, татар культурасы һәм фәне үсешендәге роле турындагы докладны ТАССР культура министры Ә. Миндубаев ясады. Җыелышка ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Батыев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. Усманов, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре Ф. Панин, КПСС өлкә комитеты секретарьлары М. Вәлиев, Ф. Гайнуллин, КПСС Казан шәһәр комитетының беренче секретаре Р. Мусин катнашты.

Соңыннан республикабыз сәнгать осталары башкаруында зур концерт бирелде.

## ӨЧЕНЧЕ КИТАП

Татарстан китап нәшрияты, Кама автомобиль гигантын төзүчеләрнең 1973 елда ирешкән нәтиҗәләрен гәүдәләндереп, «КамАЗ» циклыннан өченче китап бастырып чыгарды. «Батыр набирает высоту» («Батыр — күтәрелештә») дип исемләнгән бу китап КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Р. Беляевнең «КамАЗда хәлиткеч ел» исемле мәкаләсе белән ачыла. «Сүнмәс ут», «Елга буендагы шәһәр», «КамАЗның чит илләр белән бәйләнеше», «Хәлиткеч ел» дигән бүлекләргә Мәскәү һәм республикабыз язучыларының, журналистларының элек «Правда», «Известия», «Социалистическая индустрия», «Советская культура», «Литературная газета», «Советская Татария», «Социалистик Татарстан» газеталарында, «Новый мир», «Юность», «Казан утлары», «Татарстан коммунисты», «Азат хатын» журналларында чыккан очерклары, мәкаләләре, зарисовкалары, репортажлары, шулай ук статистик материаллар һәм төсле фотодокументлар тупланган. Китап офсет кәгазенә басылган. Тиражы — 11 мең. 216 бит. Бәясе 1 сум 27 тиен.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Тәнкыйтьчеләр һәм драматурглар секциясенең берләштерелгән утырышында бүгенге комедия жанры турында сүз барды. Филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллин соңгы елларда татар драматурглары иҗат иткән комедияләр турында доклад ясады. Доклад буенча фикер алышуга драматург Х. Вахит, сәнгать фәннәре кандидаты Х. Гобәйдуллин, филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче Б. Гыйззәт, драматург А. Гыйләҗев, филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче Ф. Мусин, Н. Ханзафаров, филология фәннәре кандидаты, тәнкыйтьче Ш. Әхмәдуллин һ. б. лар катнашты.

Шул ук утырышка катнашучылар Ш. Әхмәдуллинның тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы турында фикер алыштылар. Фикер алышуга филология фәннәре докторы, тәнкыйтьче Н. Юзиев, филология фәннәре кандидаты А. Әхмәдуллин, Н. Хисамов, Ф. Миннуллин, Ф. Мусиннар катнашты. Җыентыкка нигездә уңай бәя бирелде һәм бастырып чыгару өчен Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итәргә яраклы дигән карарга киленде.

*
* *

Проза секциясенең чираттагы утырышында «Язучының осталыгы» дигән темага сөйләшү булды. Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни үзләренең иҗат тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Соңыннан яшь язучылар һәм әдәбият сөючеләр күренекле язучыларыбызга күп кенә сораулар бирделәр.

## БӨЕК ҖИҢҮГӘ БАГЫШЛАП

Соңгы айларда язучыларыбызның укучылар белән очрашулары — радио, телевидение, матбугат аша чыгышлары — барысы да бер темага — совет халкының фашистлар Германиясен җиңүгә 30 ел тулуга багышланды.

Кулларына корал тотып турыдан-туры фронтта сугышкан язучылар сугыш елларында иҗат иткән әсәрләрен кабат хәтерләренә төшерделәр, бу елларны күз алларыннан кичереп, ул көннәр турында яңа әсәрләр, сугышчан иптәшләре турында истәлекләр яздылар һәм аларны иң башта трибунадан халыкка җиткерергә ашыктылар. Мөхәммәт Садри, Габдрахман Минский, Хәсән Сарьян, Рәдиф Гатауллин һәм Рәзил Вәлиев Кукмара районы предприятиеләрендә, колхозларында, мәктәпләрендә күп санлы укучылар белән очрашып, үзләренең Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләрен укыдылар, истәлекләр сөйләделәр.

*

* *

Рәшит Гәрәй, Фәнил Мансуров, Әхмәт Рәшитов Алексеевский районында шул ук темага укучылар белән очрашулар үткәрделәр.

*

* *

Казан шәһәренең Офицерлар йортында һәм Питрәч район китапханәсендә Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» исемле китабы буенча укучылар конференцияләре булды. Автор укучыларның бик күп сорауларына җавап бирде. Бөек Ватан сугышы чорында үзенең күргәннәре, әсәрнең язылу тарихы турында сөйләде.

*

* *

Татарстан язучыларының Габдулла Тукай исемендәге клубында «Дан сиңа, совет солдаты» дигән темага әдәби-музыкаль кичә булды. Анда тамашачылар Бөек Ватан сугышына катнашкан язучылар чыгышын тыңладылар, Бөек Җиңүгә багышланган яңа музыкаль әсәрләр, җырлар башкарылды.

*

* *

В. И. Ленин исемендәге культура сарае каршында телдән сөйләнә торган «Җанлы сәхифәләр» дигән фәнни-популяр журнал эшләп килә. Журналның 287 нче чыгарылышы совет халкының фашистлар Германиясен җиңүгә 30 ел тулуга багышланды, һәм ул «Казан утлары» редакциясе бездә кунакта» дип исемләнгән иде. Журналның баш редакторы Зәки Нури, Бөек Ватан сугышында катнашкан шагыйрь Мостафа Ногман, шагыйрь Илдар Юзеев, прозаик Вакыйф Нуруллин Бөек Җиңү көненең журнал битләрендә ничек билгеләнеп үтелүе турында сөйләделәр, Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләрен укыдылар.

*

* *

СССР Язучылары союзы Минск шәһәрендә «Бөек Ватан сугышында халкыбызның үлемсез батырлыгы һәм совет әдәбияты» дигән темага киңәшмә үткәрде.

Киңәшмәдә Бөек Ватан сугышы темасына язылган әсәрләргә анализ ясалды, бу әсәрләрдә совет кешесенең характеры, социализм казанышларын саклау өчен ул күрсәткән бөек батырлыкның чагылышы турында сүз барды.

Язучылар Брест крепостенда, Хатынь мемориалында, Бөек Ватан сугышы, партизаннар хәрәкәте белән бәйле башка тарихи урыннарда булдылар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Совет Армиясе сугышчылары, чик сакчылары, республика хезмәт ияләре, партия-совет хезмәткәрләре белән очраштылар.

Бөек Җиңүгә 30 ел тулу уңае белән үткәрелгән бу киңәшмәдә Татарстаннан Белоруссия партизаннар хәрәкәтенә актив катнашкан шагыйрь Зәки Нури булды.

## АГИТАЦИЯ ҮРНӘКЛӘРЕНӘ КҮРГӘЗМӘ

Мәскәүдә, СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе павильоннарында агитация буенча күргәзмә әсбапларның иң яхшы үрнәкләре күрсәтелә. Анда ике меңнән артык экспонат бар. Шулар арасында Татарстан художниклары хезмәтләренә дә шактый урын бирелгән. «XXIV съезд карарларын тормышка», «Бишьеллык адымнары» исемле материаллар тирән эчтәлекле һәм заманча эшләнешле булулары белән аерылып торалар.

Мондый күргәзмә илебездә беренче тапкыр үткәрелә.

## ТАТАРСТАН МУЗЫКА СӘНГАТЕ ОСТАЛАРЫНЫҢ УҢЫШЫ

Мәскәүдә, Бөтенсоюз композиторлар йортында хәзерге татар совет музыкасына багышланган зур концерт булды. Мәскәү музыкантлары башкаруында Р. Еникеевнең кыллы квартетын, Бөтенсоюз конкурсы лауреаты Р. Ибраһимов башкаруында Х. Вәлиуллинның «Тынычлык кирәк» җырын, пианист М. Сиражетдинов башкаруында А. Миргородскийның фортепиано өчен концертын, Н. Җиһанов, З. Хәбибуллин, Р. Яхин, А. Монасыйпов, М. Яруллин, Р. Билалов, Ш. Шәрәфетдинов һәм башка композиторларыбызның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрен концерт залына җыелган тамашачылар: бөтен илебезгә танылган совет композиторлары, башкаланың музыка сөюче интеллигенциясе, завод һәм фабрика эшчеләре бик яратып тыңладылар.

Соңыннан РСФСР Композиторлар союзы секретариатында бу отчет концерты буенча фикер алышу булды. Р. Щедрин, А. Флярковский, В. Казенин, В. Агофонников, В. Плотниченко һ. б. лар концертка карата фикерләрен әйттеләр, Татарстан композиторлары иҗатында гражданлык юнәлеше, алар иҗат иткән әсәрләрнең тирән эчтәлекле, талантларының күптөрле булуы, татар музыкасының чын-чынлап җитлеккәнлеге турында сөйләделәр. Башкаручыларыбызның да осталыгына зур бәя бирелде. Анда шулай ук СССР халыклары музыкасын пропагандалау, алмаш концертлар, телевидение һәм радио тапшырулары оештыру, ноталар чыгару, грампластинкаларга яздыру мәсьәләләре дә күтәрелде. Бу концертны Бөтенсоюз телевидениесеннән күрсәтергә тәкъдим ителде.

## СӘНГАТЬ ОСТАЛАРЫ КОНЦЕРТЫ

Башкаланың «Россия» исемле Дәүләт үзәк концерт залында ике көн рәттән Татарстан артистларының зур концерты булды. Җырчылардан РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты И. Шакиров, Р. Сибгатуллина, Р. Ибраһимов, Р. Мифтахова, Р. Аббасов, Н. Василова, Т. Якупов, В. Гыйззәтуллиналарның татар композиторлары иҗат иткән әсәрләрне һәм татар халык җырларын башкарулары, Э. Закирова, И. Хәкимова, Р. Садыйков, бертуган Ибатуллиннарның биюләре, Татарстанның халык артисты А. Арсланов белән артистка Н. Минкинаның татар әдипләре әсәрләрен нәфис итеп укулары Мәскәү тамашачыларының күңеленә хуш килде.

## БӨЕК АРТИСТ ХӨРМӘТЕНӘ

СССРның халык артисты В. И. Качаловның тууына 100 ел тулу көнен шәһәребез җәмәгатьчелеге киң итеп билгеләп үтте.

Казан рус драма театрында В. И. Качалов үзенең профессиональ иҗат юлын башлап җибәргән. Шуңа күрә дә бу театр хәзер СССРның халык артисты В. И. Качалов исемен йөртә.

Юбилей көннәрендә театр музеенда В. И. Качаловның Н. Э. Бауман белән очрашуларын, алар арасындагы дуслыкны гәүдәләндергән яңа бүлек оештырылды.

Театр бинасында бөек артистның тууына 100 ел тулуга багышланган зур кичә үткәрелде.

## КОМПОЗИТОР ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

Казан шәһәр башкарма комитеты карары нигезендә Киров һәм Ленин районнарын тоташтырган урамнарның берсенә Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган күренекле татар совет композиторы Фәрит Яруллин исеме бирелде.

## ХАЛЫК ТЕАТРЛАРЫ КАЗАНДА

Республикабызның халык театрлары һәм үзешчән коллективлары Бөек Җиңүгә 30 ел тулу уңае белән Казан шәһәре хезмәт ияләренә культура сарайларында, клубларында үзләре әзерләгән спектакльләрне күрсәттеләр. Сарман районы халык театры Ю. Әминевнең «Язылмаган законнар», Азнакай халык театры Н. Анкиловның «Хатыннар», Алабуга рус халык театры В. Соловьевның «Хәвефле һөнәр», Кама тамагы рус халык театры А. Макаенокның «Трибунал», Чүпрәле районыннан үзешчән курчак театры «Аленький цветочек», Столбище рус халык театры Кац һәм Сазоновның «Өч кешегә өч шпага», Әгерже халык театры М. Кәримнең «Ай тотылган төндә», Кукмара халык театры М. Шәрифуллинның «Туганнар», Актаныш халык театры Ә. Атнабаевның «Мәхәббәт турында җыр», Биектау рус халык театры В. Рудныйның «Гомер бәрабәренә», Шәпше халык театры Ә. Атнабаевның «Ана хөкеме», Әтнә халык театры Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш», Чаллы халык театры А. Коломецның «Зәңгәр болыннар», Чистай рус халык театры И. Соболевның «Разведчик кызлар», Яңа Ибрай авыл үзешчән драма коллективы К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», Минзәлә татар драма коллективы Т. Миңнуллинның «Уйланыр чак», Зәй-Каратай үзешчән драма коллективы Ә. Атнабаевның «Ул кайтты» әсәрләрен куйды.

## МИНЗӘЛӘ ТЕАТРЫ КАЗАНДА

Минзәлә дәүләт театры Казанда, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында, В. И. Ленин исемендәге культура сараенда, Химиклар культура сараенда һ. б. культура сарайларында һәм клубларда драматург Сәет Шәкүровның «Сары елан» әсәре буенча куелган спектакльләрен күрсәтте. Тамашачылар спектакльләрне һәркайда яратып карадылар.

## КУЛЬТУРА УНИВЕРСИТЕТЫНДА

Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе каршындагы культура университетының татар бүлеге быел үзенең дәресләрен Әгерже районында үткәрә.

Күптән түгел анда композитор Җәүдәт Фәйзи иҗатына багышланган концерт-лекцияләр булды. Концерт-лекцияне Татарстанның атказанган культура хезмәткәре Зәйнәп Хәйруллина алып барды. РСФСРның халык артисты Азат Аббасов, Татарстанның атказанган артисткасы Җәвәһирә Сәләхова, Нажия Теркулова һәм Камил Басыйров Җ. Фәйзи иҗат иткән җырларны башкардылар.

# ИҢ ЯХШЫ РЕЦЕНЗИЯЛӘРГӘ КОНКУРС

Яңа китапларга әдәби рецензия язу эшен тагын да яхшырту һәм яшь тәнкыйтьчеләрнең иҗат активлыгын көчәйтү максатыннан чыгып, Татарстан язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе иң яхшы рецензияләргә ачык конкурс игълан итә.

Резенцияләр татар совет язучыларының заман темасына караган һәм бүгенге көн геройларын сурәтләүгә багышланган барлык жанрлардагы яңа әсәрләренә, шулай ук җыентыкларына язылырга тиеш.

Конкурста 35 яшькә кадәр булган тәнкыйтьчеләр, язучылар һәм укучылар катнаша ала.

Рецензияләр 1976 елның 1 августына кадәр кабул ителә.

Жюри тарафыннан яхшы дип табылган рецензияләр журналда басыла, иң яхшыларына акчалата бүләкләр биреләчәк.

Конкурста җиңүчеләргә түбәндәге бүләкләр билгеләнде:

I бүләк — 150 сум
II бүләк — 100 сум
III бүләк (икәү) — 50 шәр сум.

*Рецензияләрне (исем-фамилиягезне һәм тулы адресыгызны күрсәтеп) түбәндәге адрес белән җибәрергә: Казан, 420066, Декабристлар урамы, 2. «Казан утлары» журналы редакциясе. Конкурска.*

Журналыбызның 4 нче саны
2 нче битендәге рәсем авторы — В. Игнатьев.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210